

# КАЗАН УТЛАРЫ

10
ОКТЯБРЬ
1982



**Шагыйрь Хәсән Туфан пионерлар арасында.** Н. Седов фотоистәлеге.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

**10**

ОКТЯБРЬ

1982

## *Бу санда*

СССРның ТӨЗЕЛҮЕНӘ 60 ЕЛ

**Ф. ЯРУЛЛИН.** Уртак сыйфат. Шигырь . . . . . . 3

**Т. МИҢНУЛЛИН.** Монда тудык, монда үстек. Драматик повесть . . . . . . . . . . . . 4
**Г. БӘШИРОВ.** Бибек нигә елый. Хикәя . . . . . 34
**С. БАТТАЛ.** Ике йөз елдан соң. Поэма . . . . . 48

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Ш. ГАЛИЕВ.** Маяк. Шигырьләр . . . . . . . . 51

**К. ТИМБИКОВА.** Кышкы талпыну. Повесть . . . . 56
**К. МОСТАФИН.** Хыял кошы. Шигырьләр . . . . . 99
**Н. ХИСАМОВ.** Төрле еллар дәфтәреннән. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 102
**З. МАНСУРОВ.** Шөгыль. Шигырьләр . . . . . . 105
**Г. ЛОТФИ.** Пума белән Кәберлә. Повестьтан өзек 109

СССРның 60 ЕЛЛЫГЫНА

**Д. ЗӨБӘЕРОВА, М. БАИНОВ.** Таң җыры . . . 116

ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

**Э. МӨЭМИНОВА.** Без дә үсеп җиттек... . . . 120
**Ш. РӘКЫЙПОВ.** Сөенчегә — алтын сәгать . . . 126

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Р. ВӘЛИЕВ.** Халык исеменнән сөйлим дисәң . . 145
**С. МАННАПОВ.** Дәвам . . . . . . . . . . . 155

КАЗАН АЛАРНЫ МӘҢГЕ ОНЫТМАС

**Р. САБИРОВ.** Зиратта булган вакыйга . . . . . 166

СӘНГАТЬ

**Р. ФӘХРЕТДИНОВ.** Халык көйләре һәм Илһам Шакиров . . . . . . . . . . . . . . . 170

Г. ХУҖИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

**Р. ГӘРӘЙ.** Җыры атлый безнең сафларда . . . 177

А. ӘХМӘДУЛЛИНГА 50 ЯШЬ

**Р. МӨХӘММӘДИЕВ.** Бәйрәмнәр дәвам итсен . . 180

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Х. ГОБӘЙДУЛЛИН.** Ә. Синяеваның тууына 90 ел . . 183

ТӨРЛЕСЕННӘН

**Г. ӘЮПОВ.** Онытылмас очрашу . . . . . . . 184
**М. МОЛЧАНОВА.** А. Н. Анненская Казанда . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 191

Баш редактор: **ЗӘКИ НУРИ**

Редколлегия: **ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ** *(баш редактор урынбасары)*, **РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63; сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-63, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 21/VI-1982 ел. Басарга кул куелды 8/IX-1982 ел. ПФ 09037. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65049 экз. Заказ Ю-277. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1982 ел.

# СССРның төзелүенә 60 ел

## Фәнис Яруллин

### Уртак сыйфат

Безнең илдә барлык халыкларга
Уртак сыйфат нәрсә? —
Бердәмлек!
Бердәм булганга без илебезне
Шушы биеклеккә күтәрдек.

Дошманнарның бүрекләре төшә
Караганда безгә үрелеп.
Бу бердәмлек туды көрәшләрдә
Ленин акылы белән берегеп.
Бар дөньяны таң калдырган сыйфат

Тагын нәрсә дисәң —
Юмартлык!
Без никадәр ярлы елларда да
Актык сынык икмәгебез белән
Бүлешерлек бөек көч таптык.

Ватаныбыз безнең шуңа көчле,
Сафларыбыз безнең шуңар нык:
Берләштерә безнең күңелләрне
Ленин васыять иткән Туганлык!

Туфан Миңнуллин

# МОНДА ТУДЫК, МОНДА ҮСТЕК

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ ДРАМАТИК ПОВЕСТЬ

КАТНАШАЛАР

Саттар Биккинин — пенсионер карт, 76 яшьтә
Рауза — аның карчыгы, 74 яшьтә
Зариф — аларның улы, скважиналар ремонтлау цехында өлкән оператор, 56 яшьтә
Илфат — Зарифның улы, промысел начальнигы, 30 яшьтә.
Надия — Зарифның кызы, Госгортехнадзор инспекторы, 28 яшьтә
Нурания — бухгалтерия хезмәткәре, 28 яшьтә
Газизов Шәүкәт Садриевич — Нефть берләшмәсе генераль директор урынбасары, 59 яшьтә.
Нәҗибә — күрше хатыны, 50 яшьләр тирәсендә.
Надир — нефть һәм газ чыгару идарәсе (НГДУ) начальнигы, Илфатның яшьтәше
Ревекка Львовна — газета хәбәрчесе

Вакыйга нефть шәһәрләренең берсендә бара.

## Беренче пәрдә

Эфирда мең төрле аваз. Төрле илләрдән, төрле радиостанцияләрдән әллә ничә телдә соңгы хәбәрләр тапшыралар. Ирешкән уңышларыбыз, дөньядагы хәвефле хәлләр турында татар һәм рус телләрендә сүз бара. Нефть дигән сүз еш кулланыла. Чит телләрдә дә ул сүз еш әйтелә, шуның белән бергә безгә янау сүзләре дә ишетелә. Тавышлар буталалар, кушылалар. Спектакль дәвамында ул тавышлар бер тыналар, бер көчәяләр. Хәтта иң интим сөйләшүләр арасына да килеп керә ул тавышлар — нефть, энергия кризисы, табигатьне саклау, кешелекнең киләчәге, сугыш һ. б. һ. б. Спектакль беткәндә дә тавышлар яңгырап кала.

Менә, әлеге тавышлар тәэсирендә, без нефтьчеләр шәһәре читендә үз йортлары белән яшәүче Биккининнар ишегалдына керәбез. Ишегалдында җәй көннәрендә чыгып утыру өчен беседка сыманрак нәрсә эшләнгән. Кайвакытларда анда чәй дә эчәләр. Тәбәнәк рәшәткә аша — күршеләрнең ишегалды. Пәрдә ачылганда сәхнәдә Саттар һәм күршедә яшәүче тол хатын Нәҗибә. Саттар беседка идәненә утырган да, транзисторлы радиоалгычын колагына ук куеп, соңгы хәбәрләр тыңлый. Нәҗибә ике терсәге белән рәшәткәгә таянган да Саттарга карап тора.

Нәҗибә. Саттар абзый...

Саттар *(Нәҗибәнең кинәт эндәшүеннән куркып китә)*. Тьфү, мәлгунь. Тавышың тавыш түгел. *(Радиога ишарәләп.)* Кирәклесенең тавышы чыкмый, кирәкмәгәне үкерә.

Нәҗибә *(көлеп)*. Нәрсәләр сөйлиләр соң радиодан, Саттар абзый.

Саттар. Өеңә кереп тыңла.

Нәҗибә. Өйгә керәсе килми шул, Саттар абзый. Әле менә шәһәрне урап кайттым да эчем пошып китте. Нефть чыга, нефть чыга дип

шаулаганда да шушы йортта идек, нефть бетә дип сөйләгәндә дә шушында. Без дә инде шәһәрдә яшәдек дисәк...

Саттар. Кем тота сине. Фатир ал да куч.

Нәҗибә. Җиңел генә бирделәр сиңа. Торыр урының бар диләр. Малаем армиядән кайтып эшкә урнашкач фатир бирерләрме дигән идем, кая инде, кайтмыйм дип хат язган, Саттар абзыкаем. БАМ дигән җирдә эшкә калабыз дигән.

Саттар. Үзебезнең як ошамаганмыни?

Нәҗибә. Шулайдыр инде. Нефтькә буялып йөрисе килмәгәндер.

Саттар. Анда нәрсәгә буялып йөрмәкче була соң?

Нәҗибә. Кем белә инде аныкын... Бер ялгызыма бу йортны тоту авыр шул.

Саттар. Кияүгә чык.

Нәҗибә. Кияүгә чыга-чыга да туйдым инде. Рәтле ир кешесе юк. Эчеп йоклар өчен йортка керәләр дә, эшкә кушкач, чыгып сызалар. Эш эшләүче кеше бетеп бара бит, Саттар абзый. Управлениегә кереп чыккан идем дә, эшләргә кеше җитми диләр. Бер өстәл артында икешәр начальник, барысы да эшләргә кеше җитми диләр. Миңа әйтәләр: тизрәк эшкә чык диләр. Юк инде, мин әйтәм, отпускамның соңгы сәгатенә хәтле ял итәм, дим. Былтыр да отпускамда эшләттеләр.

Саттар. Туктале, кыткылдама. *(Радиоалгычны колагына ук куеп тыңлый.)*

Нәҗибә. Кычкыртыбрак сөйләт әле, Саттар абзый.

Саттар. Батарые беткән.

Нәҗибә. Берәр әйбер булганмы әллә, Саттар абзый?

Саттар. Талашалар. Бүлешәләр. Берсе бир ди, икенчесе бирмим ди — тарткалашып җир шарын урталай ярмасалар ярый инде. Күбрәк нефте өчен талашалар хәзер. Нефтенең кадере елдан ел арта.

Нәҗибә. Нефть бетсә, без нишләрбез икән, Саттар абзый? Бигрәкләр дә иямләшкән идек инде.

Саттар. Курыкма, синең белән миңа җитә әле ул.

Нәҗибә. Үзең әйтмешли, синең белән мин генә түгел бит әле. *(Өйдән коляска сөйрәп Рауза чыга. Аның чыкканын күреп, Нәҗибә югала. Коляска эчендәге бала елый.)*

Рауза *(коляска эчендәге балага)*. Тукта инде, җан көеге. *(Саттарга.)* Сиңа әйтәм... Куеп тор әле шул радиоңны. Бетмәгән радио булды. *(Коляска эчендәгегә.)* Иә, җитте диләр сиңа. И ходаем, үтерә бу бала. Токмач басарга да ирек бирми. Сиңа әйтәм, тирбәтә тор әле шуны. Токмачны басып бетерәм дә алырмын.

Саттар. Хәзер без аны, җылак батырны, акылга утыртырбыз. *(Коляска өстенә иелеп.)* Тукта, молокосос! Стоп! Майна! *(Шуны гына көткәндәй, бала елаудан туктый.)*

Рауза. Кара син аны, җан көеген... Акыл белән, явызланып җылый ул, мине санга сукмый.

Саттар. Алып калмагыз диделәр бит сиңа.

Рауза. Алып калмый нишлисең — бала...

Саттар. Баланың анасы бар. Җитәр. Үзебезнекеләрне үстердек, аларның балаларын үстердек, инде хәзер аларның балаларын үстерикме? Карасын үз анасы. Шуңа күрә ходай тәгалә аңарга ике имчәк тутырып сөт биргән. Анасының сөтен без аңа каян алыйк? Хәер, хәзерге хатыннарның имчәкләре булса да, сөтләре юк. Имчәкне фасон өчен генә йөртәләр. Ярый, бар, эшеңдә бул. *(Рауза өйгә кереп киткәч, коляскаkы янына куя да радиоалгычын тыңлый-тыңлый сөйләнә.)* Син нәрсә, ә? Менә, каеш монда гына, тотып ярырмын. Әнә анда дөнья айкала. Илләр белән илләр сугыша. Ә син, җебегән авыз, рәхәтеңә чыдый алмыйсың. Анда сиңа атап бомба ясыйлар. Мин яшисен яшәгән, сиңа яшәргә кирәк. Җылап ятсаң, күрсәтерләр күрмәгәнеңне. Синең

өчен мин сугышып йөри алмам хәзер. Үз хакыңны үзең якла. Ыггы шул. Ыггы икәнен беләсең, ә үкерәсең. Радионың батарые беткән дип атаңа ничә әйттем, колагына да элми. Сине китереп ыргытырга беләләр.

Нәҗибә (*Ул инде рәшәткә янына килеп җиткән.*) Алайга киткәч, тормыш түгел инде ул. Үз балаң үзеңнән арта башлагач... Һаман сезгә инде, Саттар абзый.

Саттар. Безгә шул.

Нәҗибә. Рауза апага да авыр. Сиксән ягына баскан кешегә. Зариф абый өйләнсен иде инде. Хатыным үлде дип, үлгән артыннан үлеп булмый.

Саттар. Өйләнсен, кем аңа сүз әйткән. Өйләнми бит. Аның яшендә хатын табуы да...

Нәҗибә. Әллә кайдан эзлисе юк. Күршегездә генә. Рәшәткәне сүтеп ташлыйсы да ике йортны бер итәсе.

Саттар. Чынлап сөйлисеңме?

Нәҗибә. Чынлап булса, ни булган? Мин кемнән ким? Йортыгыз белән мине сөймәдегез. Зариф абый да. Эзләде, эзләде дә... Үлгән кешегә тел генә тидерәсем килми. Ул өйләнгәч бер атна җыладым. Шуны да сизмәде. Кияүдән кияүгә йөрисең дип көләсез, җанын сөймәгәннәр белән торып карагыз әле сез. Иялəшеп булмасмы дип чыгасың да...

Саттар. Бар. Бар, кит моннан. Бар, өеңә кереп утыр. Рауза апаң ишетсә...

Нәҗибә. Шул Рауза апа аркасында бәхетсез булдым инде. Зариф абыйны миңа каршы котыртты.

Саттар. Кит диләр... Рәшәткә аркылы шулай... Ишегалдына керсәң...

Нәҗибә. Керсәм керер идем инде, кермим генә. Кереп алганыгызны көтәм. (*Көлә-көлә китә. Надия керә.*)

Надия. Мөмкинме икән боларга керергә?

Саттар (*борылып карамыйча гына*). Кем ул анда?

Надия. Мин әле бу, бабай. (*Саттарны килеп кочаклап.*) Саумы, бабай, сәламәтме?

Саттар. Синмени әле? Ничек тик торганнан?

Надия. Командировкага, бабай.

Саттар. Тагын тикшерергәме?

Надия. Тагын тикшерергә. (*Коляскага ымлап.*) Абыйныкыдыр инде.

Саттар. Шуларныкы ла. Сүзгә килешәләр дә, баласын монда китереп ыргыта килен. Без изаланабыз.

Надия. (*Коляска янына килеп.*) Кем син, ә? Исемең ничек? (*Саттарга.*) Зөфәрме әле исеме?

Саттар. Зөфәр.

Надия. (*Коляскага иелеп.*) Зөфәрме син? (*Зөфәр елап җибәргәч.*) Ай, бигрәк җылак икәнсең.

Саттар. (*Колясканы үзенә тартып.*) Булды! Җитте! Стоп!.. Майна! (*Зөфәр җылаудан туктагач.*) Хатын-кызны яратмый ул. Әтисенә охшамаган. Әтисе бигрәк ярата шул хатын-кызларны. Шуның аркасында ямьсезләнешәләр килен белән. Йөри белеп йөрмәгәч, ничу хатының өстеннән йөрергә.

Надия. Йөри белеп йөрсәң, ярыймы, бабай?

Саттар. Синең эшләр ничек соң?

Надия. Шул, нефтьчеләр белән талашабыз.

Саттар. Нефте өчен бөтен дөнья талаша. Радиодан да сөйләп торалар, ай-яй... Японына да нефте җитми, Америкасы да, бирән, нефтегә туймый. Кораблары гел нефтеле җирләр тирәсендә болгана. Ул бу булса, шул нефте өчен генә булачак.

Надия. Егерме ел нефтяник булып, нефть сүзен әйтергә өйрәнә алмадың, бабай.

Саттар. Нәрсәнең ни икәнлеген аңлагач, сүзен ничек әйтсәң дә ярый... Кияүгә чыкмадыңмы әле?

Надия. Вакыт юк, бабай.

Саттар. Картаеп бетәсең ич.

Надия. Кияүгә чыгып вакытсыз картайганчы, үз җаең белән әкренләп картаю яхшырак... Әти эштәме?

Саттар. Эштә. Бик арып кайта.

Надия. Чыксын соң пенсиягә... Абый килеп йөрими?

Саттар. Килгәли. Утырып кычкырышабыз да, үпкәләп кайтып китә.

Надия. Ни өчен?

Саттар. Шул нефте инде һаман. Безнең өйдә бүтән сүз юк, хатын-кыз да нефте, хатын-кыз да нефте. Ябышып каттык шул нефтегә. Бетсә, нишләрләр, кимегәннән кими бара.

Надия. Кайгырма, бабай.

Саттар. Мин кайгырмыйм да, менә бу җылаклар нишләр.

Рауза. *(Чыгып.)* Кем белән сөйләшә дисәм... Исәнме, кызым. Минем янга кермисең дә.

Надия. Бабай җибәрми бит, әбекәй. *(Раузаны кочаклап.)* Саумы, әбекәй.

Рауза. Аллага шөкер. Сиңа әйтәм, Зарифның кайтыр вакыты җитте. Йоклап киткән бугай, берәр күләгәле җиргә илтеп куй, күз алдында тормасын. *(Саттар коляскасны алып чыгып киткәч.)* Әтиең ачулана, алып калмагыз ди. Алып калмыйча нишлисең — капка төбенә куя да китә килен. Әйдәле, кызым, миңа булыш әле ичмасам. *(Өйгә кереп китәләр. Зариф кайтып керә. Арыган. Килеп, беседка идәненә утыра. Кепкасын, курткасын салып, җиргә ыргыта. Саттар керә.)*

Саттар. Кайттыңмы?

Зариф. *(Төксе.)* Юк, китеп барам.

Саттар. Рәтләп сөйләш.

Зариф. Күреп торасың бит.

Саттар. Юын әйдә, аш өлгертә әнием.

Зариф. Ярый. Хәл алыйм бераз.

Саттар. Кызың кайтты.

Зариф. Кайсысы?

Саттар. Надиябез.

Зариф. Яхшы булган. Мунчада җылы су бар микән?

Саттар. Гел булганны, бүген генә булмый калмас! Чиста киемнәрең дә шунда. *(Кереп китә. Зариф, кепкасын, курткасын алып, китәргә җыенганда, Нәҗибә күренә.)*

Нәҗибә. Исәнме, Зариф абый?

Зариф. Нихәл.

Нәҗибә. Эш авыр булган ахыры бүген.

Зариф. Бездә җиңеле юк.

Нәҗибә. Беләм инде ремонт эшен. Нигә пенсиягә чыкмыйсың?

Зариф. Син ни әйтерсең икән дип... *(Китеп бара, өйдән Надия йөгереп чыга. Карана. Нәҗибәне күреп ала.)*

Надия. Нәҗибә апа, әти кая китте ул?

Нәҗибә. Каян белим, мин әтиеңне тикшереп тораммыни? Нихәл соң үзең?

Надия. Әйбәт.

Нәҗибә. Тагын нефтьчеләрне туздырырга кайттыңмы? Кирәкләрен биреп кит әле шуларның.

Надия. Ни үчең бар, Нәҗибә апа? Үзең дә шунда эшлисең.

Нәҗибә. Син кайтып киткәннән соң бу ишегалдында тавыш бер айга хәтле бара. Пыр тузалар.

Надия. Сиңа кызыкмы?

Нәҗибә. Кызыкмы дип... Мин синең әбиеңне яратмыйм да, абыеңны яратмыйм. Абыең үзен әллә кемгә куеп йөри. Начальник имеш. Объединениедә аңардан зур башлыклар бар, исәнләшеп үтәләр. Әнә элеккеге күршебез Шәүкәт абый, замгенеральный директор, исәнме Нәҗибә, ди күргәндә. Ә абыең... Энекәшең әйбәт иде, анысы Саттар абзыйга тарткан. Минә ул ичмасам. Начальник булам дип маташмады, китте дә барды Төмәнгә. Саттар абзыйга тун җибәргән — күреп туймаслык та, киеп туймаслык. Ә абыең Саттар абзыйдан малаен карата. Менә сиңа начальник. Беләсең килсә, ул сине дә яратмый. Төкерәм мин аның бәйләнүләренә, ди. Үзем ишетеп тордым, былтыр менә син киткәч, синең урыныңда басып торган килеш әйтте. *(Рауза чыкканын күреп.)* Чыгып килә инде, кеше белән туйганчы сөйләшергә дә бирми. Безгә дә кереп чык, Надия. *(Китеп югала.)*

Рауза. Нәрсә сөйли ул нәмәрсә?

Надия. Исәнлек-саулык сораша.

Рауза. Кәнтәйләнәдер инде. Тыңлама син аны. Ирдән иргә йөргән хатын-кызны... Кулыннан килмәгән эше юк үзенең, бер нәфсесен тыялмый. Табынны әллә монда гына әзерлибезме, кызым, өйдә кызу булыр.

Надия. Тәрәзәне ачып куярбыз.

Рауза. Әйдә алайса. Әтиең юынып кергәнче. *(Өйгә керәләр. Өстәл артында утырган Саттарның колагында һаман радиоалгыч.)* Куй инде шуны, ничек ялыкмыйсың?

Саттар. Тукта, ашыкма. Төмәндәге нефтьчеләрне бүләклиләр. Әкрен!.. *(Рауза белән Надия якынрак килеп тыңлыйлар. Саттар кинәт кычкырып җибәрә.)* Әйттем бит. Безнеке дә булсын, орден да алмасын. *(Бик горур кыяфәт белән бүлмә буйлап йөри.)*

Рауза. Ни булды?

Саттар. Рафаэль!.. Безнең Рафаэль! Биккинин Рафаэль Зарипович диде. За достигнутые успехи диде. Орден! Күңел сизеп тора минем. Төмәнские нефтяники дию гә үк, Рафаэль дә эләгәчәк, мин әйтәм, һәм эләкте дә.

Надия. Нинди орден, бабай?

Саттар. Ордены булгач, нинди дә мени хикмәт! Молодец, Рафаэль!

Надия. *(Ишектән кергән Зарифка.)* Әти, Рафаэльгә орден биргәннәр. Яна гына радиодан әйттеләр.

Зариф. Башта исәнләш.

Надия. Исәнме, әти. Рафаэльгә — орден.

Саттар. Санап-санап китте дә, шунда әйтте — Биккинин Рафаэль Зарипович диде, бурильщик диде. Молодец, Рафаэль!

Рауза. Кара син аны, ә. Сүзен сүз итеп йөри.

Зариф. Нәрсәгә исегез китте? Орден күргәнегез юк мәллә?.. Ашарга китерегез.

Саттар. Тьфү, мәлгунь. Шатлана белерсеңме син кайчан да булса, юкмы? Малаең орден алган. Синең малаең бит ул.

Зариф. Алса ни. Синдә ул орденнар өчәү-дүртәү.

Саттар. Синдә менә берәү дә юк.

Зариф. Булмаса тагын. Орден алып син нишләдең? Юкка алданып үтте гомереӊ. Мине укыта да алмадың. Йөрмәс идем нефтькә батып, өстәл артында кул куеп утырыр идем. Гомерең буе рабочий класс, нефтяник дип, күкрәк кактың. Рафаэль синең сүзгә ышанып укымады. Әнә синең сыман хәзер орденга алданып йөри.

Саттар. Дәшмә. Мин орденга алданып сугышмадым, анын өчен эшләмәдем. Мин чистный сугыштым, чистный эшләдем.

Зариф. Ярый, ярый, булды...

Надия. Рафаэльне яратмыйсың син, эти.

Зариф. Яратмыйм. Сүземне тыңламады, укымады. Бер заман минем көнгә калачак.

Саттар. Син нинди көнгә калдың соң әле? Нәрсә җитми сиңа? Чык пенсиягә дә, ал уч тутырып пенсияңне. Яшә рәхәтләнеп. Кем куша пенсия яшендә эшләп йөрергә?

Зариф. Мин эшләми, кем эшләсен? Кеше җитешми. Эшләми нишлисең? Сорыйлар да — тыңлыйсың.

Саттар. Кит тә бар, җылап эшләгәнче.

Зариф. Мин җылап эшләмим.

Саттар. Әй, синең белән сөйләшкән — мин җүләр. Үстердем шуңда бер күсәк.

Рауза. *(Өстәлгә ризыклар ташыган җиреннән.)* Иә, житте, сиңа да. Ач кеше белән булышып утырма. Утырышыгыз. Надия, кызым, борыч куйдыңмы?

Надия. Бабай борыч сипте инде әтигә.

Рауза. Котыртма. Әләгешергә генә торалар. Гомер буе шулай. Монысы рабучий класс дип мактана. Синең рабучилыгың инде. Иллегә житкәндә нефтегә барып керешкән булды да. Буялып кайтканына куанып... Гомере буе ат җигәргә, сыер асрарга өйрәнгән кешегә җитә калды.

Саттар. Мин өйрәнмәдем. Мин теләмәдем генә. Ник дисәң, мин тумыштан пырлитар. Рәхмәт нефтегә, безнең җирдә чыгып, менә кеше итте. Безнең җирдә чыкмаса да, эзләп таба идем барыбер. Барыбер авылда калмый идем.

Рауза. Авылда начар кешеләр генә яшимени?

Саттар. Мин алай димәдем. Ат җигәргә, сыер асрарга яраткан кеше шунда яшәсен. Монда килеп интегеп йөрмәсен, зарланып яшәмәсен. Күңелең тарткан эшне эшләргә кирәк. *(Зарифка күрсәтеп.)* Юкса, моның эшләвеннән ни мәгънә. Чөнки моңарда пырлитар каны юк.

Зариф. Ярый, булды инде, булды. Син бик әйбәт. Утыр, пырлама, җилкенмә, я очып китәрсең.

Саттар. Очырмын да. Менә син оча алмыйсың. Синдә сәүдәгәр каны бар, Зариф. Әниең синең кибетче кызы иде. Шуңа күрә сез нефтегә буялуны яратмыйсыз. Әниеңнең иң яраткан эше — акча санау. Син дә акча санарга яратасың. Шуңа күрә генә авыр эштә эшлисең.

Рауза. Дәшми, дәшми торгач та... Нигә яшәдең сөймәгән кешең белән?

Саттар. Кем әйтә сөймәгән дип. Син миңа бераү генә, карчык. Менә моңарга ачу чыкканнан гына әйтүем. Улын мактаганга көенеп кара көйдә. *(Зарифка.)* Сине мактасалар, мин сөенеп туя алмыйм.

Зариф. Бер башласаң, туктый белмисең. Сүздән туйган — гарык. Ну, маладис, Рафаэль, маладис.

Саттар. Маладис түгел, молодец. *(Надия көлеп җибәргәнгә канатланып китеп.)* Кеше арасында йөреп, урысча да җүнләп белми.

Рауза. Картайталар болар менә, Надия кызым.

Надия. *(Чын күңелдән.)* Рәхмәт сиңа, бабай.

Рауза. Сиңа җитә калды инде. Бабаңны бик яраткач, ташлап китмиләр аны, интегәм берүзем. Ярый әле үземне йөртәм әлегә, түшәккә егылсам, нишләрләр. *(Берара тыныч кына ашыйлар.)*

Надия. Һаман да скважиналар ремонтлыйсыңмы, эти?

Зариф. Юк, министр итеп куйдылар.

Рауза. Рәтлерәк итеп әйт. Кунакка гына кайткан кызың. *(Пауза*

*Тышта Зөфәрнең елап җибәргәне ишетелә. Зариф, ашавыннан туктап, Раузага карап тора.)*

Р а у з а. Китермәделәр, үзем алып кайттым, чирләп тора. *(Кабаланып чыгып китә. Илфат белән Надир керәләр.)*

И л ф а т. Бездән башка гына сыйланалар болар. Узыгыз, Надир Рәхимович.

Н а д и р. Исәнмесез. Мактап йөрибез икән. Ашлар тәмле булсын.

С а т т а р. Рәхмәт.

И л ф а т. Нигә бик алай коры гына? Син, бабай, кешеләргә якты чырай күрсәтегез дип өйрәтәсең... Мине инде син яратмыйсың. Кунак бар. Мин дә атнага бер генә килеп китәм.

С а т т а р. Малаең аның каравы көне-төне монда ята. Әнә, әле дә үкерә. Миннән нәнкә ясап бетердегез.

З а р и ф. *(Илфатка.)* Тагынмы?

И л ф а т. Минем бер гаебем юк. Киленегезне үзегез тыегыз. Кая, аш салыгыз инде безгә.

З а р и ф. Кулыңны юып кер башта.

И л ф а т. Киттек, Надир Рәхимович. Безнең өй мәчет кебек, тәһарәт алмыйча бусагадан да кертмиләр.

Р а у з а. *(Кереп, Саттарга.)* Бар әле чык янына, җылатмале шуны. Синнән бүтәнне тыңламый. *(Саттар чыга башлагач.)* Сөтен алып чыгарга онытма. *(Илфат белән Надир керәләр. Надия аларга аш бүлә.)*

Н а д и я. *(Илфатка.)* Рәхәт сезнең, ә?

И л ф а т. Ни әйтергә телисең?

Н а д и я. Рәхәт яшисең дим. Балагызны бабай карый, ашарыгызга әбекәй пешерә.

И л ф а т. Башта ашыйк, сеңелкәш. Аннары бәйләнерсең.

Н а д и я. Ә мин бәйләнергә җыенмыйм.

И л ф а т. *(Бер-ике кашык аш капкач.)* Яшәрсең сезнең белән рәхәт.

Н а д и я. Кем инде ул — сезнең белән?

И л ф а т. Инспекторларны әйтәм.

Н а д и я. Ә-ә... Әллә мин хатын-кызлар белән дип әйтәсеңме дип торам.

И л ф а т. *(Кычкырып көлә.)* Ну, этләшәсең, сеңелкәш. Бабайның этләшүе синең янда чепуха гына. *(Зарифка.)* Мине яклап берәр сүз әйт инде, әти.

З а р и ф. Чәй... *(Надия чыгып китә. Саттар ачык тәрәзә янына килә.)*

С а т т а р. Үкерә. Астына җибәргән дә үкерә, молокосос. Әйтерсең бүтәннәр гаепле. *(Раузага.)* Бирәле шуннан коры чүпрәк. *(Рауза чүпрәк китереп биргәч, Илфатка.)* Китсәңдә, малаеңны ала кит.

И л ф а т. Кем китергән, шул алып китәр. *(Кычкырып көлә.)*

С а т т а р. Авызыңны бик ачып көлмә, акыл тешләрең юклыгы күренә.

И л ф а т. *(Усал.)* Чамалап, бабай... Мине мыскыл иткәннәрен мин яратмыйм.

З а р и ф. *(Надия китереп биргән чәйне бер йотып куйгач.)* Булды...

И л ф а т. Көләргә дә ярамый. Җылап җибәрсәм, күңелегез булыр иде.

Р а у з а. Әтиең, булды, диде.

И л ф а т. Әти булды дигәнгә генә булмый шул.

Н а д и я. Син нигә кызасың соң әле?

И л ф а т. Нигә кызаммы? Үзеңнән сора. Син ялыңны онытып, яныл-көеп, җиде кат тирең чыкканчы эшләп йөр дә, сиңа килеп бәйләнсеннәр. Казанда китап актарып инструкция укып яталар да, эчләре поша башлагач, монда килеп эшләгән кешеләргә бәйләнәләр.

Н а д и я. Адәм рәтле итеп эшләргә кирәк.

Н а д и р. *(Ул һәрвакыт елмаеп сөйләшә.)* Адәм рәтле? Ә ничек була соң ул адәм рәтле, Надия Зариповна?

Н а д и я. Актка кул куйганда күренер. *(Акт сүзен ишеткәч, Саттар тәрәзәдән башын тыгып тыңлый.)*

З а р и ф. Нинди акты ул?

И л ф а т. Минә синең кызың, минем сеңелкәш житәкчелегендәге гортехнадзор комиссиясе безнең өстән акт төзиячәкләр.

З а р и ф. *(Надиягә.)* Тагынмы? Нәрсә, бүтән тикшерер урының юк мәллә?

Н а д и я. Монда җибәрделәр.

И л ф а т. Акт!.. *(Надиягә.)* Сезгә акт, монда факт. Монда тормыш. Тормыш ул синең инструкцияң түгел.

Н а д и я. Бүтәннәргә дә тормыш. Аларда синдәге башбаштаклык юк.

И л ф а т. Бүген булмаса, иртәгә булыр.

Н а д и я. Булса, аларга да тиешле чара күрелер. Җирне, суны пычратырга, җир байлыгын таларга ирек куймаслар.

И л ф а т. *(Кычкырып көлә.)* Демагогия. Син ул сүзне җыелышларда сөйлә, мыек астыннан көлеп тыңларлар. Илгә нефть кирәк, милая моя. Аңлыйсыңмы — нефть? Бик кирәк! Бүген кирәк! Күп кирәк!

Н а д и я. Минә монысы инде чынлап та демагогия.

И л ф а т. Әй, син нәрсә беләсең.

Н а д и я. Мин — геолог.

И л ф а т. Геолог. Мин — инженер. Шуннан ни?

Н а д и я. Инженер булсаң, нефтьне чын инженерларча, фән кушканча алырга кирәк.

И л ф а т. Ай-ай-ай!.. Дәшмә ичмасам, сеңлесе тиле икән дип миннән көләрләр.

Р а у з а. Тыныч кына сөйләшә аласызмы сез, юкмы? *(Зарифка.)* Әйт шуларга бер сүз.

З а р и ф. *(Урыныннан кучеп диванга барып утыра.)* Укыган кешеләр... Сөйләшсеннәр.

Н а д и я. Сезнең кебек инженерлар илгә кыйммәткә төшә. Сез җирне талаучылар, ил байлыгын талаучылар. Җир астына бөтен проектлардан узып су кудырасыз. Нефть катламын су баса. Бер тонна нефть алып, өч тоннаны җир астында калдырасыз. Эксперимент өчен туктатылган скважиналарны урлап кына эшкә кушасыз. Скважиналарны эштер-өштер генә ремонтлап, аларны эштән чыгарасыз. Намусы бар инженер шулай эшлиме? Илгә нефть кирәк, имеш. Алдашма, абый җан кисәгем. Сезгә нефть түгел, дан кирәк.

И л ф а т. Нинди дан?

Н а д и я. Анысын үзегез беләсездер.

И л ф а т. Дан! Бераз кеше күзенә күренә башласаң, шул сүз белән йөзеңә чәпиләр. Әгәр аңарга китсә, дан бөтен кешегә дә кирәк. Кеше ни өчен яши, ни өчен тырыша, сугелер өченмени? Кеше мактау сүзенә һәрвакыт мохтаж.

Н а д и р. Берәүнең дә әле орденнан баш тартканы юк, Надия Зариповна. Менә сез ни өчен бездән тырышып-тырышып гаеп эзлисез? Җитәкчеләрегез алдында яхшы күренер өчен. Янәсе, принципиаль инспектор.

Н а д и я. Маташмагыз, иптәш Рәхимов. Сез мине бик яхшы беләсез. Һәм, гомумән... Мин бертуган абыем белән сөйләшәм. Адвокатлар кирәкми.

Н а д и р. Гафу итегез. Мин, әгәр комачауласам, чыгып китә алам. Ләкин шуны әйтәм, Илфат Зарипович яклауга мохтаж түгел. Ул минем

кул астында эшли, аны сезгә караганда яхшырак беләм. Илфат Зарипович — безнең нефтьнең киләчәге.

Н а д и я. *(Илфатка.)* Син шул сүзләргә алданып яшисеңме?

И л ф а т. Мин бер нәрсәгә дә алданмыйм. Минем үз иманым. Илгә нефть кирәк. Миннән нефть сорыйлар. Һәм мин аны бирәчәкмен. Мең акт төзегез, мин нефть бирәчәкмен. Мактыйлар икән, мин каршы түгел. Ләкин мин макталып дан алыр өчен генә эшләмим. Нефть кирәген мин күңелем белән дә, башым белән дә аңлыйм. Шуңа күрә синең кебекләрнең казынуын эшкә комачау итү дип кенә саныйм.

Н а д и р. Тыңлагыз әле, Надия Зариповна, ачулансагыз да, мин сезгә бабамнан ишеткән гыйбрәтле бер нәрсә сөйлим. Борын-борын заманда бер патша, иске киемнәр киенеп, үзенең кем икәнен белдерергә теләмичә шәһәргә чыккан. Карап йөри икән бу... Шуннан күрә: бер урам чатында көрәшеп яталар. Карап тора патша — бер егет бөтенесен дә егып бара икән. Патшаның бу егетне егып карыйсы килә. Түгәрәк уртасына керә дә егеткә әйтә, әйдә көрәшәбез, ди. Егетнең янына патшаның вәзире килеп җитә, колагына әйтә: кара аны, егыл, ул патша, ди. Егетнең исе дә китми. Күтәреп алып җиргә сылый патшаны. Карап торучылар гөр киләләр. Патшаның ачуы чыга. Егетне тотып алырга куша. Патшаның солдатлары егетне эләктереп алалар да җиргә салып суктыралар.

Н а д и я. Шуннан.

И л ф а т. Син, сеңелкәш, Госгортехнадзорның гап-гади инспекторы, патшалар белән көрәшергә алынма.

Н а д и я. Үзегезне патша дип санамыйсыздыр ич?

Н а д и р. Кая безгә андый дәрәҗә.

И л ф а т. Бүгенге көннең патшасы да, алласы да — политика. Җиңүчеләрне дә, җиңелүчеләрне дә шул патша билгели. Ә нефть ул бүген — политика. Дөньяда энергия кризисы. Нефтьне чыгаручылар — без.

Н а д и я. Зурдан торып сөйләшәсең.

И л ф а т. Без беркайчан да вакланмадык. Нефть вакланганны яратмый. Ваклanып, миллиардлаган тонна нефть чыгарып булмый. Имеш, эчә торган су катламына тозлы су җибәргәнбез. Җибәрсә. Кырык елга якын нефть чыгарабыз, берәүнең дә тозлы су эчеп үлгәне юк. Имештер, җиргә нефть агызабыз. Агадыр. Чәйнектән стаканга су салганда да берничә тамчы читкә чәчри.

Н а д и я. Сала белеп салсаң, чәчрәми.

И л ф а т. Җир, имеш. Мең, мең ярым гектар әрәм була икән, нигә каравыл кычкырырга? Нефть кирәк! Бүген кирәк!

Н а д и я. Иртәгә кирәкмәсме?

И л ф а т. Бүген кирәгрәк. Бүген нефть бирмәсәк, иртәгә ул җирләрегезне яндырып, көйдереп ташлаулары мөмкин. Шуны көтеп кенә торалар океан артында. Иөрерсең аннары тозсыз су эзләп... Без нефть бирәбез, күп бирәбез — без көчле. Безнең көчтән куркалар. Менә нәрсә турында уйла, сеңелкәш. Кирәк икән, берничә районыңны тозлы суга күмәрбез, әллә ничә район җирен актарып ташларбыз. Җир шарын сакларга кирәк, нәрсә ул синең районыңның җире.

С а т т а р. *(Тәрәзәдән үрелеп.)* Монысын арттырып җибәрдең.

И л ф а т. Син күбрәк беләсең, бабай, радиодан аерылмыйсың. Айкала дөнья, чайкала, чайкалып түгелмәсә ярар иде дисең. Исән-сау чакта үз үлемем белән үлсәм иде дисең. Мин дә үз үлемем белән үләргә телим.

З а р и ф. Энекәшеңә орден биргәннәр.

И л ф а т. Нинди орден?

Н а д и я. Нинди икәнен ишетми калдык, радиодан әйттеләр.

И л ф а т. Молодец, энекәш.

С а т т а р. Син әтәчләнәсең дә менә, тик орден гына тәтеми.

Илфат. Син тик тора беләсеңме, бабай, юкмы? Туйганым шушы пенсионерлардан. Ветеран дигән булалар да теләсә кая килеп кысылалар. Без фәлән иттек, без төгән иттек...

Саттар. Иттек шул.

Рауза. Җитте инде сиңа, үртәмә баланы. *(Тәрәзәне ябып куя.)*

Саттар. *(Тәрәзәне ачып.)* Тәрәзәне япсаң, үзең чыгып кара малаеңны.

Илфат. Синең заманда, бабай, бәгырь кисәгем, нефть үзе чыга иде, хәзер чыгарырга кирәк. Сез каймагын җыеп дан алдыгыз, безгә әйрәне калды. Әле аны да күпсенәләр. Инструкция тотып өстендә торалар. Пенсияңне ал да тик ят, бабай, кысылма.

Саттар. *(Өйгә үк атылып керә.)* Нәрсә син һаман минем пенсиягә бәйләнәсең. Кысылмам мени. Мин памбур булып җир тишә башлаганда, синең атаң кемгә өйләнергә белми аптырап йөри иде. Каймак... Бабаңның бөкересе каймак ашап чыккандыр шул. Молокосос!

Надия. Кызма, бабай.

Саттар. Кызмыйм. Ачуны китерә. Берни булса — пенсионер. Пенсиядә булгач аңгыра дип уйлыйлар. Синең кебек молокососны унны алыштырам әле мин. Ә җиргә син тимә, белдеңме? Минем җиремә тимә? Тимә җиремә! Нефтесен ал, җиремне пычратма. Үзеңә җир тап та, шуның астын өскә әйләндер, шуны тозла. Мин монда тудым, монда үстем, монда күмәчәкләр. Син пычраткан җир астында ятасым килми минем. Әнә андагы молокососыңа да пычрак су эчертәсем килми. Аның әле яшисе бар. Сиңа мең гектар чүп тә түгел. Ә мин ил өчен сугышканда бер кишәрлек җир өчен дә сугыштым. Әтиең дә унҗиде яшендә шул җир өчен ут эченә барып керде. Син чыгып аунарлык чирәмле җир калсын дип тә сугыштык. Тимә минем җиремә.

Зариф. Синең җирең юк бит. Син рабочий класс. Рабочий классның җире булмый. Крестьяннең генә җире була.

Саттар. *(Сүзсез калып, Зарифка карап тора. Илфат көлә. Саттар рәнҗеп, кулын селтәп куя.)* Аңгыралар сез. Аталы-уллы аңгыра. *(Чыгып китә.)*

Рауза. Хәтерен калдырдыгыз. Хәзер бер атна буе авызын ачып сүз әйтмәячәк. Олысы олы, кечесе кече була белмәгәч, шулай инде ул. Хәерле булсын.

Илфат. Чыннан да... Нигә дип әле без?.. Надир Рәхимович, гафу итегез. Әби, гафу ит инде безне. *(Тәрәзә янына барып, тышка карый.)* Үпкәләгән. Урамга чыгып бара. Менә, сеңелкәш, без синең белән... Ярый. Әйдә, киттек ресторанга. Инспектор булсаң да, син — кунак. Бүген анда оркестр, танцевать итик. *(Көйләп.)*

Алар, бертуганнар диеп,
Калсын дошман көнләшеп.

Зариф. Өеңә кем кайта?

Илфат. Вакланма, әти. Без вакланган да җиткән. *(Тышта Зөфәр елап җибәрә.)* Малай җылый, бабай үпкәләде. Әйттем бит мин сиңа, әби, алып калмагыз дидем.

Рауза. Капка төбендә калдырып киткәч, кая куйыйм. Барысы да алып калма кирәк. Берсенең дә аласы килми. Җан әрнетергә туган бала. *(Чыгып китә.)*

Зариф. *(Надирга.)* Агай-эне, син бездән көлмә инде. *(Чыгып китә.)*

Надир. Миңа китәргә вакыт, Илфат. *(Надиягә.)* Гафу итегез, Надия Зариповна, сезне борчыдык.

Надия. *(Надирның үзенә охшатып.)* Гафу итегез, Надир Рәхимо-

вич, без сезне борчыдык.Ләкин сезгә бер соравым бар. Сез абый белән якын дуслармы?

Илфат. Җитте сиңа, наконец!

Надир. Сабыр, Илфат. Нигә шулай дип сорадыгыз, Надия Зариповна? Әллә берәр шигегез бармы?

Надия. Бар. Сез — идарә начальнигы, абый промысел начальнигы гына. Сезнең өчен күбрәк ул сөйли, сез елмаеп тыңлап торасыз.

Надир. Туганнар сөйләшкәндә мин нишләргә тиеш?

Надия. Яки чыгып китәргә, яки үзегезнең кул астында эшләүчене тыярга тиеш. Нигә килдегез сез безнең өйгә?

Илфат. Җитте диләр сиңа... Киттек, Надир Рәхимович.

Надия. Кычкырма, абый, мин синнән курыкмыйм.

Надир. Усал сез, Надия Зариповна. Ләкин юкка шикләнәсез. Без Илфат белән бер чорда укыдык. Сүзләребез, эшебез уртак. Аннан соң, мин кешеләргә кеше итеп карыйм, үземнең җитәкчеләргә дә, минем кул астында эшләүчеләргә дә. Ә сөйләүгә килгәндә, Илфат Зариповичның сезгә әйткәннәре белән мин тулысынча килешәм, шуңа бүлдермәдем.

Надия. Акт барыбер язылачак.

Надир. *(Елмаеп.)* Анысы сезнең эш. Мин теләнергә килгән дип уйласагыз, ялгышасыз. Актларны без күп күргән. Тик менә сеңелесенең абыйсына баз казырга маташуы гына миңа аңлашылмый. Ни дисәң дә, дөньяда мораль нормалар бар. Әтисен сатып, тарихка кергән малайлар чоры узды. Сау булыгыз. *(Чыгып китә.)*

Илфат. *(Арттарак калып, Надиягә.)* Менә шул явызлыгың аркасында син кияүгә чыга алмыйсың. *(Чыгып китә. Сәхнә караңгылана. Эфирда һаман төрле телләрдә соңгы хәбәрләр тапшыру дәвам итә. Беседкада тәмәке тартып Зариф утыра. Рәшәткә артында Нәҗибәнең моңланганы ишетелә.)*

Биек тауның башларында
Аэродром коралар;
«Уф» димәгез — дошманнар бар —
«Их» дияргә торалар.

*(Нәҗибә үзе дә күренә, рәшәткә янына килә.)*

Нәҗибә. Кем икән, мин әйтәм, ут белән уйнап утыра. Нишләп бу вакытта утырасың, Зариф абый? Иртәгә иртүк эшкә барасың бар. Миңа төн буе йөрсәм дә ярый — мин отпускада. Көн озыны йоклыйм да...

Зариф. Төнлә тавык кебек кытаклап йөрисеңме?

Нәҗибә. Тавык төнлә кытакламый, Зариф абый, төнлә хатын-кыз гына кытаклый. Онытып бетергәнсең инде. Хәер, син чын хатын-кызны күргәнең дә юк әле. Үлгән кешегә тел генә тидерәсем килми. Әнисең кушканга өйләндең, торасың килмичә тордың.

Зариф. Син бик әйбәт яшәдең инде.

Нәҗибә. Мин дә бит әле мактанып тормыйм. Иң бәхетле кеше бу дөньяга тумаган кешедер ул, Зариф абый. Их...

Әнә килә автомобиль —
Төягәннәр значок;
Ятлар якын, без ят инде
Ярамадык, значит.

Зариф. Бар, арырак китеп сайра.

Нәҗибә. Эч поша бит, Зариф абый. Малай да кайтмыйм дип хат язган. Әтисе шикелле зимагур булыр микән. Синекеләр ичмасам барысы да кеше булдылар.

Зариф. Каян беләсең?

Нәҗибә. Күреп торам, лабаса. Шоферлы машиналарда гына утырып йөриләр. Ичмасам, шәһәре дә безнең янга килеп җитми. Өйне сүтәр иделәр дә фатир бирер иделәр. Кешеләр арасында яшәр идем. Төзегән булалар, төзегән булалар... Нихәтле нефть чыгарып, урамында адашып йөрерлек шәһәребез дә юк. Чаллыга барып кайттым әле, менә ичмасам шәһәр.

Зариф. Таш өйгә күчсәң, агач мунчаңны сагынып җыларсың.

Нәҗибә. Юк, сагынмыйм. Мунчасының ни рәхәтен күрдем. Җаным сөймәгәннәрнең аркаларын ышкып үтте гомерем... Акчаны син нигә җыясың, Зариф абый?

Зариф. Нинди акча?

Нәҗибә. Пенсиягә чыкмый эшлисең ич. Эшнең дә әле иң авырында. Бетермә үз-үзеңне акча дип, яшисең бар.

Зариф. Акча өчен эшлимме мин?

Нәҗибә. Нәрсә өчен соң?

Зариф. Пенсиягә чыгып нишлим? Көннәр буена синең белән бытылдап утырыргамы?

Нәҗибә. Бытылдап дип... Рәтлерәк сүз тапмадыңмы?

Зариф. Яратып диммени?

Нәҗибә. Әйтсәң, телең корымас иде әле. Үз гомеремдә миңа да ул сүзне ишетергә ярыйдыр.

Зариф. Әйткәннәре булмадымыни?

Нәҗибә. Бәлки әйткәннәрдер дә, ишеткәнем булмады. Син әйткәнне генә хәтерлим.

Зариф. Кайчан?

Нәҗибә. Син сугышка китәсе көнне. Аракы эчкән идең. Минем баштан сыйпадың да, яратам дидең.

Зариф. Ул вакытта син бала гына идең бит әле.

Нәҗибә. Алай димә, Зариф абый, унбер яшьтә идем инде. Син уңҗидедә. Ни әйткәнеңне белгәнсеңдер. Кайттың да оныттың. Рауза апа яратмады шул мине. Начарлык та эшләмәдем юкса. Күч минем өйгә, Зариф абый, үзеңнеке ит. Сиңа бит тәрбия кирәк. Эшең бигрәк авыр. Рауза апа өлгерә алмый. Синең күңелеңә җылы җитми, Зариф абый. Хатын-кызның күңел җылысын тойганың юк синең. Шуңа күрә эшеңдә яратып бетермиләр сине.

Зариф. Кем яратмый.

Нәҗибә. Үзең белән бергә эшләүчеләр. Ат кебек эшли, эт кебек ырылдый диләр. Син бит үзең яхшы кеше. Синең беркайчан да кеше хакына кергәнең юк. Яшәвең кызыксыз. Саттар абзый синнән күңеллерәк яши.

Зариф. Аның да күңелле яшәве инде. Утырабыз да талашабыз.

Нәҗибә. Ә син талашма, Зариф абый, аны күбрәк тыңла.

Зариф. Ярый, бар, торма өстемдә карылдап. *(Паузадан соң.)* Әллә ничек әле. Малай белән хатыны да...

Нәҗибә. Яшәячәк түгел алар, Зариф абый. Яшь булганына, чибәр булганына кызыгып өйләнде Илфат, яратканы бүтән иде аның.

Зариф. Бер дә белмәгәнең юк.

Нәҗибә. Белмәскә. Мин аларны үз балаларым кебек күрәм. Әниләре үлгәч, минем ишегалдында үстеләр. Рауза апа гына биздерде. Илфат бик үзгәрде. Яратып йөргән кызына өйләнмәкче иде ул, Рауза апа белән синең сүзне тыңлады.

Зариф. Мин нәрсә әйттем аңа ул хәтле.

Нәҗибә. Нефтегә батып кайтучылар өйдә дә җитәрлек дидең.

Зариф. Күп сүз — чүп сүз. *(Урыныннан торып, өйгә таба атлый.)*

Нәҗибә. Зариф абый... *(Зариф туктагач.)* Кил әле монда, Зариф абый.

З а р и ф. *(Нәҗибә ягына бер-ике адым атлап.)* Нәрсә булды.
Н ә җ и б ә. Якынрак кил.
З а р и ф. *(Якын ук килеп.)* Иә, нәрсә?
Н ә җ и б ә. Кочакла мине, Зариф абый. Аннан кереп китсәң дә ярый. Юкса, мин йоклый алмаячакмын.
З а р и ф. Нишләдең соң син? Гомерендә кыланмаганны...
Н ә җ и б ә. Бүген әллә ничек. Үлеп китәрмен төсле.
З а р и ф. Җүләрләнмә.
Н ә җ и б ә. Дөньяда мәхәббәт күрми үлеп китәрмен төсле.
З а р и ф. Әлегә хәтле үлмәдең ич. Картаеп беткәндә.
Н ә җ и б ә. Мәхәббәт картаймый бит ул, Зариф абый. Җаның юкмыни синең?
З а р и ф. Җаным бар дип алтмышка җиткәндә кочаклашып торыйммы?
Н ә җ и б ә. Туң йөрәк. Бар, йокла кереп. Кырык яшеңдә тол калып, салкын мендәрдә аунап ятасың. Йөрәгенә мүк үскән нәрсә. Бар, йокла. Бөтен рәхәтең шул булсын. Эшлә дә йокла, эшлә дә йокла. *(Елап җибәрә.)*
З а р и ф. Син... Син әллә чынлапмы?
Н ә җ и б ә. Бар, кит. *(Үзе рәшәткә яныннан китә.)*
З а р и ф. *(Югалып калган.)* Җүләр... Кил әле монда... Кил диләр... Сиңа әйтәләр, әллә ишетмисеңме?
Р а у з а. *(Тавышы ишетелә.)* Зарифулла, синең тавышмы соң ул? *(Зариф рәшәткә яныннан китә. Рауза чыга.)* Зарифулла, синме?
З а р и ф. Мин булмый, кем булсын.
Р а у з а. Кем беләндер сөйләштеңме соң?
З а р и ф. Җеннәр белән сөйләшеп утырдым.
Р а у з а. Иртәгә эшкә барасың бар. Надия кайда йөри икән? Кыз балага шул вакытка чаклы.
З а р и ф. Нинди кыз бала булсын, утызга җитеп килә инде.
Р а у з а. Йокла, утырма төн саклап. Әтнеңнең кәефе китеп тора. *(Кереп китә. Зариф тәмәке кабыза. Надия кайтып керә.)*
З а р и ф. Кайда йөрдең.
Н а д и я. Абыйларга бардым. Хатыны җылый, абый кайтмады.
З а р и ф. Кайтыр, чуртыма да китмәс.
Н а д и я. Аракы эчә башламагандыр ич?
З а р и ф. Башласа. Хәзер кем эчми.
Н а д и я. Син бозасың аны, әти. Кирәгеннән артык яратасың. Барыбызга караганда аны иркәләдең.
З а р и ф. Иркәләп нишләгән?
Н а д и я. Укы, укы, кеше бул. Зур кеше бул. Безнең нәселдән дә укыган кеше чыксын дип. Эшләп тапкан акчаңны аңа биреп укыттың. Хәзер дә сүз әйттермисең. Теләсә нишләп йөри.
З а р и ф. Нәрсәле син бөтен кешегә бәйләнеп йөрисең? Сине кем укытты соң? Сеңелеңне кем укытты? Рафаилның укымаганына мин гаепме? Менә сине укытканыма үкенәм. Атаң өенә кайтып талаш чыгарасың. Остардың. Дәшми-дәшми торгач та теге. Синнән башка акты яза белүче юкмыни Казанда? Кайтасың да акты язып китәсең. Бүтәннәргә кара, туганнар берсен берсе күтәрәләр. Йөрмә ирдәүкәләнеп, кияүгә чыгарга вакытың җиткән.
Н а д и я. Нәрсә, мин хаксызмыни?
З а р и ф. Сезнең галәмәтләрегездә минем эшем юк. Талашмагыз гына.
Н а д и я. Ничек инде эшең юк? Син нефть чыгаручы бит.
З а р и ф. Без буяучы гына, чыгаручылар бүтән. Бабаң гына үртәчләнеп йөри нефтяник дип. Министр булып утыра диярсең.
Н а д и я. Бераз да үзгәрмисең.

Зариф. Бүтәннәр аның каравы тиз үзгәрә. Җыелышта түр башына утыртсалар, әллә кем дип уйлый. Иртәгә минем белән бергә нефтькә батып йөрисен белми... Миңа тимәгез. Үзегез теләсәгез нишләгез. Ә абыеңа бәйләнәсе булма. Җае чыкканда, якла. Син якламасаң, кем якалр. Аның бит махнатый рукалары юк.

Надия. Кем, кем?

Зариф. Кем булсын — махнатый рука.

Надия. Кем соң ул, махнатый рука?

Зариф. Белмисең — бәйләнәсең. Махнатый рука ул — сине яклаучы начальник дигән сүз.

Надия. Карале, әллә ниләр беләсең син, эти.

Зариф. Мин кешеләр арасында йөрим.

Надия. *(Зарифны кочаклап.)* Их, эти, эти... Син бит бабайның малае... Дөньяны аңламыйча картаеп барасың... Бүген карап утырдым үзеңә, чәчләрең агарган. Минем дә ак чәчләрем бар инде, эти.

Зариф. *(Надияне читкә этеп.)* Ярый, бар йокла.

Надия. Ә син?

Зариф. Сез барында миңа йокы эләгәмени? Сез генә бит ул мине ишәккә санныйсыз. *(Ут сүнә. Эфирда тавышлар. Шулар арасында Илфатның кычкырып көлгәне ишетелә. Сәхнә яктыртганда Илфат Нуранияның бер бүлмәле фатирында идән уртасына баскан да кычкырып көлә. Кухнядан Нурания чыга. Кулында чәй салынган чынаяклар.)*

Нурания. Ни булды, тагын?

Илфат. Искә төште. Мин бәләкәй чакта безнең бозавыбыз бар иде. Бервакытны шул бозау ниндидер ярамаган эш эшләде. Шуның өчен орышты тегене әби. Бозау, үз гаебен үзе аңлап, күзләрен мөлдерәтеп, әбигә карап тора, ярамаган эш эшләгән өчен үз койрыгы белән үзен кыйный. Менә болай итеп.

Нурания. Нишләп әле ул бозау бүген исеңә төште?

Илфат. Ә син башта көл.

Нурания. Көлмим. Көләсем килми.

Илфат. Юкка. Минем ни өчендер бүген көләсем килә. Кеше нигә көлә? Рәхәтлектән, күңеле көр булганлыктан. Миңа рәхәт. Нурания, ап-ак алъяпкыч ябып, миңа чәй кайната. Ә мин, ярамаган эш эшләгәнемне аңлап, үземне үзем кыйнамакчы булам — койрыгым юк. *(Кычкырып көлә.)*

Нурания. Син күп көлә башласаң, хәерлегә түгел, Илфат.

Илфат. Әйе, шулай шул. Мин бүген өйгә кайтырга тиеш идем. Кайтасым килми, Нурания. Синнән ун яшькә яшь, синнән ун тапкыр чибәррәк хатыным көтә өйдә, ә кайтасым килми. Бәлки көтмидер дә инде, ул да өйгә кайтмыйм диде.

Нурания. Минем яңа хатының турында сөйләргә килдеңме?

Илфат. Гафу ит. Әйдә, чәй эчик. *(Идән уртасына утырып чәй эчәләр. Илфат Нураниягә карап торган килеш көйли.)*

Алмалы көянтәсе...
Менә шушы була инде
Илфатның сөяркәсе.
Алсуланып кояш чыга таң аткач,
Сагынырга туры килә яраткач.

Нурания. Минме инде ул Илфатның сөяркәсе?

Илфат. Кем соң?

Нурания. Әллә нинди серле бу адәм баласы, әйеме, Илфат? Кеше үзен-үзе дә аңламый. Менә дигән, һәр ягы килгән кешеләр була, ләкин син аны күңелеңә якын итә алмыйсың. Һәр сүзе белән сине мыскыл иткән хамны оныта алмый интегәсең.

Илфат. Минме инде ул хам?

Нурания. Кем соң?

Илфат. *(Кычкырып көлеп.)* Чөнки ирләр белән хатыннар мөнәсәбәтендә бернинди дә логика юк, Нурания. Дөньяда логикасыз бер генә бер нәрсә — мәхәббәт.

Нурания. Нинди мәхәббәт? Ни сөйлисең? Синдәме ул мәхәббәт?

Илфат. Юк, синдә. Син мине яратасың.

Нурания. Күпме яратырга мөмкин.

Илфат. Үлгәнче. Син мине яратырга хөкем ителгән.

Нурания. Ә син?

Илфат. Мин дуңгыз малае прачунок. Сиңа өйләнмәгән булдым. Янәмәсе, тиң түгел — укымаган. Шуннан ни булды инде? Барыбер сөйрәләм дә синең янына киләм.

Нурания. Үкенмә, Биккинин. Мин үкенмим. Сиңа үч итеп институтка укырга кердем. Менә укып йөрим. Картайган көнемдә. Ә син? Син бит? Син бит барыбер минем янда. Сөяркәң генә булсам да, син минем янда. Кем белә, хатын булуга караганда сөяркә булу бәлки әйбәтрәктер дә әле... Без икебез дә ике чабата бер кием, Илфат. Тик икебез дә бер аякныкылар. Карап торырга бар — кияргә юк.

Илфат. *(Тагын кычкырып көлеп.)* Сөйлә әле, Нурания, сөйлә. Син сөйләгәндә, миңа рәхәт. Валлаһи, рәхәт. Син, китәм, яшәмим, дип жыламыйсың, бер әйтеп бирәгәйле итәсең дә... Югыйсә, чәй куеп эчерә белмиләр, китәм дип ялындыралар. Тотам да синең янга күчеп киләм, Нурания.

Нурания. Күчеп килеп нишләрсең икән соң? Китәм дип ялындырып торырсыңмы?

Илфат. *(Көлеп.)* Үтерәсең, билләһи. Көл әле миңа кушылып, Нурания. Икәүләшеп, тәгәрәшеп көлешик әле. Дурак мин, әйеме?

Нурания. Кайсыбыз дураграктыр инде, кем белә.

Илфат. Мин дураграк. Юк, болай акыллы мин. Синең янда гына дурак. Сөяркәсе янында иң акыллы ир дә дуракка әйләнә, дигән бер китапта. Мин дураграк. Син һәрвакыт акыллы. Шуңа күрә, син бәхетсез.

Нурания. Әйтмә шул сүзеңне.

Илфат. Бәхетсез. Мин килгәнне көтеп утырып картаясың. Ә мин я киләм, я юк. Әйдә, танцевать итәбез.

Нурания. Кирәкми.

Илфат. Нигә?

Нурания. Син танцевать итә белмисең.

Илфат. Менә сиңа кирәк булса.

Нурания. Музыканың ритмын сизмисең син. Гомумән, син ритмсыз кеше.

Илфат. Ишетмәсәң ишет — этнең борыны тишек. Рәхәтләнеп танцевать итә идек ич.

Нурания. Биеп азапланганда син кысып кочаклыйсың — шунысы рәхәт иде.

Илфат. Бүген?

Нурания. Бүген кочаклашасым килми.

Илфат. Нигә?

Нурания. Сорама.

Илфат. Да-а-а... Әллә нинди көн булды бүген. Иртә таңнан бирле бөтенесе дә миңа каршы. Жылыйлар, бәйләнәләр, сүгәләр, упкәлиләр... Әллә ошамый башладыммы? Әйт. Мин теләнергә яратмыйм. Чыгармын да китәрмен, бүтән килмәм дә.

Нурания. Шулай итәрсең.

Илфат. Нурания! Син минем иң якын кешем — уйнама минем

белән. Мин, үзең әйтмешли, эгоист кеше. Эгоист кеше кактырып-суктырып сөйләгәнне яратмый. Әйт, ни булды?
Нурания. Бүген идарәдә ни сөйләп чыктың?
Илфат. Кайчан?
Нурания. Бүген дидем.
Илфат. Бүген, бүген... Аның сиңа ни кагылышы бар? Надия сенел кайтып бәйләнеп йөри...
Нурания. Бухгалтериядә — кызларга.
Илфат. Анда да кердем микәнни? *(Кычкырып көлеп җибәрә.)* Ә-ә-ә... Шуны әйтәсеңме?
Нурания. Нәрсәне?
Илфат. Чын ир кешенең бер аерган хатыны, бер законлы хатыны, өч-дүрт сөяркәсе булырга тиеш дигән идем. Шулмы?
Нурания. Мин ничәнчесе?
Илфат. Әллә көнләштеңме? Болай гына ич ул — кызлардан көлеп кенә.
Нурания. Шуннан?
Илфат. Нәрсә инде син? Ул печтрихалар белән тагын ни сөйләшим.
Нурания. Сөяркә нишли дә, хатын нишли?
Илфат. Ну, әйттем. Сөяркә көлеп каршы ала, хәлеңне сорашып тормый, кочагына сарыла дидем. Ә хатын сөяркә яныннан кайткан иренә: ятып ял ит, арыгансың дип кайгыра дидем. *(Нуранияның күзләрендә яшь күреп.)* Нигә инде син? Мин бит синең турыда әйтмәдем. Разрядка өчен. Җылама, күз яшен мин өйдә дә күреп туйган.
Нурания. Эх, Илфат, Илфат... Иптәш Биккинин. Син үзеңнең кем икәнеңне беләсеңме? Уйлыйсыңмы син аз гына башың белән? Сөяркә дә сөяркә. Теләсә кайда теләсә нәрсә сөйләнеп. Дөньяда син үзем генә яшим дип беләсеңме? Син бәлки үзеңне әллә кем дип саныйсыңдыр... Аңла, бәгырькәем, бик кызганыч кеше син. Мин үземне түгел, сине кызганып җылыйм. Харап булачаксың син, җан кисәгем.
Илфат. Интересно...
Нурания. Кыланма. Кылану сиңа килешми. Күпме әйтәм мин сиңа ул хакта, тыңламыйсың. *(Радиоланы кабыза.)* Кил әйдә, биибез.
Илфат. *(Үҗәтлек белән.)* Мин бии белмим, ритм юк миндә.
Нурания. Сабый... Кил. *(Бүлмә уртасында әкрен генә әйләнәләр, дөресрәге, Нурания Илфатны йөртә.)* Әллә нинди кешеләр сез. Нәселегез белән.
Илфат. Син безнең нәселне каян беләсең?
Нурания. Кызыксынсаң — беләсең. Мин дә бит шушы шәһәрдә туып үскән кыз. Ишетеп-күреп торам. *(Биеп сәхнә алдына килеп җиткәч, Илфатны туктата.)* Син аз гына булса да җитди була беләсеңме, Илфат?
Илфат. *(Ачуы чыгып.)* Син нәрсә мине?..
Нурания. Булды, булды, кызма. Мыскыл итәргә җыенмыйм. Мине җитди итеп тыңлый аласыңмы дим?
Илфат. Вәгазь укысаң, тыңламыйм. Туйган вәгазьләрдән.
Нурания. Аз гына түз.
Илфат. Йә, сөйлә, аз гына түзәм.
Нурания. Син карьера яратасың, дан яратасың...
Илфат. Нәрсә сез бүген барыгыз да?..
Нурания. Бүлдермә инде.
Илфат. Яратам, ну, яратам. Прицеп булып яшисем килми минем дөньяда. Алдан барасым килә, ерып барасым килә. Авырлыгына да чыдап, барысына да чыдап. Уйлап чыгардылар бер сүз, тыйнак бул. Минем тыйнак буласым килми. Скромность украшает тех людей, у кого нет других украшений. Мин нефть чыгарам. Мин — нефтяник! Белә-

сеңме кем ул бүген нефтяник? Кемне бүген, махсус самолетка утыртып, мең чакрым җиргә эшкә алып баралар һәм, рәхмәт әйтеп, кайтарып куялар? Мине, нефть чыгаручыны! Дөнья миңа карап тора.

Н у р а н и я. Купшы сүзләр болар, Илфат.

И л ф а т. Булсын. Тиешле урында лозунглар да кирәк.

Н у р а н и я. Син минем квартираны лозунглар кычкыра торган урын дип беләсеңме?

И л ф а т. Бикләп куймагыз мине квартираларыгызга, бәйләп куймагыз мине инструкцияләрегез белән. Мин нефть чыгарам. Илгә нефть кирәген белеп чыгарам. Кирәк икән данын да алам, кирәк икән выговорына да түзәм. Син мине бөтен яклап тиргә, тик карьера, дан дип нервыма тимә. Карьера артыннан кусам, хатынымны, баламны өйдә калдырып, сөяркә янына килмәс идем, безнең заман карьеристлары андый ахмаклыкны эшләмиләр.

Н у р а н и я. Җаның юк синең, Илфат. Ничек син?!.

И л ф а т. *(Бераз тынычланып.)* Авыр сүз ишетергә теләмәсәгез, кешене чиккә җиткермәгез, мәҗбүр итмәгез.

Н у р а н и я. Мин сиңа киңәш кенә бирмәкче идем.

И л ф а т. Киңәш бирүчеләр бик күбәйде: от министра до уборщицы.

Н у р а н и я. Әйтәсе сүземне барыбер әйтеп бетерәм, Илфат. Син Надир Рәхимович үстергәнгә үсенеп йөрисең. Күреп тор, шул Надир Рәхимович синең башыңа да җитәчәк. Ул синең белән уйный. Син, беркатлылыгың аркасында, сизмисең.

И л ф а т. Гайбәтегезне бухгалтериядә сөйләшегез.

Н у р а н и я. Мин әйтәсен әйттем, сау бул. *(Паузадан соң.)* Сау бул. Килмә дип әйтмим, барыбер киләчәксең. *(Ишектә звонок.)*

И л ф а т. Кем ул?

Н у р а н и я. Каян белим. *(Звонок кабатлана.)*

И л ф а т. Ничек инде белмисең? Үз ишегеңдәге звонокка кемнәр басканын беләсеңдер. Ач әле, карап карыйк әле, кем икән? *(Нурания барып ишекне ача. Зариф керә. Һич кенә дә аны көтмәгән Илфат югалып калган.)* Әти?

З а р и ф. *(Килеп Илфатның якасыннан эләктереп алып ишеккә сөйри. Бер сүз генә әйтеп куя.)* Дуңгыз!

И л ф а т. *(Ычкынырга теләп.)* Нишлисең син, ә? Әти!.. *(Зариф аны сөйрәп алып чыгып китә.)*

**П ә р д ә**

## Икенче пәрдә

Эфирда тавышларның көчәйгән чагы. Төрле телләрдә, төрле илләрдән. Бер тавыш өстенә икенчесе менә — барысы да кабатланалар, әйтеп калырга ашыгалар. Нефть дигән сүз еш әйтелә. Ә шул нефтьне чыгаручыларның икесе кабинетта утыралар. Биккинин Илфат һәм Рәхимов Надир.

Н а д и р. Менә, Илфат Зарипович, шундый хәлләр. Синең сеңелкәшең үз дигәнен эшләде. Абыйсының йөзенә шәп итеп кенә төкерде.

И л ф а т. Минем сеңел генә түгел иде комиссиядә.

Н а д и р. Ул күбрәк бәйләнде.

И л ф а т. Чепуха. Андый комиссияләрнең актларын күргән бар. Берләшмәдә ахмаклар утырмый. Нәрсәнең нәрсә икәнен алар бик яхшы аңлыйлар. Без планны арттырып үтәп барабыз. Калганы спишется.

Н а д и р. Карале, Илфат, син матуррак итеп утыр әле. Җәелгәнсең. Әйтерсең бу кабинетның хуҗасы мин түгел, ә син. Дөрес әйтәсең.

берләшмәдә ахмаклар утырмый, Илфат Зарипович. Шуңа күрә безгә җавап бирергә туры киләчәк. Мине бүген чакырып сөйләштеләр. Без синең белән дуслар, яшермичә әйтәм, миңа нык эләгәчәк.

Илфат. Выговормы?

Надир. Шәүкәт Садриевичның сөйләшүенә караганда, алай гына булмавы да мөмкин.

Илфат. Нәрсә эшләгән без ул кадәрле?

Надир. Бала булып утырма. Эшләнде. Актка язылганнарның берсенә дә каршы чыга алмадык.

Илфат. Без нефть бирдек.

Надир. Син нәрсә попугай шикелле һаман бер сүз кабатлыйсың?

Илфат. Ә син нигә кычкырасың?

Надир. Син түгел, сез, иптәш Биккинин.

Илфат. *(Кычкырып көлеп.)* Нишлисең соң син?

Надир. Нишлимме? Мине эштән алып ыргытачаклар. Ә минем ыргытыласым килми, аңладыңмы?

Илфат. *(Паузадан соң.)* Ләкин без бит нефть бирдек.

Надир. Уф... Нефтьне без технологик процессларны бозып бирдек, аңлыйсыңмы?

Илфат. Ләкин ансыз мөмкин түгел бүгенге көндә. Шунсыз планны үтәп булмый. Берләшмәдә аны белергә тиешләр.

Надир. Син бар да исбатла аларга.

Илфат. Исбатлармын да.

Надир. Илфат Зарипович, син промысел начальнигы гына. Син үзеңне зур шишка дип уйлыйсыңдыр. Берләшмә алдында җавапны мин тотачакмын. Син — минем алда. Кыскасы болай: Сезгә эштән китәргә туры киләчәк, Илфат Зарипович.

Илфат. Кая?

Надир. Урын табылыр. Нефть бездә генә чыкмый. Сезнең югары белемегез бар.

Илфат. Кыланмале. Мин беркая да китмим.

Надир. Үзегез китәргә теләмәсәгез, җибәрергә туры килер. Чөнки актта язылган фактларның күбесе Сезнең промыселда.

Илфат. *(Сикереп торып.)* Син нәрсә?..

Надир. Син түгел, Сез...

Илфат. Син мине уенчык дип белдеңме? Син миннән корбан тәкәсе ясамакчы буласыңмы?

Надир. Мин түгел, сеңелегез. Сеңелегез белән уртак тел таба алмаганга мин гаепле түгел.

Илфат. Нигә мин аның белән уртак тел табарга тиеш? Аның үз эше, минем үз эшем. Яхшылап сөйләшик, Надир, без дуслар.

Надир. Дуслык әшнәлеккә әйләнергә тиеш түгел. Мин Сезгә чара күрергә тиеш, Илфат Зарипович. Әйтеп килдем мин Сезгә.

Илфат. Нәрсә әйтеп килдең? Давай, Илфат, давай дипме?

Надир. Давайны төрлечә аңларга була. Бүтән промысelларга да әйттем мин, ләкин алар үзләренең бурычларын дөрес аңладылар, Сез...

Илфат. Әйтеп бетер...

Надир. Давай яхшы гына аерылышыйк, Илфат. Тавыш, шау-шусызгач, карарбыз. Үзең аңла, ул актта язылганнар өчен кемдер җавап бирергә тиеш. Мәсьәлә шулай тора. Син безнең дуслыкны дөрес аңламадың. Хатын-кызлар белән буталып, теләсә кайда теләсә ни сөйләп йөреп... Без бала-чагалар түгел. Ачуланма миңа, шулай тиеш.

Илфат. Менә ничек... Яхшы... Яхшы... Ләкин минем гаебем юк. Бәлки булгандыр да... Мин кәгазьгә язылган мәгънәсез инструкцияләргә буйсынмадым да дип... Ярый, этлек эшләдем ди. Димәк, син боларны күреп тордың? Ул-бу булса, читкә китеп, мине уртага төртеп чыгарырга син алдан ук әзер идең?

Надир. Тирәнгә кермик.

Илфат. Мин берләшмәгә барачакмын.

Надир. Файдасы булмаячак.

Илфат. Мин файда эзләмим. Миңа дөреслекне табарга кирәк.

Надир. Нинди дөреслек? Сеңелеңә сөйләгән әкиятне исеңә төшер, ахмак.

Илфат. Аны син сөйләдең.

Надир. Син нәтиҗә ясап куйдың. Базардагы хатыннар кебек сатулашмыйк, Илфат Зарипович.

Илфат. Әшәке кеше икәнсең син, Надир.

Надир. Син нәрсә, шома гына эштән китеп котылырга теләмисеңме? Статьялар белән кирәкме?

Илфат. Сылыйммы берне үзеңә?

Надир. Рәхим ит. Тик үтерерлек итеп сукма, үзеңә читен булыр.

Илфат. *(Кычкырып көлә дә, кинәт туктап, Надирга карап тора.)* Телефоннан шалтыратырга ярыймы?

Надир. Кая шалтыратасың?

Илфат. Курыкма.

Надир. Мин курыкмыйм.

Илфат. Куркасың. *(Телефоннан шалтыратып.)* Нюру дайте... Нурания?.. Мин бу... Син — гений, Нурания... *(Телефон трубкасын ташлый.)* Сау булыгыз, Надир Рәхимович. Мин промыселга киттем. Шома гына булмаячак. Җинаять эшләгәнмен икән, җәзасын да алырмын. *(Чыга-чыга.)* Мин беркайчан да... *(Аның тавышы эфирдагы тавышларга кушылып югала. Ут сүнеп-янып алганда, Шәүкәт Садриевич Газизов кабинетына керәбез. Газизов ялгызы, телефоннан сөйләшә.)*

Газизов. Безнең хәлләрме? Хәлләр — хәл, Анатолий Федорович. Кичә Казанда булган идем. *(Ишекне ачып караган Зарифка, кулы белән ишарәләп керергә куша.)* Гостиницада люкска урнаштым. Телевизорыгыз эшләми, дим. Нишләп эшләмәсен, эшли, тик күрсәтми генә ди. Эшлибез, Анатолий Федорович, тик күрсәткечләр генә әллә ни түгел. Беләбез. Мәскәү алдында оятка калганыбыз булмады. Үтәрбез. Планны сез үтәрлек итеп бирәсез бит. Бернинди дә ирония юк, Анатолий Федорович. Сезгә дә, безгә дә нефть кирәк, беләбез. Исән булыгыз. *(Трубканы куеп.)* Нигә басып торасың, Зариф, уз утыр. *(Урыныннан торып, Зариф янына килә. Кулын сузып күрешә.)* Нихәл, картаеп буламы?

Зариф. Таныйсыз икән әле.

Газизов. Сине дә танымагач, бер урамда үсеп.

Зариф. Ничә ел инде аңа. Күрешкән юк. Күчеп киткәнегездән бирле.

Газизов. Күрешеп булмый шул. Бөтереләбез дә бөтереләбез. Саттар абыйны мин еш күрәм. Сөйләшеп утыргалыйбыз.

Зариф. Ул шундый инде — куштан. Җитмәгән, кермәгән җире юк. Мин Сезнең янга килдем, иптәш Газизов.

Газизов. Газизовлап сөйләшмик әле, Зариф. Миңа уңайсыз.

Зариф. Аның каравы, миңа уңай. Ник дигәндә... Мин Сезнең янга замдиректор итеп килдем. Замдиректор булып тыңлагыз да.

Газизов. Тыңлыйм, Зариф туган. Туктале, тыңлый башлаганчы котлыйм әле үзеңне.

Зариф. Ник?

Газизов. Улың Рафаэль белән. Орден алган бит. Аның яшендә Хезмәт Кызыл Байрагы...

Зариф. Әллә кайчан инде ул. Минем сүзем аның турында түгел. Аңардан олысы турында. Берсен мактап, икенчесен таптамыйлар аны.

Газизов. Зариф туган, әйдәгез алай сөйләшмик.

Зариф. Мин бүтәнчә сөйләшә белмим, мин Сезнең кебек укыган кеше түгел, уйлаганым телемдә. Мин черный рабочий.

Газизов. Без, Зариф туган, олы кешеләр, әйдәгез бер-беребезгә сырт куймыйча гына, бер-беребезне мыскыл итмичә генә сөйләшик. Черный рабочий дигән булып мескенләнмә дә. Без барыбыз да үз эшебездә черный рабочийлар. Ни өчен килгәнеңне беләм бугай мин. Кайда йөри ул малаегыз?

Зариф. Бездә ята.

Газизов. Үзенең квартирасы юкмыни? *(Зариф дәшмәгәч.)* Нигә минем янга килми? Мин бит аны чакырттым.

Зариф. Хурланадыр. Хурланчык ул.

Газизов. Ул хурланчык. Ә без кем?.. Менә болай, Зариф туган, улыңның язмышы борчый икән, минем ярдәмем тияр дип уйлыйсың икән, монда килсен.

Зариф. Тыңлыймыни ул мине...

Газизов. Сине тыңламый, безне тыңламый. Хатыны җылап генераль директор янына килә. Генераль директорның эшен күз алдына китерәсеңме син, Зариф туган? Кылны кырыкка ярган вакытта бер хатын кабинетына бәреп керә дә ире өстеннән зарлана. Ул ир — синең малаең.

Зариф. Нишләтим инде аны...

Газизов. Ә без нишләтик? Ул идарәнең партия җыелышыннан демонстратив рәвештә ишекне бәреп чыгып китә. Нишләтсеннәр аны? Сүз аның ялгышлары турында бара, ул бөтен дөньяны гаепләп кычкыра, бөтен кешене намуссызлыкта гаепли. Нишләтик?

Зариф. *(Торып ишеккә таба бара.)* Ярый, хушыгыз.

Газизов. *(Аның каршына чыгып.)* Үпкәләдеңме, Зариф?

Зариф. Юк, нигә үпкәлим. Шулай инде, сез бүрекне кыңгыр салып сөйләшүчеләр. Безгә бөкрең чыкканчы эшләргә генә. Берәр әйбер сорасаң, тотыналар закон сөйләргә. Мин закон сөйләп тормыйм — эшлим дә эшлим.

Газизов. Зариф... *(Шул вакыт телефон шалтырый.)* Аз гына сабыр ит, зинһар. Казаннан шалтыратырга тиешләр иде. *(Телефон янына килеп трубканы ала.)* Тыңлыйм, Рөстәм Мостаевич... Генераль директор кайтып җитмәде шул әле. Кәефме? Безнең кәеф сезнең кәефкә карап йөри инде ул, Рөстәм Мостаевич. Планмы? Үтәргә кирәк булгач, үтәмичә нишлисең.

Карчык белән икебезгә алдык план:
Һәр малайдан иң кимендә өчәр олан.

Үзем яздым. Була, Рөстәм Мостаевич, башны җүләргә салган чаклар да була. Борчылмагыз, Рөстәм Мостаевич, Татарстан нефтьчеләренең әлегә сынатканнары юк. Монысын шаяртмыйча әйтәм. Рәхмәт. Исән булыгыз. *(Трубканы куйгач, борылып карый — Зариф чыгып киткән. Ишеккә килеп, ишекне ачып карый — анда Саттар. Ул солдат гимнастеркасыннан, орденнарын, медальләрен таккан, кулында транзистор.)*

Газизов. Саташаммы соң мин?

Саттар. Саташмыйсың син, Шәүкәт энекәш. Ярыймы шулай дип дәшергә? Ачуланмассың, күршедә уйнап үстек.

Газизов. Узыгыз, әйдә, Саттар абзый. Әле генә Зариф бирердә иде. Сабыр ит дидем.

Саттар. Чыгып китте ул. Исең китмәсен, пырлый торган гадәте бар. Көйсез хатын-кыз шикелле. Олыгайган саен хуҗылана. Нихәлләрдә соң?

Газизов. Сезнең хәер-фатихада, Саттар абзый. Форманы китергәнсез. Парадка чыккан кебек.

С а т т а р. Синең военный званиең ничек әле, күрше?

Г а з и з о в. Майордан узып булмады, Саттар абзый.

С а т т а р. Мин — солдат. Иң зур звание — солдат, дип әйтә иде безнең командир взвод Григорий Васильевич Родионов. Бер чакта да мин аның кәпрәйгәнен күрмәдем. Ул приказ бирми иде, надо дип кенә әйтә иде. Үлсәк үлә идек, аның надо дип әйткәнен үти идек.

Г а з и з о в. Сүзне ерактан башладыгыз, Саттар абзый.

С а т т а р. Ерактан башламаска. Син бит бу урында генерал армии белән бер. Зуррак булмаса. Шуңа күрә һәр солдатны күреп бетермәвең дә бар. Бу булды бер сүз — санап бар.

Г а з и з о в. Бу булды бер сүз.

С а т т а р. Икенчесе. Нефте дигән нәрсә, үзе тирәндә ятса да, хәйләкәр нәрсә. Я ул кешене кеше итә, я әрәм итә. Чөнки нефте мәртәбә дигән алдавыч нәрсәгә якын. Мәртәбә яратучылар шул нефте аркасында юкка чыгалар. Бу булды икенчесе.

Г а з и з о в. Бу булды икенчесе.

С а т т а р. Хәзер шуларны бергә кушыйк — нишләтәсең минем оныкны? Мин аны мактарга җыенмыйм, сезнең урында булсам, мин аны менә шушында сузып салып суктырыр идем. Бер яхшы ягы бар аның, Шәүкәт күрше, хәйләсез ул. Беләсең, безнең нәселебездә хәйләкәр кеше юк. Тимәгез сез аңа — эшләсен үз урынында. Үз урынында эшләп төзәлсен. Юк нәрсә белән вакытыңны алганга ачуланма. Минем өчен ул — онык, этисенә — малай, малаена — ата.

Г а з и з о в. *(Паузадан соң.)* Әй-е... Әйе, әйе, әбекәй, әйе, бара урамнан... Әкәмәт төш күрдем бүген төнлә, Саттар абзый. Суд залында утырам икән. Бер склад мөдирен хөкем итәләр. Әйбере артык чыкканмы шунда, әллә җитешмиме. Кыскасы, ничәдер ел бирделәр моңа. Шуннан склад мөдире нишләде дисезме? Кычкырып җырлап җибәрде. «Алмагачы» көенә. Җыры да хәтердә калды.

> Сберкнижкам җилгә очты
> Вклады-ние белән;
> Сау бул туган-үскән җирем —
> Складың-ниең белән.

Кызыкмы, Саттар абзый?

С а т т а р. Кызыгын кызык та...

Г а з и з о в. Сез гаҗәпләнмәгез, шулай ычкынып киткәлим мин. Килегез әле монда, Саттар абзый. *(Саттар тәрәзә янына килгәч.)* Дөнья матур, әйеме, Саттар абзый? Әнә бер кызый кибеттән чыгып килә, әнә бер бала колясkада йоклап ята. Әллә бар аңа нефть, әллә юк, исендә дә юк.

С а т т а р. Минем коляска ул.

Г а з и з о в. Ничек Сезнеке?

С а т т а р. Рауза апаң миңа тагып җибәрде. Җылый. Миннән башка кешене бар дип тә белми. Шул теге сабатажник малае.

Г а з и з о в. Алай. Взвод командирыгызны кем дидегез әле, Саттар абзый?

С а т т а р. Григорий Васильевич Родионов.

Г а з и з о в. Бу очракта минем урынымда Григорий Васильевич Родионов булса, ни дип әйтер иде?

С а т т а р. Если нужна для пабеды, зделаем, дядя Саттар, дияр иде.

Г а з и з о в. Если нужно для победы, сделаем, Саттар абзый.

С а т т а р. Миңа рәхмәт күрше. Тик эшли алмаслык булса...

Г а з и з о в. Григорий Васильевич Родионов күп сөйләргә яратмагандыр, Саттар абзый.

Саттар. Аңладым. Китәм, Шәүкәт энем. Син инде мине гаеп итмә. Солдат янына солдат килгән кебек килдем, соранып түгел. Аннан соң мин солдат кына да түгел, рабочий класс та. Рауза апаң көлә миннән, тик ул белеп көлми — надан ул. Сау бул, күрше. Әгәр дә мәгәр мин кирәк булсам, турыдан-туры әйт, нады, Саттар абзый, диген. Ышанмасаң сора, буровой конторда мине һаман да сагынып сөйлиләр. Бүген килсәң, бүген эшкә алам ди Николай Иванович Дунаев. Я, кулыңны бир дә, Шәүкәт энем...

Газизов. Исән булыгыз, Саттар абзый. Әйтегез ул малаегызга, килсен минем янга. Мин бит аны конвой белән китертә алмыйм. *(Саттарны озатып кала. Телефон шалтырый. Газизов телефон янына килә, трубканы ала. Тәрәзәгә карап сөйләшә.)* Әйе, тыңлыйм. Исәнмесез, Геннадий Александрович. Безнең эти элек ат җигә иде, Геннадий Александрович, ат белән Бөгелмәгә барып җитү өчен, Карабашта туктап, атны ашатып алырга кирәк дия иде. Югыйсә, Бөгелмәгә барып җиткәч, ашатуның мәгънәсе юк, ат эштән чыккан була, дип әйтә иде... Карабашта туктап алмыйбызмы, Геннадий Александрович? Аңлыйм. Аңлыйбыз. Әйе, без эшләми кем эшләсен. Йөз дә бер процент канәгатьләндерәме?.. Исән булыгыз, Геннадий Александрович. *(Трубканы куя да, ике кулын чалбар кесәсенә тыгып, тәрәзәдән карап торган килеш көйли.)*

Маржаларның исемнәре
Түтинкә дә мүтинкә —
Төнлә йөргән егетләрнең
Кесәсендә бүтилкә,—

дип әйтсәң дә ярый ди ара-тирә, башларың әйләнеп киткән чакларда.

*(Ут сүнә. Эфирда тавышлар. Андагы тавышларга эт өргән тавыш кушыла. Ул эт Илфат Биккининның эте икән. Ә Илфат үзе Казан янындагы бер кооператив бакчага каравылчы булып урнашкан икән. Әнә ул, сакал-мыекка батып, каравылчы өе янындагы сәкедә ята. Эт өргәләнеп өрә башлагач, торып утыра, капка ягына карый.)*

Нурания тавышы. Илфат! Илфат дим!

Илфат. Нәрсә кычкырасың, кер.

Нурания. Этеңне ал.

Илфат. Бәйдә ул.

Нурания. Килеп ал.

Илфат. Пират! *(Эткә кычкыра да, теләр-теләмәс кенә урыныннан торып, капка ягына китә. Аннан Нураниянe ияртеп керә. Кыяфәтенә караганда, ул Нураниянe көтмәгән һәм аның белән сөйләшәсе дә килми.)*

Нурания. Исәнләшик инде.

Илфат. Исәнме.

Нурания. Кулыңны бирергә теләмисеңме?

Илфат. *(Кулын сузып.)* Мә.

Нурания. *(Илфатның кулына, йөзенә карап торганнан соң.)* Кыргыйга әйләнгәнсең ич син. Кай арада?

Илфат. Үз асылына кайтыр өчен кешегә күп вакыт кирәкми. Кеше булып кыланыр өчен генә ул кеше гомере буе тырыша.

Нурания. Философка әйләнгән бераү. Әллә юынмыйсың дамы?

Илфат. Нигә килдең?

Нурания. Ничек таптың, дип сора иң элек. Интеккәннәремне белсәң. Кача белеп качкансың алай да...

Илфат. Бу дөньяда качып котылып буламыни.

Нурания. Шулай икәнен белгәч, нигә качтың соң?

Илфат. Мин качмадым — үземә лаеклы эш таптым.

Нурания. Эш? Ишеткәч шаккаттым. Бакча каравыллыйсыңмы?

Илфат. Ни гаебе бар?

Нурания. Югары белемле инженер.

Илфат. Бакча каравылчысы надан булырга тиеш дигән инструкция юк.

Нурания. Протестмы?

Илфат. Нинди протест?

Нурания. Имештер, миннән башка гына чыгарыгыз нефтьне. Ә мин бакча каравылларга ялланам.

Илфат. Анда синең ни эшең бар. *(Сәкегә йөзтүбән сузылып ята.)*

Нурания. Кояшта кызынып яту рәхәттер, ә? Миңа да бирәр эш юкмы?

Илфат. *(Торып утырып, ачу белән.)* Ник килдең?

Нурания. *(Көйләп.)* Алсуланып кояш чыга таң аткач,
Нихәл итим, сагындыра яраткач.

Илфат. Мин сагынмадым.

Нурания. Ялганлыйсың, кичә генә мине төштә күрдең.

Илфат. Искергән сөяркәләр төштә күрер өчен генә алар.

Нурания. *(Паузадан соң.)* Тапкыр сүз әйттем дип уйлыйсың инде син, әйеме? Шулай инде, искергән сөяркә — төштә күрер өчен, хатын — аерылып китәр өчен, бала — этиләргә ташлап калдыру өчен...

Илфат. Бар, кайтып кит.

Нурания. Җиңел генә котылмакчы икәнсең. Алай булмый ул, җанкисәгем. Шул чаклы азапланып эзләп тапкач, тиз генә китмим. Күрергә теләмәгәч, кертмиләр аны, этеңне бәйдән җибәреп талаттыралар.

Илфат. Хәзер дә соң түгел.

Нурания. Кем алды сине эшкә? Югары белемле икәнеңне беләләрме? Типсә тимер өзәрлек егет — бакча каравыллап ята.

Илфат. Инженерлар буа буарлык. Санитарлар белән каравылчылар җитешми.

Нурания. Күпме түлиләр инде?

Илфат. Сиңа да биреп тора алам.

Нурания. Малаеңа җибәр.

Илфат. Анысы синең эш түгел. *(Кычкырып.)* Беләсеңме, синең эш түгел!.. Синең эш түгел!..

Нурания. Элек кычкырып көлә идең, хәзер көлмичә генә кычкырырга өйрәнгәнсең. *(Як-ягына каранып.)* Матур урында икән бакчаларың. Шәп саклыйсыңмы соң, зарланмыйлармы бакча хуҗалары? Яхшылап сакла инде, алар сиңа хәләл акчаларын түлиләр. Чыннан да, Илфат, каян башыңа килде мондый уй? Синең характердагы кешеләр тормышта абынганнан соң я эчләшеп ныграк эшли башлыйлар, я эчәргә сабышалар. Син — бакча каравылларга...

Илфат. Кочаклашасың киләме?

Нурания. Кем белән?

Илфат. Бакча каравылчысы белән.

Нурания. Килә.

Илфат. Шуның өчен килдеңме?

Нурания. Шуның өчен.

Илфат. Алайса, кочаклаш та сыпырт моннан.

Нурания. Якынрак кил.

Илфат. *(Дурт аякланып Нурания каршына килә.)* Менә килдем. *(Нурания аны кочаклап алып сакалыннан, яңагыннан, маңгаеннан үбә. Пират шашынып өрергә тотына.)*

Нурания. *(Илфатны җибәреп, Пират ягына карый.)* Нигә өрәсең, кил син дә, сине дә үбәм. Бүген минем дүрт аяклыларны үбә торган көнем. Кил, кил, җаным. *(Эт өрүдән туктагач.)* Хуҗаңның яңагы-

на суга дип уйлагансыңдыр. Әйе, мин син уйлаганча эшләргә тиеш идем. Элекке заманның искергән сөяркәләре мондый очракларда шулай эшләгәннәр. Ләкин без бит бүгенге заман сөяркәләре, тупаслыкка күнеккәнбез.

Илфат. *(Дүрт аякланып Нурания каршына килгәндә чыннан да Нураниянең сугуын көткән, Нурания бүтәнчә эшләгәч, югалып калган. Ниһаять, исен җыеп.)* Гафу ит.

Нурания. Нигә инде...

Илфат. Зинһар, гафу ит.

Нурания. Беренче тапкыр гынамы...

Илфат. *(Шактый озак паузадан соң.)* Нурания... Эзләп тапкансың икән... Китмә син моннан.

Нурания. Нишләрмен соң монда?

Илфат. *(Паузадан соң.)* Ә бит чынлап та мин синең киләсеңне сиздем. Һәм төшемдә дә күрдем. Минем өчен болай бары син генә эшли аласың.

Нурания. Алай ук әйтмә инде, я жылатып җибәрерсең.

Илфат. Көлмә. Беләсеңме, монда рәхәт. Тыныч. Дөньяның ыгызыгысыннан читтә. Беркем белән талашырга кирәкми. Баштарак күрше авыл малайлары йортларга кергәлиләр иде, аларны да биздердем. Нигә кирәк булган институтта интегеп укып нефть, нефть дип чабып йөрергә? Сүгенергә һәм сүгелергә. Нефть чыкса ни дә, чыкмаса ни, кимесә ни дә, артса ни. Кеше борын-борын заманнардан бирле үзенә тынычлык эзли. Элек ичмасам монастырьлар булган. Кеше кергән дә, шунда бикләнеп, җанына тынычлык тапкан.

Нурания. Монастырьга сөяркәләр белән кертмәгәннәр.

Илфат. Сөяркәнең монда ни катнашы бар?

Нурания. Син бит миңа үз янында калырга кушасың.

Илфат. *(Элеккечә итеп кычкырып көлеп җибәрә дә кинәт туктый, җитдиләнә.)* Шулай да монда рәхәт. Машина үкерүеннән сискәнеп уянмыйсың. Сандугачлар сайрап уята.

Нурания. Сызылып таң ата, шәфәкъ алсулана, назланып кына кояш чыга, кич җитә, җем-җем итеп йолдызлар калка, урман артыннан ай күтәрелә, талгын гына җил исә... Партвзносыңны кая түлисең?

Илфат. *(Нураниягә текәлеп карап торып.)* Нәрсә син? Мин бит монда качып ятмыйм. Закон нигезендә. Официаль оешманың кооператив бакчасында.

Нурания. Юкка сине строгий выговор белән генә җибәрделәр. Сандугач сайравын тыңлап, монастырь турында уйлап яту өчен партбилетның кирәге юктыр.

Илфат. Тимә син минем билетка.

Нурания. Кызганыч, официаль оешманың җитәкчеләре синең белән кызыксынмаганнар. Йөрмә кыланып, Илфат. Үз-үзеңне алдап маташма. Сандугач үз тавышы белән сайраганга матур сайрый. Син үзең аңламаган уенны уйныйсың. Кайт үзебезгә. Беләсеңме, берләшмәдә сине Төмән ягында дип беләләр. Әйдә бераз өйрәнсен, дөнья күрсен, ди Шәүкәт Садриевич. Әгәр дә ул синең монда ятканыңны белсә...

Илфат. Белсә нишләтә? Институтлар бетереп, базарда ит чабалар, кемне кем нишләтә?

Нурания. Алайса мин үтенәм.

Илфат. Син зимагурлар җырын беләсеңме?

Нурания. Беләм. Зимагурлар бакча каравылламаганнар. Алар аптыраганнан буталып йөргәннәр, ә син...

Илфат. Юк инде, агай-эне, моннан кузгалдым юк. Миңа табигатьне сакла диделәр, мең саклыйм. *(Сәке өстенә аягүрә басып.)* Бер генә чия агачының, бер генә ботагын да сындырттырмыйм. Яшәсен табигать һәм аның матурлыгы. Ура-а-а! Яле, Пират! *(Бии башлый, Пират улый.)*

Ниһаять, мин үз ритмымны таптым. Ритмың юк дими Пират. Яле, Пират! *(Дүрт аякланып өрә башлый. Пират шатлана-шатлана аңа кушыла.)* Молодец, Пират. Мине аңлаган бердәнбер җан иясе. Нурания бар иде, ул да кирәкмәгән сүзләр сөйли башлады. Яратам ди, тик ни өчендер «ләкин» дигән сүз өстәп куя. Яратсаң, син мине ләкиннәрсез генә ярат. Ләкин белән мине барысы да ярата. Хәтта хатын да. Яратам, ләкин күп итеп акча тап, яратам, ләкин тун, импортный сәләмә, алтын йөзек, алтын алка алып бир, яратам, ләкин ашарыма пешереп ашат, яратам, ләкин бүген яныма ятма, ди. Бала табып бирәм, ләкин үзең кара. Югыйсә, китәм дә барам, ди. Кирәкми миңа ләкиннәр. Яратасыз икән — менә мин — шул килеш яратыгыз. *(Нуранияга текәлеп.)* Булдымы?

Н у р а н и я. Булды. Мин синең янында калам.

И л ф а т. *(Аптырап.)* Нәрсә-ә?

Н у р а н и я. Синең янында калам. Мәңгелеккә.

И л ф а т. Ничек инде?

Н у р а н и я. Шулай. *(Көйләп.)*

Игене дә игене...
Менә шушы була инде
Биккининнәр килене,
Алсуланып кояш чыга таң аткач,
Калам инде, нихәл итим яраткач.

Әллә курыктыңмы?

И л ф а т. Курыкмадым. Ләкин...

Н у р а н и я. Ләкинме? Нигә ләкинләнәсең?.. Эх син, калай этәч. Ярый, хуш, мин киттем.

И л ф а т. Киттем?

Н у р а н и я. Күрдем — җитәр. Табалмам дип борчылган идем.

И л ф а т. Бик аз булды түгелме соң? Нурания... Чүт кенә тор инде. Йөзгә хәтле санаганчы гына.

Н у р а н и я. Саный башла.

И л ф а т. Бер, ике, өч, дүрт... Нурания, бераз гына алдыңа ятып торыйм.

Н у р а н и я. Сонга калам, иртәгә эшкә.

И л ф а т. Аз гына. *(Нурания сәкегә утыра. Илфат аның алдына башын куеп ята.)* Ничек соң анда?

Н у р а н и я. Яхшы.

И л ф а т. Минем промысел ничек икән?

Н у р а н и я. Яхшы.

И л ф а т. Мин булмагач, технологик нормаларны бозучы юктыр инде. Мине искә алалармы?

Н у р а н и я. Алалар.

И л ф а т. Кемнәр?

Н у р а н и я. Мин һәм башкалардыр.

И л ф а т. Безнекеләрне күрәсеңме?

Н у р а н и я. Кемнәрне?

И л ф а т. Әти, дигәндәй. Бабай күренәдер, аның җитешмәгән җире юк.

Н у р а н и я. Күренә. Беркөн минем янга килгән иде.

И л ф а т. Нишләп йөри тагын?

Н у р а н и я. Эзләп тап, ди.

И л ф а т. Ни өчен сиңа?

Н у р а н и я. Белмим.

И л ф а т. Кеше кыланмаганны ул уйлап чыгара. Сагындым мин аны, сәлам әйт. Бәхәсләшергә кеше җитми монда. Надир эшлиме?

Н у р а н и я. Юк.

Илфат. Киттемени?

Нурания. Җибәрделәр. Кудылар... Кайт, Илфат.

Илфат. Мин анда кемгә кирәк.

Нурания. Ай алла... Нинди кеше соң син. Саттар бабай әйтә, Газизов белән сөйләштем ди, шул эшендә калдырырга күндердем ди. Шәүкәт Садриевич ничә тапкыр чакырткан.

Илфат. Нишләп ялынып йөрим. Эш беткәнмени дөньяда.

Нурания. Эш. Мин илгә нефть бирәм, кирәк икән данын да алам, кирәк икән выговорына да түзәм диюче кем булды икән ул.

Илфат. Йөз булды... Рәхмәт. Әйдә станциягә озатып куям. Мине монда күргәнеңне берәүгә дә әйтмә.

Нурания. Илфат.

Илфат. Дәшмә.

Нурания. Мәгънәсез уен уйныйсың, Илфат.

Илфат. Уенның мәгънәлесе булмый. Пират, апаны озатам, саубуллаш. *(Пират өрергә тотына. Ут сүнеп ала. Яңадан кабынганда, Пират һаман өрә. Сәхнәдә беркем юк. Зариф керә.)*

Зариф. *(Пиратка.)* Пшул. *(Сәкегә утыра. Кармак сапларын күтәреп, Илфат кайта.)*

Илфат. Әти? Синме соң бу?

Зариф. Әллә әтиеңне дә танымый башладыңмы?

Илфат. Ничек килдең? Кем алып килде сине?

Зариф. Әйдә, кайтабыз.

Илфат. Кем алып килде?

Зариф. Кайтасыңмы син, юкмы? *(Илфат капка янына йөгереп бара. Карана, анда Нуранияне күреп ала.)*

Илфат. Нәрсә, дуслаштыгызмыни? Нигә аны калдырып кердең?

Зариф. Әйдә, кайтабыз.

Илфат. Кая?

Зариф. Атаң башына.

Илфат. Килгәнсең икән, әйдә, өйгә керәбез, чәй куям.

Зариф. Зимагурның өе буламыни. Дәшми-дәшми торгач та, укыган дип тормам. Тапкан җайлы урын. Монда син йокы симертеп, без нефть чыгарыйкмы? Пенсиягә дә чыкмыйча.

Илфат. Чык, сине кем тота.

Зариф. Тота... Менә синең ишеләр. Барысы да җиңел эш эзли. Өйрәнделәр. Салагалар! Сиртмә койрыклар! Хәзер бөтен бакчаларын ут төртеп яндырам.

Илфат. Бакчаның ни гаебе бар.

Зариф. Ятмасыннар дуңгыз асрап.

Илфат. Монда дуңгыз асрамыйлар.

Зариф. Син дуңгыз түгелмени? Кайтасыңмы, юкмы?

Илфат. Юк.

Зариф. *(Сикереп торып, Илфат өстенә бара.)* Кайтасыңмы, юкмы диләр сиңа?

Илфат. *(Әтисенең сугарга дип күтәрелгән кулын тотып.)* Әкрен, әти.

Зариф. Көчең бар, ә?

Илфат. Бар. *(Зариф сәкегә килеп утыра. Пауза. Әтисенең күзләрендә яшь күреп, Илфат югалып кала.)* Әти!.. Нишлисең, әти?

Зариф. Җансызлар... Пәрәксезләр... Көне-төне эшләп укыттым. Кеше булсыннар дидем. Азапланмаган булсам. Балаларны ятим итмә дип үлде әнигез. Ятим итмәдем, ә менә үземне ятим калдырдылар. Әйткән сүзеңне дә ишетмиләр. *(Пауза.)*

Илфат. Әти... Минем аркада бөтен балаларыңны каһәрләмә.

Зариф. Бала үстерүне җиңел дип беләләрдер. Бер балаларын ка-

рый алмыйлар. Малаеңны бабаң карап үстерә. Кайт, квартираңны алалар. Хатының баланны, квартираңны ташлап ияреп китте.

Илфат. Ничек инде китте?

Зариф. Хуҗасыз эт теләсә кемгә ияреп китә ул. Якты чырай күрсәтүче генә булсын... Бабаң түшәк өстендә ята...

Илфат. Аңа ни булды?

Зариф. Ни булсын. Ул бит сезнең шикелле ике кулын кесәсенә тыгып шаталтриста йөрмәгән. Сезгә җиңел. Арт ягыгызга камыл кадалса, китәсез дә барасыз. Эзләп тә табып булмый. Ә без кая барыйк. Без эшләргә өйрәнгән. Эш сайлап йөрергә өйрәнмәгән, ни кушсалар, шуны эшләргә өйрәнгән. Кайт. Начальник итеп куймасалар, эш бетмәгән. Утыз өч ел эшлим — үлгәнем юк. Энекәшең дә начальник түгел, орденнар алып эшли. Безнең нәселгә начальник булу килешми дә ул. Бабаң әйтмешли, без рабочий халык. Кайт. Бабаң да әйтте, кайтсын, күреп каласым килә, диде.

Илфат. *(Паузадан соң.)* Әбигә Зөфәр белән авырдыр.

Зариф. Өйрәнгән инде... Бабаң янында кайнаша шунда малаең. Аягына баса башлады. Кайт, улым, ә?

Илфат. Улым? Беренче кат ишетәм синнән. Нураниягә монда алып килергә син куштыңмы?

Зариф. Бабаң... Ул чакырттырып алды... Иртәгә эшкә барасы бар бугай аның. Әйдә, соңгы самолетка өлгерик.

Илфат. Нигә монда кермәде Нурания?

Зариф. Каян белим. Без аның белән сөйләшмәдек. Күрсәтте дә, мин сезне монда көтәм, диде.

Илфат. Бар, көтеп арыгандыр.

Зариф. Ә син?.. *(Ут сүнә. Эфирдагы тавышлар безне нефть каласына алып кайта. Биккининнар ишегалды. Зариф гадәттәгечә беседка идәнендә утыра. Өйдән портфель тоткан Надия чыга.)*

Надия. Мин китәм инде, әти.

Зариф. Җидесен көтмисеңмени?

Надия. Мин бит эштә.

Зариф. Әбиең аякка басканчы өйне караштырып идең.

Надия. Мин өч кенә көнгә сорап кайттым. Мэнә отпуск алырмын да берничә көннән кайтып җитәрмен. Рафаэль дә отпуск алып кайтырмын, диде. Бергәләп күңелле дә булыр.

Зариф. Абыеңны көт, кайтып җитәр.

Надия. Вакытым юк, әти.

Зариф. Тикшеренеп йөрергә булса, вакыт табасың. Ярый, сау бул.

Надия. Әти... Без... Без... берәү белән минем отпуск вакытында... Аның да ялы... Без берәр җиргә барырбыз дигән идек... Монда кайтасы булгач... Әгәр дә ул да кайтырга риза булса... Кайтсынмы?

Зариф. Кем ул?

Надия. Без аның белән дуслар. Без ахры өйләнешербез.

Зариф. Өйләнешкәч кайтыр.

Надия. Сау бул, әти. Мин кайтырмын. *(Капкага таба атлый.)*

Зариф. Тукта. *(Надия туктагач, аның янына барып.)* Үзеңә карале, Син инде бала-чага түгел. Өй иркен. Киявенә дә, килененә дә урын җитәр. Исән-сау барып җит. Карап йөр юлда. *(Надияне капка ачып озатып кала. Машина килеп туктаган тавыш. Газизов белән Хәбәрче керәләр.)*

Газизов. Исәнме, Зариф.

Зариф. Саумысез.

Газизов. Мәнә синең янга килдек. Мәскәүдән килгән кунак. Мин әйткән кеше Зариф Саттарович Биккинин шул үзе була, Ревекка Львовна.

Хәбәрче. Рәхмәт. *(Зарифка кулын биреп күрешә.)* Исәнмесез.

З а р и ф. Узыгыз әйдә. Өйгә керегез дисәм...

Г а з и з о в. Без озак тормыйбыз, Зариф туган. Ревекка Львовна — газета корреспонденты. Ул синең белән сөйләшер, сорашыр. Кыскасы, ул сезнең турыда, ягъни Биккининнар турында газетага язарга тели.

З а р и ф. Мин нәрсә сөйлим. Беткәнмени бүтәннәр.

Х ә б ә р ч е. Сез борчылмагыз, Зариф Саттарович...

З а р и ф. Мин нәрсәгә борчылыйм. Сөйләшеп йөрергә вакытым да юк минем, сөйләшә дә белмим. Әти булса сөйләшер иде.

Х ә б ә р ч е. Сезнең семья нефтяниклар семьясы.

З а р и ф. Безнең шәһәрдә барысы да нефтяник. Бүтән эше булмагач, кая барсын.

Г а з и з о в. Киреләнмә инде, Зариф.

З а р и ф. Нигә мине мыскыл итеп кеше алып киләсең. Запаркка маймыл күрсәтергә килгән шикелле.

Г а з и з о в. *(Көлеп җибәреп.)* Ну и кеше син, Зариф туган. *(Хәбәрчегә.)* Сез, Ревекка Львовна, зинһар, гафу итегез. Сезгә кешенең характерын белү дә кирәктер. Бик үзсүзле нәсел бу. Принципиаль. Киреләнеп тә куялар. Ләкин бер нәрсә: болар — хезмәт кешеләре, болар хәйләли белмиләр. Кызганыч, Саттар абзый исән чакта күрмәдегез. Яраталар иде аны бездә. Хушлашырга янына бик күп кеше килде.

Х ә б ә р ч е. *(Зарифка.)* Кайгыгызны уртаклашам.

З а р и ф. Ярый... Мине гаеп итмәгез инде, аптырабрак торган чак. *(Илфат кайтып керә.)*

Г а з и з о в. Менә монысы Зариф Саттаровичның улы була инде. Шулай ук нефтяник.

И л ф а т. Исәнмесез.

Г а з и з о в. Гафу итегез, Ревекка Львовна, бер генә минутка... *(Илфатка.)* Кил әле монда. *(Илфатны култыклап, сәхнә алдына килә.)* Нихәл соң, сукбайулла?

И л ф а т. Яхшы.

Г а з и з о в. Яхшы? Синең хәлләр яхшы булгач, начары ничек була соң?

И л ф а т. Белмим.

Г а з и з о в. Син, агай-эне, минем белән сөйләшкәндә белеп сөйләш, ярыймы? Кайчан минем янга киләсең? Әллә, заявление язып, үзем синең каршыңа тезләнимме? Син үзеңнең кем икәнеңне һәм ни кылганыңны ахырынача төшенәсеңме? Мин оялам синең өчен. Мин дә, син дә шушы җирдә туып үскән кешеләр. Миңа сезнең һәрберегез кадерле. Аңлыйсыңмы, син миңа бик кадерле. Бик кадерле. Син өлкән абыеңның өметләрен аклау урынына... Син бит Биккининнар токымыннан. Ышанычлы токымнан. Бабаңа ышанып була иде, әтиеңә дә ышанып була, сиңа — юк. Аңлыйсыңмы, сиңа ышанып булмый. Безгә ышанычлы кешеләр елдан-ел кирәгрәк. Кырыйга сикерү буенча чемпионнар синнән башка да җитәрлек. Аңладыңмы?

И л ф а т. Аңладым.

Г а з и з о в. Нәрсә аңладың?

И л ф а т. Кырыйга сикерү буенча чемпионнар миннән башка да җитәрлек.

Г а з и з о в. Кил иртәгә минем янга. *(Зариф белән Хәбәрче янына килә.)* Кайчан очрашырга сөйләштегез, Ревекка Львовна? Иртәгә дип билгелик.

З а р и ф. Иртәгә мин эштә булам.

Х ә б ә р ч е. *(Зарифка.)* Кайсы сменада эшлисез?

З а р и ф. Иртән барам.

Х ә б ә р ч е. Мине дә үзегез белән алырсызмы?

З а р и ф. Пычрак анда.

Г а з и з о в. Ревекка Львовнаның нефть күргәне бар.

Х ә б ә р ч е. Димәк, иртәгә чаклы саубуллашып торабыз. Зариф Саттарович. Исән булыгыз.

З а р и ф. *(Газизовка.)* Капка төбеннән борылып китү уңайсыз бит... Чәй дә эчмичә.

Г а з и з о в. Борчылма диделәр сиңа. *(Илфатка.)* Ә мин сине көтәм... *(Китәләр.)*

З а р и ф. Кайда йөрдең?

И л ф а т. Йөрдем инде.

З а р и ф. Надия китте... Ул кияүгә чыгарга җыена ахрысы.

И л ф а т. Күптән вакыт.

З а р и ф. Инде нишлибез?

И л ф а т. Нишлибез дип. Мин Рафаэль белән сөйләшкән идем Аның янына китәргә.

З а р и ф. Ә мин? Ә без? Әбиең түшәк өстендә ята. Ә малаең?

И л ф а т. Баланы үзем белән алып китәргә була.

З а р и ф. Син аны чумадан дип белдеңме әллә? Әйтте бит Шәүкәт абыең, кил, диде. Монда эш беткәнме?

И л ф а т. Монда эшли алмыйм мин, оялам.

З а р и ф. Кемнән?

И л ф а т. Кешеләрдән.

З а р и ф. Эшнең ояты юк. Теге кемең белән арагыз ничек?

И л ф а т. Әйбәттер.

З а р и ф. Без тыйганда шунда яттың, хәзер әйбәттер генәмени?

И л ф а т. Ну, әйбәт инде, алайса, ул да минем белән китмәкче иде.

З а р и ф. Әтиеңнең ялынганын көтәсеңме?

И л ф а т. Нигә ялынырга.

З а р и ф. Җибәрәсем килми. Минем янымда да кеше кирәк. Утырып киңәшергә якын кешең дә булмагач. Мин дә китмәкче идем заманында, әти җибәрмәде. Монда тудың, монда үстең, үстергән җиреңне үпкәләтмә, диде. Мин аңладым, сез минем чаклы да аңламыйсыз.

И л ф а т. Я, ярый... китмәгән ич әле. Нәрсә, бабай турында язарга килгән мәллә?

З а р и ф. Аның турында да, минем турыда да. Шәүкәт абыең маташтыра. Минем турыда нәрсә язасың.

И л ф а т. Ә нигә? Син кемнән ким...

З а р и ф. Юкны сөйләп утырма.

И л ф а т. Без монда гына йоклап китәрбез. Мунча суынмады микән әле. Хәзер Зөфәрне дә үзем белән алып керәм.

З а р и ф. Аны Нәҗибә апаң юындырып чыкты бугай инде.

Н ә җ и б ә. *(Өйдән чыга.)* Илфат та кайткан икән. Рауза апа да, Зөфәр дә йокладылар. Ашарыгызга холодильникта, җылытырсыз. Илфат, син мунча сүрелгәнче кереп чык. Чиста сөлгеләрегез верандада, бауга эленгән.

И л ф а т. Рәхмәт, Нәҗибә апа. *(Өйгә кереп китә.)*

Н ә җ и б ә. *(Зариф янына килеп утырып.)* Менә бу турыдан капка ачарга кирәк. Әйләнеп йөрүе җайсыз... Чыраеңны җимереп карама, көченергә җыенмыйм, кереп-чыгып йөрергә, күз-колак булырга кирәк. Кеше ялламассың. Рауза апаның хәле әйбәттән түгел... Саттар абзыйга бигрәк матур көннәр туры килде. Көз ае димәссең. Карале бу кояшның җылылыгын... Зөфәрне анда-монда тарткалап йөрмәгез, әнә үстердем малаемны, берәүнекеннән дә ким түгел. Урнашканына кайчан гына, ике йөз тәңкә акча җибәргән. Моны да үстерербез. Нәҗибә дип кешеләр авыз ерсын. Нәҗибә кебек яшәп карасыннар әле. Алтын кебек бер ирләрен яманлап сөйлиләр. Мәнә дүрт зимагур туры килде, урамга чыгып кычкырмадым... Ник бер сүз дә дәшмисең?

З а р и ф. Син сөйлисең ич.

Нәҗибә. Отпускамны бетерми эшкә чыгарганнар иде, калган отпускамны алдым. Тартынып торма, тот та кычкыр, кереп житәрмен.

Зариф. Кычкырмасам да кереп житәсең син.

Нәҗибә. Алай димә, Зариф абый. Ничек җырлыйлар әле:

Бишмәт кигән — биш кат кигән,
Алай да тирләмәгән,
Сездә булган тәкәбберлек
Бездә дә чирләмәгән.

Мин, Зариф абый, гомерем буйларына падручком йөргән ир белән хатынга кызыгып яшәдем. Миңа өйләнгән булсаң, падручком йөрткән булыр идең микән?

Зариф. Юк сүз сөйләп ничек туймыйсың?

Нәҗибә. Нәҗибә диген.

Зариф. Нәрсә?

Нәҗибә. Юк сүз сөйләп ничек туймыйсың, Нәҗибә, диген. *(Зарифның ирексездән елмайганын күреп.)* Ходаем, елмайды. Белеп елмайдыңмы, Зариф абый?

Зариф. Бар, чык өеңә.

Нәҗибә. Эшкә кия торган киемнәрең юып куелган. Лапаста эленеп тора. Ярый, мин чыгыйм инде, Зариф абый, кеше әллә ни уйлар. *(Ләкин чыгып китәргә уйламый да.)*

Илфат. *(Өйдән чыгып.)* Әти, сиңа начальнигың Хафизов шалтыратты.

Зариф. Мансурмы? Ни булган?

Илфат. Эшкә чакыра. Бүген чыга алмас микән ди.

Нәҗибә. Чыга алмас диген. Таптылар йомшак икмәк. Аңа өч көн ял бирелгән, беркая да бармый.

Илфат. Бик кирәк, ди. Мин аңа бара, дип җавап бирдем.

Нәҗибә. Нишләп син әтиең өчен җавап бирәсең әле. Үз теле юкмыни?

Илфат. Беләм ич инде мин аны. Сүгенә, зарлана да барыбер бара.

Нәҗибә. Бу юлы бармас. Ике аягыңның берсен дә атлама, Зариф абый.

Илфат. Хафизов үтенеп сорады.

Нәҗибә. Үтенеп сораган саен...

Зариф. *(Нәҗибәгә.)* Тик тор. Синең эшең юк анда.

Нәҗибә. Мин болай гына, Зариф абый. Киемнәреңне алып килимме?

Зариф. *(Илфатка.)* Минем белән барасыңмы?

Илфат. Миңа анда ни калган?

Зариф. Мансур юкка гына чакырмагандыр. Син инженер. Миңа иптәш тә булырсың.

Илфат. Иптәш?.. *(Кычкырып көлеп җибәрә. Аның көлүенә эфирдагы тавышлар кушыла. Төрле иләрдән, төрле телләрдә соңгы хәбәрләр. Нефть дигән сүз еш әйтелә.)*

Пәрдә

Гомәр Бәширов



# БИБЕК НИГӘ ЕЛЫЙ

хикәя

## Шомлы хәбәр

Тыныч кына эшләп утырганда, кинәт телефон чылтырады. Каяндыр автоматтан чылтыраталар иде булса кирәк, бик начар ишетелә иде. Азаплана торгач, телефон трубкасына ниндидер малай тавышы килеп керде:

— Абый, синме бу?— диде ул.

Мин әчемнән генә көлеп куйдым. Шулай да:

— Әйе, мин бу, мин!— дип җавап бирергә туры килде.

Нидер шытырдады, җулап торды да, теге малай тавышы тагын:

— Абый, монда кил әле!— диде.

Тавышына караганда, ул шаяртмый иде булса кирәк. Күрәсең, кайдадыр нидер булган. Мин телефоннан:

— Кая соң ул «монда?»— дип сорадым.

Бераз тынып торганнан соң әлеге малай тавышы:

— Кая дип... беләсең ич инде, Аккош күлендә!— диде.

Тавышыннан чамалаганда, язучыларның Аккош күлендәге иҗат йортлары тирәсендә яшәүче таныш малайларның берсе булырга тиеш иде бу. Ләкин мин аның исемен хәтерли алмадым.

— Кем соң син? Мин нигә кирәк булдым? — дип сорадым.

Трубкада һаман нидер шытырдый, сызгыра, чыелдап куя иде. Шул шау-шу арасында әлеге малай бәлки исемен дә әйткәндер. Ләкин мин аның бер-ике сүзен генә ишетеп калдым:

— ... Муйнакны дим, муйнакны! Кузгала да алмый. Харап иттеләр!.. Абый, килми калма, яме!

Телефон шунда өзелде. Баланың ачынып әйткән сүзләре мине борчуга салды. Муйнак дигәне безнең Аккош күлендәге иң ягымлы, иң яраткан дус этебез иде. Ни булды икән аңа? Кем харап иткән? Ни сәбәпле? Шуның өстенә, әлеге малайның еларга җитеп минем килүемне үтенүе уйга калдырды. Хәл аянычбулмаса, ул бала шулкадәр борчылып идеме, унбиш километр ераклыктан ярдәмгә чакырыр идеме? Бәлки ул кечкенә кеше өчен бу зур фаҗигадер? Шундый чакта, каты бәгырьле булып, гозерен кире каксаң, бала күңелендә ул төзәлмәстәй яра

булып калуы да мөмкин. Әшем күп булса да, бармыйча ярамый дигән уйга килеп, юлга чыктым.

Трамвайда һәрвакыттагыча кеше күп иде. Ял көне булганлыктан, киенеп-ясанып, бала-чага ияртеп, каядыр баралар, каяндыр кайтып киләләр. Сөйләшәләр, көлешәләр. Ә минем күз алдымда — һаман Муйнак. Я мин аның мөлдерәп торган саргылт күзләрен күрәм, я ул, куанычыннан нишләргә белмичә сикергәләп, каршыма чабып килә...

Беренче мәртәбә мин аны узган ел менә хәзерге шикелле үк язгы сулар кузгалган көннәрдә, урман юлында очраткан идем. Тузгак чәчле, озын сыйраклы бер яшүсмер аны чәнәшкәгә[1] җигеп, шуңа утырган да үзен тарттыра иде. Кар, изелеп, боламыкка әверелгән, юлдагы бозлар ватылгалап беткән, чәнәшкә шуа алмый иде. Муйнак, мескен, чәнәшкәне кузгата алмыйча, пычракка тезләнә, чиный, аның аяк бармаклары канаган. Ә теге малай аны чаж-чож чыбык белән кыйный иде.

Тузгак чәчлене мин күргәч үк танырдым. Белмим, шундый рәхимсезлек аңа каян килгәндер, әмма ул миңа һәркайчан нинди дә булса берәр бозыклык эшләгәндә очрый торган иде. Я ул үсеп утырган агачларга, куакларга балта белән чапкалап йөри, я кырмыска өемнәрен, кош ояларын актарып ташлый. Узган җәй ул азгынлыгын тагын да арттырды. Күршеләре аннан җиләк урлый дип, күз карасыдай күреп тәрбияләп үстергән чәчәкләребезне утап чыга дип, зарлана башладылар.

Мин ул юньсезне бабасы белән бергә бик каты орышкан идем. Үзем Муйнакның тамагын туйдырып, яраларын дәваладым да Казанга кайтып киттем. Әмма Муйнак кайсы ягы белән булса да тегеләйме, болаймы Казанда да һаман искә төшкәләп торды.

Менә һавалар тагын да җылыта төшеп, урман юллары кардан-боздан да арчылды, җәй уздыру өчен Аккош күленә чыгар көннәр дә җитте.

Муйнак белән очрашуны мин кызыксынып көттем. Ничек икән ул җәнлекнең хәтере? Онытмы икән, әллә берәр нәрсә хәтерлиме?

Муйнак мине ерактан ук төсмерләде. Мине күрүгә, куанычын эченә сыйдыра алмыйча, дулкынланып өреп җибәрде, аннары, чиный-чиный, дүрт аяклап туптай сикерергә кереште. Тагын да якыная төшкәч, җирдән мүкәләп килде дә алгы аяклары белән балтырымны кочып алды. Ни гаҗәептер, ул миннән һич ятсынмый иде. Аның йөзендә, күзләрендә шундый тирән шатлык балкыды ки, әйтерсең, аның белән без гомерлек дуслар, әйтерсең, шушы бер-ике атна эчендә ул бары тик мине көтеп, мине сагынып кына яшәгән. Шул теләгенә ирешү шатлыгыннан менә хәзер нишләргә белмичә бер алдыма, бер артыма төшеп әйләнәмдә бөтерелергә тотынды.

Җәмәгатем Кәримә безнең шушылай сагынышып очрашуыбызны карап торды да:

— Шушымы инде теге акыллы дигән этең? — диде.

— Әйе. Нигә? Сиңа ошамыймы әллә? — дидем.

— Ошавын ошый да... Шулай да күрер күзгә әлләни ис китәрлек үк түгел икән димәсәң... Ни Сарбай, ни Акбай дигәндәй.

Дөрес, төсе-бите, тышкы кыяфәте ягыннан Муйнак чыннан да күккә чөеп мактарлык ук түгел иде. Табигать кием-салым өләшкәндә, Муйнак, күрәсең, кая да булса биләмдә йөреп матур туннан колак каккандыр, аңа ак та, ачык сары да булмаган агач көле төслерәк соры тун гына эләккән. Аның бу килбәте табигатьнең үзенә дә бик үк ошап җитмәгән булса кирәк, исемасам күзгә ташланырлык бер урыны булсын дигәндәй, ул соңыннан аның муенына, очлары түшенә асылынып торырлык итеп, ап-ак шарф салган. Шулай да минем Муйнакка тел-теш тидерәсем килмәде.

---

[1] Чәнәшкә — кечкенә балалар чанасы.

— Син Казан урамнарында очраткан тәкәббер овчаркаларны, нечкә билле бурзайларны, кәкре аяклы бүлмә көчекләрен генә эткә саныйсың ахрысы!— дидем.

Кәримә, көлеп, кулын гына селтәде.

— Кая инде моны алар белән чагыштыру!..

Мин һаман да Муйнакны якладым.

— Шулай инде анысы, моның муенында каешы, күкрәгендә медальләре дә юк. Ул нибары урам эте генә. Аның исемен дә малайлар гына кушкан.

— Күренеп үк тора...

— Шулай да мин Муйнакны бүлмә этләренең унысына да алыштырмас идем!

Кәримә иңбашларын селкетеп:

— Белмим, кайсы ягы белән сихерләгәндер сине бу нәмәрсә!— диде.

«Нәмәрсә», имеш! Тагын ни кирәктер аңа, менә дигән эт ләбаса! Үзенең яманатын сатканны аңлагандай, Муйнак, Кәримәгә кырын карап, шыпырт кына миңа килеп сыенды.

— Беләсең килсә, синең ул тәти этләрең, кеше ашатмаса, ачтан үләләр! Ә урам эте, беләсеңме, нинди әрсез, нинди чыныккан! Ул теләсә кайда үзенә ризык таба, теләсә нинди кыенлыкларга да түзә. Тик без аларның кадерен генә белмибез!

Кәримәнең һаман да бирешәсе килми иде:

— Синеңчә, ул алтын медальләрне төчкергән өчен генә таккан булалар инде алайса, әйеме?

— Юк, аның өчен түгел. Ул ялтыравыклы медальләрне бер эткә танавы җәенкерәк, икенчесенә, киресенчә, танавы таррак булган өчен, бер ишесенә койрыгы бер сантиметрга озынрак, икенче төренә нәкъ бер сантиметрга кыскарак булган өчен тагалар...

— Алай үртәмәскәе, дөнья иркен, тормышта һәркайсының үз урыннары бар.

— Дөрес, андый этләр дә яшәргә хаклы, алар да табигать баласы.

— Шулай булгач...

— Тик, беләсеңме, мин нәрсәгә каршы? Бүлмә этләре белән чамадан тыш мавыгып китүгә, кешене эт белән алмаштыруга!

— Әле андыйлар да буламыни?

— Бар ләбаса шул! Кайберәүләрнең кешедән җаны бизә дә, ул эткә табына башлый. Табигатьне яратудан түгел, кешегә үч итүдән! Аларча кеше начар, кеше явыз, ә эт кешедән яхшырак, этнең кешегә явызлыгы тими, ул яхшылыкның кадерен белә, дип уйлый ул. Ифрат та зарарлы караш бу — кешене эт белән алыштыру!

— Андый бәндәләр күп түгелдер лә!

— Күп булмаса да, бар. Эрмитаж бакчасында миңа очраган хатын, минемчә, нәкъ әнә шундыйларның берсе. Аның зур гына эте ырылдап минем өстемә ташлангач, мин ул хатынга: «Тыегыз этегезне!»— дип кычкырдым. Син инде ул хатын гафу үтенгәндер дип уйлыйсыңдыр, әйеме?

— Соң, юньле хатын булса...

— Киресенчә, ул мине сүгеп ташлады! «Сез үзегез гаепле! Нигә селкенеп Рексны раздражать итәсез?! Тик торыгыз! Кыймылдамагыз!» диде. Беләсеңме нәрсә дигән сүз бу?! Тын урында ял итәргә, саф һава суларга чыккан кеше, аның этенең капризына буйсынып, арестант шикелле үрә катып торырга тиеш икән!

— Күңелсез булган икән шул,— диде Кәримә. Ул, Муйнакка карап, нидер уйлап алды.— Ә бу этең андый капризлы булмас, эшлекле булыр димәкче инде син?

— Урам эте холкы белән дә бөтенләй башка! Өйрәтүеңә дә карый

Кирәк чагында ул — аучы, кирәк булса — сакчы. Өйрәтсәң, ул бөтенесен булдыра. Карама беләккә, кара йөрәккә!

Муйнак, үзе турында сүз барганны аңлагандай, әле беребезгә, әле икенчебезгә карап ала, үз исемен ишеткәндә койрыгын селкетеп куя иде.

— Ярар, күреп карыйк,— диде Кәримә.



## Муйнакның җан дусты

Кирәк-яракны төяп, Аккош күленә даими торырга барган көнне Муйнак тагын бер ягы белән хәйран калдырды.

Бу юлы да ул безне капка төбенә үк чыгып шатлыгыннан сикерәсикерә каршы алды. Әмма яши торган өебезгә кереп өс-башны алыштырган арада, ул — син күр дә, мин күр!— кинәт нәрсәдер исенә төшкәндәй, кабаланып чыкты да чапты. Койма астыннан чыкканда, без аның тузгак койрыгын гына күреп калдык. Бу безне гаҗәпкә калдырды. Ничек була инде бу? Сагынып каршы алды, килүебезгә куанды, ә үзе...

Бу хәлгә ризасызлыгын белдереп, Кәримә:

— Менә синең мактаулы этең! Ичмасам үзенә дип алып килгән күчтәнәчләрдән дә авыз итмәде, китте дә барды!— диде.

Бу дорфалык аңа һич килешмәсә дә, мин Муйнакның гайбәтен сатарга теләмәдем.

— Ярар, үзе белә торгандыр,— дип кенә бетердем.

Кайчан нишләргә кирәген чыннан да белә икән Муйнак! Ун-унбиш минут үттеме икән, юкмы икән, яңадан баскыч төбенә чыксак — менә сиңа тамаша!— Муйнагыбыз кунак алып кайткан икән ләбаса! Гәүдәгә Муйнакның үзе кадәрлерәк булыр, сөйкемле генә бер Сарбай. Муйнак шуның белән янәшә каршыбызга килеп баскан да, койрыгын болгый-болгый, күзләрен елтыратып, әле миңа, әле Кәримәгә карый, нидидер бик җитди бер хәлне аңлатырга теләгәндәй, өзек-өзек кенә өреп тә куйгалый. Шушы әкәмәтне күзәтеп тора торгач, Кәримә бот чабып көлеп җибәрде.

— Аһ алла! Аңламый да торам, җан дустын алып кайткан икән ләбаса, хәзергечә әйткәндә, тормыш иптәшен! Күрмисеңмени? Бу бит аның: «Менә, таныш булыгыз, моны да мине яраткан шикелле яратыгыз!» дию инде.

Эшләр болай зурга киткәч, Муйнакның бу үтенечен игътибарсыз калдыру тупаслык булыр иде. Мин Сарбайның каршысына чүгәләп кулымны суздым.

— Әһә, шулай укмыни әле? Әйдә алайса, бир тәпиеңне, таныш булыйк!— дидем.

Тик Сарбай-килен оялчанрак булып чыкты. «Әйем лә! Беренче очрашуда ук кул биреп күрешергә әллә!..» дигәндәй, кыюсыз балалар сыман, күзләрен яшереп, башын читкә борды. Муйнак исә, үзенең төшеп калганнардан түгел икәнлеген монда да күрсәтте: Сарбай алдына чыкты да, авызын ерып масайган кыяфәт белән тәпиен сузды. Билгеле, монда бераз көнчелек тә бар иде. Мин аның кулын кысып мактап алдым:

— Менә шулай! Егет кеше кыю булырга тиеш!— дидем.

Сарбай да гомерен арлы-бирле тегендә-монда уздыручы билгемче эт кенә түгел икән. Баштан ук шуны сиздерде. Үзе яши торган пионер лагеренда, күрәсең, ашыгыч эшләре булгандыр, ул кирәгеннән артык юанмады. Безнең белән танышып, Муйнакка дип алып барган күчтәнәчләрне икесе янәшә ятып «ялтыратып» куйганнан соң, Сарбай

шул ук урман сукмагыннан өенә кайтып китте. Муйнак исә шул көннән башлап үзе теләп өстенә алган төп хезмәтенә керешге.

Билгеле, Муйнакка беркем дә эш кушмады, беркем, бернәрсәгә өйрәтмәде, ул һәммәсенә үзе белеп кереште. Искитмәле бит: «Яхшылыкка яхшылык белән кайтарырга кирәк» дигән әхлак кагыйдәсен ул каян белә? Турысын гына әйткәндә, аны бит әле кешеләрнең дә байтагысы аңлап җиткерми, я аңларга теләми. Ә ул аңлый, әле ничек кенә аңлый! Бүгеннән башлап бу йорттагы кешеләрнең иминлеге — бөтенләе белән аның өстендә! Караңгы төшүгә, ул тышкы ишеккә аркасын куеп килеп ята да төн буе ник кенә шуннан китсен! Кайбер төннәрне кинәт давыл куба, биек агачлар егылырдай булып чайкала башлый, урман үкерә, бөтен дөньяны гөрселдәтеп күк күкри, чатырдатып яшен яшьнәп җибәрә. Ләкин нинди генә гарасат купмасын, Муйнак беркайчан да саклаган урынын ташлап китми иде.

Тик кайбер төннәрне генә, бик кирәк булганда гына ишек төбеннән кузгала ул. Кайчагында ихата эченә төлке-мазар яки бүтән урман киеге керергә чамалап карый, я булмаса, күлгә су эчәргә төшешли койма янына пошилар килеп туктый. Андый чакта Муйнак сырт йоннарын кабартып, тешләрен ыржайтып, өермәдәй, дошманнар өстенә ташлана. Җитәме көче, җитмиме,— анысы белән исәпләшми Муйнак. Кирәк икән, ул җанын фида кылырга әзер!

Көн тудымы, Муйнак тагын да сакта. Мин верандада язып утырам, ә ул, ян тәрәзә каршысындагы өстәлгә менеп, башын алгы аяклары өстенә сала да акыллы күзләре белән минем эшләвемне карап ята. Әгәр бу аның бүтән эше булмаганлыктан, ялкауланып ятуы гына дип уйласаң, бик нык ялгышкан буласың. Һич алай түгел. Ярык кына булып күренгән шул кысык күзләре белән ул һәммәсен күреп, белеп, «мыегына чорнап» ята. Тора-бара хәтта ул минем нишләвемне дә, көннәр буе өстәл янында утыручы бу кешене борчырга ярамаганны да аңлый кебек тоела башлады. Шушы кайгыртуын чамадан арттырып җибәрүе нәтиҗәсендә көлкегә калган чаклары да булгалады. Верандадан беренче мәртәбә радио тавышы ишеткәндә булды бу хәл: радиоалгычны борып җибәрүем булды, Муйнак верандада ят ир тавышы ишетелүгә әсәрләнеп сикереп торды да бик яман ырылдый башлады. Әлеге ят кешене алай гына күрә алмагач, аны куып чыгару нияте белән булса кирәк, веранда ишегенә ташланды. Алай да булмагач, арт аякларына басып, күзләрен утландырып, әлеге тавыш иясен веранда эченнән эзли башлады. Муйнакның һич башына сыймый иде: ишектән күзен дә алмыйча саклый торып, ничек килеп кергән ул ят кеше верандага! Хурлык бит, хурлык! Ахыр чиктә, верандага Муйнакның үзен кертеп чыгармыйча булмады.

— Әйдә, үз күзең белән күреп чык, беркем дә юк лабаса!— дидем мин аңа.

Муйнак атылып килеп керде дә шаккатып ишек янында туктап калды. Әлеге ят ир тавышы ниндидер кара тартмадан гына чыга икән бит! Ул үзенең, юкка тавыш чыгарып, оятка калуына уңайсызлангандай, башын иеп, арты белән чигенә-чигенә кире чыгып китте.

Ни гаҗәптер, Муйнак иҗат йорты ишегалдында шауларга ярамаганны да чамалый иде булса кирәк. Урамдагы этләр нинди генә шаушу кубармасыннар, безнең йортлар тирәсендә аның тавышланганы булмады. Ул мондагы тормышка тиз ияләшеп, тәмам «үз кеше» булып яши башлады. Иҗат йортында яшәүчеләрнең олысыннан кечесенә кадәр һәммәсе аның белеше — әшнәсе иде. Җае килгәндә ул аларның да хәлләрен белеп әйләнә, бакча казуларын, яшелчә утыртуларын, гөлләренә су сибүләрен карап йөри, Казанга барырга җыеналар икән, кешесенә карап астагы үзәнгә тикле озатып та кайткалый.

Җәй башындарак безне әйләндереп алган урманда берөзлексез

кошлар сайрый, йортларга авардай булып торган имәннең иң биек ботагында тирбәлә-тирбәлә күке кычкыра. Муйнак аларга да колак сала, сыңар күзе белән генә аларны да күреп ята. Кайчакларда хәтта күкенең тавышын хуп күргәндәй башын кыңгырайтып аңа яратып та карап куйгалый. Әгәр дә ишек алдына саескан килеп төшә икән, аңа көн юк инде! Шул сөйкемсез кыркылдап тавыш чыгара башладымы, Муйнакның җеннәре чыга, ул яткан җиреннән уктай атылып китә дә теге пырдымсызны «эһ» дигәнче куып та җибәрә.

Хәзер инде Муйнак элекке шикелле үзен теләсә кемнән җәберләттерми, урам этләре белән дә бик алай вакланмый. Чөнки аның хәзер сыеныр урыны, арка таянычы, дус-ишләре бар. Ул үзенең дәрәҗәсен, тормышның ямен, тәмен белеп, үз дигәнчә яши башлаган иде.



## Эт — эт кенә түгел

Тора-бара Муйнак Кәримәгә дә ошап китте.

— Акыллы җан булырга ошый бит әле бу эт,— диде ул.

«Эт» дию бу юлы ничектер колагымны рәнҗетте. Каршыбызда чирәмдә яткан Муйнак, кем сүз әйтсә, шуңа карый, башын бер болайга, бер тегеләйгә кыйшайтып, колагын бер торгызып, бер салпыландырып, без әйткәннәрне аңларга тырышкандай күренә. Шунлыктан без икәү генә түгел, өчәү сөйләшәбез кебек тоела иде.

— Әйтсәм әйтим, эт дигән исем шул хәтле пычранган, Муйнакны «эт» дип атарга хәтта телем бармый,— дидем.

Кәримә икеләнебрәк калды.

— Шулаен шулайдыр да... Тик эткә карашны син генә үзгәртә алмыйсың бит инде. Үзең дә беләсең, иң әшәке кешене «эт син, эт!» дип сүгәләр. «Аргы якта алабай, бирге якта ялагай» дип тә яманатын саталар. Нишлисең бит...

Бу әйтелгәннәрнең халык мәкальләре булуын да беләм. Шулай да Кәримәнең сүзен «нишлисең бит» дип очлап куюы миңа ошамады.

— Кычкырып торган гаделсезлек бит бу!— дидем.

— Халык телендә шулай йөри дип әйтүем...

— Халык арасында да төрле кеше бар. Сай башлы кешеләр телендә дисәң, тагын бер хәл! Үзләрендәге начар сыйфатларны әнә шундый кешеләр эткә сылаганнар да инде!

Кәримә, Муйнакка карап, беравык уйланып утырды.

— Булса да булыр. Телевизорда галимнәр әйтте шикелле: этләр акыл дәрәҗәсе ягыннан дельфинар, атлар белән бер баскычтарак торалар ди түгелме соң?

— Менә монысы, ичмасам, сүз! Бактың исә, эт ул кыргый хайваннардан кешегә иң беренче булып ияләнгәне. Ул кырык-илле мең елдан бирле кешенең иң тугрылыклы, иң ышанычлы иптәше, мин әйтер идем, хәтта иң якын дусты! Менә безнең Муйнак та шундый!

Үз исемен ишетүгә, Муйнакның күзләрендә нидер кабынып алды. Ул хәзерге заман хатын-кызларының модный сапожкие төсле ялтырап торган кап-кара танавын, елмайган сыман, кәмит кенә җыерып: «Карале, дөрес әйтәсең бит, әй!» дигәндәй, койрыгын шап иттереп җиргә бәрде.

Бу хәлгә хәйран калып, Кәримә:

— Карасана! Елмая бит, елмая!— диде.

Муйнакның саргылт күзләрендә, ахырына кадәр ерылган ирен кырыйларында чыннан да көләмсерәү бизәкләре уйный иде. Мин аны үз яныма дәшеп, башын сыйпадым, тамак астын кашырга тотындым. Ул күзләрен йомган, аякларын күтәргән хәлдә балалар кебек иркәләнү рәхәтенә талды.

Кәримә башын чайкап:

— Бөтенесен аңлый, Муйнак, тик теле генә юк...— ди башлаган иде, Муйнак сикереп торды да: «Я, я, тагын нәрсә әйтерсең икән?» дигәндәй, аның каршысына барып йөзенә текәлде. Кәримә: «Күрдең-ме?»— дигәндәй ым какты.

— Адәм акыллары бар анда. Каян беләсең, я бәлкем яхшы гадәтләр аңа кешедән йога торгандыр?

— Ихтимал, анысы да юк түгелдер. Ләкин эт токымының үзенә генә була торган сәләтләре дә җитәрлек. Әйтик, эт исне кешегә караганда меңнәрчә тапкыр көчлерәк сизә икән!

— Ай-яй, меңнәрчә тапкыр! Булыр, бик зирәк җәнлек,— диде Кәримә.— Менә без әле кеше булсак та вакытны сәгатькә карап кына беләбез. Ә аңа сәгатьнең кирәге дә юк. Ашарына бирер вакыт җиттеме, ул минутын да кыештырмыйча тәлинкә янына килеп баса!

Табигатьнең бу сөйкемле баласын урынсызга җәберләүләр, мәсәлән, кыйнаулар, тиресе бүреккә кирәк булган өчен генә бәреп үтерүләр, тагын шундый кансызлыклар соңгы елларда бик борчый башлаган иде. Шунлыктан мин аның уңай якларын исемә төшерергә тырыштым.

— Этләрдә иптәшлек, дуслык тойгысы да бик көчле. Үз нәселен генә түгел, эт кешене дә бик якын итә. Ул сине яраттымы, синең өчен җанын фида кылырга да әзер тора! Шуның өстенә, эт халкы бик гадел дә...

Күрәм, монысына җәмәгатемнең бик үк ышанасы килми шикелле. Ул көлемсерәп кенә:

— Азрак арттырып җибәрмисеңме? Ни әйтсәң дә, эт — эт инде ул,— диде.

— Мин дә бит аны кешегә тиңләмим. Шулай да, мин әйтер идем, эт — кайберәүләр аңлаганча, теләсә кем арт ягына тибеп китәргә ярый торган карусыз, әрсез алабай, иң түбән җанлы бетәшкән бер мәхлук түгел! Эт — эт кенә түгел, ул җәнлектә без хәзергә белеп җиткермәгән әллә нинди серләр бар, үзенә күрә, анда хәтта горурлык тойгысы да юк түгел.

— Бик югары күтәрдең син этне!

— Дөресе шулай! Мин күргәнем-белгәнемне әйтәм.

— Берәр мисал да китерсәң...

— Мәсәлән, ике эт үләрен белмичә сугышканда, шуларның берсе, җиңелүен белдереп, чалкан ятса, җиңүче эт аңа тими. Бүреләр дә шулай.

Кәримә башын игәләп:

— Менә монысы бик гыйбрәтле! Алайса, этләрдә кешеләрдәге шикелле, егылганны түбәләү гадәте юк икән,— диде.

— Шулай ук, юньле эт үзен мыскыл да иттерми! Юк!

Без көлешә-көлешә күптән түгел безнең күз алдында булып алган бер мәзәк хәлне искә төшердек. Күршеләргә килгән бер салмыш егет Муйнакны баскычтан типкәләп төшерде. Бик тә хурланды моңа Муйнак, теге егетнең кыланышларын читтән-читтән генә карап йөргән булды да, кызлар белән шау-гөр килеп капкадан чыгып барганда чалбарын тешләп ертмасынмы!..

Миңа Казанга кайтып килергә кирәк иде. Көньяктан җылы яңгыр җилләре исә, Идел ягында урман өстен тоташ болытлар каплаган. Шулардан чамалап, өстемә пинжәк кидем, зонтик та аласы иттем. Җыенып, капка төбенә чыксак, хәйран калдык: Муйнак автобуска бара торган юлга алдан ук чыгып баскан! Кәримә аңа башы белән ымлап көлеп җибәрде:

— Мин барып йөрүнең кирәге юк, әнә озатучың! — диде.

Озатып калу, кая барсак та «күз-колак булу» Муйнакның көндәлек гадәтенә кергән иде. Урманга чыгабызмы, шәһәргә барабызмы, ул безне беркайчан да ялгыз җибәрми. Тик шунысы гаҗәп, минем кая барасымны ничек алдан белә икән ул?

— Нинди кием киюеңнән чамалый торгандыр,— диде Кәримә.

Муйнак белән һәрвакыт юлың кыска, җаның тыныч була. Бердән, үзеңне озаттырып, син аны чиксез куандырасың, ул, рыясыз җан, аңа шундый зур, «җаваплы» вазифа йөкләнүгә башы күккә тигәндәй, горурлана белә, янәсе, әнә нинди эшкә ярый ул! Шуның өстенә, ул бит юл буе чын күңелдән синең иминлегеңне кайгыртa, як-ягына карана-карана алдан юыртып, җыен ыбыр-чыбырдан юлны тазартып бара. Сез аның исерекләрне, я булмаса, чит-ят этләрне ничек куркуга салуын күрсәгез иде! Андый чакта Муйнак шундый куркыныч итеп ырылдый, сырт йоннарын кабартып, тешләрен ыржайтып шундый дәһшәтле кыяфәткә керә, тегеләр, моның артыннан килүченең дәрәҗәсе япон императорыныкыннан һич тә ким түгелдер дип, тизрәк читкә тайпылу ягын карыйлар.

Әмма без, исерекләрне күрәсебез килмичә, күп вакытны олы юлдан читкә тайпылып, автобуска урман сукмагыннан турыга бәреп чыга идек. Урман куелыгына килеп керүгә, Муйнак үзен бабалары кебек кыргый хәленә кайткан, кыргый урманнарда йөргән шикелле иркен хис иткәндер, күрәсең. Бередә ул бөтенләй үзгәрә иде. Монда мин аның, безнең кебек, табигатьтән аерылып бетмәвен сизәм. Агачлар куелыгына керү белән, ул хәзерге дөньясын да, мине дә онытып, үзе шикелле кыргый җаннарның хәлләрен белешергә тотына. Кырмыска оясы янына барып баса да, башын кыйшайта-кыйшайта, бу хезмәт ияләренең мәш килеп тормыш итүләрен күзәтә, тора-торгач, нәрсәнедер хуплагандай, койрыгын селкетеп куя. Ул бер читтәге карт юкә янына да барып килмичә булдыра алмый, чөнки анда сыерчык бала чыгарган. Бер нарат ботагыннан икенчесенә сикерә-сикерә үз шөгыле белән йөрүче тиенгә дә ул ваемсыз гына карый алмый, аңа өзек-өзек кенә итеп өреп тә куйгалый.

Шулай да Муйнакның үзен тудырган табигатькә иң якынайган, шуның рәхәтен татыган урыны — сукмак өстендәге кечкенә алан була иде. Анда барып кергәч, Муйнак бөтен килеш-килбәте, үзен тотуы белән сабый балага әверелә. Ул озын сабаклы үләннәр башында атынаатына бал суыручы төклетураларга, бал кортларына, күптәнге танышларын очраткандай, кызыксынып карый, ул да түгел, атылып-бәрелеп, тычкан куып китә дә, пошкыра-пошкыра, аның оясын казырга тотына. Анда эше барып чыкмаганга һич тә исе китмәгәндәй, гамьсез кыяфәт белән янә кузгалып китә дә, җилгә каршы торган хәлдә, башын чөеп, һаваны иснәргә тотына. Ул хуш исләрнең тәмен, кадерен белеп, кара борынын кыймыл-кыймыл иттереп, татлы шербәт эчкәндәй рәхәтләнеп, озак итеп исни. Мин агач күләгәсенә ышыкланган җиремнән Муйнакның бу рәхәтенә кызыгып, аннан көнләшеп торам. Без, кешеләр, кызганычка каршы, табигатьтән бик ераклашканбыз, безнең табигатьне белү чамабыз да, ис сизү сәләтебез дә бик тә тупасланган, чикләнгән. Без бит, оятыбызга каршы, энҗе чәчәк белән шомырт чәчәгеннән бүтәннәренең исен түгел, хәтта исемнәрен дә онытып барабыз. Ә менә Муйнак алай түгел! Ул аланчыктагы берничә дистә чәчәкнең затлы, назлы хуш исен берьюлы иснәп рәхәтләнә. Без барлыгын да белмәгән нинди генә затлы хуш исләр килеп кермидер аның борынына! Күрәсең, аңа таба аланның төрле ягыннан төрле чәчәк исләре агыла торгандыр, ул, күзләрен йома төшеп, танавын әле бер якка, әле икенче якка бора. Бу шөгыльгә ул шулкадәр бирелә, үзен-үзе шулкадәр оныта, мин хәтта аның бу рәхәтен бүлдерергә кыенсынып торам.

Автобус тукталышында безнең ике арада һәрвакыт диярлек бик тә нәзәкатьле бер аңлашу булып ала торган иде. Автобусны озак көтәсе булганда, мин Муйнакка кайтыр юлын күрсәтеп:

— Бар кайт инде, кайт!— дим.

Муйнак, янәсе минем киңәшемне тыңлаган кыяфәт белән башын иеп, кырын карый-карый, олы юлның аргы ягына чыгып баса. Әмма һич тә кайтып китәр шикелле күренми, кыяр-кыймас кына тагын миңа күтәрелеп карый. Сизеп торам: ул миңа: «Утырып китүеңне генә карап торыйм инде»,— димәкче була.

Мин, ачуланган кыяфәт белән кашларымны җимереп, катырак кычкырам:

— Юк, юк, ярамый, кайтасың! Күрмисеңмени, машиналар ничек котырынып чабыша! Я таптап китәрләр үзеңне! Бар, кайт!— дим.

Шуннан соң гына Муйнак теләр-теләмәс кайтыр юлына таба атлаган була. Ләкин хәзер дә хәйләли ул!

Менә шыгрым тулган Юдино автобусы Аккош күленә килеп туктый. Эчкә кереп басканнан соң, бик күп береткалар, кепкалар, тузгыган чәчләр арасыннан яшеренеп кенә юлның аргы ягына күз салам. Әйтәм бит, теге наян чыннан да хәйләләгән! Магазин почмагыннан, «Күренмиме икән?» дигәндәй, автобуска текәлеп тора.

Нечкә күңелле шушы табигать баласы миндә әллә никадәр тирән кичерешләр уята. Мин чын күңелдән аның хәвефсез-хәтәрсез, исән-аман өенә кайтып җитүен телим. Әгәр кичкә каршы борылып килгәндә Муйнак мине шушында каршы алса, аның белән бергә кайтуы күңелле дә, хәвефсез дә булачагы турында уйлап куям. Күп көннәрне ул мине чыннан да шушында каршы ала торган иде...

## Кечкенә Рамайның зур кайгысы

Аккош күлендә мине Рамай исемле таныш малай каршы алды. Алар безнең иҗат йортының күршесендәге дүрт-биш кенә өйле поселокта яшиләр. Рамайның әнисе якындагы пионерлар лагеренда, әтисе Оргсинтезда эшли. Рамай үзе өченче класста укый шикелле. Җәй көне безнең ишегалдында еш була, язучылардан укырга китаплар да алып торгалый иде.

Рамайның бу кайгыртуыннан бик канәгать булып, мин аның аркасыннан кактым.

— Син чылтыраттыңмыни?— дидем.

— Әйе, мин,— диде Рамай. Ярый, килдең әле, абый! Әни әйтә, Муйнакны больницага салмыйча булмас, ди.

— Хәле шулай бик авырмыни?

— Авыр. Имгәтteләр аны, арт санын тота алмый, кан да күп киткән, ди, әни.

Димәк, безгә ашыгырга кирәк икән. Тик шунда Рамайның өстенә-башына күзем төште. Аның курткасы белән чалбары манма су булган, аягы да чыланган, куллары кызарган, борын аслары да корыдан түгел иде. Күрәсең, аңа мине озак кына көтәргә туры килгәндер. Мин аңа таныш кешеләргә кереп җылынып чыгарга әйттем. Ул төшлектән шактый авышкан кояшны күрсәтте:

— Кирәкми, абый, җылынып торсак, озак булыр. Муйнак бик сызланадыр, барыйк тизрәк!— диде.

Мин Рамайга киеме эченнән үз фуфайкамны кийерттем.

— Әйдә алайса, йөгерик.

Ләкин йөгереп булмый икән. Баскан саен аяк пычракка бата. Ни арба, ни чана дигәндәй, урман юлы кардан-боздан арчылып кына килә иде әле. Фуфайканың итәге Рамайның аягына сылана, аңа кыенрак. Шулай да ул, кайда пычрак, кайда су ерып, миннән калышмаска тырышты.

Ай Муйнак, Муйнак! Ул минем бер генә минутка да исемнән чыкмады. Ул безнең урмандагы тормышыбызга шулкадәр тирән кереп утырган, аңа ул-бу булса, аннан башка җәй уздыруны күз алдына да китереп булмый иде. Юл буе үземне-үзем юатып бардым: Муйнак урам эте бит. Аның ата-анасы да, бөтен токымы да, көчек чагыннан ук һәр төрле кыенлыкларга: ачлыкка, суыкка, төрле чир-чорларга каршы чыдам булып, чыныгып яшәгән. Ул йомшак миндәрдә генә йоклап, тәмле ашап яшәүче иркә этләр ише түгел. Юк, бирешмәс Муйнак, бирешмәс!

Шулай да күңел нидер сизенә, тынычланып булмый иде. Гәрчә Муйнакны җәберләгән бәндәнең исемен ишетәсем килмәсә дә, бара торгач, сорарга туры килде:

— Кайсы явызның эше?

Юлда бездән башка берәү дә юк иде. Шулай да Рамай баштá якягына карап алды. Аннары гына миңа таба иелеп:

— Теге инде, абый, шул үзе!— диде.

Шунда ук аңлашылды, Муйнакны узган ел азаплаган әлеге азгын димәкче була.

— Баламутмыни?— дидем.

Малай сүзсез генә баш какты. Монысы да мине гаҗәпләндермәде. Баламут бу тирә малайларыннан я акча, я бүтән әйбер таптырып, тыңламасалар, кыйнап, котларын алып тора иде.

— Әле һаман кулына сукмадылармыни шул юньсезнең? Нигә каныга ул Муйнакка?— дидем.

Кичә булган хәлне әйтеп салырга теле бармадымы, әллә Баламуттан шүрләдеме, Рамай, иңбашларын сикерткәләп, беравык дәшми барды. Ул да түгел, кинәт нидер исенә төшкәндәй, кояшка карап алды.

— Абый, больницага илтергә соң булмасмы икән?— диде.

— Башта үзен күрик әле...— дидем.

Рамай тагын үз эченә бикләнде.

— Шуннан соң?— дидем мин.

Бераз борынын тарткалап барганнан соң гына, кыенлык белән генә теле ачылды Рамайның.

— Шуннан соң дип... ни инде. Баламут кичә үзе шикелләләрне җыеп кайтты. «Кая Муйнак? Тотып бирегез Муйнакны!» — ди. Без шикләнәбез инде, берәүнең дә Муйнакны тотасы килми. «Нәрсәгә ул сиңа?»— дибез.— «Аның тиресенә өч таңкә бирәләр, хәзер шундый йонлач бүрек модный!»— ди бу.

Мин, куркып, этигә әйтергә дип йөгердем. Чаттан гына борылганыем, Муйнак бик каты чинап җибәрде, анда тавыш купты. Әти белән без чыкканда, Баламут белән каравылчы абый якалашалар, ә Муйнак, арт санын сөйрәп, елый-елый мунчага таба бара иде.

Бу тирә кешеләренең шундый ваемсызлыгы миңа һич тә ошамады.

— Их сезне! Шул чагында Баламутны җыйнаулашып бөтереп алмагансыз икән!— дидем.

Рамай беравык аптырабрак торды да, үпкәләгән сыман авызын бүлтәйтеп:

— Ие, бар, әтәчләнеп кара! Алар бишәү лә! Ә кесәләрендә пычак. Алардан олылар да курка!— диде.

## Бибек нигә елый

Без барып җиткәнче, тагын утыз-кырык минут узгандыр. Шулай да, әгәр автобус бик озак көттермәсә, мин Муйнакны Казанның ветеринария поликлиникасына якты көздә илтеп җиткерә алачак идем әле. Муйнакны күтәреп кайту өчен, Рамай йөгереп кенә барып өйләреннән зур гына брезент сумка да алып килде.

Ләкин Муйнак яткан мунча янына барып җиткәч, без аптырап калдык. Алачык ишеге бераз ачылып калган, мунча эченнән җылы пар бөркелеп тора, ә Муйнак юк иде. Почмакта аның яткан урыны бар, тәлинкәсе дә, ашалмый калган ризыклары да бар, ә үзе юк.

Рамай, арлы-бирле йөгереп:

— Аһ син аны! Качкан бит!— дип кычкырды.

— Юктыр ла! Кая китсен ул?— дидем мин.

— Баламут яңадан килер дип курыккан да качкан!

— Юк, аннан куркудан узгандыр ул, энем. Арт саны имгәнгән диден бит!

Рамай уйга калып башын чайкады.

— Белмим тагы. Үз күзем белән күрдем: көчкә-көчкә генә сөйрәлә иде.

Рамай каравылчыдан да сорашып чыкты. «Иртә белән генә шунда иде» дигәннәр. Аннан соң байтак вакыт узды шул инде. Тиз генә поселок тирәсен әйләнеп чыктык, Тирән күл буена төшеп мендек, төрле якка сузылып киткән урман юлларына чыгып карадык. Юк кына бит Муйнак!

Каян эзләргә, нишләргә белмичә аптырап йөри торгач, юллардагы эзләрне тикшерергә булдык. Рамайның үткен күзләре тиз үк нидер тапты.

— Менә!— дип кычкырды ул.

Барып карасам, карурманга кереп киткән урынтын юлга сирәк-сирәк кенә кан тамып барган, күләгәдә эреми яткан иртәнге кырау өстендә эт эзләре дә күренгәли, нидер сөйрәлеп тә барган шикелле. Без бер-беребезгә карашып алдык та шул юлдан урман куелыгына кереп киттек. Як-якта юан кара чыршылар үсеп утыра, бу тирә болай да бик тын, бик караңгы иде.

Байтак баргач, юл кырыендагы черек төп янында тагын аның эзен күрдек. Узган елгы ылыслар җиргә иңеп, ул төш бераз чокырланып калган иде. Күрәсең, монда ятып хәл җыйгандыр... Боларның Муйнак үзе булуы турында безнең шигебез юк иде инде.

Караңгы чырайлы чыршыларга карап бара торгач, Рамай шомланып туктап калды.

— Абый, карале, нигә монда китте икән ул?— диде.

Бу сорау минем үземне дә борчый иде. Чынлап та, нигә Муйнак нәкъ менә шушындый кеше бик сирәк була торган иң караңгы почмакка кереп киткән, нигә башка юнәлешкә китмәгән? Кайбер акыллы этләр, мәчеләр урманга шифалы үлән эзләргә дә чыгалар. Алай дисәң, аңа әле иртәрәк, үләннәр әле яңа борын төртә башлаган. Мин Рамай соравына:

— Аңа тынычлык кирәктер, поселоктагы шау-шудан качадыр бәлки...— дидем. Дөресен генә әйткәндә, мин моңа үзем дә ышанмый идем.

Шулай уйланып бара торгач, кинәт минем башыма ап-ачык булып, чын-чынына үзеннән-үзе ышандырып, яңа уй килеп керде. Мөгаен шулайдыр! Муйнакны тәгаен генә этләр токымының нәсел буенча ата-бабаларыннан килә торган көчле инстинкт алып киткәндер! Кыргый җанварларның кайбер гадәтләрендә кеше аңлап җиткермәгән караңгы яклар азмыни әле?!

Хәзер ул турыда уйланып торырга вакыт калмаган, безгә ашыгырга кирәк иде. Мин Рамай кулыннан брезент сумканы алып:

— Әйдә, энем, йөгерик, бәлки соң түгелдер әле!— дидем.

Юлдашым миңа сәерсенеп карап алды.

— Нәрсәгә «соң түгел», абый?— диде.

Мин йөгерә биреп, башым белән алга таба ишарә иттем.

— Артыннан барып җитик әле...

Бераз гына йөгерүгә, кечкенә генә аланда ике юл чатына барып туктадык. Сулдагы юл якындагы урман инешенә алып төшә. Ул яктан язгы ташу тавышы ишетелеп тора иде. Әгәр дә Муйнак шул якка киткән булса, аны коткарырга соң булыр иде инде.

Кай таба йөгерергә белмичә икеләнеп торганда, уңнан чәң-чәң өргән эт тавышы ишетелде. Ул нәрсәгәдер кайгырган сыман еламсырап, язмышыннан зарлангандай кызганыч тавыш белән өрә иде.

Мин аңа колак салып:

— Әһә, исән икән әле!— дип әйтеп куйдым. Рамайның да күңеле күтәрелеп, минем алдымнан йөгерә башлады.

Юл дигәнебез бераздан сукмак кына булып калды. Кайда куаклар чытырманы арасыннан, кайда аркылы яткан агачлар өстеннән сикергәли торгач, кинәт текә яр кырыена барып төртелдек. Сукмак өзелде. Яр астында тирән чокыр, аның аргы ягында яртылаш су баскан күе әрәмәлек белән болынчык күренә, шул тирәдә чыелдап кычкыра-кычкыра бибек очып йөри иде. Рамай әсәрләнеп:

— Абый, мин беләм, тәкәрлек бит бу! — диде.

— Әйе, нәкъ үзе! Тавышына охшатып, аны бибек дип тә атыйлар. Берәр нәрсә борчыса, ул әнә шулай би-й-бек, би-й-й-бек! — дип кычкыра-кычкыра очып әйләнә.

Ул арада куаклар арасыннан Сарбай килеп чыкмасынмы! Әлеге тавыш биргән эт Муйнак түгел, Сарбай булган икән бит! Күрәсең, ул да безнең шикелле дустын эзләп киткән дә аны бездән элегрәк барып тапкан. Безне күргәч ул: «Эшләр зурга китте бит әле!» дигәндәй, безнең тирәдә шыңшып йөрде дә яңадан яр буена барып басты. Сарбай яр астындагы чокырда нидер күрә иде шикелле. Ул аска әсәрләнеп, колакларын торгызып текәлеп тора да, нидәндер курыккандай, сискәнеп китә. Кинәт артка сикерә дә, танавын күккә чөеп, кызганыч тавыш белән уларга тотына иде.

Рамай, куркып, минем беләгемә килеп ябышты:

— Абый, нишләп анда карап улый икән ул? Әнә Бибек тә жылый, диде.

— Алар без күрмәгәнне күрәләрдер, энем.

— Муйнакнымы?

— Әйе, шуны, Рамай.

— Алайсам, нишлибез инде, абый, анда ничек төшәбез?

— Анда төшүнең кирәге калмады инде, энем,— дидем.

Рамай моңа бик гаҗәпләнде.

— Ничек була инде бу? Шунда калдырабызмыни? Больницага салсак, дигәниек бит?!

— Дигәниек тә... Больницаны кирәксенмәгән бит Муйнак, бу дөньядан үзенчә китеп барырга булган, борынгы бабаларынча...

Рамай, йөгереп барып, астагы чокырга текәлде, бибек тавышын тыңлап торды да яңадан минем каршыма килеп басты.

— Каян беләсең? Анда сызланып ятмыймы икән соң? — диде.

— Юк, ул сызланмый инде, бөтенләйгә тынычланып калган... Мин аңа Муйнакның яр кырыена шуышып барган эзен күрсәтәм. Күрәсең бит, нинди тирән! Моннан төшкән җан иясе яралы булмаса да исән кала алмый. Әнә бит, Сарбай белән бибек тә юкка гына еламыйлар. Ни булганын беләләр алар. Бу аларның Муйнак белән мәңгегә хушлашуыдыр бәлки...

Урман артында кояш баеп килә. Зәңгәрсу-соры томан астында калган әрәмәлек кешеләр аңламастай ниндидер серләр яшереп ятучы бүтән бер дөнья, шомлы дөнья булып күренә иде.

Безгә дә Муйнак белән хушлашырга кирәк дип уйлаштык. Аның, бабаларыннан калган инстинктка каршы килмичә, шундый тәвәккәллеккә баруы ихтирам хисе уята иде. Ләкин ничек хушлашырга? Салют

бирер идек, мылтыгыбыз юк, бер уч туфрак салыр идек, аның кабере юк. Шулай да соңгы сүзне әйтмичә китүне күңел өнәмәде. Яр кырыена килеп бастык та мин, астагы чокырга карап:

— Хуш инде, Муйнак!— дип кычкырдым.— Син дөньяда тикмәгә генә яшәмәдең, безнең күңелләрдә яхшы истәлекләр калдырып киттең. Хуш! Тыныч йокла! Без сине онытмабыз!..

Муйнакны мәңгелеккә үз кочагына алган караңгы упкынга тагын бераз карап тордык. Хәзер инде Сарбай да тынды. Тик астагы болынчыктан бибек елаганы гына ишетелә иде.

Кайтыр юлга чыккач, Рамай ул якка берничә мәртәбә борылып карады. Бу сәер хәл берничек тә аның башына сыймый иде ахрысы, уйланып кайта торгач, сорамыйча түзә алмады:

— Үз аягы белән үләргә барган булып чыга инде, имә?— диде.

— Әйе, шулай була.

— Нишләп икән? Бу якты дөньядан кем туйган?

Монысы Рамайның үз сүзе түгел, ул аны я китапта укыган, я олылардан ишеткән булса кирәк. Кыргый табигатьнең бу борынгыдан килгән законын бала күңеленә сеңдерерлек итеп ничегрәк аңлатырга? Күрәсең, ерактанрак башларга кирәктер, дип уйлап алдым.

— Бәлки ишеткәнең бардыр, я китапларда күзеңә чалынгандыр, кыргый хайваннарда шундый гадәт булган: аларның картлары, я тазармаслык авырулары кая да булса, шулай читкә китеп, кеше аягы басмый торган яшерен урыннарда үлә торган булганнар.

— Этләр дә шулай үләнме?

— Әйе, этләр дә. Халык аны күптән үк белгән. Әнә безнең борынгы бабайлар «Яхшы эт читкә китеп үләр» дигән мәкаль дә әйтеп калдырганнар.

— Андый хайваннар әле хәзер дә бармы?

— Бар шул. Әнә филләр шулай. Алар әле хәзер дә кеше күз алдында үлмиләр икән. Әҗәл житүне сизү белән, көтүләреннән аерылып, кая да булса, кеше аягы басмаган тау-ташлар арасына, я урман чытырманлыгына кереп югалалар.

— Ә нишләп алай итәләр?— диде Рамай.

— Ничек төшендерергә икән сиңа?— Күңелемнән бала аңлардай мисаллар эзләп беравык уйланып кайттым.— Менә син әйтеп кара әле: ни сәбәпле этләр, юлда берәр куакмы, түмгәкме очраган саен, арт тәпиләрен күтәрәләр?

Бүген беренче мәртәбә йөзе яктырып Рамай елмаеп куйды.

— Нигә? Пес итәселәре килгәнгәдер...

— Юк шул, энекәш! Алай гына түгел! Беләсеңме, кыргый чагында этләр дә, филләр шикелле, көтү булып яшәгәннәр. Алар, азык эзләп, бер урыннан икенче урынга күчеп йөри торган булганнар. Менә шул чагында алдан баручы эт, үз артыннан килүче нәселдәшләре юлдан язмасын өчен, әнә шулай билге салып барган. Бу — бер...

— Кара, кызык икән!— диде Рамай.

— Кызык та, мәгънәсе дә бар. Кайбер галимнәр башкача аңлата: шундый исле тамга белән эт токымы үз биләмәсенең чикләрен билгеләгән, диләр. Янәсе, «бу тирәләр минеке, монда тыкшынмагыз!» дип кисәтеп куюы була. Бу гадәт аларның канына сеңеп калган. Шунлыктан, бер дә кирәге булмаса да, хәзер дә шуны кабатлыйлар. Читкә китеп үлүләре дә шулай борынгыдан калган. Андыйлар бер дә кирәкмәгәнгә эшләнми. Күрәсең, ул нәселне саклау өчен дә кирәк булгандыр.

Ләкин Муйнакның үзенә-үзе шундый хөкем чыгаруы белән Рамай һаман да килешеп бетми иде әле.

— Ул бит борынгы заманда. Ә хәзер докторлар бәлки тазартканбулырлар иде әле,— диде ул.

— Тазармаслык булып имгәнүен Муйнак тәгаен белгән, ахрысы.

— Ничек белсен икән, җәнлек кенә бит ул?

Рамайның болай төпченүе нибары кызыксынудан гына булырга охшамый иде. Ул табигатьтәге һәр җан иясен чын күңелдән кайгыртучы нечкә күңелле бала булып чыкты. Муйнакның һәлак булуын ул чыннан да авыр кичерә иде. Минемчә, бу хәл аның күңелендә тирән уелып калачак, ул аны гомер буе онытмаячак. Алай гына да түгел, минем әле Рамай яхшы күңелле, игелекле кеше булып үсәр, җырдагы адашы шикелле, киләчәктәге халык күңеленә кереп калырдай зур егетлекләр күрсәтер дип тә ышанасым килә иде. Шунлыктан, кечкенә юлдашым белән мин үз тиңем итеп сөйләштем.

— Зур үсеп, күбрәк укыгач, үзең дә аңларсың әле, энем. Кыргый табигатьнең хәзергә әле ачылып җитмәгән бик тирән серләре бар. Тазарырлык булмагач, яшерен урында юкка чыгарга тиешлекне дә аңа табигать кушкан. Ничек кушкан?

— Бәлки кошларның туган ояларына адашмыйча кайтып төшүләре шикелледер?— диде Рамай.

— Менә, менә, нәкъ шулай! Ул тойгы аларның каннарына сеңгән диләр бит.

Рамайга, башын аска иеп, атлар-атламас кына безнең арттан кайтып килүче Сарбайны да күрсәттем.

— Этләр үлем-җитемгә дә бик сизгер. Эт кенә димә! Җан дустын мәңгелек йортта бөтенләйгә калдырып кайтуын ул да аңлый, ул да әнә ничек авыр кичерә!

— Нәрсә ул «мәңгелек йорт?»

— Менә шушы без яши торган бөтен табигать.

Безгә язгы матурлык та күренми, агач башларындагы кошлар чырчуы да ишетелми иде. Күңел юксына. Моннан соң безнең тормышыбызда нидер җитмәс, мөгаен бик кадерле, бик тансык дуслык җылылыгы җитмәс. Муйнак баскыч төбен саклап ятучы гади каравылчы гына, кайберәүләр аңлавынча, типке астында яшәү өчен яратылган әрсез алабай гына түгел иде. Юк! Яшәешебезне матурлап, аны үзенең ягымлылыгы, дуслык җылысы белән баетып торучы сөйкемле җан иясе, ышанычлы якын дустыбыз иде Муйнак.

Байтак кына араны борынын тарткалап, сүзсез генә кайта торгач, юлдашым тагын башын күтәрде.

— Абый, этләрне, мәчеләрне шулай азаплаган кешегә закон бармы?— диде ул.

Кечкенә кешенең бик урынлы соравына тынычландырырлык җавап бирәсем килә иде. Ләкин андый сүз таба алмадым.

— Җинаять эшләре кодексында андый статья юк шул, Рамай энем,— дидем.

Аның ышанасы килмәде, ул моңа бик гаҗәпләнде. Күзләремә туптуры карап:

— Нишләп юк икән, абый?!— диде.— Агач кискәнгә закон бар, әйбер ватканга да бар. Эт бит ул әйбер генә түгел, тере җан бит, матур җәнлек бит ул!

Кечкенә дустымның бу ачынып әйткән сүзләренә мин бернинди җавап та бирә алмадым.

Без поселок урамыннан узып барганда, Баламут капка төпләрендә тәмәке тартып тора иде. Сарбай, аны күрүгә, чинап, урамның икенче ягына атылды. Баламут моңа бик канәгать булган сыман иһаһайлап көлеп җибәрде. Ул Муйнакның башына җитүче кеше тәгаен үзе булуын да, безнең кайдан кайтып килүебезне дә яхшы белә иде. Җәзасыз калачагы да аңа көн кебек ачык иде булса кирәк. Баламут үзенең шушы явызлыгы белән, бөтен якын-тирәне куркытып торуы белән масая иде кебек күренде.

1982

# Салих Баттал

## ИКЕ ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ

ПОЭМА

Гаҗәп бер төш күрдем: ике мең дә
йөз сиксән икенче ел, имеш,
Коллык беткән. Инде табигатьнең
барлык кыргый көче кол, имеш.

Хезмәт хезмәт түгел — гармун уйнау:
кнопканы бастың, шунда ук
күңелең ни тели — пәйда була.
Бары атаң башы гына юк.

Мин шукландым: күңел теләгәнне
тик кнопка гына хәл итсә,
басыйм әле... Бастым: — Нәрсә кирәк?
— Миңа кирәк, — мәйтәм, — больница!

Көткән идем, җавап ишетелер дип:
— Авырулар юк, — диеп, — бу чорда.

Бер минуттан күрәм: рәт-рәт койка,
мин — берсенең башы очында.

Бала ята. Күптән түгел, имеш,
яткырганнар күчереп бишегеннән.
Һәм ул бала минем нәсел, имеш,—
танып алдым борын тишегеннән.

Үлгәнсыман, үзе тере, имеш,
хәтта сөйләшергә тели, имеш.
Миңа наушниклар китереп,
утырттылар шуны кидереп.

Кызыксындым — нәрсә белән авырый?
Шыпырт кына җавап бирделәр:
«Авыруы шул аның — үсә алмый,
туган килеш калган»,— диделәр.

Кибернетик җайланмалар җебе
ике арабызга сузылып.
авыру миендәге биотоклар
ишетелде миңа сүз булып:

— Кара мине асраучыларга —
башка планетадан бит алар;
экспериментлары өчен безне
җәнлекләрдәй итеп тоталар.

Бабамнарның син бабасы, тыңла —
күпме ятам дисең мин череп? —
Миңа унсигез яшь. Бу яшьтә син
паспорт алган мәктәп бетереп.

Тарихны һәм башка төр фәннәрне
тик авыруым миңа өйрәтте.
Сезнең чорның атом сугышы чөнки
минә безнең чорны көйрәтте.

Син җаваплы! Шартлау продуктлары
барсы да бит сезнең заманда
доллар булып күчте банкларга
һәм стронций булып — каннарга.

Шуны белә торып, түшәктә сез
дөньягызны онытып кунгансыз —
ерак әбием белән, минем дә сез
тууыма сәбәп булгансыз.

Күрше караватка күз сал: авыру, —
аңар минекеннән күп тыгыз:
бала тиресенең карцерында
җәзалана кырыктагы кыз!

Тик шундый зур сынау көтә мине,
син иртәгә тагын кереп чык, —
котың очар! Бүген күргәннәрең
булып калыр бары уенчык!

Безне барокамерага салып,
абсолют ноль салкын булдырып,
иртән әнә шул кыз бала белән
кавыштырачаклар туңдырып.

Җылы килеш куша алмадылар, —
организм карыша ничектер.
«Ә абсолют нольдә ток үтәчәк,—
сөю бит ул, — диләр, — электр...»

Ә син аңла ник бу тәҗрибәдән
котым очып минем куркуны:
ул кыз — Җир шарына ут төртүче
президент... Н. Н. токымы!

Күп калмады, ярты тәүлектән ул
минә миңа ябышып туңачак.

Шул минуттан ул куш фамилияле —
«Батталова — Н.Н.» булачак!

Син әйт хәзер миңа: банкирларның
сателлиты лакейларыннан
менә шундый нәсел калдыруда
бармы синең бирәр аермаң?

Аермаң шул булыр — ыруыңа
салкын карап үтмә яңадан;
буып үтер, коткар мине хәзер
яшәү дигән шушы җәзадан!

* * *

Тетрәтте бу төш. Мин уяндым
тиргә батып кара кайгымда, —
сыйныфым, — дип, — төштә, яисә өндә
хәтта үзенең ачы хәсрәтендә
туганлашмасайде Н. Н. га!

Мин уяндым. Бу җаваплы чорда
йоклап яту ни ул — аңладым.
Һәм бу сугыш белән алышымда
җиңми, тыныч йоклый алмамын.

*1981*



## Шәүкәт Галиев

### Маяк

Океан-диңгездә,
Чоңгыллы юлда,
Караңгы төндә,
Томан-давылда
Кораб юл яра.
Юк, кораб түгел,
Кеше юл бара.
Хәтәр чакларда
Юлдан язмыйм, дип,
Кеше шомлана.

Кинәт алдында
Утрау-кыяда,
«Юлың дөрес!» — дип,
Нур-маяк яна!
Юк, маяк түгел,
Яна ул шулай
Тынгысыз күңел,
Тынгысыз кеше.
Яктырту аның
Гомерлек эше!

### «Җиңел мамык»

Борын заман, имеш, берәү
Әйткән иләйһи уптым:
«Җиңел бит ул — мамыкның мин
Күтәрәләм йөз потын!»

Өф итсәң дә оча үзе,
Канатланып, җил белән.
Җиңел мамыкны үстерү
Түгел икән җиңелдән:

Без чөгендергә йөргәндәй,
Эшли мамыкчы халык,
Бәбәк-бәбәнәктән башлап,
Тәрбия сорый мамык.

Эсседә сусын канганчы
Эчерсен генә арык —
Үз тирең белән сугарып,
Булырсың тәмам гарык...

Өлгергәч тә кардай кырны
Чеметемләп җыясы.
Чеметемләп җыелганны
Таудай өеп куясы.

Имеш түгел, үзбәк дустан
Була чынлап күтәргә —
Миллион тонна мамыкны ул
Ил алдында күтәрә!

## Авыр сүз

Йөк бар, йөктә бабай бар,
Бабай янда агай бар.
Юк аты, юк арбасы —
Болар ничек бара соң?!

Малайлар юл буенда,
Малайлар гел уенда:
— Хи-хи-хи, ишәк килә!
Бу ялкау нишләп килә?
— Әй, ишәк, син бит кире!
Килмә бире, кит кире!

Ишәк йөккә күмелгән —
Колак кына күренә,
Авыр йөк алып бара.
Тырышып, чынлап бара,
Кушканны тыңлап бара.

Сүзегезне, малайлар,
Ахры, кире алырсыз —
Йөге авыр болай да,
Өстәмәгез авыр сүз!

## Базарда

Бар нәрсә бар базарда —
Юк нәрсә юктыр бер дә!
Әмма акчаң булмаса,
Бушка кызыгып йөрмә.

Кавын, карбыз, алмалар
Ымсындырып яталар...
Акча гына юк монда —
Ансын эштә саталар!

## Чәй кырында эш кайный

Безгә инде көз килде,
Грузиядә җәй иде —
Басуларда офыктан
Ташып торган... чәй иде!

Йомры, яшел дулкыннар
Ята тезелеп кенә,
Чәй диңгезе өстеннән
Комбайн йөзеп килә!

Чая кызлар чәй җыя,
Бик җәһәт сайлый-сайлый,
Ми кайнарлык эссене
Оныттырып эш кайный!

Күрдем мин чәй үскәнне,
Кайнарланып пешкәнне.
Тирләп чәйләр җыйганда
Салкын су да бик тәмле!

## Уртак алма

Башта Кояшка карады:
«Кайчан пешәрмен?»
Үсте дә Җиргә тартыла:
«Кайчан төшәрмен?»

Кояш-Әти, Җир-Ананың
Уртак баласын,

«Сикердем!» — дигәндә генә
Тотып каласы;

Матурлангач, тулгач кына
Тәме качмасын —
Үзен үстергән җиренә
Каты басмасын!..

## Өйрәнүләр

Бокс дипме, болаймы,
Төрткәләшүләр була,
Артыгракка киткәндә
Үпкәләшүләр була.

Кылычка-кылыч килеп,
Килеп мылтыкка-мылтык,

Өйгә кайтулар була
Тозлы төкереп йотып...

Ничек әүмәкләшәсең,
Ничек тәгәрәшәсең! —
Дошманны җиңәр өчен
Дус белән көрәшәсең!

## Кара мәче

Кара мәче очратсалар,
Җен күргәндәй булалар —
Юл уңмас, диеп куркалар,
Таш ыргытып куалар...

Андыйларның үзләренә
Булуын берни булмый,
Аларга юлыккан саен
Мәченең юлы уңмый...

Ә бер көнне кара мәче
Үз юлыннан китмәгән,
Өркеткәндә өрекмәгән,
Мыек та селкетмәгән:

«Үз хакымны белеп мин дә
Йөрим, дигән, бүгеннән —
Кара тәнле дип куарга
Америка түгел лә!»

## Тургай аэродромы

Аэродромда самолетлар
Гел кайнашып торалар:
Җиргә төшеп куналар,
Күккә менеп китәләр —
Дөньяны селкетәләр!

Янәшә, акрын гына,
Йөрим иген кырында.
Тургай сайравы монда
Челтер-челтер биектән
Чәчелеп тора күктән.

Зур-зур тимер кошлар да
Җиңүгә ирешмәгән —
Нәни генә җырчылар
«Беттек...» дип килешмәгән,
Китмәгән, бирешмәгән!

«Үз җирем!» — диеп кенә
Сөенеп күккә мендә —
Ышана көткәненә.
Тургай аэродромында
Күңелләр күтәрелә!

## Чәчәк — шәфкать туташы

Ромашка — ак канатлы,
Ромашка — ак халатлы.
Пакь кына, ару гына —
Шифалы дару гына.

Өлгергәч, аптекага,
Ромашка, юл тотарсың,
Сихәт булып килерсең,
Чәчәк — шәфкать туташы!

## Мескен чыршы

Чыршы күргәч бәйрәмдә
«Бигрәк матур!» — дигәннәр.
Уенчыклар элгәннәр,
Конфет тагып биргәннәр,
Төрлечә бизәгәннәр,
Тирәсендә йөргәннәр,
Уйнаганнар, көлгәннәр!

Яңа ел бик тиз үткән,
Инде чыршы чүплектә...

Ник саклап үстергәннәр,
Ник алдап китергәннәр?
Яратып, мактап кына
Бәйрәмдә бетергәннәр...

## Тавыклар көлә...

Үрдәк йөзә белә,
Казлар йөзә белә.

Сыер йөзә генә!
Сарык йөзә генә...
Ат та йөзә белә,
Эт тә йөзә белә,
Мәче йөзә белә!
Ничек шулай булган,
Ничек бар да белгән,

Ничек белеп туган?
Белмим икән бер мин,
Тик мин генә белмим,
Ярда җәяү йөрим...

Минем арттан кыр-р, кыр-р,
Тавык җырлап килә.
Үзе белсә икән —
Үзе йөзә белми,
Үзе миннән көлә!..

## Юмарт малай

Кайсы малай үзенә
Алырга гына карый,
Ни булса да кесәгә
Салырга гына карый.

Бу исә, киресенчә,
Бирергә генә тора,
Сиңа нәрсә кирәген
Белергә генә тора.

Бар булганын бүлешә,
Кызганмый бусы берни.
Ник ул теге саранга
Бераз юмартлык бирми?

## Бурыч

Нигә эчем поша әле,
Нигә борчыла күңел?
Бер малайга өч тиенне
Бирәсе икән бүген...

Биш тиенгә билет алып,
Илтеп бирдем бурычны.
Акчам бетте — җәяү кайтам,
Әмма инде тыныч мин!

## Вакытлы вакыт

Вакыт-вакыт уйлап куям:
Йөгерсәм вакыт тиз уза,
Укысам вакыт тиз уза,
Тик утырсам — әкрен уза!

Моннан соң бер максат куям:
Тик ятып күп вакыт җыям,

Вакламыйча салып куям —
Янга калса, итмәс зыян,
Кирәк булыр киләчәктә —
Вакыт җыям мин маяга!

Бер вакыт карыйм — кая ла,
Вакыт узган ич заяга...

## Бәлкем?

Тегесе — начар,
Бусы да яман...
Ошатмыйча син
Сөйлисең һаман.

Кулыңны гына
Селтәп куясың:
«Бар кеше шундый,
Шундый дөньясы!»

Ә син иң элек
Үзең яхшы бул,
Шул чакта бәлкем
Дөнья яхшырыр?

## Мәктәпкә кучтәнәч

Геолог абыем җибәргән
Якутиядән! —
Ящик тутырып төрле таш —
Якут төягән!

## Без — Тукай оныклары

Халкым бер тумыш көндә дә
Тукаен онытмады:
Без — «Туган тел»дән туганнар —
Без — Тукай оныклары!

## Тәртип казыгы

Бозауны башта
Малай саклаган.
Тик вакытында
Алар беркайчан
Өйгә кайтмаган.

«Беттеләр тәмам
Шаярып, азып!» —
Диган дә абзый,
Тәртип булсын, дип,
Каккан нык казык.

Казыкны йолкып,
Мунчакны чөеп,
Әй киткән бозау,
Киткән уйнаклап,
Чирәмдә биеп!

...Ул кызык көннәр
Инде үттеләр:
Малай — укуда,
Бозау — көтүдә,
Бик тәртиплеләр!

## Туган тел

Туган тел — иң татлы тел,
Туган тел — иң тәмле тел.
Тәмле дип, телең йотма, —
Туган телне онытма!

## Кояш Тимбикова

# КЫШКЫ ТАЛПЫНУ

ПОВЕСТЬ



Гадәти кичләрнең берсе иде. Шәрәфә өендә тынлык. Телевизорга каршы куелган ике креслоның уң яктагысына, иңенә мамык шәлен салып, ул үзе менеп кунаклады. Икенчесендә, һәрвакыттагыча, Карәхмәт атлы мәче бөгәрләнгән. Икәү яшиләр алар. Кайчак Шәрәфә янына дус-ишләре килә. Өйне музыка тутыра. Музыканы басарга тырышып, кычкырып-кычкырып сөйләшәләр, бәхәс кыза. Андый чакта Карәхмәт диван артына поса да, хуҗабикәсенә зур үпкә белдереп, үзенеке дип саналган креслога читтән генә карап утыра. Креслолар уртасында кечкенә генә тәбәнәк өстәл тора. Анда — телефон. Һич көтмәгәндә ул шалтырап куйды. Икесе дә сискәнеп киттеләр. Карәхмәт, атылып төшеп, диван артына керде. Шәрәфә башта телефонга, аннан стенадагы зур сәгатькә күз салып алды. Соң иде инде. Телевизор карамаган көнне, китап укып утыра-утыра, вакыт сизелми дә уза.

Шәрәфә мондый шалтырауларга әллә ни гаҗәпләнми, ияләнгән инде, ашыкмый гына трубканы алды. Беренче сүзеннән үк шалтыратучы кешенең типографиядән, производство бүлеге начальнигы Хәйрия икәнен таныды.

— Йокыңнан үк уяттыммы, Шәрәфә?

— Юк та...

Хәйрия чигенергә урын калдырмаслык итеп үтенечен ярып салды:

— Хәзер машина җибәрәм, зинһар, әзерләнеп тор да ике генә минутка килеп кит әле, сәбәбен монда аңлатырмын, яме?!

Шәрәфә бу сүзләрнең мәгънәсенә төшенеп җиткәнче, Хәйрия трубканы куеп та өлгерде, автоматның сузынкы авазлары гына ишетелеп калды.

Типографиядә бүген журналның соңгы табагын баса башларга тиешләр иде. Шәрәфә, күпме генә кабаланса да, шуны көндез, редакциянең һәр кешесе үз урынында чакта, машинага тапшырттыра алмады. «Икенче сменада, сәгать алтыларда гына баса башлыйбыз әле», — диделәр.

Инде ничә мәртәбә тикшерелгән, бөтен кирәге төзәтелгән булса да, машинада тоташ басыла башлаган битләрне күздән кичермичә, җан тынычланмый. Күп очракта юкка гына борчыласың, ә бөтенләй уйла-

маганда, шактый ук четерекле хаталар табыла. Машиналарны туктатырга, эшнең бер өлешен өр-яңадан кабатларга туры килә.

Бүген Шәрәфә эш сәгатеннән соң калып та бераз көткән иде, барыбер басарга тотына алмадылар. Машина көйли-көйли озак вакыт үтте, сабырлык бетте, артык калырга мөмкин түгел иде инде.

Күрәсең, нәрсәдер бар, болай өйдән чакыртып алулар — сирәк була торган хәл. Шәрәфә сабыр гына җыена башлады. Җылы өйдән салкын караңгы урамга чыгып китүне күңел һич өнәми иде.

Телефон кабаттан шалтырады. Шәрәфә, әйтерсең лә аны шулай да ишетәләр, ерактан ук сөйләшә башлады.

— Барам инде, барам,— диде.— Үзегезгә кирәксә, берни белән санашып тормыйсыз. Журналга кирәк булса, типографиянең бер кешесен төнге сәгать унда урыныннан кузгата алыр идеңме?..

Трубканы кулына алгач та шуңа охшаш сүзләр тезеп китмәкче иде әле ул, ничектер тыелып калды, коры гына:

— Тыңлыйм,— диде.

— Шәрәфә!

Шәрәфә буш кулы белән маңгаен сыйпарга тотынды. Төн уртасында телефоннан яңгыраган бу таныш тавышның чынлыгына ышанырлык көч кирәк иде.

— Шәрәфә, синме, исән-саумы?

Елмаюлы иреннәрен көчкә җыеп, күзләрен чытырдатып йомып:

— Биләров! —диде Шәрәфә.— Сәлам, Биләров!

— Исемемне оныттың мәллә?

Онытып булса икән! Ул исемне кычкырып әйтергә көч кирәк бит, батырлык кирәк. Каян алсын Шәрәфә андый куәтне?

— Кайлардан китереп нинди җил ташлады?

— Җилнең бер катнашы да юк, үзем килдем.

— Кәлимә дә мондамы?

— Юк, ул юк, ул булмаган да, беркайчан да!

— Ни сөйлисең син?

— Телефоннан гына аңлатырлык түгел, хәзер янына барам, Шәрәфә!

Шәрәфәнең тел әйләндерерлек тә көче калмады, бөтен тәнен сарып алган хәлсезлектән гаҗизләнеп, ул лыпылдап кабат креслога утырды. Еллар буе тыела килеп, күңел түрендә таштай катып калган хисләр өере берьюлы яңадан җанланды. Әле генә ниятләнгән эше дә, укый башлаган китабы да, өйнең рәхәтлеге дә, урамның салкынлыгы да — барысы да юкка чыкты. Хәзер бер генә хакыйкать бар иде: Кадыйр — Казанда, Кадыйр килгән, Кадыйр Биләров!

Шәрәфә соңгы вакытта Кадыйрны сабый чакта ишеткән беренче әкияте кебек итеп, инде еракта калган, тормышта бервакытта да булмаган, телдән-телгә генә сөйләнеп йөргән ләззәт итеп истә тота. Кадыйр турындагы уйларга чумса, Шәрәфә тиз генә арына алмый. Кайчак бөтенләй ят бер сүз дә аны искә төшерә. Шәрәфә шуңа да канәгать, көне буе үзалдына елмаеп йөри. Хәтта Кадыйрның кайчандыр ачуны китергән кыланмышлары да, үзәккә үткән сүзләре дә кыз өчен кадерле. Тик барысы да, барысы да, архив фондындагы язма кебек, читкә чыгармаслык итеп бикләп куелган. Очрашмауларына да ун елдан артып китте. Шәрәфә очрашуны өмет тә итми, хәтта кирәксенми дә кебек иде. Әллә кайдан, ерактан, телефон чыбыгы буйлап кына килгән сүзен ишетү әлегәчә тыныч кебек торган кичерешләрне кабат уятты. Үзен күреп, җылы сулышы белән өртелгән сүзләрен тыңласаң, хәрәкәтләрен күзәтсәң, җаныңны ничек тыярсың?!

— Шәрәфә, ник дәшмисең?— Кадыйр тынычсызлана башлады.— Әллә комачауладыммы?

«Нәрсә дияргә соң? Әлеге халәтне Кадыйрга ничек аңлатырга? Хәер, ник сөйләп-нитеп азапланырга — үзен өйгә чакырырга кирәк, тизрәк!..»

Шунда гына Шәрәфәнең хәзер үк чыгып китәргә тиешлеге исенә төште.

— Кадыйр...

— Нәрсә, Шәрәфә, кунакларың бар идеме?

— Юк, беләсеңме, мин китәргә әзерләнгән идем, бармый калырга ярамый, типографиядә журнал басылып ята, ниндидер көтелмәгән хәл килеп чыккан...

— Калдыр ла, барысын да! Нинди журнал инде ул төнге унда?!

Ул арада гына журналист хезмәтенең хикмәтләрен ничек аңлатмак кирәк? Сәгать унда гына түгел, җиде төн уртасында да журналистның җаны — үзе язачак кешеләр, ул күтәреп чыгачак мәсьәләләр кулында. Башында — башкалар язмышы, күңелендә чишелмәгән проблемалар чуалчыклыгы, кулында — кәгазь дә каләм...

— Ярамый, Кадыйр, китеп бармасаң, иртәгә кил, телефоның ничек, үзем шалтыратырмын.

— Юк, телефоннарга ышанмыйм. Үзем барам, минем башка сүз кушар кешем юк, бел шуны!

Нәкъ шул минутта ишек кыңгыравына кагылдылар. Полиграфия комбинатының шоферы иде бу.

*

* *

Шәрәфә үзенең машинага ни өчен утырганын, кай якка, ни йомыш белән барганын онытып, бу мәшәкатьле дөньядан аерылды. Аның бар вөҗүден Кадыйрга бәйле уйлар-истәлекләр биләгән иде.

Аларның очрашып-сөйләшмәгәннәренә ун елдан да артып киткәндер инде. Казанда яшәүче курсташларын күргәндә генә Шәрәфә ничек тә Кадыйрлар гаиләсе хакында берәр яңалык ишетергә тырыша һәм кайчак имеш-мимешле хәбәрләр алгалый иде.

Башта Кадыйр җитәкче органнардагы эше буенча квалификациясен күтәрү өчен Мәскәүгә укырга китте. Гадәттә, анда укучыларның гаиләләре Казанда яши иде. Кадыйр хатыны Кәлимәнең исә аерым торасы килмәде, ул, бәләкәй Гөльязын алып, башкалага барып урнашты. Ике елдан соң алар әйләнеп тә кайттылар. Кадыйр зур заводның профсоюз җитәкчесе итеп сайланды. Университетта татар әдәбиятын укыту буенча алган һөнәре шулай акрын-акрын аннан ераклаша барды.

Үзе ул моңа зур әһәмият бирми, чөнки коллективны оештыру, җитәкләү, олы эш өчен янып-көеп йөрү аның күңеленә, теләкләренә, омтылышларына туры килә.

Кадыйрлар гаиләсе Казанда яшәгәндә, алар очрашкалыйлар иде әле. Шәрәфәнең туган көне җитсә, Биләровлар өйгә беренче булып килеп өлгерә, таң беленгәнче утыралар, кайчагында кунып та калгалыйлар. Шәрәфә үзе, атап чакырмасалар, аларга тиктомалдан барып керергә яхшысынмый. Чакыру булса, һәрчак, вакыттан алда бара, тик сәгате җитмичә барыбер керми, өйләре тирәли йөреп, билгеләнгән вакытны көтә иде.

Шәрәфә мондый очрашуларны бик ярата, күрешкән көннәрдә вакыт үтүен дә сизми, соңыннан атналар буе шул кичә хакында ләззәтле уйлар кичереп йөри. Тик шикләнә: Кадыйрның бик игътибарлы, шәфкатьле булуы аны тәмам исертер дә, я елап җибәрермен, я ялвара башлармын, дип курка. «Ник болай булдык соң без, ник бергә яшәмибез? Яратам бит мин сине, Кадыйр!..» Кәефе җиде кат күкләргә менеп җиткән Кәлимәнең шаркылдавы аны сискәндереп җибәрә.

— Әйдәгез, Бюль-бюль оглы җырлавына бик әле! Кадыйр, зур люстраны сүндер, бра гына янсын! Серлерәк була ул!

Кадыйр каршы төшә:

— Җыр көенә бииләрмени?

— Хәзер бит бию көенә җырлыйлар...

Өйдә азербайҗан музыкасы яңгырый, Кәлимә, Кадыйрын каршысына бастырып, яшьләрчә бии башлый. Аның бераз кәкрерәк аягы, тактадай туры биле, май сарылган эче, бу хәрәкәтләргә ризасызлык белдергәндәй, теләр-теләмәс кенә кыймылдый башлый. Шәрәфә аларның Гөльяз исемле биш яшьлек кызларын биергә чакыра. Гөльяз рәхәтләнеп сикергәли, Шәрәфә дә көй агышына бөгелеп-бөгелеп куя, кул чаба, Гөльязның килешле хәрәкәтләренә соклана...

Соңыннан Биләровлар гаиләсе шактый еракка китте. Кадыйрны тагын да җаваплырак эшкә, башта бер шәһәргә, аннары шахталы якка, еракка күчерделәр. Берничә хат алышканнар иде, тора-бара котлау открыткалары гына салыша торган булдылар. Кайлардан гына җил ташлады икән?

Шәрәфә үзен-үзе битәрләргә тотынды: эш дип, еллар дип, шул кадәр якын дустының язмышыннан һичнинди хәбәрсез яшәү килешәмени? Авылдашлар, агалы-сеңелле кебек бергә укып йөргән сабакташлар, курсташлар арасында, болар, мөгаен, өйләнешерләр инде, дип, телгә кергән аерылмас дуслар иде бит алар. Кадыйр һич уйламаганда Кәлимәгә өйләнеп куйгач та аларның мөнәсәбәтендә үзгәреш сизелмәде. Хәер, кешеләргә, читтән күзәтүчеләргә генә тоелмады инде ул. Шәрәфә үз хәлен үзе генә белде.

Яз. Бишенче курс студентларының эшсезлектән аптырап йөри торган чагы иде. Диплом яклаганнар авылларына ук кайтып китә бара, якламаганнары яки туган йорты артык еракта булганнары көннәр буе юк эшне бар итеп гомер уздыралар.

Ул көнне Шәрәфә кичтән укый башлаган китабына капланып караватта бик озак аунады. Бүлмәдә ул үзе генә калган иде. Башка бүлмәләрдә яшәүче түбән курс студентлары иртән, дөбер-шатыр килеп, коридорны бер шаулатып алдылар да дәрескә йөгерделәр. Тып-тын булып торды. Алардан соң Шәрәфә тагын бер онытылып йокыга талып алды да кабат уянды, әмма барыбер урыныннан күтәрелми иренеп ята бирде.

Кинәт коридорда аяк тавышы ишетелде. Кадыйрның кем беләндер сөйләшкән авазлары яңгырады. Шәрәфә башын күтәреп сынап тыңлады, озак яту галәмәтеннән колагына гына ишетеләдер дип шикләнде. Юк, алай түгел, аяк тавышлары тагын да якыная төште, нәкъ Шәрәфә бүлмәсенең ишек төбенә килеп җитте. Шәрәфә, нишләгәнен уйлап-нитеп тормастан, йокы күлмәгеннән генә барып ишекне ачты. Каршыда, күзлеген елтыратып, кыешрак авызын ерып Кәлимә баскан иде. Ул коридорны яңгыратып:

— Бәй, бу һаман йоклап ята!— дип кычкырып җибәрде.

Кадыйр, яман эш кылганда тотылган кеше кебек, бусага төбендә таптанып тора.

— Киен!— диде Кәлимә моңарчы аңарда һич ишетелмәгән үзе горур, үзе боеручан, үзе шаян тавыш белән.— Шул гомер йоклыйлармы соң? Килгән бәхетең кире борылып китәр. Тор! Беләсеңме, син йоклаган арад ı без нишләдек? Өй-лә-неш-тек!

Шәрәфә бер сүз дә эндәшә алмады, күзләрен шардай ачып, Кадыйрга текәлеп торды. Аның карашында Кәлимә сүзләренә ышаныргамы-юкмы дигән сорау да, ник алай иттең дигән дәгъва да, мине кемгә калдырдың соң дигән үпкә дә бар иде.

Язмышының кисәктән шул юлга кереп китүенә әле үзе дә ышанып җитмәгән Кадыйр Шәрәфә сорауларына төгәл генә җавап бирерлек

хәлдә түгел иде. Ул күзләрен кыздан яшерергә тырышты, башын аска иде, аннары авыз эченнән генә:

— Э-э... әйе,— дип мыгырданып куйды.

Шәрәфә караватбашындагы халатны сузылып алды, аны өстенә ничек житте шулай әлде дә, сикергәләп килеп, Кәлимәнең муенына сарылды.

— Котлыйм!— диде.— Бәхетле була күрегез!

Кадыйрга да кулын сузды Шәрәфә. Әйтеләсе сүзләр Кәлимәгә әйтелгән иде инде, кабатларга теле әйләнмәде. Соңыннан ул үзалдына сөйләнгәндәй:

— Бер булырга тиеш иде инде...— дип куйды.

Хәзерге акылы булса, Шәрәфә болай җинел генә бирешмәс, Кадыйрның да, Кәлимәнең дә, үзенең дә язмышын ялгыш юнәлешкә борып җибәргән ул вакыйганы тормышка ашырмау ягын карар иде.

...Алар укытучы булырга әзерләнделәр. Мөгаен, Биләров белән Шәрәфә үскән авылда күз кунарлык, яшүсмерләрне кызыктырырлык башка һөнәр иясе булмаганга шулай килеп чыккандыр. Килеш-килбәте күркәм, өсте-башы җыйнак, сөйләгән сүзләре алтынга алыштыргысыз авыл укытучылары кечкенәдән үк Шәрәфәнең хыялы иде.

Калдык-постык чүпрәкләрдән үзе теккән эреле-ваклы курчакларны тезеп куеп та укытучы булып кылана, тирә-күрше балалары белән дә мәктәп-мәктәп уйнарга ярата иде. Кадыйрның бу теләге кайчан уянганын Шәрәфә белми. Бу турыда ул мәктәп белән саубуллашу кичәсендә, аттестатлар алган көнне генә ишетте.

Мәктәп директоры документларны өләшеп чыкты, аннары чәй табынына утырдылар, бераздан бию көе яңгырады. Пыр тузып биергә тотындылар. Көй башланып та өлгерми, малайлар үзләре теләгән кыз каршына килеп басалар да, тегесенең ризалыгын да көтеп-нитеп тормыйча, зырылдатып зал уртасына алып кереп китәләр. Иң соңгы саубуллашу вальсы белдерелгәч, Шәрәфә янына Кадыйр килеп басты. Ул башкалар кебек әрсезләнмәде. Билдән эләктереп алып, зиһеннәрне таратырлык тизлектә әйләндереп җибәрәсе урынга:

— Мин вальска әйләнә белмим, Шәрәфә,— диде.— Әйдә, риза булсаң, әкрен генә биик әле!

Вальс — Шәрәфәнең иң яраткан биюе. Иң борынгы көйләрне дә, хәзерге вальсларны да бөтен җаны-тәне белән кабул итә ул. Дөньяларын онытып әйләнергә ашыга. Биергә чакырган егет үзеннән озынрак булса, билгә салган кулында көч-гайрәт сизелеп торса, Шәрәфә, башын арткарак ташлап, күзләрен йомып-йомып алгалый. Әйләнәсең, әйләнәсең, әйләнәсең. Гәүдәң генә түгел, бөтен дөнья әйләнә, җанны сөйләп аңлата алмаслык рәхәтлек били. Андый чакта җирдән, бөтен авырлыкны үзенә тартучы, бәхетлесен-бәхетсезен, шәфкатьлесен-явызын тигез күреп, үзенә сыендыручы илаһи җирдән бер мизгелгә генә аерылгандай хис итәсең, күккә ашкандай буласың. Моңа, бердән, вальс яңгырашы, икенчедән, кешенең иркен хәрәкәте ярдәм итә. Очасың гына, аякларның кая басканын чамалап-уйлап тору юк. Онытыласың. Көйнең беренче аккордлары яңгырауга шундый ләззәт көткәндә, мин әйләнә белмим, дип ничек җибеп тормак кирәк!

Кадыйрның күзләрендә ялвару сыман чагылыш күреп, Шәрәфә баш тартырга кыймады.

— Әйдә,— дигән булды.— Әйләнә-әйләнә арып беттем инде.

Уртага керү белән Кадыйр тагын сүз башлады.

— Сине университетка бара дип сөйлиләр, хакмы?

— Хак ярым хак!— диде Шәрәфә һәм мәктәп залын яңгыратып көлде.

Кадыйр комач кебек кызарды. Гомер эчендә беренче тапкыр җитди сүз башлап караган иде, аңа да кеше төсле җавап ала алмады. Ни-

чек сөйләшергә соң бу Шәрәфә белән? Кызның күзләренә карап, теләгән соравын сүзләрдән башка гына чишмәкче булган иде ул, тик беренче мизгелдә үк карашын читкә борды, аларга карап тору мөмкин түгел иде. Ни бу? Шәрәфәне беренче күрүе түгел ләбаса.

Кадыйр белән Шәрәфә бер авыл туфрагында тәгәрәшеп үстеләр. Күрше үк түгелләр иде түгеллеген. Шулай да бер-берсенең күзенә чалынмый калган көннәре булмагандыр. Мәктәпкә йөри башлагач — әйтеп торган да юк инде. Алар икесе дә бер-берсен үз итә, якын күрәләр иде. Шулай да кайчак, башка малайларга ияреп китеп, кызларны үрти башласалар, куып-этеп шаярышсалар, Кадыйр да коры калмый, Шәрәфә бит әле бу, дип, туктап тормый иде.

Бер елны Шәрәфә вельвет тышлы түгәрәк якалы саргылт бишмәт белән озын колакчынлы куян бүрек киеп йөри башлады. Бишмәтнең күкрәк өлгесе кыска гына киселгән, итәге бишек чаршавы кебек киңәеп киткән. Киң җиңнәре беләзек турысында бөрелеп куелган. Сәер бишмәт иде ул. Авыл җирендә андыйны гомер тектерәселәре юк. Шәрәфәгә аны Казанда яшәүче туган тиешле бер апалары алып кайтты — үз кызына кечерәйгән дә Хәмдия түтиләргә бүләк итәргә булган. Апасына да кечкенә иде бишмәт. Шәрәфәгә — тап-таман. Чаршаусыман бишмәт белән куян бүрекне киеп, көзге каршына килеп баскач, Шәрәфә сөенеченнән көләргә тотынды. Матур иде шул! Үзен ул әллә нинди серле бер дөньядан килгән кеше кебек хис итте. Чабуларын җилфердәтеп-җилфердәтеп карады, зыр-зыр бөтерелде. Бүрегенең озын колакчыннарын аркасына ташлап шаярды, бәйләп-бәйләп тә карады. Хәмдия түти җиңел сулап:

— Котылдым болай булгач,— диде.— Моңа ярарлык тилгрәйкәсе дә юк бит әле аның, каян аласың?! Ә укырга йөрисе бар.

Кунак апа җәй көне кайткан иде. Салкын кышлар килеп, сәер киемнәрне кияр чак җиткәч, Шәрәфә уңайсызлана калды. Классташлары телогрейка яки гадәти генә бишмәт киеп, башларына шәл кисәге бәйләп йөри. Ул алар арасында әллә каян аерылып торачак, кыяфәте көлке булачак. Әмма киреләнер чама да юк, күлмәкчән йөрергә салкын. Тәвәккәлләргә булды Шәрәфә. Киенде дә букчасын селки-селки чыгып китте.

Урамда барганда ук бер-ике яктан үртәү сүзләре ишетелде:

— Сары чыпчык,— диде күрше малае.

Анысына Шәрәфә көлеп кенә җавап бирде.

— Әле кайчаннан бирле чыпчык сары булды соң?— диде.— Сары булгач, песнәк була инде ул.

Тегеләрнең кушаматы Песнәк иде.

Икенчесе куян бүреккә бәйләнде:

— Йомшак кына куяным, мич астына куямын...

Шәрәфә аңа сүз катып тормады, телен генә чыгарып күрсәтте.

Класска барып кергәч, инде болай җиңел генә котылып булмады. Ишектә Шәрәфә күренүгә, бөтенесе: «У-у-у!»— дип гүләшергә тотындылар. Малайлар гына түгел, кызлары да көлә, Шәрәфә артыннан ук килеп җиткән Песнәк кулы белән үк орынды. Аны этеп кенә җибәргән иде, икенчеләре килеп капшый башладылар. «Ни бу? Чүпрәкме? Тиреме? Күнме? Бер дә күрмәгән нәрсә ич? Теккәнме, коеп яки ябыштырып ясалганмы?» Чеметкәләргә тотындылар. Букчасы белән берничәсенең башына суккалап алган иде Шәрәфә, тора-бара болай гына котылып булмый башлады. Песнәк бүреккә ябышты.

— Кара, тоташ бүрек тә була икән.

— Колаклары тагын бер бүрек тегәргә җитә ич моның!

— Йоны йолкына микән?

Төрлесе төрле яктан бүрек тиресен йолыккалый башладылар. Бүрегеннән колак кагасын уйлап, Шәрәфәнең коты алынды. Ни киеп йө-

рер ул? Өйләрендәге бердәнбер шәл аңа тимәячәк бит. Аны әнисе белән олы апасы алмаш-тилмәш бәйлиләр.

Шәрәфә ачу белән каршы тора башлады. Куллары белән дә селеккәләнде, аяклары белән дә типкәләп-типкәләп җибәрде. Каршында Кадыйрны күреп кенә чарасыз калды. Моңарчы яклаучысы итеп йөрткән Кадыйр да бүрекнең ˚нәкъ маңгай турысыннан бер чеметем мамыгын йолкып алган иде. Кыз тел тибрәтеп сүз әйтмәде. Мөлдерәмә яшь тулган күзләре генә: «Кадыйр, син дә миңа каршымыни? Син дә кул күтәргәч, мин нишлим соң инде?» — дип карыйлар иде.

Укытучы кереп, барысы үз урыннарына урнашып, дәрес башлангач та Кадыйр шул карашны оныта алмады. Ник икәнен анык кына белмәсә дә, үзен начар эш кылган кешедәй тойды.

Бер уйлаганда, сабыйларча шаяру гына дип каралырга тиешле шул хәл мәктәп еллары буена Кадыйрга сабак булды. Башкалар белән тәнәфестә өелешеп-өелешеп кыйнашсалар да Шәрәфә дә, Кадыйр да бер-берсенә авыр сүз әйтешмәделәр. Хәер, мөнәсәбәтләре шуннан узмады да. Усаллык эшләмәгән кебек үк, әлләни ярдәмләшергә дә туры килмәде. Соңгы кичне саубуллашу вальсын биергә чыкканнар иде, анда да әнә сүз ябышмый. Ахырдан Кадыйр турыдан-туры:

— Мине дә алып бар әле,— диде.— Казанда йөргәнем юк бит минем.

— Ни йомышың калган анда?

— Язмышны сынап карамакчы булам.

— Әллә без язмышны, әллә ул безне сыный инде бу дөньяда, һич белерлек түгел.

Килешүләренең рәте-башы булмаса да, алар юлга бергә җыендылар. Әнисе Шәрәфәнең тиз арада әйләнеп кайтуын даулады. «Бәрәңгеләрне алабута баскан. Печәнне дә житәрлек әзерли алмадык. Казанда йөрер чакмы?..»— дип, һаман үзалдына мыгырданып йөрде.

— Алайса, бөтенләй барып тормыйммы соң әллә, әни? — диде Шәрәфә.

Ана кешегә анысы да ошамады.

— Кирегә тырнама,— диде.— Ниятләнгәнсең икән, барып кайт, әнә алтмыш йомырка санап куйдым, җитәр бит?

Казанга чыгып китәр көнне генә Шәрәфәнең унъеллыкны тәмамлагач ук күрше авылның башлангыч мәктәбендә укыта башлаган Гөллия апасы Алабугадан кайтып төште. Күңеле белән инде әллә кайчан тек-тек басып Казан урамында йөрүче сеңелесен күреп, кашын-күзен җыерды ул.

— Алабуга гына ярамас идеме? Апаңнан уздырмакчы буласың инде, ә? Безгә сайланырга туры килмәде, аттестатны алуга, эшли башладык, укуны аны җәен, ял вакытында да дәвам итеп була.

— Барып карыйм әле, апа, аннары, эш пешмәсә, күз күрер. Документлар анда бит инде.

— Күзең күктә...— Апасы, әйтергәме-юкмы дигәндәй, уйланып алды, пышылдауга күчеп, Шәрәфәнең башына да килмәгән киңәшен бирергә ашыкты.— Казанга аяк басуга, сеңелем, колхоз базарына барып, лифчик алып ки. Күптән вакыт җиткән инде сиңа. Йөрмә имиләреңне болай былкылдатып!

Әле генә апасының бөтен сүзен ихластан бирелеп тыңлап торган Шәрәфә башын аска иде. Йөзен комач каплады. «Абау! Шул турыда сөйләшер көннәр дә җитте микәнни?!.»

Апасы да бу хакта беренче киңәш ишетүләрнең никтер оят, никтер килешсез икәнен белә иде. Шулай да әйтә башлаган фикерен урта юлда бүлеп калдырмады.

— Без аны синең кебек чакта үзебез тегеп киядер идек. Казаннар-

га йөрергә туры килмәде. Сүземне тыңла. Әни йомырка бирер әле, шуны базарга чыгып сат та, алып ки!

— Ярар, апа,— диюдән башка чара калмады Шәрәфәгә.— Шулай итәрмен.

— Харис малае белән барасың икән, кара аны, җебеп төшмә! Харисныкылар тыштан гына песием-песием булып күренәләр.

Гөллиянең бу сүзенә гаҗәпләнерлек түгел. Малай халкына алар өендә, Шәрәфә белә башлаганнан бирле, шул караш яши иде инде. Әтиләре фронтта ятып калмаса, бу кадәр үк каты тормаслар да иде, бәлки. Өйдә ир-ат заты булмагач, Хәмдия түти кызларын йөзгә кызыллык китермәслек итеп тәрбияләүнең иң беренче шарты итеп аларны егет халкыннан сакланырга өйрәтте.

Апасының Шәрәфәгә ясаган кисәтүе артык та иде хәтта.

— Беләм инде, беләм,— диде ул.— Харис малае белән ун ел бер класста укудым, кирәк булса, тотам да тукмыйм мин аны.

Нәкъ шул чакта капка келәсе шалтырады. Ишегалдына чалбары бик әйбәтләп өтеләнгән, чәче тигезләп алынган, аксыл күлмәк, билдән кысып төймәләнә торган кыска куртка кигән Кадыйр кереп басты. Өйгә үтәргә кыймый шактый торгач, Шәрәфә үзе чыкты.

— Ник кермисең?

— Анда, ындыр табагында, пристаньга китүче машина бар, җыенып беткән булсаң, әйдә, киттек.

— Мин бармасам нишләрсең?

— Бармасаң, бармыйбыз гына инде.

Шәрәфәнең такта чемоданы кичә кичтән үк тутырып куелган, болдыр баскычы өстендә тора. Өйгә кереп тормаса да була. Кыз, Кадыйрны шатландырырга теләп, чыннан да шул чыгуыннан ук кузгалып китәргә чамалады.

— Апа,— дип, өй эченә кычкырды.— Мин китәм. Кадыйр алырга килгән энә.

Чемоданын күтәреп, әле һаман ишегалды уртасында каңгырап торган Кадыйрга сузды. Үзе бәрәңге бакчасы ягына атылды.

— Әни, китәм. Харис абый малае алырга килгән. Машина бар, ди.

Алабута йолкый-йолкый куллары яшелләнеп беткән, терсәгеннән туфракка баткан Хәмдия түти үзе дә күренде.

— Хәерлегә!— диде.

Гөллия сүзсез генә елмайды. Өйдә калучыларның бөтен торышында: «Бер ниятләгәч, әйләнеп кайтыгыз инде, бөтен кешегә укырга димәгән. Авылда да эш муеннан. Барам дисәң, бүген фермага алалар. Сыер савучыларга эш хакы да шактый бирелә — укыган кешедән бер төшләре дә ким түгел»,— дигән мәгънә ярылып ята иде.

— Теләктә торыгыз!— диде Шәрәфә.— Бөтен кешегә фермада эшләргә димәгән. Барып кайтыйк әле, бәлки керербез.

Кадыйр баш иеп кенә саубуллашты да урамга чыкты. Шәрәфә дә шул якка атлады. Капка ябылыр алдыннан ул тагын әнисенә борылып карады.

— Керерeңнән элгәре чыгарыңны уйла, кызым. Бабайлар шулай дигәннәр.

*
* *

Кадыйр шактый вакыт Кәлимәне күрми йөрде. Күрешү кайгысы идемени соң аларда?! Бер урынга җиде кеше, диделәр. Коридорда очраган һәр абитуриент шул ук син теләгән урынны дәгъвалый сыман. Танышуыңнан танышмавың артыграк. Шәрәфә белән Кәлимә бер бүлмәгә билгеләнгән булып чыкты.

Билгеләнү дигәннән, анысы да мең мәшәкать икән. Башта көчкә университетны эзләп таптылар. Кадыйр берни белми, бар ышаныч Шәрәфәнең хәтерендә иде. Ул, бишенче классны тәмамлагач, Казанга, теге сары бишмәт бүләк иткән апаларына кунакка килгән иде. Алар Кремльгә, шуннан туры гына университет янына баргалап йөрделәр. Бу мәшһүр уку йорты турындагы хыял да шушы чакта кабынды. Яхшы хәтерли иде Шәрәфә: Кремльнең сәгатьле ак манарасыннан туптуры баргач, Ленин укыган университетка килеп чыгасың.

Кыз, пароходтан төшүгә, Кадыйрны Кремль янына алып китте, шома ташлы шактый текә таудан меңгезде. Баксаң, университетның үзенә туп-туры бару җиңелрәк булган икән.

Аларга халык телендә Арча кыры дип йөртелә торган яктагы тулай торактан урын бирделәр. Расписаниедән консультацияләрнең, имтиханнарның кайсы көндә булачагын күчереп алдылар да ары киттеләр. Кадыйр, бар егетлеген сабырлык капчыгына төйнәп куеп, Шәрәфәгә буйсынып баруында булды. Кыз монысын да чамалый, Арча кырына китүче трамвайларның Ленин бакчасына каршы якта туктаулары белә иде.

Тик бу килеш кенә тулай торакка кертмиләр икән. Ябык кара хатын:

— Санпропускниктан справка кирәк,— диде.

— Анысы ни тагын?

— Мунча керегез,— дигән сүз. Юынып килмичә чиста урын-жиргә яткырмыйм.

Шунда гына Кадыйр үзенең егетлеген күрсәтеп маташты.

— Мин кичә генә мунчада юындым, апа, үз мунчабызда, авылда, кертегез мине!

— Справкаң бармы?

Авыл мунчасында түгел, хан сараеның алтын читле бассейннарына чумып чыксаң да, кулыңда акка кара белән язылган белешмәң булмаса, тулай торак бүлмәсенә керергә ярамый икән. Ул язуны алыр өчен исә мунча керүеңнең дә кирәге юк. Утыз ике тиенлек билет алгач, мунчачы хатын Шәрәфәгә бармак бите кадәре генә кәгазь кисәге сузды.

— Юынып тормыйсыңдыр бит?— диде.

Ике-өч минуттан алар мунча ишеге төбендә Кадыйр белән очраштылар. Аңа да, чишенеп-юынып тормаска киңәш итеп, кирәкле кәгазьне кулына тоттырып чыгарганнар.

— Кызык икән монда,— диештеләр.— Дөрес түгел бит инде бу?!

Ничек булса булды, аларга бүтән бәйләнмәделәр, урын-җир кирәк-ярагы күтәртеп, тиешле бүлмәләрен күрсәтеп, тулай торакның өченче катына менгезеп җибәрделәр.

Шәрәфәнең бүлмәсе ачык иде. Түр башындагы караватта, ап-ак ятак өстендә пуфылдап бер кыз утыра. Ул Шәрәфәне:

— Ниһаять!— дип каршылады.— Ялгыз башым кая барып бәрелергә белми аптырадым. Ник бик озак килми тордың? Кайсы факультетка? Исемең ничек?..

Керергә теләгән бүлекләре бер үк иде.

Шәрәфә исемен әйткәч ул да сөйләп китте:

— Минеке — Кәлимә! Мәгънәсен беләсеңме? Юктыр. Сүз дигән сүз ул, минем исемем җисемемә туры килгән. Сөйләшергә кеше булмаса, эчләрем поша, телем кычыта башлый...

Шәрәфәнең көләсе килде. Аның күңелен, албасты баскандай, алда торган имтиханнар куркыта иде. Башкаларда да шул ук хәл, монда берәү дә сүз сөйләп, бытылдап яту өчен килмәгән. Кәлимә генә сәер күренә. Ул утырган җиреннән сикереп торы да Шәрәфәнең каршысына ук килеп басты.

— Килешәме?— дип сорады.

Нәрсәсенең килешү-килешмәве белән кызыксына икән соң бу: күлмәгеме, яулыгымы? Шәрәфә уйлап өлгергәнче, Кәлимә пыр-пыр әйләнгәләргә тотынды, кыска итеп киселгән чәчен куллары белән туздырып җибәрде.

— Менә! Яңа гына кыскартып кайттым. Шәһәрдә барысы да шундый чәч белән йөри. Әйдә синекен дә кисәбез. Әбиләребезнең, әниләребезнең чәч тарый-тарый чиләнүләре дә житкән!

Әллә ни калын, озын булмасалар да, Шәрәфә толымнарын ярата иде. Күкрәкләреннән аз гына түбәнгәрәк салынган толымнарын кулларына алды. Әйтерсең лә, Кәлимә аның ихтыярыннан башка кисеп ташлый инде үзләрен.

— Тукта, сабыр ит, урнашыйм,— диде.— Чәч кистерерлек эш кылганым юк бит әле.

Кәлимә тагын көләргә тотынды. Аның һич кенә дә тик торырлык сабырлыгы калмаган. Шәрәфәнең артык акрын кыймылдавына, бернн белән дә кызыксынмавына ачуы чыкты аның, тагын сорау тапты.

— Син мине кайсы районныкы дип беләсең?

Шәрәфә мендәренә ак тыш кидерә иде.

— Белмим шул,— диде. Чыннан да, ник сорамый тора соң әле ул аның районын. Хәер, Шәрәфәнең дә кайдан икәнен белмидер бит ул. Үзе ник сорамаган соң? — Каян белим?

— Мин синекен чамалыйм,— диде Кәлимә.— Я Чистай, я Чирмешән мишәре син. Мишәрләрне әллә каян белеп була.

Шәрәфәнең ачуы чыкты.

— Син дә әллә кем түгел инде,— диде елмая төшеп.— Минзәләнең «кыдыл бодавы»дыр әле, сүзеңне аңлап та булмый.

— Бәй, хак әйтәсең!— Кәлимә рәхәтләнеп көлеп алды.— Болай булгач, бүген паркка чыгабызмы соң? Андагы тансыларны күрсәң, малай, башларың әйләнеп, егылып үләрлек...

— Минем чәч озын бит, кертмәсләр.

— Әй, гел кирегә борып маташма инде, тимим чәчеңә, тимим.— Кәлимә сынап карап алды да, очып-кунардай булып, тагын Шәрәфәгә килеп ябышты.— Беләсеңме, синең йөзне чәчеңә караганда кашың күбрәк боза. Күрче, чабата сыман кашлар! Әллә кайчан йолкып атасы булган. Миндә эскәк бар, тигезлә үзең. Борын төбеңдә дүртәр төк калдыр, очына таба нечкәртә бар.

Шәрәфәгә монысы бөтенләй ошамады. Әле бик кечкенә чакта ук аңа Миһривафа әбисе тәкърарлый торган иде:

— Балакайларым, әйткән сүземне тотыгыз, кашыгызга кул тидерсәгез, риза-бәхил түгелмен. Кыз бала булгач, бизәнми йөрмәссез. Сөрмәсен тартырсыз, иннеген сөртерсез, кершәнен дә ягарсыз, кашыгызга тотынмагыз. Кашы йолкынган хатыннан да чиркангыч зат юк.

Шәрәфәнең, әбисе сүзләрен кабатлап, үзеннән көлдерәсе килмәде, шулай да эндәшми калмады:

— Син тигезләгәнсең инде әнә, нечкәрткәнсең, шул житкән. Икебездә дә бер төсле каш булгач, кызыгы китәр,— диде.— Паркка да бармыйм, танцысына да исем китми, урынны җайлап куям да укыйм мин хәзер. Башымда бернәрсә калмаган төсле, ике көннән сынау бит, үләм!

Кәлимә, Шәрәфә белән артыгын сөйләшә торгач, үз ниятенең суына башлавыннан курыккандай, кулын кисәк кенә селтәп алды да бүлмәдән чыгып китте.

Әгәр кешеләрнең холыкларын төсләр белән билгеләп булса, төсләрне бер-берсенә каршы куярга яраса, бу кызларның холкын ак һәм кара дип күрсәтергә туры килер иде. Шунысы гаҗәп: холыклары капма-каршы кешеләр еш кына гомер буе бер-берсеннән аерылмас дус-

лар булып китә. Кәлимә белән Шәрәфә арасындагы мөнәсәбәт тә мең каршылык аша шул дәрәҗәгә житте.

Кадыйр исә, танышулары кавышу белән тәмамланса да, Кәлимәне алдан күп очраттым, күп күрдем, дип мактана алмый иде. Керү имтиханнары биргән чакта Кәлимәне ике тапкыр гына күреп калды.

Кадыйрның тарихтан бишле алган көне иде. Сөенечен кем белән уртаклашырга белми, шәһәр урамы буйлап, ары сугылып, бире кагылып, озак кына йөргәч, ул тулай торакка кайтты. Вакыт шактый соң иде инде. Шәрәфә дә өйдә булырга тиеш. Эче тулы шатлыктан тәмам канатланган егет, үз бүлмәсенә кагылып та тормастан, туп-туры Шәрәфә бүлмәсенә юнәлде. Ишекне шакыгандай гына итте дә, җавап-фәлән көтеп тормыйча, барып та керде. Ишек төбеннән бер генә адым алга атлаган иде, нишләргә белми тораташ булып катты. Бүлмә уртасында анадан тума чишенгән сылу кыз басып тора. Ул, ишеккә арты белән борылганга, Кадыйрны бөтенләй абайламады, егет исә, кыймылдап кына куйса да, кызның коты алынудан курка, шул ук вакытта үзен дә ярамаган эш кылучы итеп тоя иде. Икенче мизгелдә ул, ни булса шул дип, кырт борылып, коридорга сикерде, үз бүлмәләренә ашыкты. Тик аңа каршы кулына кайнар таба, чәйнек тоткан Шәрәфә килә иде.

— И Кадыйр, әйдә, тот әле чәйнекне!— дип Шәрәфә, аны еректан ук күреп, үз янына чакырды.— Кулым пешә, бетә-әм!

Кадыйрның, йөгереп барып, кыз кулындагы кайбер нәрсәләрне алудан башка чарасы калмады.

Алар, документларын икесе дә бер үк көнне җибәрсәләр дә, имтиханнар биргәндә икесе ике группага билгеләнгән булып чыктылар. Шунлыктан «сират күпере» кичү минутларында бер-берсен күрмиләр иде.

— Ничек бирдең, Шәрәфә?

Кыз үзе турында сөйләргә тотынудан элек Кадыйрны котлады:

— Ишеттем, бишкә биргәнсең икән. Әйбәт булган. Мин дә бирдем, минеке дә — биш.

Кадыйрның шатлыгы икеләтә артты.

— Бишле булмаса, һич үтәсең юк монда,— диде.— Тагын икесенә чыдасак...

— Түзмичә ярамый.

Шәрәфәнең гел шулай аның — кырт кисеп куя, кысадан чыкмый, акыл кушканнан башкага тайпылмый.

Алар минут эчендә Шәрәфә бүлмәсенә килеп тә җиттеләр. Кадыйр аны-моны әйтмичә генә артка чигенде. Әгәр теге кыз һаман шәрә булса, Шәрәфә бүлмәгә керергә рөхсәт итмәс, дип көтте. Андый-мондый кисәтү ишетелмәгәч, түргә үк узды Кадыйр. Бая таш сындай басып торган сылу кыз инде өстенә кыска гына матур күлмәк кигән, һаман көзге алдында боргалана иде. Бүлмәгә кеше керүенә әллә ни исе китмәде.

— Исәнмесез, кем дип белик?— диде.

— Кадыйр.

— Мин — Кәлимә.

Кадыйр башта кызга күтәрелеп карарга кыймый торды. Кәлимә аңа: «Кызларның кием алыштырган вакытында рөхсәтсез кереп йөрү оят түгелме сиңа?», дип бәйләнер кебек иде. Өстәвенә, җанны кытыклап, күз алдында әле генә күргән гәүдә тора.

Кәлимәнең һичнинди битәрләү-фәләне сизелмәгәч, Кадыйр кызга кырын-кырын гына күз салгалап алды. Шәрә гәүдәсе сынны катырып калдырырлык тәэсир иткән булса да, Кәлимәнең йөзендә кычкырып торган чибәрлек юк. Шактый ямьсез кысалы, калын пыялалы күзлек аша мәченекедәй сыек яшел күзләр эчеңне актарырдай итеп карый-

лар, өзлексез елмаялар. «Уф, беттем, сизгән бугай бу»,— дип уйлады Кадыйр, бая үзенең бүлмәгә кереп пошамангa төшүен онытa алмыйча. Бүлмәгә кереп чыгучының Кадыйр икәнен белсә, кыз хәзер турыдан-туры ачуланмаса да, берәр төртмә сүз әйтергә тиеш иде. Кәлимә аны-моны эндәшмәде. Караваты өстеннән бер чүпрәк кисәге алды да, аның бер читеннән генә тотып, югарыга чөйде.

— Миңа карагыз, болытсыман яулыгым бар минем, матурмы?— диде.

Яулык чыннан да зәңгәрле-яшелле, төтен кебек бик җиңел, үтә күренмәле тукымадан ясалган, үзе шактый зур булганга, бүлмә биеклегендә чыннан да сәер болыт булып тоелды.

Кадыйр, сүзнең башка юлга кереп китүенә сөенеп:

— Матур, матур,— дияргә ашыкты.

Шәрәфә генә үз холкына тугры булып калды.

— Ничек синең кибет буенда йөрергә күңелең күтәрелә, Кәлимә,— диде.— Без бер минутны кырыкка ярырга тырышабыз, вакыт җитми.

— Бәй, минем селдә ни эшем бар?— Минзәлә кызы үз якларындагыча «з» урынына «д» авазы әйтеп сөйләшә иде.— Подумаешь, экдамен. Ун ел буе укып белә алмаган нәрсә хәдер генә башка керми инде ул. Кире китәргә туры килсә, кала күреп калыйк, ичмаса — тансыларын, киноларын, кибетләрен... Шулай түгелмени?

Кәлимә Кадыйрдан үз сүзләренә хуплау көтте. Юк, Кадыйр аның яклы түгел иде, әмма егет яшел күзләрнең күңелне айкардай көченнән котыла алмады.

— Гомер бер генә! — диде.— Аны үз җаның теләгәнчә кичә белергә кирәк.

— Во! Менә, ичмаса, бу — егетләр җавабы, китәбедме киногa?..

Кадыйрның икеләнеп торуын сизеп, кире җавап ишетергә теләмичә, Кәлимә сүзне үзенчә борып алып китте.

— Әй, бара алмыйм икән шул.— Ул Кадыйрның каршына ук килеп басты.— Кичерә күр, егет, бара алмыйм, икенче берәү белән очрашырга вәгъдә биреп өлгергән идем.

Шаяруга каршы шаяру, көлү белән җавап кайтарды Кадыйр. Күңеленнән исә бөтенләй башка нәрсә уйлады. «Мин бит сине шәрә килеш күрдем, җен кызы, үзең сизми дә калдың.— Аннары егет башына яңа төрле фикер килде.— Әллә ул да мине күреп калды микән, шуңа чытлыклана түгелме?»

— Син башка белән китсәң, без әнә Шәрәфә белән паркка барып килербез.

Кәлимә, Шәрәфәгә ымлап, эче катып көлә башлады.

— Бу кешене бүлмәдән алып чыгып китәлсәң, Казан каласы урыныннан кузгалыр, андый бала түгел ул.

Шәрәфәнең ачуы да чыга башлаган иде инде, ул сүзне икенчеләйгә борды:

— Чәйне суытып бетерәсез, әйдәгез, утырыгыз. Имтиханнан кайтышлый бәрәңге алдым. Сары майда кыздырдым, килегез, телеңне йотарлык булган...

Кәлимә Кадыйрга телен чыгарып күрсәтте.

— Менә шулай, бәбкәчем, тансы-мансы урынына сары майлы бәрәңге аша!

Кадыйрның моңарчы кирәксә-кирәкмәсә Шәрәфә янына кереп йөрү гадәте юк иде. Болытсыман яулыгын муенына урап, Кәлимә шәһәргә чыгып китте, Шәрәфә белән икәү генә калгач, егет:

— Әллә киләсе экзаменга бергә әзерләникме?— дип куйды.— Безнең бүлмәдәге егетләрнең өчесе дә кайтып китте. Берүзем калдым.

— Икеле алдыларммыни, бичаралар?

— Төрлесе булды инде.— Кадыйрны сүзнең бу ягы кызыксындырмый иде.— Ничек соң, бергә әзерләнергә ризамы?

Шәрәфә ояла-ояла:

— Ярар, керермен,— диде.

Кадыйр әрсезләнеп аны төзәтүен үзе дә сизми калды.

— Юк, мин үзем керәм.— Чынында аңа менә шушы бүлмәдә гел булып тору кирәк иде. — Сездә яктырак димме шунда.

— Алайса, әйдә, хәзер үк укыйк, кая китап-дәфтәрләрең, әллә минеке дә җитәрме?

— Бик ашыксаң, авызың пешәр,— Кадыйрга Шәрәфәнең өзлексез китапка капланып утыруы һич ошамый.— Ичмасам, кичкә кадәр ял тиештер бит инде. Кичен керермен. Ял ит син дә.

Бергәләшеп укып утырулар барып чыкмады. Кичен дә, хәтта төн урталарында да Кадыйр монда керепкереп йөрде. Шәрәфә, караваты өстенә менеп утырган да, чайкала-чайкала укый, укыганын күңелендә калдырыр өчен яттан сөйләп-сөйләп тә ала. Кергән саен:

— Соң, әйдә, утыр, бергә укыйк, дигән идең бит!— дип, Кадыйрны да янына чакыра.

Кадыйр исә кереп баса да, үзе дә сизмәстән, көндез Кәлимә басып торган төшкә текәлеп, казыктай катып кала. Аннары: «Әй, минем бүген укыйсым килми әле, Шәрәфә,— ди.— Иртәгә иртәдән тотынырмын инде».

Шәрәфә аңа гаҗәпләнеп карый: «Алай булгач, ник мең кереп, мең чыгып йөрисең?»

Төнге сәгать уникеләр якынлашып килә иде. Кадыйр тагын керде. Әле һаман укып утыручы Шәрәфә, халатының чабулары белән тезен япкалап:

— Әй, тагын син икәнсең,— диде.— Мин, Кәлимә генә кайтты дип, туарылып утырам.

Ниһаять, Кадыйрга да сорар җай чыкты:

— Әле ул юкмыни? Кая соң?

Шәһәр җирендә төнге уникедә дә өенә кайтмаган кеше кайда булырга мөмкин? Шәрәфә аны каян белсен.

— Ул һәр көнне шулай йөри. Тик бу кадәр үк соңга калганы юк иде.

Кадыйр башка керергә кыймады. Кәлимә ул кичне бөтенләй кайтмады. Күп укудан күз аллары әлҗе-мөлҗе килә башлаган Шәрәфә, ишекне эчтән элеп, япа-ялгызы ятып йоклады. Алтыда ук уянып сикереп торды. Бүлмәдәше урынында юк иде.

Моны култык астына китап-дәфтәрләр кыстырып килеп кергән Кадыйр да беренче мизгелдә үк сизеп алды.

— Әллә синең «болытсыман яулыгың» бөтенләй кайтмаган инде?

— Нишләргә соң, Кадыйр? Югалган кешене каян, ничек эзлиләр икән монда?

Егет, кемгә ачулануын үзе дә белештермәстән:

— Кызлар югалса, аларны беркаян да табып булмый инде,— диде.— Ярар, мин укырга кердем, әйдә, башлыйк. Нишләгәнен үзе беләдер.

Кәлимә төшләр узгач кына кайтты. Очынып керде дә ишектән, тәрәзә төбенә килеп, пыялага капланды. Куллары, бармаклары тәрәзә аша кем беләндер сөйләшә башлады. Шактый кылангач кына, бүлмәдәгеләргә игътибар итеп, тагын тәрәзәдән урамга төртеп күрсәтте.

— Әнә ул!— диде.

Шәрәфә дә, Кадыйр да, бу хәлнең ниләр аңлатуын белергә теләп, ихтыярсыздан тәрәзә янына килделәр, урам якка карадылар. Анда озын буйлы, кара чәчле, кыска җиңле ак күлмәк кигән бер егет туптуры тәрәзәгә текәлгән иде.

— Күрдегезме? Апагыз әнә шул егет солтанына кияүгә чыгып кайтты.— Кәлимә кая басканын, ни сөйләгәнен чамаламас хәлдә иде.— Менә, ул бүләк итте,— дип аягындагы кызыл киндер босоножкаларын күрсәтте.— Авылдан киеп килгән чүәкләремне яратмаган иде, бер кибеткә керде дә алды да бирде. Әллә кайчан кызыгып йөридер идем.

— Чүпрәк чабата инде.— Кадыйрның кашы-күзе җимерелеп төште. Өстәл өстендәге китабын шапылдатып ябып куйды. Ашыгып чыгып китте.

Шәрәфә бу хәбәрдән өнсез калган иде. Сүз табалмый шактый озак азаплангач:

— Кит моннан, башка сыймый бу минем,— диде.

— Сыя ул!— Кәлимәнең авызы колагына җиткәнче ерылган.— Бездең якта егетләр белән куна йөрү гадәте бар. Миңа, әле сигездә укыганда ук, үдебеднең укытучы белән дә кунарга туры килгән иде. Бернс дә юк аның.— Кыз баскан урынында сикергәләп куйды.— Сашаны ул кунулар белән чагыштырып булмый, бусы — бөтенләй башка.

— Имтиханыңны бирәлсәң ярый инде,— диде Шәрәфә.

— Әй, Шәрәфә! Син дә дөньяда яшим дисең инде, ә! Китап, дәфтәр, имтихан, мәктәп, университет — нинди кысаларга бикләгәнсез сез үзегезне, просто кызганыч. Хис белән яшәргә кирәк. Саша шулай, ди. Дөньяда бер генә яшибез, бер генә! Имтихан! Нәрсә ул имтихан? Кеше имтиханны көн дә бирә — үз-үзе алдында: дөрес үткәрәме ул шушы көнен. Җанына рәхәтлек китерә аламы? Мине хәзер китаплар, имтиханнар гына канәгатьләндерми, минем хисләремә җирлек кирәк.

— Хис бер синдә генә түгелдер инде ул?

— Әллә үзеңдә дә хис бар, димәкче буласыңмы, Шәрәфә, аллам колы? Хисле кеше тәүлек буе «ә-ө-ү-һ» дип, хәреф ятлап утыра аламы? Юк. Үлгән ул синең хисең, яки бөтенләй тумаган да әле. Тумавы хәерлерәктер, мөгаен, син аны барыбер дөнья рәхәте күрсәтми тончыктырыр идең.

— Кеше эчендәгене кеше белми.

— Әй, бәбекәчем, булган нәрсәне каплап куя алмыйсың аны, хис бит ул, хис! Сиңа канат үстерә, очырта, шаштыра, дөньяңны оныттыра ул...

— Мөгез чыгармый гына йөреп торучыларда хис юк инде, синеңчә.

— Белмим. Һәрхәлдә, миңа андый хис кирәкми, шаштыра торганы булсын, акылны җуйдыра торганы. Мин ярым-ярты акыл, ярым-ярты хис белән яши алмыйм. Бирелсәң, тоташ бирелергә, янарга, көл булырга, онытылырга кирәк!— Кәлимә кинәт сискәнеп куйды.— Бәй, онытылырга дигәннән, чыннан да онытканмын ич. Мин әйберләремне алырга гына кердем монда, Саша көтә бит, бәбекәчем!

Саша — әллә мари, әллә керәшен татары иде. Эстрадада концерт алып баручы сүз остасы.

— Парктагы концертта таныштык, бер генә минут та аерым яшәр чарабыз юк,— дип аңлатты Кәлимә.

— Укуың нишли инде болай булгач?

— Мин бер өчле алган идем инде, китәм, синең кебекләргә конкурс кечерәя төшсен.

— Документларың?

— Соңыннан, барысы да соңыннан! — диде Кәлимә.

Ул инде, юклы-барлы әйберләрен җыеп, кара клеенка тышлы чемоданын шыртлатып бикләгән иде.

— Хуш, акыллы баш кызый! Бәхет телә миңа,— диде дә бүлмәдән чыгып чапты.

* * *

Һич көтмәгәндә җанны тәмам биләп алган яшьлек хатирәләре тәэсирендә Шәрәфә типографиягә җитүләрен сизми дә калды. Кәгазь өемнәре, басу машиналары арасына килеп кергәч кенә уйлар бүгенге көн мәшәкатьләренә күчте.

Типографиянең эшкә яраклы бөтен машиналары җаваплы секретаре Шәрәфә булган журнал табакларына көйләнгән иде. График буенча шулай каралган. Бүгенге икенче смена журналны тәмам өлгертеп җиткерергә, иртәгә «сигнальный» дип аталган беренче данәләрен редакциягә тапшырырга тиеш.

Цехта мәет чыккан йорттагыдай тынлык. Директорның үзен дә машиналар арасында күреп, Шәрәфә мәсьәләнең җитдилеген тиз аңлады. Журналның баш редакторы да очрар дип көткән иде дә, анысы күренмәде. Килеп җитмәгәндер. «Ни генә булды икән бирәдә?»

Производство бүлеге начальнигы Хәйрия, Шәрәфәне күргәч, елмаеп ук куйды.

— Бер табакта бәләкәй генә брак китә.— Сүзен исәнләшүдән дә, вакытсыз кузгатуы өчен гафу үтенүдән дә башламады ул. Редакция хезмәткәрләренә һәрчак ихлас ихтирам белән караучы Хәйриянең мондый игътибарсызлыгы хәлнең шактый мөшкеллеген тагын да ачыграк күрсәтә иде.— Өч сәгать азапланабыз. Эшчеләрнең кәефе кырылды. Аларның эш хакы сдельный бит. Директор да пошаманга төште, планның өзелүе мөмкин.

Шәрәфә бракны табакны карады, журнал битенең кыл уртасында ике катлы сыр калып бара икән. Басыла торган сүзләргә зыян килми, бер фоторәсемнең чите ямьсезләнеп чыга.

— Әллә ни юк инде үзе. Укучы аңа игътибар да итмәячәк.

— «Әлләние» булмагач әйтеп торасыгыз да калмаган.— Редакция коллективының айлар буе эзләп табылган иҗат нәтиҗәсе типография тарафыннан ямьсезләнеп чыгарылуына Шәрәфәнең ачуы кабара башлады.— Укучыга без мөмкин кадәр матур эшләнгән журнал бирергә тиешбез.

— Сезнең рөхсәт булмаса, без бу килеш баса алмыйбыз.— Хәйрия кинәт күңелсезләнде. Аның елтыр күзләренә дым бәреп чыкты. Тагын да зуррак аңлатма сорый башласалар, ул елап җибәрергә дә әзер кебек иде.— ОТК диган нәрсә бар бит әле. Ул үткәрмәячәк. Сез каршы килмәсәгез, Шәрәфә Шакировна...

— Ничек инде мин? Баш редакторга хәбәр иттегезме соң? Журнал өчен төп җаваплы кеше ул бит, беләсез инде.

Хәйрия башын чайкап куйды.

— Аңа әйтмәвең яхшы... Әле мондый сырлар китмәгәндә дә, башыбызны бәладән чыгармый. Я буявы тигез төшмәгән, я срокка сыймаганбыз, я кәгазьнең начарын биргәнбез — дәгъваләшүдән туктатыр хәл юк.

— Таләпчән ул, принципиаль.

— Теләсәң ни диген, тик мин аңа сүз куша алмыйм.

Шәрәфә шунда гына төнге чакырылуның ни дәрәҗәдә катлаулы икәненә төшенде. Типографиянең бер төркем кешесе ясаган кимчелекнең бөтен авырлыгын ул бер ялгызы өстенә алырга тиеш иде.

— Сез — җаваплы секретарь, сезнең хакыгыз бар.— Хәйриянең урынсыз кыставы Шәрәфәне бөтенләй чарасыз калдырды.

— Андый хокукны ник үз кешеләрегездән эзләмисез соң, Хәйрия? Кайда ремонтник, ник машина дөрес көйләнмәгән? Әллә кайчан дөресләтер идегез.

Хәйрия сабыр гына аңлатырга тотынды.

— Машиналар тәзек. Кәгазь дым тарткан булып чыкты. Складта чакта әйбәт күренгән иде, цехка кергәч, җебеп китте. Юеш. Майдан башлап, җәй буе, көз буе янгыр койды бит. Шуңа күрә кәгазь киңәя дә җыерыла.— Шәрәфәнең тынычлана төшүен сизеп, ул иң соңгы мөмкинлеген дә әйтте.— Сез бөтен тираж шундый була, дип уйламагыз тагын! Менә шушы кәгазьләр беткәнче генә җыерылачак ул. Иртәгә иртән корыны табабыз. Сезнең йөз меңләгән тиражда сизелмәячәк тә ул.

Шәрәфә үзе дә сизмәстән:

— Шулаймы?..— дип ычкындырды. Бу аның килешүгә таба ясаган беренче адымы иде. Шәрәфә бер тапкыр алга омтылса, кире чигендерермен димә инде. Теләсә дә булдыра алмый ул аны. Шулай да ул Хәйриягә яңа сораулар бирде.— Күпмесе шулай басылачак соң?

— Аз, дүрт-биш мең генә.

— Меңнәр белән шаярабыз, Хәйрия, ә?

Инде килешү тәмам, дип уйларга да мөмкин иде. Башка чак булса секретарь болай җиңел генә бирешмәс һәм чигенмәс иде, әлбәттә. Дистә еллар буе хыялында йөрткән Кадыйрның монда чыгып китәр алдыннан гына тавышын ишетү, аны күрергә мөмкинлек Шәрәфәне бөтенләй кысадан чыгарды. Аннары редакция үзе дә типографиягә төрле үтенеч белән гел кергәли бит: я инде басыла башлаган берәр мәкаләне үзгәртергә, я бик начар сыйфатлы тарихи фоторәсемнәрне үткәрергә кирәк булып чыга. Редакция гаебе белән кайчак машиналар да туктап тора. Андый мәшакатьләр өчен һәрчак Шәрәфәгә типография хуҗалары алдында йөз суы түгәргә туры килә. Инде менә типографиядә ничә елга бер очрый торган мөшкел хәл туган. Көз явымлы, агачлар кипми, кәгазь комбинаттан ук артык дымлы булып килә. Шәрәфә белә моны, аңлый. Хәзер бары тик кагыйдәгә ышыкланып кына: «Юк, мин мондый нәрсәгә юл куя алмыйм» дисә...

Боларның гәпләшүен, бәхәсен әллә кайчаннан бирле мыштым гына тыңлап торган директор да Хәйрия янына килеп басты. Мәһабәт гәүдәле, үзен һәрчак горур тотучан, аз сүзле, цехлар эшенә тыкшынмыйча, хәбәрне күбрәк Хәйрия аша гына ишетеп торучы Григорий Матвеевич, әйтерсең, Шәрәфәнең кабат икеләнә башлавын чамалап:

— Шәрәфә Шакировна, типографиягә сез генә булыша аласыз. Уңайсыз очрак бу,— дип башлап җибәрде.— Квартал планы, еллык план — барысы да шуңа бәйле...

Шәрәфә озын сүзне яратмый.

— Болай инде, Григорий Матвеевич,— диде ул.— Бүгенгесен, тешне кысып булса да үткәрик, алайса. Мин белдем, рөхсәт иттем. Әмма иртәгә эш көне башлануга, мин баш редактор белән дә киңәшермен. Ул эшне зургарак җибәрә-нитә калса, авырлыгын бергә күтәрербез...

Аның шул сүзен генә көтеп торган шикелле, директор:

— Машина сезне көтеп тора анда, Шәрәфә Шакировна,— диде.— Без сабырсызларны гафу итә күрегез инде. Кайтыгыз, ял итегез...

...Төннең калган өлешен керфек какмыйча үткәрде Шәрәфә. Бу юлы аның уйлары еракка китмәде: типографиядә булу мәсьәләсе чуалчыграк иде. Шактый четерекле яңалыкны баш редакторга ничегрәк хәбәр итәчәген ул төрле вариантта күз алдына китерде. Бәлки иртән базарга кагылырга, матур чәчәк бәйләме ала барырга кирәктер? Редактор, инде җиденче дистәсен тутырырга торган ханым, Ригага кунакка барып кайтканнан бирле, өстәлендә һәр көнне яңа чәчәк бәйләме булдырырга тырыша. Берәрсе китереп тә бирсә, түбәсе күкләргә тия инде. Каршысындагы бәллүр вазада мөлдерәп бер-ике сап чәчәк утырганда ул үзе дә яшьрәк, шәфкатьлерәк, матурлыкка гына омтылучан булып күренә. Әмма, ачуы кабарса, өстәлемдә чәчәк бәйләме бар бит әле, дип тормый инде: шелтәләү-янаулар, арт сабак укытулар һәм башка-

лар... Авыз да ача алмыйсың, пулеметтан аткандай, үзенекен генә тукый-тукый да иң азактан:

— Да-асс!— дип куя.

Бусы инде сүзем бетте, бар, эшеңә утыр, дигәнне аңлата.

Әмма редактор холкының шунысы яхшы: бер сөйләшкәндә ник туганыңа үкендерә, икенче сәгатьтә үк ни әйткәнен оныткан була. Аптырап каласың: шулмы соң бу? Әле генә усал иде бит, инде гап-гади адәм баласына әйләнде дә куйды?!

Шәрәфә редакторга нинди фикерне ничегрәк аңлатырга икәнне яхшы белә шикелле. Яшьләр аның белән «пыр» килеп кычкырышалар да кайчакта хәтта елап ук чыгып китәләр. Шәрәфә исә еш кына аны ышандыра, әйткәненнән чигенергә мәҗбүр итә. Бәхәс журналга тәкъдим ителгән әдәби әсәрләр турында кузгалганда, Шәрәфә дилбегәне бөтенләй уз кулына ала. Башта ул берничә әдәбият белгеченең дөнья күләм билгеле хезмәтеннән өзекләр китерә. Рус телендә басылып, укучының хушын алган яңа әсәрләрнеискә төшерә, хәтта:

— Миндә бар ул китаплар, укырга вакыт тапсагыз, әйбәт булыр иде,— дип тә өсти.

Берничә көннән соң редактор, алда булган бәхәс турында искәреп нитеп тормастан, шул әсәрләр турында мөкиббән китеп сөйләп йөри башлый. Хәтта Шәрәфә бүлмәсенә керә:

— Слушай, голубчик, менә бу китапларны сиңа катастрофически тизлек белән укырга кирәк,— ди.— Искиткеч!

Эчпошыргыч якларын беренче күрүдә үк эчтән генә елмаеп авыр кичергән булса да, Шәрәфә редакторын да, эш урынын да ихластан ярата иде. Теге яки бу житәкче холкындагы үзеңә ошамаган сыйфатларны өнәмичә, эш арты эш алмаштырып йөри башласаң, гомереңазагына ни белән килерсең? Сабыр булырга кирәк...

Шәрәфә өенә кайта-кайта тәмам тынычлангандай иде. Бүлмәсенә кереп, кечкенә өстәлдәге телефон аппаратын күреп алгач исә бу тәүлектә кичергәннәре аның бөтен вөҗүденә бердән ябырылды, хәтта тын алуы авырлашты. Кыз, көчкә кыймылдап диярлек, диванга барып капланды. Бу минутта кичергәннәре тоташ бер саташу иде.

...Ишектән кемдер керде шикелле. Шәрәфәнең кузгалырга теләге юк иде. Бу халәтне теләмәү, дип кенә дә аңлатып булмый. Теләсә дә, урыныннан кузгала алмас иде. Ишек ачык булган, күрәсең, кемнендер аяк тавышлары ишетелде. Гаҗәеп таныш адымнар. Шәрәфә бу адымнарның якынлашуын гамьсез студент елларында шулай ләззәтләнеп тыңлап яткан иде. Ул чакны, түземлеге житмичә, сикереп торып, үзе каршы атылган иде. Соңыннан сабырсызлыгына үзе битәрләнеп йөрде. Каршы йөгермәсәң дә сиңа дигән бәхет синеке була инде! ...Торырга иренүен акларга теләп, әллә кайчангы хәлләрне искә алу бер мизгелдә генә булып үтте. Шул арада ишек төбендәге кеше Шәрәфә яткан диван янына да килеп житкән иде. Утны кабызырга, йөзенә яктыда карарга кирәк. Тик һаман да аның кузгаласы килмәде. Аннары дөньяда бер генә яктылык чыганагы калмаса да бу кешенең кемлеген Шәрәфә бик яхшы белә бит. Нигә аны күрү?! Кадыйр бу. Шәрәфә аның ишеккә кагылуыннан ук белде. Каршы чыгарга гына ихтыяры житмәде. Көтеп карарга кирәк әле, барына да бер Шәрәфә генә йөгерергә димәгән. Кадыйр Шәрәфәнең йөзенә иелде: «Мин дә ятыйм әле!» Эндәшмәде Шәрәфә. Каршы сүз әйтәсе килмәде, рөхсәт итәргә кыюлыгы житмәде. Ни булса, шул! Шактый гомер кичергән кызның әллә ни югалтасы юктыр инде. Кадыйрның кайнар сулышы колак яфрагын көйдерде, еш-еш тын алуы Шәрәфәне утка салды. Дөньядагы калган бөтен нәрсә юкка чыкты. Караңгы бүлмә егерме елдан бирле бер-берсенә омтылган ике җанның, ниһаять, кавышуына шаһит булды. Шәрәфә диванның, юк бүлмәнең, хәтта алай гына да түгел, бөтен җир ша-

рының чайкала башлавын тойды. Ул, әйтерсең, кайнар дулкын ихтыярына буйсынды. Ташкын Шәрәфәне әле дулкынның иң биек ноктасына, югарыга чөйде, әле, җай гына шуытып, упкын төбенә алып төшеп китте. «Абау!» «Нәрсә, караңгылыктан куркасыңмы?» «Юк, оялам». «Оялма, син дәү бит инде». «Дәү?» Бусы нинди сүз тагын. Яшьләрә кырыкка җитеп килүче кешеләр шулай сөйләшәме? Мендәргә капланган Шәрәфә, тынына буылып, саташып уянды. Бүлмәдә ялт итеп ут яна, тәрәзәдән таң яктысы да беленә башлаган иде инде. Ул, әлеге саташуыннан оялып, үзалдына елмая-елмая, кабат яшьлек истәлекләренә, Кадыйрга, Кәлимәгә бәйле үткәндәге вакыйгаларга чумды. Күздән ихтыярсыз яшь ага иде. Ага да хатын-кызның хәсрәтен үзенә йотарга өйрәнеп беткән мендәргә сеңә бара...

*
* *

Дөресен әйткәндә, Кадыйрның бүген Казанда булуы Шәрәфәнең уй-фикерләренә әллә ни яңалык өстәмәде. Чөнки ничәмә-ничә еллар үтсә дә, нинди генә хәлләр узып торса да, Шәрәфә өчен Кадыйр дөньяда бердәнбер кеше булып кала бирде. Ерактамы ул, якында гынамы — барыбер, Шәрәфә аны бүгенгечә гел үзе янында тоеп яшәде. Кемгәдер яхшылык эшли алса, шул җиңүен Кадыйрга да бәйләп килеп ашкынды, ялгышып куйса, кайгыга батса, бу хәлен Кадыйр да беләдер дип, икеләтә кимсенде, кыйналды.

Язмышында очраган ир-егетләрне шулай ук, теләсә-теләмәсә дә, Кадыйр белән чагыштыра, ахырдан тагын өзгәләнә, чөнки никадәр генә эзләнсә дә, күпме генә чагыштырса да, дөньяда аңардан чибәр, акыллы, һәрьяктан мөкәммәл кеше таба алмый иде.

Кадыйр исә Шәрәфәне егеттәй дусты итеп күрде. Шәрәфәнең үзенә булган мөнәсәбәте хакында җитди уйламады. Кәлимәнең барлыгы егетнең бөтен зиһенен томалаган иде, күрәсең.

Кәлимә, Казанга аяк басу белән үк татар театрына керәм, дип үзенә-үзе сүз биргән иде. Сүзендә торды. Тулай торакка урнашуга, булган затлы киемнәрен киенде дә театрны эзләп китте. Билетлар алып, тамаклар ялгап йөргәли-йөргәли театрга керер чак та җитте. Монда барысы да әкияттәге кебек серле. Киң баскычлардан югары күтәрелүләр, музей бүлмәләрендә йөрүләр, кызыл бәрхет белән тышланган урындыкка утырып, пәрдә ачылганны көтүләр кызны күкләргә алып менде. Театрны ул нәкъ шундый гаҗәеп серле урын, дип белә иде, әмма монда күргәннәре хыялдан да ашып китте. Пәрдә ачылып, сәхнәгә моңарчы бер дә күренмәгән чибәр егет чыгып баскач, Кәлимә бөтенләй дөньядан кичте. Җәйге гастроль вакыты булганга, театр бинасында күрше шәһәрдән килгән артистлар концерт куя иде.

Ияк астына кара күбәләк таккан чибәр егет тамашачыга һәр чыгыш алдыннан аңлатмалар бирә яки бер-ике мәзәк сөйләп көлдереп ала.

Җырчылары да, биючеләре дә бик ошады Кәлимәгә, әмма күңел түренә концертны алып баручы кеше кереп калды. Артистларның бөтен уңышы, әйтерсең, аның нилəр сөйләвеннән, нинди сүз әйтүеннән тора иде.

Чыгышлар тәмамлангач, концертка катнашкан барлык артистлар сәхнәгә чыкты, тамашачы театр бинасын җимерердәй итеп кул чапты. Шулчак Кәлимә янәшәсендә утырган кыз:

— Ничек кенә тапшырырга инде? — дип, үзалдына сорап куйды.

— Нәрсәне, кемгә?
— Саша Кафьяновка букет алып килдем, кыюлык җитми.
— Кем соң ул?
— Конферансье.
— Шулай да итәләрмени?
— Бездә менә шундый конферансьелар юк, мин инде бу концертны бишенче тапкыр карыйм, гел шул конферансьены күрер өчен генә киләм...

Кәлиманe көнчелек катыш кызыксыну биләп алды. Бер үк концертны берничә тапкыр карарга да, күңеленә хуш килгән артистка чәчәк бирергә дә ярый икән, ләбаса...

Ул уйланып утырган арада күршесе сәхнәгә омтылды, чәчәкләрен артистлар төркеменең читендә генә басып торган егеткә сузды. Сүз остасы кызның кулын үзенә тартты да инсафлы гына итеп үбеп алды.

Кәлиманең тизрәк кассага йөгерәсе, иртәгә булачак шул ук концертка билет аласы килде. Артистларның чыгышы икенче көнне башка җирдә була икән. Билетлары да театр кассасында сатылмый. Каны кайный башлаган кыз өчен болар гына комачау була алмый иде. Әллә кемнәрне бимазалап бетерде ул, килделе-киттеле сораулар биреп, үзәкләренә үтте. Белде: концерт шәһәрнең үзәк ял паркында куелачак, ачык эстрадада.

Читтән карап торганда, сәхнәдәге артистка чәчәк бәйләме чыгарып бирүнең берние дә юк кебек. Үз башыңа төшкәч — бигрәк тә күңеленә хуш килгән артистның хур егете кебек, ә син үзең әштер-өштер генә киенгән авыл кызы булсаң — шактый каушата икән. Кәлимә тәвәккәлләгәнче, халык чыгып бетеп үк бара иде инде. Артистлар да сәхнәнең артына кереп киткән, өстен-башын алмаштыра башлаган. Концертны алып баручы исә, Кәлиманең бәхетенә каршы, әллә каян күренеп, бер читтә тыныч кына басып тора.

Никадәр әрсезләнергә тырышса да, каушавы йөзенә бәреп чыккан, кулларына тоткан чәчәк бәйләме дер-дер калтыранган кызны сүз остасы әллә каян күреп торган икән.
— Кемгә инде бу лаләләр?— диде ул.
— Бәй, сезгә!

Егет рәхәтләнеп көләргә тотынды.
— Әйттем бит! Сезне беренче рәттә күреп алгач ук күңелем сизенгән иде. Мәйтәм, бу чибәр кызыкай мине котларга килгән, ахры, дим.
— И-и, мин чибәр түгел бит.— Кәлиманең бөтен гәүдәсе калтырана. Нишләргә, чәчәк сузганда нәрсәләр әйтергә ниятләп куюын да онытты.— «Сед үдегед чибәр»,— диде. Кинәт ул «з» урынына авылдагыча «д» куеп сөйләвен сизде, алай сөйләшү монда бик көлке икәнен уйлап алды. Тиз генә «з» кергән яңа сүз уйлап тапты да чиста итеп әйтте.— Мин бит күзлекле.

Егет тагын көлде. Үзе бөгелә-сыгыла көлә, куллары белән тынлаусыз чәч бөдрәләрен сыйпап-сыйпап куя, үзе өзлексез Кәлиманe күзәтә, өстен-башын, төсен-битен, аяк-кулларын тикшерә иде. Аңа кемдер эндәшеп, чакырып та карады. Ул «хәзер, хәзер» дип кенә куйды да Кәлимә белән кара-каршы басып торуында булды. Тагын чакырдылар. Шунда ул Кәлиманең колагына иелә төшеп:
— Мин сине башка җирдә күрергә теләр идем,— диде.

Авылдагы егетләргә кыстатуы исенә төшеп, Кәлимә: «Әем лә!»— димәкче иде, булдыра алмады.
— Кайда соң ул?— дип сорады. Соравы ризалыгын белдерә, күрешергә теләвен сиздереп тора иде.

Сүз остасы, аның биленнән җитәкләп, читкәрәк, өзлексез борчып, чакырып торган кешеләрдән ераккарак алып китте.
— Бүген түгел, иртәгә. Мөмкинме?

Кәлимә, тарих имтиханыннан көч-хәл белән бер өчле тамгасы алып чыкты да йөгереп тулай торакка кайтты. Чемоданын актарды, яңабаштан кием-салымнарын барлап чыкты, имтиханга кергән киемнәрен салып атты да, күңеленә иң хуш килгәннәрен генә киеп, Саша Кафьянов белән кабат очрашырга җыенды. Кадыйр аны шул мизгелдә күреп калган иде. Язмышларының барыбер бер юлга килеп керәчәген алдан белсә, шунда ул Кәлимәне, бәйләп куеп булса да, бүлмәдә калдырыр, бәхетсезлегеннән коткарыр иде.

Кызганычка каршы, кыз ул кичне бер генә каршылыкка да очрамады. Урамга чыгып басуга, кирәкле транспорт туры килде. Автобустан төшкән җирендә, һич уйламаганда, аны чибәр артист каршы алды.

— Әнеккәчкәем,— диде Кәлимә.— Кай арада килеп өлгердегез, әле сәгать җиде тулып та җитмәгән бит.

— Соң булмасын дидем. Без болай сөйләшик, концерттан соң әнә теге скамейка янында очрашырбыз. Халык күп булыр, буталышмыйк. Безнекеләргә аерым машина килеп тора. Ә без синең белән икәү генә кайтып китәрбез, ярыймы?

Бу кичне концерт шәһәр читендәге культура сараенда барды. Уңышлы булдымы ул, тамашачы яраттымы чыгышларны — Кәлимә берсен дә хәтерләми. Аның җанын алда буласы серле очрашу биләгән иде. Аңа барысы да кызык та, куркыныч та тоела. «Саша күрсәткән эскәмияне бутамаммы? Икәүдән-икәү генә калгач, ни булыр?..» кебек сораулар, күңелне кытыклап, уйны бөтенләй башка юнәлешкә алып китте.

Чынында, күпме генә уйланса да, алдына нинди генә сораулар куеп азапланса да, күрәселәренең бик аз өлешен дә чамалый алмады. Культура сараеннан ул ашыкмыйча гына чыкты. Кешеләр таралышсын, артистларның эше бетсен, тыныч кына бер-беребезне табарлык булсын, дип фикер йөртте. Теге эскәмия ягына тайпылырга да базмады, һаман башка кешеләр белән бер рәттән атлады.

— Ә-ә, син әле мине көттереп алҗытмакчы идеңмени?— дигән сорауга күтәрелеп караса, дерт итеп китте.

Саша Кафьянов аны инде байтактан күзәтеп тора икән. Кәлимә:

— Әле бит... ни,— дигән булды. Дөресен генә әйткәндә, аның сүзе юк иде.

Сашаның беренче авазын ишетүгә, әйтерсең, гәүдәсе кабат ут дәрьясына чумды. Саша, киресенчә, бик тыныч күренә. Ул башта Кәлимәне беләгеннән җитәкләде, аннары кулын билгә үк салды. Авыл егетләре булса, Кәлимә рөхсәт итмәс иде. Кафьянов алдында киреләнә алмады. Килешмәс. Матурлык дөньясына килеп кергәнсең икән, аның кайбер четерекле якларына түзәргә кирәктер. Хәер, ят тоелган гадәткә дә тиз күнекте. Биләндә егет кулын тою әйтеп аңлата алмаслык рәхәт икән бит ул. Бу — кулның нинди кешенеке булуыннандыр, мөгаен. Кәлимәләр авылында егетләр белән куна калу гадәте бар. Куллар билләрдә була, тик аның әллә ни рәхәтен тоймыйсың. Берничә пар егет-кыз кичке уеннардан соң җыйнаулашып берәр аулак өйгә кунарга керәләр. Өс-башны салу юк. Өстеңдә пиджакмы, свитермы, калын күлмәкме — шул килеш чөмәшәсең. Мәмрәп китеп йокламыйлар да анда. Пыш-пыш сөйләшәләр, бәхәсләшәләр генә.

Кәлимә Кафьянов кулының кайнарлыгыннан тәмам эрегән иде инде. Кая баруын да сизми, егетнең ни сөйләвен дә ишетми. Автобус тукталышын үткәч кенә, аптырый төште ул.

— Бәй, ничек кайтырбыз соң?

— Синдәй асыл затны общи транспортта йөртәмме соң?— Артистның һәр сүзе Кәлимәнең зиһенен чуалта иде.— Җиңел машиналар ни өченгә уйлап табылган, дисең. Сине очыртып йөртер өченгә ул!

Көлде Кәлимә.

— «Өченгә»?— диде. Күп китаплар укыган кызга артист кешенең болай сөйләшүе кызык иде.— Сездә шулай сөйләшәләрмени?

Егет җылы бите белән Кәлимәгә кагылып:

— Кем белә бит, кем белә?— диде.— Минем туганнардан аерылганга мең былтыр. Илләр гизәм, сәхнәләрдә йөрим. Халыкка ни сөйләргә икәнен миңа язып тоттыралар.

Бу сүз Кәлимә күңеленә шом сала башлаган иде. Сәхнәдән сөйләвен тыңлаганда һич тә андый тәэсир калмый, ул үзенең уй-хыялларын әйтә, үз күңелен ярып сала кебек тоела бит.

Артист та сөйләшүенең кирәкмәс якка кереп китүен абайлап өлгерде бугай, кызны шомландыра башлаган уйны «өреп» кенә юкка чыгарды.

— Беләсеңме-е... э-э... исемең ничек әле?

— Кәлимә.

— Беләсеңме, Кәлимә, артистның көче, сәләте, тамашачыны ышандыра алуда аның. Менә син игътибар иттеңме, телим икән, мин тамаша залын көлү дәрьясына әйләндерәм, көлү туйдыра икән, чебен очканы да ишетелерлек тынлык урнаштырам, җитдилек җитенкерәми икән: «Тыңла, бала, газиз әнкәң сөйли» шигырен укыйм да, имәндәй ирләрне үксетәм.

Дөресен әйтә иде ул, Кәлимә дә аның концертында нәкъ шул хисләрне кичерде: көлде, уйга талды, елап та алды.

— Сезнең талант алдында баш ияргә мөмкин,— дип сөенеп пышылдады Кәлимә. Теленә шундый урынлы мактау сүзләре килеп кергәнгә бик куанды ул.— Мин бик яратып тыңладым.

Кәлимәнең таксига беренче утыруы иде бу. Йомшак, җылы, тыныч һәм караңгы. Очырта гына. Кафьянов кулын Кәлимәнең иңенә салды.

— Йокың киләме?— дип сорады.

— Ю-ук, без төнге икеләргә чаклы утырабыз, имтиханнар вакыты бит.

— Бүген нишли имтиханың?

— Бәй...

Кафьянов кызны үзенә тартты.

— Куй башыңны минем күкрәгемә, куй!

Алай ук итмәсә дә, Кәлимә канатланып, күкнең җиденче катына менеп киткән иде инде. Башыңны кыңгыр салсаң, бөтенләй акылыңны җуярсың.

— Ярар инде. Болай гына барыйк.

— Ярый алайса, ихтыярың.— Кафьянов елмаеп Кәлимәнең күзләренә карады. Машина эчендәге ярымкараңгылыкта ул күзләр ялтйолт килә иде.— Күзлегеңне салсаң, ни була?

Кәлимә күзлек турындагы сүзләрне бер дә яратмый. Аның үзәгенә үткән нәрсә ул — күзлек. Авылда да шул күзлеге хакында күпме кимсетүләр кичерә иде. Математика дәресендә, тактага язганны күчергәндә, төрле тамгаларны бутап, күпме хата җибәрә иде ул! Укытучы Кәлимәне игътибарсызлыкта, наданлыкта, башсызлыкта гаепли, әрли. Әмма кыз: «И-и, абый, мин илтифатсыз түгел, минем күзләрем ерактан начар күрә»,— дип акланырга гарьләнә. Өйләрендә аны әтисе тиргәп теңкәсенә тия, чөнки Кәлимә һәр көнне төн урталарына кадәр көтүдән кайтмаган кәҗә-сарыкларын эзләп изалана. Әңгер-меңгердә олаудан төшеп калган бер уч салам да, юл читендәге ак таш та сарык бәтие булып күренә башлый. Су буйларындагы түмгәкләрне, әрәмәлектәге агач төпләрен капшап бетереп, өйләренә кайтып кергәндә, сарыкларны әтисе әллә кайчан абзарга ябып куйган була. Кызга башка сыймаслык гаеп ташлыйлар:

— Син, бәдбәхет, юньле юлда йөрмисең, нәселдә булмаган азгынлыкка чыккан син, йөзгә кызыллык китерергә маташасың...

Кәлимә әтисе белән җаваплашырга ярамаганны яхшы белә, телләшә башласаң, сугып җибәрергә дә күп сорамый. Аңардан шул кадәр курыкмаса:

— И-и, әти, күзләрем күрми бит минем, сарыкларны танып бетерә алмыйм, син мине врачка күрсәт, яхшы күзлек ясатып бир!— дип, сөйләп-аңлатып та карар иде.

Юк, әйтми дә, сорамый да иде кыз. Әчтән генә көя, дөньяның тигезсезлегенә хәйран калып, исән-иминнәрнең авыру кеше хәлен аңларга теләмәүләренә аптырый, җаны кыйнала иде аның.

Инде монда Кафьянов та шул күзлеккә бәйләнеп тора. Кәлимәнең сүз уйнатып азапланасы килмәде, турысын гына әйтеп бирде.

— Күзлексезме? Күзлексез булсам, сукыр тавыкка әйләнәм дә калам.

— Әйбә-ә-әт, бик әйбәт!

Артист кешенең башка нәрсә уйлап әйтүедер инде, яшь-яшь кызның шундый күз белән йөрүе ничек әйбәт булсын ди?!

Кәлимә Сашаның кинәт әйтелгән бу «әйбәт»ен шулай юраган иде. Тик ул аны чынлап ук ычкындырган бугай. Чөнки артистлар урнашкан гостиницага кайтып, бүлмәгә керү белән үк Кафьянов Кәлимәнең күзлеген салдырып алды. Әле ишек янында үтмәгәннәр, бер генә адым да атламаганнар иде. Егет аркасы белән ишекне «дыңк» итеп терәтте, күзлеге салдырылган Кәлимәне ике куллап үзенә кысты. Тын алырга да, «әһ» итәргә дә өлгерә алмады кыз. Әллә ни иде бу.

Тумыштан ук беркатлы, тиз мавыгучан, җилбәзәк холыклы Кәлимә тагын онытылды. Кечкенәдән үк әбисе тәкърарлый килгән вәгазьне хәтереннән бөтенләй чыгарып җибәрде. Мәрхүмә карчык түр сәке өстендә аякларын бөкләп утырган килеш, тәсбихен тарта-тарта, җайлы бер көйгә тирбәнә-тирбәнә, үзалдына гына сөйләнгәндәй һаман өйрәтә иде: «Әй кызларым, йөрмәгез соңга калып!— ди торган иде.— Кермәгез егетләр чакырган өйгә! Бусаганы атлап эчкә узганда гына кызык булыр. Бераз торуга, караңгы төшәр, урамга чыгарга куркырсыз, өйгә кайтыр юлларыгызны күздән үк җуярсыз...»

Кәлимә аңлады аңлавын. Кыз бала башына гомердә бер генә килә торган имтихан иде бу. Монысыннан, укытучы алдында сүз уйнатып, бәләкәй өчле алып кына котыла торган түгел. Башында «Ярамый!» дигән кисәтү дә уянды. Егетнең куе бөдрәләренә уралган нечкә бармаклары сыйпаудан туктап-туктап та калгалады. «Ярамый!» Бөдрә чәчле баш исә бер генә мизгел дә тик тормады. Егет еландай боргалана, үзе «Уф!» дип көрсенә.

Кәлимә талпынып куя. «Ярамый!» Күзләр йомыла, тәне буйлап рәхәт кайнарлык йөгерә, йөрәкнең дулавы чамадан аша. Ми ярымшарларындагы «Ярамый!» көчсезләнә, һаман саен ерагая. «Нигә ярамасын? Шундый асыл зат, аяк астында туфрак булып, синнән шәфкать сорый икән, нигә ярдәм кулы сузмаска?!» Кәлимәнең куллары, акыл боерыгын тыңлап тормастан, Кафьянов гәүдәсенә чатырдатып ябышты...

Башта Кәлимә уянды. Бүлмә яп-якты, җылы нур белән тулган иде. Кыз, күзләрен ачып җибәргәч, кыймылдарга кыймый ятты, тирә-юнен өр-яңадан кымшанмый гына күзәтергә тотынды. Кафьянов аны стена белән ике арага кыскан, үзе аңа аркасы белән борылган. Ул шул килеш тә, таушалып беткән ятакта берни белми йоклап яткан хәлендә дә гаҗәп чибәр иде. Коңгырт кара бөдрәләр тәртипсез тузгыган, кояшта

янган тәне ялтырап тора, гәүдәсе төз, озын, сулу алуына кадәр җанга якын, үз...

Кәлимәнең эче күңелне кытыкландыргыч шатлык белән тулы иде. Узган төнне кичергәннәрен кабат хәтереннән үткәреп, ул үзалдына елмайды, үзе дә сизмәстән: «Ah!»— дип куйды да авызын учы белән томалады: зуррак ачсаң, эчтәге кайнар куанычлар кими башлар, чыгып китәр кебек. Кафьяновның чәчен сыйпыйсы килде, тыелды. Уяныр. Аңа бит йокларга кирәк. Артистлар көндез озак йоклыйлар, чөнки эшләре кичен генә башлана. Моннан соң Кәлимәгә дә шул тормышка күнәргә туры киләчәк. Көндезләрен гел йоклап кына ятмас ул, иренең төнлә эштән кайтуына кайнар аш-су өлгертеп, рәхәтләнеп ял итәрлек шартлар тудырып торыр. Тагын елмайды ул. Хәзер аңа әнә шундый нәрсәләр турында да уйларга кирәк инде, ир хатыны булу — уен-муен түгел ул сиңа!

Күзләр асты-өскә килгән бүлмәне тагын тикшерә башладылар. Елмаймый ничек түзәсең инде. Идән, өстәл, урындыклар — бөтен төш Кәлимә белән Сашаның чәчелгән киемнәре белән тулган. Торырга да, Сашаны уятмыйча гына, барын да җыеп куярга кирәк. Аннары чәй кебек нәрсә өлгертергәдер инде. Монда мич-фәлән яки плитә-мазар бар микән? Бардыр, ник булмасын! Ничек мыштым гына торырга соң? Саша уянса... Кәлимәнең күңеле кытыкланды, тагын үбә, шаяра башлар. Тыелып торамы соң инде?! Елмайды Кәлимә. Тыелып кала торган хис түгел икән шул ул!

Күңеле бик сизгер булып чыкты — Саша да уянган бит. Уянган шул. Ул Кәлимә ягына борылып-нитеп тормастан гына:

— Ник йокламыйсың, әле иртә бит? — диде.

— Бәй!..— Кәлимә торып утырды.

— Нәрсә, «бәй»?— Кафьянов теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалды. Аның хәрәкәте дә, сүзләре дә бөтенләй Кәлимә көткәнчә түгел иде. Көчкә әйләнеп, хатынның зур ачылган сораулы күзләрен, суырылганагарып киткән йөзен күргәч, иренеп кенә:— Безнең халык озак йокларга өйрәнгән ул,— диде.

— Анысын чамалыйм.— Кәлимә иренең уянгач әйткән беренче сүзен, сүзен генә түгел, хәрәкәтен, күз карашын шул кадәр дә илтифатсыз булыр дип, башына да китермәгән иде.— Мин торам,— диде ул.

Сикереп идәнгә төште, бүлмә буйлап йөгереп, эчке киемнәрен җыя башлады. Ул күлмәген генә киеп куйган иде, Кафьянов ят бер тавыш белән:

— Слушай, син анда коридорга чыга күрмә тагын!— дип кисәтте.

— Бәй!?

— Төнлә ни булганын онfamт син!

Кәлимә авызын ачты — сүз әйтә алмады. Аның кинәт уелып-кыелып төшүеннән шүрләп калган ир ике кулын алга сузды, кочагын җәйде.

— Кил әле монда!

Күптән шулай итәргә идең, дигәндәй, Кәлимә иренә барып сыенды.

— Авыртамы әллә берәр җирең?— Ир Кәлимәнең янбашларын капшаштырды.— Җылап, әнисең янына кайтып китмәссеңме соң, ы-ы?

— У-у, әнкәйләр ерак бит минем.

— Кайда торасың соң син, ы-ы?

Башта Кәлимә:

— Күк белән җир арасында,— диде. Аннары, Кафьяновка сыенып:— Менә шушында торам,— дип төзәтте.— Менә шушы кеп-кечкенә бүлмәдә артист Саша Кафьянов белән торам, белдеңме? Кирәксә, тәрәзәне ачам да бөтен Казан каласына кычкырам: ә-әй, җәмәгать, мин монда тора башлады-ы-ым!

— Мин бит үзем дә бүген моннан китәргә тиеш.

— Кая?— Кәлимә сүзнең житдиләнүен, бу яңалыкта аның файдасына бер генә нәрсә дә булмавын сизеп алды.— Кая? Ничек?

— Кычкырма шул кадәр!— Кафьянов аның зур итеп ачылган авызын каплады.— А что ты думала? Безнең бригаданың гастрольдә икәнен беләсеңдер бит син, кыз бала? Кичә бирелә соңгы концертны бирдек. Бүген кичке биштә пароходыбыз китә, эллюр! Тю-тю!

Кәлимәнең иреннәре дерелди башлады һәм «Мин нишлим?» дип, үзалдына гына сорап куйды. Елыйсы килә иде аның. «Мин нишлим соң хәзер?»

— Көтәрсеңме соң, ы-ы? Мин икенче килеп чыкканчы...

— Юк, юк, мин синең белән китәм. Теләсә кая.

— Ярый, ярый, мин бит бер нәрсә дә әйтмим, һы-һы!

— Әйдә, общежитьега икәү барабыз, яме? Минем бүлмәдә йомыкый бер кыз бар, күзе маңгаена менсен әле!

— Ярый, ләкин мин эчкә кереп тормам...

Артистларның тормышы кызык икән: сәхнәдә киенгән киемнәре гел әерым чемоданда йөри. Күбесе аны чыгыш ясыйсы бинада ук калдыра. Урам буйлап төен-төен әйбер ташымас өчен шулай итәләр.

Сашаның әйберләре бик аз иде. Сәхнә кирәк-яраклары, костюмы, ялтыравык туфлие, алмашка алынган берничә күлмәге — барысы да бер чемоданга сыйган. Аны ул бригадаларындагы башка иптәшләренең багажлары арасына урнаштырды. Каютага кергәндә кулы буш иде. Кәлимәнең чемоданын ятар өчен җайланган йомшак эскәмия астындагы сандыктай тирән тартмага салдылар.

Пароходларга утырырга туры килгәләсә дә, Кәлимәнең мондый йомшак каютада барганы юк иде. Ике кеше генә сыешлы каюта зиннәтле залларга алыштыргысыз булып тоелды аңа. Ул ояла-ояла гына Сашага эндәште:

— Кил инде, мондарак утыр, ишек төбендә торма!

Күңелсезләнеп калган ир теләр-теләмәс кенә буйсынды. Кәлимәнең анда-монда эше юк. Ишетеп белә ул: юньле кешеләр, өйләнешкәч, берберенә ияләшеп житү өчен, ерак юлга, туй сәяхәтенә чыгалар. Яшьләр ата-ана, туган-тумача, таныш-белеш, күрше-күлән күзеннән читтә чакта бер-берсеннән яшеренмичә, тәмам ачылып яши башлыйлар.

— Бу безнең туй сәяхәтебез була инде, ә-әме?

— Ы-ы! Арытты ләкин.— Кафьянов уйлана иде. Кәлимәгә әйтер сүзләрен дә чамалап кына чыгара. Ялгыш ычкындыруыннан шикләнә кебек.— Ы-ы, арытты.

Кәлимә аның чигә чәчен сыйпап куйды.

— Ял ит соң, ят!— диде.

— Тукта, мин бер чыгып әйләнеп керим дә, аннары...

Шул чыгуыннан ул каютага шактый озак керми торды. Кәлимәгә аны инде мәңгегә югалткан кебек тоелган иде дә, бүлмәнең пароходта икәнен, пароходның су өстендә шапылдап баруын исенә төшергәч, тынычланды. Үзе дә палубага чыкты. Күзне кытыклаучан ялтыравык дулкыннарга, алланып, инде баерга җыенган кояшка карап торды. Аннары кинәт палубаның икенче ягына күзе төште. Анда Саша кем беләндер сөйләшеп тора иде. Күбрәк теге кеше сөйли, кулларын да селтәп-селтәп җибәрә, Саша башын аска иеп аны тыңлап кына тора. «Җитәкчеләредер, күрәсең,— дип уйлап алды Кәлимә.— Бәлки аңардан башка гына туйлап йөрүен өнәп бетермиләрдер.— Саша озак уйлап тормас, тотар да, дусларын җыеп, каютага алып керер. Бераз тәртипкә китерергә кирәк». Кәлимә, дәртләнеп китеп, бүлмәгә керде. Артык-портык күренгән нәрсәләрне яшергәләде. Үзенең өстен-башын рәт-

иде. Бәйрәм төсе өстәргә тырышып, муенына болытсыман яулыгын бәйләп куйды.

Каютага кергәндә Сашаның да йөзе яктырган, кәефе яхшырган иде.

— Хәзер безгә ашарга кертәчәкләр, тагын туй итәбез,— диде ул.— Икәү генә, шыпырт кына туй итәбез.— Иптәшләре хакында актан-карадан сүз әйтмәде. Кәлимә дә төпченергә батырчылык итмәде.

Шыпырт туйның дәвамы башланды. Эскәтерсез кечкенә генә өстәлчектә салкын ит кисәкләре, бер-ике төрле шешә тора. Саша нигәдер, үзе әллә ни эчми, ә Кәлимәне үтереп кыстый иде. Башта Кәлимә, ир сүзен сүз итми ярамас дип, бер-ике йотты. Төсе кызгылт булса да, аракы бик тәмсез, әче, телне өтеп ала иде. Яратмыйча, чыраен сыта-сыта гына эчте. Аннары күнекте, бик кыстатып тормады.

Бу мәҗлеснең азагы кичәге кебек, дөньяны оныттырып, дип көтте Кәлимә. Дөрес, ул болай да рәхәтлек диңгезендә йөзә, болай да бәхетле, әмма... башны югалту ике булмый икән ул. Аннан соңгы югалтулар, үкенечләр өчен әнә шул беренчесе җитеп ашкан.

— Я, чишен инде!— диде аңа Кафьянов. Аның тавышында иркәләүназлау да, үтенү-ялвару да сизелмәде.— Вакыт соң, ятыйк.

Боерык кына да түгел, ә куркыту кебегрәк бер тавыш иде бу. Һәрхәлдә, Кәлимә курка калды. Шул минутта ук сүзен тыңламасаң, бүлмәдән үк чыгып китәр төсле иде. Күлмәген үзе салды Кәлимә. Калган киемнәрен иренеп кенә, тупас кына кыланып, Саша йолыккалады.

Кәлимә, бичара, барысына да түзде, ризалашты. «Ник син болай үзгәрдең?» — дип тә сорый алмады. Саша кинәт: «Мә, боларын киең куй»,— дип, эчке күлмәкләрен аңа кире бирде. Кәлимә: «Ник?» — димәде.

Күңелендә шуңа охшаш вак-төяк ризасызлыклар кузгалса да, Кәлимә канәгать иде: янында — сөйгәне, җанда-тәндә рәхәт талчыгу. Шул сихри дөньядан йокы дәрьясына чумуын ул сизми дә калды.

Йокыга ничек талса, шулай ук кинәт уянып та китте ул. Пароходниндидер бер пристаньнан кузгалган гына иде. Бәлки аның дебаркадер бортларына бәрелүеннән уянгандыр да әле. Юктыр. Бернинди ят хәрәкәтләрне тоймаса да, каютадагы шомлы салкынлык Кәлимәне уятмый калмас иде. Туңуга чыдый алмыйча, ул одеялны тыгызлап тәненә чорнап азапланды. Шунда айнып китте. Кәлимәне куркуга салып, эченнән коточкыч аваз чыкты. Елау да, ыңгырашу да түгел иде бу. Мондый хәлдә артык кала алмыйча, ул торып ут кабызды. Өстәлдән бөтен нәрсә ялт иттереп җыелган. Бер валчык та, бер кәгазь кисәге дә калмаган. Шешәләр дә юк. Кафьяновның кием-салымнары да табылмаячагын Кәлимә, барлап тормаса да, сизенә иде инде. Ул үз алдына: «Әнеккәйгенәм!— дип куйды.— Әнеккәчкәйгенәм!».

Үз гәүдәсен үзе кочаклап урынга килеп утырды ул. Шунда гына башының чатнап авыртуын, тәненең мунчаладай йомшап калуын, шешенкерәгән иреннәренең сулкылдавын тойды. Беләкләрен, муен тирәләрен сыйпаштырды. Өзлексез сыйпый-капшый торгач, кулы бер чүп кисәгенә килеп эләкте. Тыгыз тәнгә батып кергән лифчик бавы астында салфетка кисәге бар иде. Бармак бите хәтле генә кәгазьнең пөхтәләп төрелгән булуы Кәлимәне сискәндереп җибәрде. Әйләндереп, туздырып карады. Салфеткага: «Хуш, күзлеклем! Мин шушында төшеп калам, сине уятып тормыйм инде, хуш. Киләчәктә саграк бул, табигать шуның өченгә сезгә саклануның бөтен чараларын биргән. Ирләрдә юк алар... Диалектика. Синең янда башкача кала алмыйм, семья бар минем. Хуш»,— дип язылган иде.

«Өченгә, өченгә...»— дип үзалдына мыгырданды Кәлимә һәм оныһтылды, аның өчен дөньяда хәзер берни дә юк, бары да убылды. Бит алмаларын көйдереп аккан ачы яшьнең тозлы эзе генә калды...

Кәлимә янадан Казанда күренгәндә, Шәрәфә белән Кадыйр дүртенче курста иделәр инде.

— Минем группада ямь-яшел бала-чага, алар — мине, мин аларны аңламыйм, ачуланмасаң, синең белән дуслашыр идем мин,— дип, Шәрәфәгә чат ябышты ул.

— Без күптәнге дуслар бит инде.— Шәрәфә шул кадәрле дә беркатлы күренгән кызга һичничек усал сүз әйтә алмады. Үзе сөйләмәсә, Саша турында да берни дә сорамаган булыр иде әле.

Кадыйр ул вакытта укуын үзмичә генә кайдадыр эшли дә башлаган иде инде. Ул тулай торакка да авылдашы Шәрәфәне күрергә генә килеп йөри. Үзе эшенә якынрак җирдә, квартирада тора иде. Ялга каршы көннәрнең күбесендә Кадыйрны командировкага авылларга җибәрәләр, шуңа күрә ул күңел ачу кичәләренә катнаша алмый. Ул килмәгәч, Шәрәфә дә танцыларга чыкмый, китапка капланып утыра иде.

Берсендә Кадыйр атна уртасында килеп керде. Өстенә яңа пальто кигән, аягында — озын кунычлы ботинкалар. Йөзе көләч, күңеле шат.

— Беләсезме, кызлар, урамда яз исе аңкый башлаган,— диде ул. Кызларның бөтенесенә мөрәҗәгать итсә дә, карашы Шәрәфәдә генә иде.

Кызларның кайбере эндәшмәде, кемдер көлгәндәй итте. Шәрәфә, «Ни булган моңа?» дигәндәй, Кадыйрга төбәлде.

— Чынлап, Шәрәфә! — Кадыйр да кызның аптырап калуын сизде.— Ышанмасаң, әйдә, урамга чыгабыз!

— Тик торгандамы? Ни калган анда?

— Әйдә, дим, үзең күрерсең...

Кадыйрның моңарчы эшсез-нисез генә урамда йөрергә чакырганы юк иде әле. Шәрәфә ни дип җавап бирергә дә белмәде, бүлмәдәге кызларга карады, аларның һәркайсы үз эше белән мәшгуль, боларның ни турыда сөйләшүен дә тыңламыйлар. Һәрберсенең үз юлы, чакырыр үз кешесе бар. Шәрәфә өчен кем баш ватсын?! Аңа килгән, аның авылдашы, аны чакыра — үзе хәл итсен!

Тәвәккәлләде Шәрәфә. Күңеленнән барын да үлчәп-исәпләп, акрын гына киенә башлады. Кешегә әйтсәң, кеше ышанмас — дүрт ел буе Казанда яшәп, шау-шулы студентлар арасында булып, аның әле бер генә тапкыр да Кадыйр белән икәүдән-икәү генә урамнар буйлап йөргәне дә, хәтта киногa барганы да юк иде. Тулай тораКтагы бәйрәм кичәләрендә гел бергә күренәләр, табынНарда икәү рәттән утыралар. Кадыйрның бөтен игътибары бары тик Шәрәфәдә генә кебек. Һәрхәлдә Шәрәфәгә шулай тоела. Хәер, башкалар да сизә моны, югыйсә шәһәр кызлары Кадыйрдай егет-солтанына тыныч кына карап торырлар идеме? Мең хәйләсен табып, әллә кайларга алып китәрләр, башларын әйләндереп бетерерләр иде. Юк, Кадыйрга берәү дә өметле караш ташламый, чөнки барысы да: ул — аныкы, Шәрәфәнеке, дип уйлый.

Әмма ләкин Шәрәфәнең эчен көйдереп торган бер шикне һичкем башына китерми. Кеше алдында бик инсафлы, игътибарлы, гел Шәрәфә өчен генә туган кеше кебек кыланса да, егетнең кыз белән ялгыз калырга, икәүдән-икәү чакта серле сүзләр сөйләргә ишарәләп кенә дә караганы юк. Ярый әле Шәрәфә сабырсызланмады, өметен өзмичә көтә бирде. Менә бит, җитте ул көн, ашкынып килгән егет, җил-буранлы февраль аенда: «Яз җитте!» — дип, шашынып килгән.

Бүлмәдә, кешеләр бар чакта, Шәрәфә кыюрак кыланган икән. Коридорга чыкканнар иде, сөйләр сүз кинәт өзелде, күзләр аска гына карый башлады, аяклар хәлсезләнеп калды. Кадыйр гына сер бирми.

— Кара инде,— ди,— ничә ел шушында яшәп, синең белән бергә

Казан урамыннан үткән дә юк бит безнең. Авылдашлар булып йөри-без тагын.

Шәрәфә аптырабрак калды: авылдашлар гынамы соң алар? Юк, алай гына түгел, әле монысы сүз башлар өчен сәбәп кенә, тагын бер баскычны үткәч, яки урамга чыгып җиткәч, Кадыйр үзенең күңелендәге серләрен дә ачып салыр әле. Шәрәфә, үз колаклары белән үк ишетмәгән булса да, гашыйкларның бер-берсенә нинди сүзләр әйтешүен чамалый.

— Бәй!..

Көтелмәгән, әлегә һич кирәге булмаган бу таныш тавыш ләззәтле уйларга чумган Шәрәфәне сискәндереп җибәрде. Инде баскычтан төшең җиткән Шәрәфә белән Кадыйрның каршысында, җир тишегеннән калкып чыккан кебек чытлыкланып, Кәлимә пәйда булды.

— Кая китеп барасыз миннән башка?

Әйтерсең лә Шәрәфә аны үзе кая барса, шунда тагып йөрергә йөкләмә алган, оятлы эш өстендә тотылгандай, кызарынып, көчкә ишетелердәй тавыш белән:

— Син өйдә юк идең бит,— дип, акланырга тотынды.

Кадыйр бер-ике басма арттарак тора иде, анысының, Кәлимәне күргәч, аяклары атламас булды, телсез калды. Бу хәл хәтта Шәрәфәгә дә сәер тоелды, ул Кадыйрга борылды. Ник кенә борылды икән, гәүдәсе төпсез, салкын чоңгылга төшеп киткән кебек булды — Кадыйр Кәлимәгә карап бар дөньясын онытканн. Авызы, күзе кәлә, йөзе балкый, ул хәзер ерык авызлы Кәлимәдән күзен ала алмый.

— Бәй, нәрсә шулкадәр аптыраштыгыз, әйдәгез, киттек!

Кәлимәнең әрсезлеге авыр хәлдән коткарды. Алар өчәүләшеп карлы урамга чыктылар. Кәлимә, эткәләп-төрткәләп, Кадыйрны икесенең уртасына бастырды, икесен дә җитәкләргә мәҗбүр итте.

— Менә шулай йөртәләр кызларны, егетем! — диде.— Инде өйрәнергә вакыт, киләсе елга диплом аласың.

Бер булмаса булмый дигәннәре шул икән — Шәрәфәгә Кадыйр белән икәүдән-икәү генә, шагыйрьләр әйтмешли, тынлыкны тыңлап, эндәшмичә генә сөйләшеп йөрү барыбер эләкмәде. Әлеге көннән алып, алар гел өчәү күренә башладылар. Моңа Шәрәфә үзе дә ияләнеп китте. Кадыйр берәр җиргә чакырса, иң элек:

— Хәзер, Кәлимә янына керим әле, ул өйдә микән? — дип, тиз генә бүлмәдән чыгып йөгерә иде.

Кәлимә икенче курска аяк басканда, Шәрәфә белән Кадыйр дипломниклар иде инде. Кыш тагын үтте, тагын яз килде, җәй якынлашты. Җитәкчесе белән уртак тел табып, язганнарын машинисткага тапшырган көнне Кадыйр кызлар бүлмәсенең ишеген шакыды.

— Шәрәфә, әйдә, бер йөреп керик, сиңа да ял кирәк бит! — дигән булды.— Кәлимә өйдә микән?

Шәрәфә яши торган бүлмәдәге бер кызның туган көне, шуңа күрә кызлар мәш килеп мәҗлес үткәрергә җыенып яталар иде. Кичәгә кызның башка институтларда укучы якташлары да, аларның дуслары да киләчәк икән. Шәрәфәнең бердәнбер дусты буларак, әлбәттә, Кадыйр да чакырыла.

— Менә кызык, үзем килеп кермәсәм, минсез үтәчәк икән бит туган көнегез?! — диде Кадыйр үпкәле сыман тавыш белән. Чынында аның моңа һич үпкәсе юк, тик хәзер монда утырасы гына килми иде.— Мин китим әле.

Винегрет ясап азапланучы Шәрәфә сүз әйтергә өлгерми калды, Кадыйр, солдаттай нык-нык басып, икенче катка төшеп китте. Шәрәфә аның артыннан атылып чыгарга кызлардан оялды. Бераздан тәрәзә ягыннан әйләнгәндәй итенеп, урамга күз ташлаган иде, егылып китә

язды. Тын таулар арасына китә торган тар сукмактан алар икәү атлыйлар иде: Кәлимә Кадыйрның уң беләгенә ике куллап ябышкан.

Шәрәфә моңарчы бөтенләй таныш булмаган хис кичерде. Көнләшү идеме бу, кызыгуммы, үкенүме, әллә шуларның кушылмасымы? Ул шул хәлендә, җитәкләшеп китеп барган Кадыйр белән Кәлимәнең йөзләрен күрергә, сүзләрен ишетергә теләде. Нәкъ шул мизгелдә Кадыйр артына борылды, Шәрәфәләр тәрәзәсенә күз ташлап алды.

Шәрәфә ул карашны куркынып, шомланып, әллә ничә мәртәбә искә төшерде: егет шул чакта ук мәңгегә аерылышуларын сизенгән булды микәнни? Дөрес, бу көнне үк өйләнешмәделәр алар. Әле аннан соң да өчәүләп-өчәүләп шактый күп җирләргә бардылар. Барысы бергә чакта, Кадыйр кызларның һәр икесенә бертигез игътибарлы иде, Кәлимәгә дә өстенлек бирми, Шәрәфәне дә какмый.

Беркөнне алар өчәүләшеп кино карадылар. Күңелләре күтәренке, ашыгыч эшләре юк. Кадыйрның инде диплом да якланган, үзе әле яңа гына командировкадан кайткан иде. Шәрәфәнең дипломы язылып беткән, яклау көнен көтеп йөри. Ә Кәлимә һаман шундый ул — борын төбендә имтиханнары торса да, аһ-уһ килми, бәләкәй генә бер өчле алуына ышанып, хөрлеккә куанып тик йөри иде.

Җылы май киченең рәхәтеннән тиз генә аерыласылары килмәде, алар, кинодан чыккач, тулай торак юлына борылмадылар. Кадыйр шунда:

— Карагыз әле, кызлар,— диде.— Елдан артык аерым бүлмәдә яшәп, сезгә үземнең торган урынны күрсәтә алганым юк. Әйдәгез, миңа киттек!

Кадыйрның бөтен гадәтләрен беләм, дип йөргән Шәрәфә өчен көтелмәгән яңалык иде бу, Кадыйр кешеләр белән никадәр якыннан аралашса да, түренә берәүне дә уздырмый.

Ике кызны квартирына чакырырга нәрсә мәҗбүр иткән аны? Болай гына, сүз юктан, аптырганнан гынамы?

Шәрәфә аны уңайсыз хәлдә калдырырга теләми иде. Иң беренче ул кычкырды:

— Әй, кирәкми лә, мондый кичне бүлмәгә кереп бикләнүнең гөнаһысын кая куярсыз?! — диде.

Кадыйр Шәрәфә сүзенә әллә ни игътибар да итмәде, каршы сүз дә әйтмәде. Инде син үз теләгеңне белдер, дигәндәй, Кәлимәгә карап тора иде. Башка чакта бөтен кешедән алда кычкыра торган чытлык Кәлимә, телен йоткандай, ләм-мим эндәшми иде. Анысы да Кадыйрга текәлгән, бер сүз дә әйтми, үзең аңла! — ди сыман.

Тып-тын булып калды. Шул мизгелдә тәҗрибәсез Шәрәфә Кәлимә белән Кадыйр язмышы өчен хәлиткеч тагын бер адым ясады. Шәрәфә, гадәтенчә, үзенең кырыс табигате таләбеннән котыла алмыйча, әйткән сүзенә өстәп, тагын кабатлады:

— Сез теләсәгез нишләгез, мин бүлмәгә кереп утырмыйм!

Үзләре һаман баруларында булдылар. Әллә ни озак вакыт та үтмәде, егет:

— Керергә теләмәгән кешене көчли алмыйм,— диде.— Минем бүлмә — хан сарае түгел. Теләгән кеше рәхим итсен, без кайтып җиттек.

Хәтта шул аерылышудан соң да әле Шәрәфә күңелендә өмет сүнмәде. Белмәде шул ул, үзе абына-сөртенә тулай торак ягына китеп баргач, Кәлимә белән Кадыйр арасында ни булганын һичничек белә алмады. Ул үзенең иске караватында боргаланып-сыргаланып азапланганда, Кадыйрның яртылаш җиргә сеңгән бер тәрәзәле бәләкәй генә бүлмәсендә көтелмәгән бәйрәм башланып китте.

Беренче карашка, шапшак кына, ат үлсә — ит, арба ватылса — утын, дип, дөнья мәшәкатенә бирелмәүчән күренгән Кәлимә, бусагадан атлауга:

— Бәй, идәнең юылмаган ич синең,— диде дә, җиңнәрен сызганып, чабуларын кыстырып, иркенләп торып, егетнең бүлмәсен җыештырырга тотынды.

Кадыйр аның яулыкка төйнәп куелган эре алмаларны хәтерләтүче күкрәкләренә, шәрә беләкләренә, кәкрерәк булса да, матур балтырларына сокланып та, оялып та карап-карап ала иде.

Сафланып калган, иркенәеп, яктырып киткән аулак бүлмәдә каракаршы утырып чәй эчтеләр. Өчәүләп йөргәндә гел сөйләшәләр иде, монда телсез калдылар. Моңарчы алар гел киресен эшләгәннәр икән — күңелдәге талпынуларны яшерер өчен юри өзлексез лыбырдаганнар.

Инде барысы да узды. Идәннең дымы да кибеп бетте. Чәй дә суынды. Нидер әйтмичә мөмкин түгел иде.

— Киттем мин.— Кәлимә урыныннан беренче булып кузгалды.— Сондыр инде?

Кадыйр да торып басты, сабыр гына, киңәш биргән сыман иттереп:

— Кал монда гына! — диде. Кәлимәнең күзләренә өздереп карады. Бу сүз кызны һич тә гаҗәпләндермәгәнен аңлагач, нәтиҗә дә ясап куйды.— Без барыбер өйләнешергә тиеш бит инде. Сизәсеңдер...

Кәлимә кулына тоткан кечкенә сумкасын киредән урындыкка куйды да салмак адымнар белән түргә үтте.

...Бер атнадан, кавышу ләззәтенең беренче тәэсиреннән айныгач, кулга-кул тотынышып, Шәрәфә янына килделәр алар.

— Тор! — диде Кәлимә...— Өйләнештек!

*

* *

Иоклый алмый азапланса да, яңа көн тууын түземсезлек белән көтеп ятса да, Шәрәфә җылы урын-җирдән аерылып китәргә теләми иде әле. Телефон тавышы аны сикереп торырга мәҗбүр итте.

— Кичә соң кайткансың, уникегә кадәр бер-ике мәртәбә шалтыратып караган идем... Инде мөнә тагын борчыйм, йокы алмады, азапланып беттем,— диде Кадыйр.

«Мин дә» димәкче иде Шәрәфә. Телен аркылы тешләп дигәндәй, тыелып калды. Унҗиде яшьтәге хыялый өметле көннәр күптән үткән, Кадыйрга, кеше иренә, Гөльяз атасына чишелеп китүдән генә яшьлек кире кайтмас.

— Ник дәшмисең, Шәрәфә?

— Исәнме, Кадыйр, хәерле иртә!

— Очрашасы иде бит, ә?

— Бүген эштән соң, башларым исән-сау калса, мин хәбәр итәрмен. Сине нинди телефон белән табарга була?

— Ышанмыйм мин бу телефоннарга, үзем барам...

Шәрәфә, эшкә барырга чыкса, ашыга, оча, кабалана. Башында яңа язылган мәкаләсенең аерым җөмләләре урала, яки алдан язганны төзәтер нәрсәләр тапкан була — кабинетка тизрәк керергә дә, язу өстәленә капланырга. Секретарь вазифасына бәйле техник эшләрдән дә рәхәтлек таба ул — цехка төшеп полиграфистлар белән гәпләшеп менсә, тынычланып китә.

Бүген әллә Кадыйрның Казанда булуы, иртәдән үк серле итеп шалтыратып куюы кысадан чыгарды — Шәрәфә ничек җыенуын да, эшкә ничек барып җитүен дә сизми калды. Ул, бүлмәсенә кереп, төнге сменадагы хәлләр яңадан исенә төшкәч кенә, сискәнеп куйды. «Әле бит редактор янына керәсе, аның өчен килешүләр төзеп йөргәнне аңлатасы бар».

Редактор төштән соң гына килде. Гадәттә, ул соңарып яки алдан китеп йөрми. Киресенчә, әдәби хезмәткәрләр эшкә тотынганчы килеп

утырган була. Ишеген төптән каерып ачып куя да кемнең кайчан эш башлавын искәреп тора. Соңгарак калучыларга, иртәрәк китеп баручыларга көнендә сүз әйтми. Әмма тәртип турында махсус җыелыш уздырса, кемнең ничә минут соңга калганын әйтми калмый.

Редакциядәге эчке тәртипне күзәтү Шәрәфәнең үз вазифасына керсә дә һәм моны редактор Шәрәфәдән таләп итәргә тиеш булса да, кемнең кайчан килү-китүен тикшереп утыру, гаеплене шелтәләү Шәрәфәнең кулыннан килми. Шунлыктан боларны үз ихтыяры белән ләззәтләнеп үтәп барган баш редакторга Шәрәфә бары рәхмәт кенә укый. Җыелышта, бөтен коллектив алдында редакторның берәүне әлеп алып селкеп салуы редакциядә ел буена нык дисциплина булдырырга бик җитеп тора.

Бүген исә редактор һаман килми дә килми. Шәрәфә, үзенчә, иртүк кереп мәсьәләне аңлатырмын да тынычлап эшләрмен, дип өметләнгән иде. Булмады. Бер кагылды ишеккә — бикле, тагын сугылды — юк.

Цехта җыерчыклана торган кәгазьне әллә кайчан бетергәннәр, инде коры кәгазь куелган, журнал әйбәт кенә басылып ята иде. Шәрәфә аннан берничә журнал алып менде. Икесен рәттән куеп чагыштырып караганда да төнлә басылган журналның җыерчыгы бу һөнәрнең серен белмәгән кешегә сизелерлек түгел иде. Шәрәфә әллә ни борчылмады. Киресенчә, төнлә килеп, эшне туктатмый калырга ярдәм итүенә сөенде дә әле. Редакторның да нәкъ шулай диячәгенә, хәтта рәхмәт әйтүенә өмет итте.

Шәрәфә редакторның ишеген ачып керү белән үк күңелсезлек булачагын чамалап өлгерде. Кабинет эчен кара болыт баскан сыман. «Кәефе юк,— дип уйлап алды Шәрәфә.— Ни генә булды икән инде? Өендәме? Мондагы эшкә кагылышлымы?» Редакторның шундый гадәте бар: эштәге берәр ярамаган хәлне белеп алса, турыдан-туры гына әйтеп, ачыклап куймый. Әле бер сотрудникны чакырып ала, аның белән бер мәсьәлә хакында сөйләшә, икенчесенә бөтенләй башка йомыш куша, әллә кемнәргә шалтырата, әллә нинди белгечләр белән киңәшә, кайберләре янына тиз генә, такси чакыртып, үзе дә барып кайта. Аннары, эшнең иң кызган чагында, кинәт җыелыш җыя. Гаеплене бөтен кеше алдында фаш итеп, аңа нинди җәза бирергә хәл кылуын белдерә.

Бүген дә нindидер хәерсез хәбәр белән килгән ул. Тик Шәрәфәнең кире чыгып китәр хәле юк, эшкә бәйле йомыш белән йөри, лабаса.

— Килгәнсез икән,— диде ул исәнләшү урынына.— Менә журналны тегә башладылар.— Ул ике журналны да редактор каршына илтеп куйды.

Гадәттә, журналның яңа санын беренче тапкыр кулга алу редакциядә зур бәйрәмгә әйләнә. Баш редактор үзе дә моңа ихластан шатлана, бүлмә саен кереп, сотрудникларның журналга карата фикерен сораша. Бу юлы ул әллә ни ачылып китмәде. Тышлыкларын әйләндергәләп карады. Аннары берсен алып, эчен актара башлады. Җыерчыклы нөсхә иде бу.

Шәрәфә нәкъ шулай булачагына ышанып торды: теге браклы биткә редактор аерым тукталып тормады, мәкалә исемнәрен кычкырып укыды да, алдагы битләргә күчте. Бәйләнерлек нәрсә тапмады, әмма әлеккечә шатлыгын да сиздермәде.

— Ярый,— дип кенә куйды.

Шәрәфә:

— Менә моңа игътибар иттегезме? — дигән булып, хәлне үзе аңлатырга мәҗбүр иде.

Төнлә цехка чакыртуларын, мәсьәләне бик тиз хәл итәргә кирәк булуын сөйләмәкче иде. Редакторга әйтерсең лә шул сәбәп кенә кирәк булган, теге җыерчыклы битне яңадан эзләп тапты да кул сырты белән төйгечләргә тотынды. Ул үзе дә моңарчы күрми үткәрүен, хәзер

чәпчүнең көлкерәк килеп чыгуын аңлады. Акланырлык сүзен дә бик тиз тапты.

— Соң мин буз экземплярны гомумән браклар арасыннан нелегально алынган дип белдем.

— Юк, алай түгел.

— Ничек син шундый журналны укучыга тәкъдим итмәкче буласың? Гомумән, кем сиңа андый эшләргә катнашырга рөхсәт биргән? Ә?

Шәрәфә үзен чыннан да гаепле саный иде, шунлыктан артык сүзләшмичә, кызарынып тик кенә басып торды.

Шактый тиргәгәч, идеология эшенә бәйле олы сүзләр бетте. Шәрәфә, бу хактагы яман хәбәр әле шактыйга барачагын аңлап өлгерсә дә, хәзергә, бәлки, чыгарга рөхсәт булыр, дип өметләнгән иде. Редактор:

— Беләсеңме, син нигә шундый? — дип, яңа яктан сорау китереп куйгач, ышанычы бетте. Иң яманы башланырга гына тора икән әле: шәхескә, өйгә, гаиләгә, нәсел-нәсәпкә, дус-ишкә бәйләнү китә хәзер.— Син үзең өчен генә яшисең, шуңа күрә бернинди җаваплылык та тоймыйсың. Сиңа нәрсә — кайттың, яттың. Гаиләгә аш пешермисең, бала чүпрәге юмаган син, бала елаганда йокы калдырмаган — эгоист обыкновенный!

Мондый сүзнең Шәрәфә үзәгенә нинди җәрәхәт булып кадалуын редактор бик әйбәт белә, шуңа да бик еш кабатламый ул аларны, әллә нигә бер генә файдалана. Шул очракларның берсендә генә дә Шәрәфәнең, тел әйләндереп, каршы сүз әйтә алганы юк иде әле.

Ул тагын, чалгы очы тигән чәчәк сыман, киселде дә төште, күзләренең нуры сүнде, йөзе сулды, хәле китте. Кабинетына ничек кереп җитүен дә хәтерләми Шәрәфә. Исенә килеп, каршында яткан кульязмаларга күз салырга да өлгермәде, коридорда редактор аягындагы киң үкчәле олы туфлялар шакылдавы ишетелде. Редактор, ут чыгарырдай нык басып, ашыгып атлый. Шәрәфә аны-моны абайлаганчы, ул килеп тә керде. Йөзе балкыган, кулында — Шәрәфәнең эчкечелеккә каршы әле кичә генә язып тапшырган мәкаләсе.

— Шәп! Великолепно! Молодец! — Редактор яктырак якка, тәрәзә янына үтеп, мәкаләне кычкырып укырга тотынды.— Менә бит ничек оста әйтелгән, э-э, «...машина — ул хатын түгел, никләр генә эчтең соң, бәгърем, дип, өзгәләнеп тормый, әйләндерә дә каплый». Шәп! Ха-ха-ха!!! Искиткеч үтемле әйтелгән. Хатынны санга сугарга кирәк, дип үгет-нәсихәт биреп тору түгел.

Шәрәфә әле генә үзен өнсез итеп чыгарган редакторның мактау сүзләренә ояла-ояла шатланып утырды. Язып азапланган кешенең күңелен күрим дисәң, иҗатына карата бер-ике җылы сүз генә тап икән. Шәрәфә ачылып китте. Редакторы да, әйтерсең лә, моннан биш минут кына элек бу кешене зобаниларча тиргәмәгән, авызы-күзе көлә, баскан урынында биеп кенә тора, башы күккә тигән диярсең.

Шәрәфә тирән итеп бер сулады да, шактый тынычланып, эшкә чумды.

*

* *

Кадыйр чыгып киткәнгә күп тә үтмәде — Кәлимә як-ягына аек күз белән карый башлады. Өч бүлмәле өйдә ул бер ялгызы торып калган иде.

Гөльяз — Казанда. Ул бала бик яшьли мөстәкыйльлеккә омтылучан булды. Сигезьеллыкны тәмамлауга, Казанга китеп, техникумга урнашты. Җәйге каникулында да әти-әнисе янына кайтмый. Сәбәбе табыла торды: я бөтен группа төзелештә эшкә калды, ди ул, я дус кызым белән җылы якка ял итәргә китәм, дип яза. Әти-әнисен якын күр-

сә, ул сәбәпләрне кире кагардай мөмкинлеге дә чыгар иде. Юк. Кайтмый. Кыз янына алмаш-тилмәш үзләре бара башладылар...

Кәлимә, уйларының күңелсез вакыйгаларга барып тоташуын өнәмичә, чыраен сытты. «Бала күңеле далада, дип белми әйтмәгәннәр. Юк инде ул, юк. Кыз бала бигрәк тә...» Хәзерге хәлендә Гөльяз белән очрашудан ул бераз курка иде. Ни өчен шикләнә, ник? Кәлимәнең нигезе бар соң? Кадыйр үзе киреләнә бит. Кәлимә иренең соңгы вакытта көн саен кызуын, ниһаять, бөтенләйгә чыгып китүен туктатырдай көч барын сизә иде. Инәлү идеме ул, тыныч кына ачыктан-ачык сүз башлау идеме, моңарчы булгалап торган ямьсез кычкырышулар вакытында эндәшми торумы, Гөльяз барын искә төшерүме — нидер бар иде, анысын аныклау кыен. Әмма Кәлимә боларның берсен дә эшләргә теләмәде. Кадыйр:

— Болай яши алмыйм мин, булмый! — дип кычкыргач та, Кәлимә гаҗәпләнмәде. Үзе дә шуны гына көтеп торган сыман, гәрчә мондый сүз әйтелүдән йөрәге ярылырдай куркып яшәсә дә, елмаеп җавап кайтарды Кәлимә.

— Соң, бар алайса, бар, тик дөньяны шаккаттырам, дип уйлама. Дүрт ягың кыйбла!

Кадыйр ул көнне үк чыгып китмәде китүен. Эч пошыргыч, гомер кыскарткыч шактый көннәр үзды.

Кәлимә, алар турында уйламаска тырышып, урыныннан кузгалды. Кулы эшкә бармый, ашыйсы-эчәсе килми, хәтта җитди генә уйларга да көч юк, фикерләр бер ноктага килеп төртелер дә, бөтен гаепләр үз өстеңә өелеп калыр, кая керер җир табалмассың, төенеңне сүтәр җай чыкмас төсле иде. Ул хәрәкәтләнергә кирәк булган өчен генә кухняга керде. Монда бөтен нәрсәнең асты-өскә килгән иде. Әллә ничә көннән бирле чәйнектә быксып утырган суны алмаштырды. Чәй эчәргә кирәк, дип уйлады. Әбиләребез, шатлык килсә дә, кайгы басса да, самовар колагына юкка гына барып ябышмый торгандыр. Ул чәй дигәненең бер хасияте бардыр, мөгаен.

Чәйнекнең кайнап чыгуы артык озакка сузылыр сыман тоелды. Кәлимә, әлгечтәге алъяпкычы белән кыекча яулыгын алып, бүлмәләрне җыештырып чыгарырга, рәткә китерергә ниятләде. Идән юа торган полиэтилен чиләк чүп белән тулган. Аны хәзер урамга чыгару мөмкин түгел. Кешедән оят. Күршеләрнең берәрсе очап: «Кадыйрың күренми, кая ул?» — дип сораса, ничек җавап бирерсең? Караңгы бүлмәдә вактөяк керләр юа торган кечкенә ләгән бар иде. Шуны эзләп тапты Кәлимә.

Әлегә кадәр өйне җыештырмый торуының да сәбәбе шул: Кадыйрның ниләр алуын, нәрсәләрне Кәлимәгә калдыруын ачыклыйсы килми. Соңгы вакытта алар икесе ике бүлмәдә яши башладылар. Уртада — зал. Кәлимә ишек төбендәге тып-тын бүлмәгә посты. Кадыйр элек-электән үзенең эш кабинеты итеп билгеләнгән түр якка бикләнүчән булып калды. Китәсе көнне иртәдән үк ул яктан дөбер-шатыр иткән тавышлар ишетелде. Кәлимә, бичара, шым булды. Йөрәгенең дөпелдәвен һичничек тыеп булмый иде. Әллә кайчан Кадыйр өчен алып куйган «Волокордин»ын да эчәргә уйлады. Аны суга тамызып эчәләр. Су алырга кухняга чыгарга кирәк. Аяклары атламады. Даруны шул килеш кенә күп итеп капты. Авызы янды, эче көйде. Элеккечә: «Кадыйр, уф, үләм, тизрәк су китер!» — дип, кычкырып җибәрә язды. Түзде, эндәшмәде. «Шул кирәк сиңа!» — диде үз-үзенә. Түр якта шап-шоп иткән тавышлар һаман тукталмый иде. Кадыйр китаплар аралый иде, күрәсең.

Бераздан ул, залның шыгырдый торган идәненә нык басып, Кәлимә бүлмәсенә якынлашты. Хатын: «Килде! Керә! Аллага шөкер,— дип

сөенде.— Нинди генә сүз әйтсә дә, каршы төшмәскә кирәк...» Ишек төбенә җитсә дә, ир тоткага кагылмады, эчкә үтмәде, тыштан торып кына сөйләде.

— Мин Болгариядән алып кайткан чемоданны алам инде, китаплар сыймый.

Кәлимә:

— Ник аны сорап торасың? — дип кенә әйтә алды.

Кадыйр кире китте. Кечкенә диван өстендә китап укыгандай итеп утырган хатын сыгылып төште. Иренең ниләрне үзенә алуы, гаҗәпкә каршы, аны бөтенләй кызыксындырмый иде. Ник алай ул? Аерылышучыларның иң зур дәгъвалары әйбер бүлешкәндә чыга, дип сөйлиләр иде бит. Кәлимә исә: «Үзе булмагач, ул калдырган әйберләр ни пычагыма кирәк?» — дип фикер йөртте.

Менә хәзер, Кадыйр бүлмәсенә килеп кергәч, ул куырылып китте. Бүлмә кабер базы кебек иде.

Кадыйр хәтта китапларны да әллә ни күп алмаган. Хуҗалыкка кирәкле уртак әйберләр урыныннан да кузгатылмаган. Сызганып-кыстырынып җыештырырлык чүп-чар да юк, ичмасам. Идәннең ялтыравыгын гына юка тузан пәрдәсе каплаган.

Кәлимә язу өстәленең өстен сөртеп алды да идәнгә бөкрәйде. Өстәл астына сузылгач, Кадыйрның өр-яңа йомшак башмакларын күрде. «Онытткан! Онытмаса, йокыдан уяну белән иң кирәкле әйберен алмый китмәс иде!» Хатын дымлы чүпрәк белән башмакларның бәрхет тышын, асларын сөрткәләде дә залга чыгып китте, үзе йоклый торган бүлмәгә керде, башмакларны кая урнаштырырга белми аптырап калды. Бүлмә уртасында шактый вакыт басып торгач, диванның кечкенә мендәре янына китереп куйды.

Чыгып киткәндә Кадыйр ашыккан-кабаланган күрәсең. Кәлимә өйдә юк иде шул, белми калды. Иренең чынлап торып җыенуын сизгәч, өйдә утырырга сабырлыгы җитмәде, ашык-пошык киенде дә урамга атылды. Башына һичнинди фикер килми иде.

Әче җил исә. Тик бөтен әгъзаларын тоташ ут алган хатын боларның берсенә дә игътибар итәрлек хәлдә түгел. Бүреген батырып кигән, тун якасын торгызган, йөзен шул яка эченә яшергән килеш, аяклары хәрәкәтенә баштанаяк буйсынып, бара да бара иде ул. Бу шәһәр зур түгел, ачуланыбрак атласаң, бер сәгать эчендә аркылыга-буйга урап чыгарга була.

Якындагы аэродромнан самолет күтәрелгән тавыш колакны ярып яңгырады. Шунда гына Кәлимә каушап калды, өйләреннән шактый еракта икәнен абайлады, җанын үкенечле сагыш талый башлады, тизрәк өйгә кайтып җитәргә, Кадыйрны күрергә, аягына егылып ялварырга, аны өйдә калдырырга иде!

Әмма ашыгуы бушка булып чыкты, Кәлимә кайтып кергәндә, Кадыйр өйдә юк иде инде. Урамда битен кисеп искән җил салкынлыгын сизмәгән дә Кәлимә эссе өйдә кинәттән туңа башлады. Төймәләрен генә ычкындырып, тунына төренде, тире эчле итекләрен дә салмады, түргә узып, люстраны кабызды. Зал уртасындагы өстәлдә Кадыйрның соңгы «сәламе» — бер төргәк акча ята иде.

Кәлимә бөгәрләнеп килде. Өстәл янындагы урындыкка лапылдап утырды, тун якасын мендәр итеп, башын өстәлгә салды. Ичмаса, хәсрәтеңне юып агызырлык яшең булсын иде... Күпме өзгәләнсә дә, Кәлимәнең күзеннән бер бөртек тә яшь чыкмады. Уйламый кылып ташлаган хата өчен табигать аны елатмас хәлгә китереп җәзалый иде, күрәсең.

Тик, ни хикмәттер, хәтта хәзер дә, шушы япа-ялгыз хәлендә дә Кәлимә үзе кылганнарның берсен дә үкенү белән искә алмый. Кадыйрга

кияүгә чыгарга, туйлар уздырырга йөргән ишеткәч, әллә ничә кыз аңа бу уеннан кире кайтырга киңәш бирде.

— Синең теге артист белән буталып йөрүләреңне кичермәс, күзеңне дә ачтырмас,— диделәр.— Әле кыз килеш алгач та, татарның дәгъвасы еш кына: «Син кыз түгел идең!» — дип битәрләүдән башлана...

Кәлимә кеше сүзенә колак салмады, һәм аның Кадыйрга булган ышанычы нигезле булып чыкты. Әллә барысы да үз күз алдында үткәнгә, әллә Кәлимәне яратканга, Кадыйр хатынының беренче хатасын, Кафьянов белән хур булуын, юри генә дә телгә алмады. Аның бу хакта фикерен белергә теләп, Кәлимә Сашаны искә төшергәләсә, Кадыйр ул сүзне ишетмәмешкә салыша, әңгәмәне бөтенләй башка якка борып җибәрә иде.

Сизенгән диярсең! Шул Кафьянов аркасында гаиләләренең челпәрәмә киләчәген алдан күреп торган диярсең!

Кунаклар сирәк күренә торган бу кечкенә шәһәргә концерт бригадасы килүен ишеткәч, бөтен кеше, яше-карты билет артыннан чаба башлады. Көн-төн заводтан кайтып керә алмаган Кадыйр булып Кадыйр да Кәлимәгә әйтеп куйды:

— Син теләсәң, аласың инде ул билетны,— диде.— Әйдә, тырышып кара әле! Безгә дә бер күңел ачу тиештер бит!

Икенче көнне Кәлимә, Кадыйр эшкә киткәч, киенеп-ясанып, концертка билетлар сатыла торган кассага йөгерде. Шәһәрнең иң зур культура сарае иде бу. Билет кассасы урнашкан фойесы үзе генә дә берише клубның тамаша залыннан зур. Стеналарга концерт бригадасының афишалары, солистларының портретлары ябыштырылган. Касса тәрәзәсе янына коллективның исемлеге, кемнең нинди жанрда чыгыш ясавы күрсәтелгән тагын бер белдерү эленгән. Концерт турында хәбәр ишеткәч үк Кәлимәнең җанын билгесез бер талпыну биләп алган иде. Инде бу бинага аяк атлап кергәч, тагын да каушады — бу бер дә юкка булмаган икән. «Концертның конферансьесы Александр Кафьянов» дигән юллар Кәлимәнең күзләрен әлҗе-мөлҗе китерде. Хәрефләр бисһа, афишалар сикерешә, тирә-юнь чайкала башлады.

Көтелмәгән бу яңалыктан Кәлимә күңеленда: «Бернинди дә билет алмаска, концертка аяк та атламаска!» — дигән уй туды. Ләкин тиз генә чыгып китәсе дә килмәде. Кассага чират тезелгән иде. Ул да барып басты. Аклану сүзләре дә уйлап тапты: «Кадыйр кушты! Үзе җибәрде!»

Урамга чыккач гаҗәпкә калды ул: кыш уртасы язга әйләнгән, кар бөртекләре күбәләкләр булып оча, муеннан батырлык көртләр челтәрәвек гөрләвекләр кебек күренә. Кәлимәнең авыр туны да канатлар шикелле җиңеләйтелгән иде. Казанга беренче аяк баскан көннәрендәге кебек, Кәлимә чынбарлыкны тоймый башлады, яшьлеге яңадан кайтты, диярсең. Аның тизрәк концертка барасы, Кафьяновны күрәсе, һәм үзен дә аңа күрсәтәсе килә иде.

Ник шулкадәр ашкынуын Кәлимә әле дә аңлый алмый. Нәрсә көтте? Аңа тагын ни кирәк иде соң? Һичнинди мохтаҗлыгы юк бит. Ул тагын бер кат тормыш аяусызлыгы алдында үзенең көчсезлеген генә күрсәтте. Язмыш исә Кәлимәнең артына тибәр өчен әзерләнеп үк торган икән.

Концертка барганчы Кәлимә Кадыйрга аны-моны әйтмәскә ният итте. Култыклашып, уен-көлке сөйләшә-сөйләшә залга килеп керделәр, иң алгы рәткә узып утырдылар. Хатынының өзлексез көлеп кенә торуын хуплап, Кадыйр:

— Син бөтенләй яшәреп киттең, карчык,— диде.— Сине гел концертка гына йөртәсе бар икән.

— Әйе шул. Синең өч булмәңне саклап ятып картаеп беттем ин-

де.— Тагын көлде Кәлимә, утырган урынында тыныч кына тора алмас хәлгә килде.— Иртәгә дә киләм әле мин бу концертка.

Пәрдә ачылып, сәхнәгә Кафьянов чыгып кына баскан иде, Кәлимә белән Кадыйрның карашлары очрашты. Кадыйр күзләре җавап көтә иде.

— Үзең куштың! — диде Кәлимә, әллә кайчан уйлап куйган аклануын эшкә җикте.

— Алай икән монда эшлә-ә-әр...— Бу Кадыйрның Кәлимәгә карата әзме-күпме кешечә әйткән соңгы сүзләре иде.— Мин китәм, син теләсәң нишлә!

Ник кенә шунда Кәлимәне дә җитәкләп алып чыгып китмәде икән Кадыйр, ник аның ялгызын гына калдырды икән? Ялгыз хатынга теләсә кем шикле караш ташлый. Бу юлы исә Кәлимәгә теләсә кем түгел, нәкъ менә шул ук Кафьянов шаккатып карап торды. Аның хәтта концерт алып баруында да сизелде бу. Сәхнәгә чыгып баса да, күзләрен Кәлимәгә текәп, шактый вакыт сүзсез тора, аннары чираттагы чыгыш ясаучының исем-фамилиясен генә әйтеп, кереп югала. Шаянлыгы да, чыгышлар арасын ялгап сөйли торган шигырьләре дә әллә онытылган, әллә кирәген югалтканнар.

Кәлимә ул концертта нинди җыр тыңлаганын да, кайсы биюне күреп сокланганын да, тәнәфес игълан ителүен дә хәтерләми. Дөньядан кичеп, онытылып, кыймылдарга да җөрьәт итмичә утыра иде, бераүнең арттан: «Ник ял итәргә чыкмыйсыз?» — дигән сүзләренә сискәнеп китте.

Киләмә борылып карарга батырчылык итмәде, чөнки билә иде Кафьянов бу. Хезмәтенең бөтен кануннарын бозып, гримлы бите, сәхнә өчен генә тегелгән костюмы белән тамаша залына төшкән. Кәлимә хакына, аның бер сүзен ишетер өчен!

Бу хәлдә бер сүз дә ала алмаячагына бик тиз төшенгәнгә, ул Кәлимәнең кулына кагылды.

— Әйдә, болай ярамый,— диде.

Якында гына, ян стенада, берәү дә кереп-чыгып йөрми торган бер ишек бар икән. Алар, шуннан үтеп, сәхнә артына килеп керделәр.

— Күзлеклем минем!

— Кирәкми, Саша, искә төшермик.

— Искә генә төшерергә ярыйдыр инде...

Аның тирән-тирән сулу алуларыннан, Кәлимәгә карата бик итагатьле мөнәсәбәтеннән анларга мөмкин иде — егетнең тормышы шома гына тәгәрәмәгән бугай. Элекке мут карашы моңлы, чәчләр сирәгәеп, чаларып киткән, бөдрәсе дә күзгә ташланмый, хәтта тавышында да элеккеге нык ышаныч, һавалану калмаган. Кәлимә исә үз хәленә үзе шаккатып утыра: нишли ул? Ник монда?

Сашаның шәлсыман озын якалы пальто киеп маташуын күргәч, ул телгә килде.

— Әле бетте дәмени концертыгыз?

— Минем алмашчым бар. Сине очраткан көнне дә мине алыштырмагач, нәрсә өченгә йөри ул?

«Өченгә!» Тагын шул килделе-киттеле сүз! Кәлимә, хәле китеп: «Э-эһ!» — дип куйды. Сашаның бөтен серләрен берьюлы әйләндереп түгәргә шул үзәк өзгеч аваз җитте.

— Минем дә тормыш барып чыкмады бит, күзлеклем! — диде Саша. Ул Кәлимәнең исемен оныткан иде ахры, хәтерендә күзлек кенә калган. Һәм ул үзенең шушы яшендә япа-ялгыз калуын, хатынының баланы алып, башка кешегә кияүгә чыгуын, хәтта алименттан да баш тартуын сөйли бирде.— Күрәм, синдә дә җиңел түгел,— диде ул сүзен очлап.— Җир читендәге бу шәһәрдә ялгыз хатынга җиңел була димени?!

Барыбер ышандыра алмаячагын абайлап, Кәлимә аңа ире, баласы барын әйтеп тормады. Кызык: аның үзенә дә ул ялгыздыр, таныш-белешләрдән дә бөтен дөньясында менә шул Саша гына торып калгандыр кебек тоелды. Кәлимә Кафьяновка гашыйк самими чагындагы хисләренең әле һаман сүнмәгәнлегенә хәйран калды.

Артист аны урамга алып чыкты, ниндидер машинага утыртты, зур бер производство берләшмәсенә караган кунак йортына алып килде.

Озак тормыйча, башкалар да кайтты. Шаулашып-гөрләшеп бүлмәгә кереп тулдылар. Күбесе урта яшьтәге кешеләр иде. Сәнгать турында, тамашачының зәвыгы хакында бәхәсләшә-бәхәсләшә сөйләшеп утырдылар. Өстәл тулы ниГЪмәт иде. Кайтып кергән мәлгә генә кызу-кызу капкалап алдылар да, сүзгә бирелеп, ашау-эчүне оныттылар. Алар Кәлимәне дә читтә калдырмады, теләсә-теләмәсә дә, фикерен сорыйлар иде.

Артистлар таралышканда, соң иде инде. Кафьянов бүлмәсендә тагын бер артист — үзенең алмашчысы йокларга тиеш икән. Кәлимә белән Сашаның күзгә-күз карашып өнсез утыруын күргәч, ул:

— Мин күршеләргә керим, булмаса,— диде.

Кафьянов сискәнеп, сикереп торды.

— Юк, юк,— диде.— Без урамга чыгабыз, күзлеклемне өенә озатырга кирәк...

Ташлап калдырылган Кәлимәне үзенә яр иткән Кадыйр шушы гөнаһсыз кичәне кичерә алмады. Хәер, Кәлимә үзе дә яхшылык өмет итмәгән иде.

Язмышына бәйле вакыйгалар турында уйлана башласа, Кәлимә үз өстенә бер өем гаеп җыя. Шунлыктан ул үткәннәрне искә төшерергә яратмый.

Кухня ягыннан ишетелгән сабырсыз гавышка сөенеп куйды ул, өрелеп-өрелеп искә төшә башлаган күңелсез хатирәләрдән арынырга җай чыкты. Кечкенә генә никель чәйнек инде баядан бирле ду килеп кайный, суы капкачны шалтырата, ыргып-ыргып ташып утыра иде.

Ашык-пошык чәй эчкәннән соң, Кәлимә киенә башлады. Сәгатенә күз салды. «Өлгерәм әле!» — дип куйды. Ул үз карарыннан бик канәгать иде. Аның өчен үкенүдән дә авыррак нәрсә юк хәзер. Бөтен кылганнары тоташ ялгышлардан торганга шулайдыр мөгаен. Инде бу юлы кулда булган бердәнбер мөмкинлекне соңыннан үкенмәслек итеп файдаланырга ниятләде ул.

Аяк астында кар шыгырдый. Кәлимә кышның нәкъ шундый әллә ни салкын булмаган һәм коры көннәрен бик ярата. Шыгыр, шыгыр, шыгыр... Бу аваз күңелдә туган көчсез генә өметне канатландыра, ышаныч уята, тәмам сүнеп барган яшәү шатлыгын яңарта кебек. Адымнар ешайган саен, аяк астындагы көр тавыш та куәтләнә бара. Кәлимәнең тагын да тизрәк атлыйсы, йөгерәсе килде, тирә-юньдәге кешеләрдән генә яхшы түгел. Аннары җан өшеткеч икенче тойгы да ерак китмәгән, өмет белән рәттән үк, авызын ерып, анысы да үз өлешен көтә. Ул хәтта аның ашыгуыннан көлә кебек: и юләр, бәхетеңне кулдан бер ычкындыргач, шәһәр буйлап чабу түгел, һаваларга менеп җилпенсәң дә, кабат эләкми инде ул сиңа.

Каршыда стеналары гел пыяладан гына торган зур бина күренде. Кадыйр шунда эшли. Ил күләмендә танылган фәнни-тикшеренү институты бу. Анда теләсә кемне кертмиләр. Ишектән бер-ике генә адым үттеңме, барьерга килеп төртеләсең.

— Кем кирәк сезгә, кайсы бүлек?

Дежур хатынның йөзендә усаллык галәмәте күренмәсә дә, үз сүзләренең бик урынлы икәненә ышану җитәрлек иде.

— Утыз өченче бүлеккә шалтыратырга мөмкинме? — Кадыйрның исем-фамилиясен телгә алырга Кәлимәдә куәт җитмәде.— Бүлек начальнигына бер генә сүз әйтәсем бар.— Дежурның әле һаман телефонга якын җибәрергә уйлап та карамавын сизгәч, өстәде: — Мин — аның хатыны, Биләрова.

Дежур бераз читтәрәк торган телефон тумбочкасына таяпылды, пыяла астындагы кәгазьгә күз салды.

Кәлимә, аның бу хәрәкәтен рөхсәт итүе дип аңлап, барьер ишегеннән эчкә үтте, телефонга якынайды. Хәзер шалтыратыр ул. Күңелендәге бөтен шәфкатьне тавышына салып: «Кадыйр,— дип эндәшер.— Син теге йомшак бәрхет туфлиләреңне оныткансың, иртәләрен ялан аяк йөрмәссең бит инде, килеп ал син аларны!» — дияр.

— Күрәсеңме менә бу исемлекне? — Дежур хатын юан имән бармагы белән тумбочка өстендәге пыялага төртте.— Монда әнә бернинди дә Биләров юк.

Кәлимә ялт итеп кыска гына исемлеккә карады. 33 нче бүлекнең начальнигы язылырга тиешле урында «Биләров» сызылган да янга «Самойлова» дип язып куелган. Кәлимә агарынып китте. Аны әле мәсьәләнең төп хикмәте түгел, үз сүзенең ялганга чыгуы, дежур алдында оятлы булуы хурландыра иде.

— Күчте микәнни? — дип үзалдына сөйләнде.— Миңа әйтеп тә тормаган, күрәсең?

Дежур хатын: «Кәмит кебек яшисез инде, берегезнең ни кылганын икенчегез белми, хәсрәт капчыклары!» — дигән кыяфәт белән телефонга ымлады.

— Шалтырат инде, әйтерләр анда...

Көтелмәгән яңалыктан Кәлимәнең тез буыннары йомшады, бармаклары дерелдәргә тотынды. Аппараттагы өч санны көчкә җыйды.

— Алло, мин тыңлыйм,— дигән гайрәтле тавыш ишеткәч, ул бөтенләй югалып калды, эндәшә алмый торды. Трубканы чыннан да хатын кеше алды. Шул «Самойлова» дигәннәре, күрәсең. Кәлимәнең котын алып «Алло!» сүзе кабатланды.

— Исәнмесез!

Җавап булмагач, Кәлимә мөмкин кадәр битарафрак тавыш белән үз йомышын әйтте.

— Миңа Биләров кирәк иде. Кадыйр.

— Ул юк һәм булмас та. Аның урынына мин билгеләндем. Хезмәткә бәйле йомыш булса, рәхим итегез.

— Юк, андый түгел.— Самойлованың трубканы элеп куюыннан шүрләп, Кәлимә ашыгып сорап калды.— Биләровка ничек шалтыратырга икәнен генә әйтмәссезме?

Самойлова Кәлимәнең Биләровны нинди дер интим мәсьәләдә эзләнеп килүен сизеп алыпмы, әллә, гомумән, бу хактагы сүзнең артык озакка сузылуын өнәмичәме:

— Һе-һе,— дип, көлемсерәп җавап кайтарды.— Сез, кадерлем, бераз соңга калып эзли башлагансыз, бит, Кадыйр Биләров әштән бөтенләйгә китте. Ялгышмасам, шәһәрдән үк китәргә йөри иде ул. Әйе, әйе, Казан самолетына билеты ук алынган иде инде аның.

Кәлимә өнсез калды. Бер-берсеннән башка яшәргә тәкатьләре калмыйча өйләнешкән кешеләр гаиләне саклап калу, мәхәббәт кебек олы хисне тормышның соңгы көннәренә кадәр җиткерү өчен беренче очрашуларын, ул көннәрдә кичергән тойгыларын, бер-берсенә күрсәткән игелекләрен әледән-әле искә төшереп торалар. «Хәтерлисеңме, син миңа ул чакта нәрсә дигән идең?..» «Бу яулык — минем туган көнгә биргән беренче бүләгең...» «Мин ангина белән авыргач, хәтерeңдәме, бөтенләй көтмәгәндә син миңа баллы кайнар сөт керттең. Тулай торакта көндез берүзем ятып, күңелсезләнеп беткән идем. Бүлмә шыксыз, егетләр —

дәрестә, сүз кушар кеше юк. Шул чакта, ишек ачылып китте дә, син килеп кердең. Үзең халаттан гына, кулыңда кайнар сөт тулы олы кружка. Мин:

— Нишләп син дәрестә түгел? — дим.

— Ә,— дисең син.— Сөткә чират иде, соңга калдым инде. Барып йөрмим...» — Тагын көлешәләр. Ир хатынын үзенә тартып ала.

Танышкан-кавышкан чакларга бәйле хатирәләрне яңартып тору күңелне яшәртә, вак-төяк мәшәкатьләрдән арындыра, барлы-юклы үпкә-сапкаларны юып алгандай итә. Ир белән хатын гүя яшьлеккә әйләнеп кайталар.

Башка гаиләләргә сафлану китерә торган андый искә төшерүләр Биләровларда хатынның мәңге җуелмаслык хаталарын, ирнең кичерүчәнлеген, кыскасы, Кәлимәнең Кадыйрга муеннан бурычлы икәнен раслауга гына кайтып калачак иде.

Дус-ишләрдән, туган-тумачадан ерактагы бу шәһәрнең кар-буранлы урамында япа-ялгызы торып калгач, яшьлек хатирәләренең барыберьюлы исенә төшеп, Кәлимәнең тынын кысты. И ул самими кичерешләр, и Казан! Кадыйрны очрату. Шәрәфә. Өчәүләшеп Казан урамнарында йөрү...

Кәлимәнең йөзе ачылып китте. «Казан бит әле дә урыныннан күчмәгән. Шәрәфә дә шунда, Гөльязы да. Кадыйр да шунда очкан. Почта бар, телефоны, телеграфы! Юк, әле берни дә бетмәгән, югалмаган. Нигә башка төшкән һәр хәсрәт алдында җебеп калырга? Тырышып-тартышып карарга кирәк!..»

Шулай бит ул: кыядагы дәү ташны аска тәгәрәтеп җибәрү ахмак кулыннан да килә, яңадан үз урынына менгезүләре генә, ай-һай, авыр.

*
* *

Көч-хәл белән атлап, эштән кайтып кергәндә, Шәрәфә күңелендә бары бер генә якты уй бар иде. Тиздән монда Кадыйр киләчәк. Аны күрү, аның тавышын ишетү җан кимергеч бөтен күңелсезлекләрне юып алыр кебек.

Хуҗасы күренүгә, Карахмәт үзенекен дәгъваларга тотынды. Аның нинди тавыш чыгарып мияулавыннан Шәрәфә песигә ни кирәген аңлый. Ишекне ачты да, Карахмәт сыешлы ара калдырып, чылбырга гына эләктереп куйды. Шәрәфә өйдә чакта, песи шуннан кереп-чыгып йөри. Монысы да — редакциядә чыккан күңелсезлекне онытырырга ярап тора торган бер шөгыль. Шәрәфәгә хәзер нәкъ шул кирәк, өй мәшәкатьләренә чумарга да эш турында онытып торырга. Бу кадәресен белә Шәрәфә, тик шуңа ирешү юлларын гына таба алмый интегә. Күңелсезлек дигәнең, бер килә башласа, төрле тарафлардан ябырыла бит ул.

Редакторы яныннан чыкканда Шәрәфә коллективта алтынга алыштырмас дуслары барына, аларның әлеге хәлне ачыклаячакларына һәм, кирәк булса, үзен яклаячакларына ышанып торган иде.

Бераздан җыелыш башланды. Редактор Шәрәфәнең «һичнинди кысаларга да сыймый торган тәртибен» коллективка җиткерде. Соңыннан:

— Ибедәшләр, без монда бик җаваплы эш башкарабыз, хәлбуки, үз арабызда шул эшкә аяк чалырга теләүчеләр дә бар,— дип Шәрәфә өстенә бер олау гаеп эеп куйды.

Моннан кырык-илле еллар элек кулланылышта йөргән янаулы сүзләр сотрудникларны ихтыярсыздан елмаерга мәҗбүр итә иде. Чөнки һәркем, хәтта редактор үзе дә, Шәрәфәнең журнал өчен җанын кыз-

ганмый тырышуын күреп тора. Редактор, берәм-берәм бастырып, Шәрәфәнең төнге «кыланышы» турында фикер сорый башлагач та җаваплы секретарьны яклау сүзләре генә ишетелде. Бу очракта башкача эшләргә ярамавына да тукталдылар. Редакторның исә үз сүзен күмеп калдырырга исәбе юк иде. Ул андый очракта кемгә таянырга кирәклеген дә алдан чамалап куйган.

— Сез, иптәшләр, хәлнең җитдилеген аңлап җиткермисез. Әмма мин алдан чакырып алып корректор ибедәш Хәмидә белән сөйләшкән идем, ул миңа җаваплы секретарьның үз эшенә шактый салкын каравын раслап күрсәтте.

Җыелыштагылар барысы берьюлы аргы почмактагы урындыкка поскан чибәр хатынга борылдылар. Ул, күрәсең, редакторга әйткән сүзләренең болай бөтен кеше алдында кабатланачагын уйламаган — комачтай кызарды. Кара керфекләр белән каймаланган сугандай яшел күзләре тычканныкыдай биешә башлады. Җитәкчесенең ятмәсенә эләккән корректор Шәрәфәгә кызганыч тоелды. «Шулай да безнең редактор дөрес эшли,— дип, күңеленнән тагын бер нәтиҗә чыгарып өлгерде.— Икенче вакытта кеше артында пыш-пыш килеп, әләкләшеп йөрмәскә әйбәт булыр!»

— Хәмидә әйтә: җаваплы секретарь соңгы вакытта нервныйга әйләнде, игътибарсызланды, кайчак хаталы битләрне дә «басарга ярый» дип имзалап җибәрә, ди.

Шәрәфә:

— Бәлки без Хәмидәнең үзен тыңларбыз, ачыктан-ачык сөйләсен әле бер! — дип, үз тәкъдимен кертте.

Бу хәл Хәмидә өчен тагын да кыен иде. Ул чалбар кесәсеннән алып, берәүдән дә рөхсәт-фәлән сорап тормастан, сигарет кабызды.

— Кичерәсез, тартмый түзә алмыйм,— диде ул. Башын аска иде, торып басты.— Э-э, Шәрәфә Шакировна алай ук нервный түгел ул, ни... э-э... Менә кияүгә чыкса...

Кемдер Хәмидәгә уенын-чынын бергә кушып:

— Синең кебекме? — диде.— Ирләрне бишташ урынына учында уйнатасың...

Редакторның гайрәтле тавышы бу ямьсез әйткәләшүләрне басты:

— Ярый, утыр, Хәмидә. Иртән син туп-туры әйткән идең, Шәрәфә үзе монда булгач, йомшап төштең бугай, ха-ха-ха... Да-ссс!

Җыелыштан чыкканда Шәрәфә корректор хатынны ышанычлы иптәшләре арасыннан сызып ташлаган иде. Бу аңа барыннан да авыррак тоелды. Редакторга рәхмәт — күзен ачты Шәрәфәнең. Шулай да эштәге һәр күңелсезлек саен моңарчы ышанычлыдан исәпләнгән кешеңне югалта барсаң, кыенгарак туры килер.

Хәзер дә, өенә кайтып, көндезге күңелсезлекләрдән арынырга тырышып вак-төяк эшләр белән шөгыльләнә башлагач та, күңеленә ин тирән яраны Хәмидә салуын тойды Шәрәфә. Эш кешесенә шелтәсен дә, мактавын да ишетергә туры килә. Дус, сердәш исә бер мәртәбә генә табыла, аны бер генә тапкыр югалтасың да...

Телефон шалтырады. Өстен яңа гына алмашып, кухняга кергән Шәрәфә, аяк арасында буталып йөрүче Карахмәт белән узыша-узыша, зал ягына ашыкты. Трубкада Кадыйр тавышы иде.

Шәрәфә аның сүзләрен ояла-ояла тыңлады: «Шәрәфә, бүген дә чыгып качма инде, хәзер барам, яме...»

Яшәреп киткәндәй булды Шәрәфә. Йөзенә алсулык йөгерде, күзләре дымланды.

— Кил, Кадыйр, кил! — диде. Бүген аңа Кадыйрдан да тансыграк кеше юк иде.— Кил, көтәм!

— Хәзер!

Икесенең дә шатлыгы телефон трубкасыннан гына аңлатып бетерә торган түгел. Тизрәк очрашырга, күзгә-күз карашып, яшьлектә ясаган хаталарны танырга, аны башка кабатламаслык итәргә, язмыш артыннан йөргән күңелсезлекләргә юлны бикләп куярга кирәк.

Шәрәфә белән аралашкан кешеләр аның хакында үзара сөйләшә башласалар: «Көчле дә кыз инде, малай! — диешәләр.— Ирләрең бер якта торсын!»

Аңардан кемнәр генә шәфкать күрмәде? Сабакташларына кулыннан килгәнчә ярдәм итүдән башлаган иде, хәзер инде аның янына, көймәләре комга терәлгәндә, таныш-белешләренең балалары йөри. Төп йортта да нужа арбасын төпкә җигелеп тартучы Шәрәфә булды. Гөллия апасы кияүгә киткәч, әнисе Хәмдия авылдагы иске йортта япа-ялгызы калды. Кияү янына барасы килмәде. Шәрәфә бу юлы да егетләр вазифасын өстенә алды: яңа квартирага бирелгән ордерын тотып авылга кайтты да, бөтен вак-төяген колхоз машинасына салып, карчыкны Казанга, үзе янына күчерде. Моны ул җиңелгә генә санаган иде дә, тиз арада мәсьәлә катлаулана башлады. Бердән, мәсәлән, Хәмдия түтине ялгыз калдырып командировкага йөрүе зур уңайсызлык. Икенчедән, бәйрәмнәрдә-ниләрдә Шәрәфәне үз итеп җыелган журналист иптәшләрен дә карчык өнәп бетерми. Алар китүгә Шәрәфәгә үпкәсен белдерә, кайчакта килгән кешеләр янына ук чыга да: «Җитте, булды, йокларга вакыт!» дип кәефне боза. Хәтта Шәрәфәгә гашыйк бер егет: шул «өстәмәсе» булганга гына өйләнмәдем мин аңа, дип сөйләп йөргән. Егет, әлбәттә, ялгышкан. Өйдә берүзе генә булса да, Шәрәфә аңа барыбер кияүгә чыкмас иде, Кадыйрдан соң берәүне дә ярата алмады ул. Яратмыйча иргә чыгуны исә ахмаклыктан саный. Аңа хәзер күбрәк әнә шундый ялгышлыкны ясаган кешеләргә киңәш бирергә, еш кына турыдан-туры ярдәм итәргә дә туры килә. Әзмәвердәй ирләр, әллә нинди уңган хатыннар, гаиләләрендәге котылгысыз хәлдән гаҗиз булып, Шәрәфәгә сыеналар. Соңыннан, тагын тыныч кына яши, эшли башлагач: «Ну, рәхмәт, Шәрәфә малай, көчле дә кеше син!» — диләр.

«Көчле Шәрәфә»нең исә үзе көчле дип санаган берәр ир-ат заты янына барып, күңелен бушатасы килә. Андый кешесе дә бар аның, Кадыйр ул. Эче тулы сагышын аңа гына түгәр иде дә... Иң кирәк чагында булмады шул. Шәрәфә тәвәккәлләгәнче, башкалар өлгеррәк булып чыкты. Хәзер инде Кадыйр да әнә ярдәм сорап аның үзенә килгән.

Шәрәфә, Кадыйр турында алай уйларга ничек оялмыйсың дигән кебек, куллары белән башын кысты, йөзен сыйпап алды. Аннары кухняга ашыкты, үзе тәмле, үзе тиз өлгерә торган аш әзерләсән яхшы булыр иде.

Кухня белән зал арасында йөри-йөри Шәрәфә күпме вакыт узуын чамалый алмады. Ул, нинди генә эшкә тотынса да, онытылып китеп, яратып үти. Аш-су тирәсендә кайнаша башласа да шулай. Салкын ашы да, авыз суын китерердәй әчесе-төчесе дә булсын, дип тырышкач, табыны шактый мул булды. Кайнар ашы — духовкада, әкрен генә лепердәп утыра. Кадыйр өстен-башын чишенеп өлгергәнче, анысы да өлгерә килеп җитәчәк.

Шәрәфәнең күптән инде болай очына-очына табын әзерләгәне юк иде. Әнисе Хәмдия карчык исән чакта килеп-китеп йөрүчеләр күп булды. Җәй саен апасы белән җизнәсе, әнинең хәлен белəбез, дип, озаклап торалар иде. Алар — укытучылар, еллары икешәр ай. Ул чакта Шәрәфә кунак-төшем аркасында яраткан эшенә вакыт тимәвенә борчыла. Шулай да өендәгеләргә сиздерми, табынын мул итеп әзерли, хәтта төн буе телевизор караучы җизнәсенә дә караңгы йөз күрсәтми иде. Ник дисәң, кунак сыйлаудан да, язгандагы кебек үк тәм таба, ләззәт

ала белә ул. Хәмдия түтине җирләгәч, туган-тумача Шәрәфәгә еш килми башлады.

Кадыйрның кайту хәбәре инде онытылып барган рәхәтләрне искә төшерде. Шәрәфә очына-очына табын тезә, өен җыештыра, музыка җайланмаларын рәтли. Барысы да көйле торсын. Кем белә, бәлки, утыра-утыра берәр җыр тыңлыйсылары килер, тыңларлар. Бәлки, музыка дөньясына кереп киткәч, биергә теләрләр. Шәрәфәнең йөздән артык пластинкасы, магнитоласы бар. Магнитофон тасмалары да җитәрлек. Җае чыкса, Кадыйрның тавышын да язып алырга була. Аннары теләсәң кайчан утыр да тыңла. Алдыңа фотосын куясың, магнитофонны борасың: каршыңда — сурәте, колагыңда — тавышы. Тагын ни кирәк?!

Шәрәфә елмая да елмая. Ул бит боларны күңеленең иң түренә кереп оялаган ышанычын, гомере буе көткәненең тормышка ашачагын тойганга гына уйлый. Кадыйр, Кәлимә турында сүз чыккач, әйтте бит: ул юк, ул булмаган да...— диде. Димәк, алар икәү генә булганнар — Шәрәфә дә Кадыйр, Кадыйр да Шәрәфә! Нигә аның фотосурәте? Нигә аның магнит тасмасыннан чыгачак җансыз сүзләре? Үзе булсын! Шәрәфәгә Кадыйрның үзе кирәк!

Аның бүген, менә хәзер, ун елдан соң Кадыйр күзенә кабат күренгәндә, бик матур буласы килә иде. Шәрәфә кунакны каршыларга барысы да әзер икәнен тагын бер кат күңеленнән уздырды да аргы якка узды. Гадәттәгечә пөхтә җыештырылган йокы бүлмәсендә дә һәр нәрсә үз урынында иде. Кием шкафын ачты. Бәйрәм булгач, бәйрәм булсын инде. Аның һәр елның 8 Мартына атап яңа күлмәк тектерү гадәте бар. Быелгы тантанага ул әле кыш уртасында ук, алтынсу-саргылт асыл күлмәк әзерләгән иде. Тотты да шуны киде. Кызык булсын әле.

Кием шкафының капкачындагы озын көзгегә күз салгач, Шәрәфә битен дә бераз «эшкәртергә» кирәк тапты. Хуҗасының аягына урапып йөдәткән Карахмәт кенә: «Нишләвең бу? Гомер кыланмаганны?» дип, кирегә үгетлидер кебек иде. Шәрәфә идәнгә чүгәләп аны иркәләргә тотынды.

— Син, Карахмәткәем, барын да аңлап бетермисең бит әле,—дип, сөйли-сөйли сыйпады.— Миңа бит бүген бик матур булырга кирәк, беләңме? Кичер син мине, аңла, бүгенгә генә... Бераз буяныйм инде! Яме?!

Битенә алсу крем сөрткәч, керфекне озынайтып катыра торган сөрмә тарткач, иренен дә алсуландырып җибәргәч, Шәрәфә үз кыяфәтеннән канәгать булды.

Хәзерлек түгәрәкләнгәч, Шәрәфә, ишек төбендәге һәр аяк тавышына колак сала-сала, сабырсызланып, Кадыйрны көтә башлады. Аның ишеге янында еш кына, «дыңк-дыңк» итеп, лифт туктый.

Бер дыңкылдау үтте, икенчесе, өченчесе... Бусы, мөгаен, улдыр инде! Шәрәфә, әле Хәмдия түти исән чакта ук ишеккә куелган пыяла тишеккә күз салды. Күренерлек түгел, килгән кеше кыңгырау төймәсенә баскан да читкә тайпылган. Кулларының калтырануын көчкә тыеп, Шәрәфә йозак боргычын кирегә тартты. Елмаеп ишекне ачып җибәрде. Каршысында...

— Кә...!

Юк, Кәлимә түгел иде бу. Егерме ел буе һаман да шулай саклана алмый ич инде Кәлимә. Ишек төбендә басып торучы кыз:

— Исәнмесез, Шәрәфә апа! — диде.

Зиһене генә чуалып китмәсен. Калганын Шәрәфә үзе очлап чыгачак. Бер, ике, өч...

— Ә, әйдә, үз!... Гөльяз! — Кәлимә түгел, аның җиткән кызы бу.— Уз, уз, тартынма!

— Сез каядыр җыенгансыз, ахры? Абау, күлмәгегезнең матурлыгы!

— Юк... әйе, театрга бармакчы идем дә...

Шәрәфәнең театрга аяк та атлыйсы килми. Үз өендә, үзе тезгән затлы табында теләгән кешесе белән кара-каршы утырып чәй эчәсе килә аның.

— Син Казандамыни, Кә... Гөльяз?

— Әйе. Сезгә керергә һич җай чыгара алмый идем. Әле әни белән телефоннан сөйләштек тә, килергә булдым.

— Уз, әйдә, түргә!

Гөльяз чишенде. Ишек төбендәге көзгегә күз салып алды.

— Әле генә чәчемне кистердем, килешәме?

Шәрәфә, ялгышмыйммы дигәндәй, кызга төбәлеп карап торды. Аннары аны-моны сиздермәс өчен генә җавап кайтарырга ашыкты.

— Килешә, Кәлимә, килешә...,

— Ха-ха-ха. Кәлимә түгел бит, мин — Гөльяз! Иң матур исем: гөлләр, язлар... Кәлимә бит ул «сүз» дигәнне генә аңлата.

— Әниеңә бик охшагансың,— дияргә мәҗбүр булды Шәрәфә. Кыз төсе-бите белән генә түгел, үз-үзен тотышы, хәтта сүзләре белән дә нәкъ әнисе иде.— Ярый, әйдә, түргә уз!

Залга үттеләр.

— Абау! — Кыз ап-ак эскәтергә тезелгән табынны күрде.— И-и, нинди тәмле нәрсәләр!

Гөльяз, күргәзмәдәге мәшһүр рәссамнарның әсәрләрен карап йөргәндәй, өстәл тирәли әйләнә-әйләнә, табынны күзәтергә тотынды.

— Икра да бар! Ике кешелек...— Ул ялт итеп Шәрәфәгә борылды.— Кемнедер көтәсез икән бит?!

Шәрәфә зур гөнаһ өстендә тотылган кеше кебек комачтай кызарды.

— Әтиемнеме? Ә-ә, әни дә әйткән иде аны-ы-ы...

Чигенер урын юк. Шәрәфә, уңай җавап биргәнен аңлатып, башын игәндәй итте.

— Шәрәфә апа, мин әни сүзләреннән дә берни аңламадым. Әйтегез әле, эти ни өчен сезнең янга килә соң ул?

Шәрәфә ни әйтергә белми торды. Аннан соң гына:

— Дуслар без. Бик якын дуслар,— диде.

Бу сүз кызга ошады, ул артык төпченүне кирәк санамады.

— Чибәр сез. Чәчегез дә, күзләр дә... Фигурагыз шәп!

Шәрәфәгә кыен булып китте. Япь-яшь кызның шулай әнисе кебек кешегә бәя биреп маташуы акылга сыймый торган тәрбиясезлек тоелды. Шәрәфә сүз ишеткән саен артка чигенә барды. Чигенә торгач, ишек төбенә үк җитте, кулы йомшак нәрсәгә тиде. Туны икән. Кисәктән башына яңа уй килде. Ул, кабаланып, элгечтәге тунын алды, бүрегенә үрелде, аягына да киндер элде.

— Соңармыйм тагын,— дигән булды.— Китим тизрәк! — Ул гүя үз өендәге бөтен хокуклардан мәхрүм ителгән дә хәзер урамга чыгар өчен Гөльяздан рөхсәт сорый.

— Кызык икә-ә-н. Үзе кунак көтә, үзе тагын каядыр ашыга...

Урам салкынлыгындагы иреккә ирешкәнче әле тагын берәзгә чыгарга кирәген аңлап алып, Шәрәфә кухня ягына ымлады.

— Кайнар аш — мичтә, яме. Мине гафу итә күрегез!..— Ул елмаерга тырышты.— Син зур бит инде хәзер. Табынга үзең хуҗа бул! Мин ашыгам...

Аһ, ашыгыр җире булса иде! Кая гына ашыксын соң ул? Юк бит, ашыгып түгел, салмак кына атлап та барыр җире юк.

Җанында бары өйдән качып котылу теләге генә котырганда, хәленең бу ягы турында уйламаган иде әле Шәрәфә. Кадыйр килеп кергәнче, ата белән баланың очрашуын үз күзе белән күргәнче, юк булырга, тыныч ялгызлыкта калырга теләде. Ишек ябылуга, лифт көтеп

тормастан, аска атылды, итегенең җиз кадаклы биек үкчәләре, таш басмалардан ут чәчрәтердәй булып шакылдадылар.

Ул инде ишек төбендәге тар сукмакка чыгып баскан иде. Урамда салкын. Кар да җил, караңгылык та ялгызлык. Шәрәфә, бер минут та туктап тормастан, алга атлады, тик кая барырга белмәүдән, адымнар үзләреннән-үзләре акрынайдылар. Нәкъ шул чакны олы урамга тоташкан чат башында төз гәүдәле бер ир күренде: «Ул! Кадыйр! Нишләргә?»..

Ачык бер фикергә килгәнче, Шәрәфә, сукмактан читкә тиз генә тайпылды да, ашыга-ашыга өй каршындагы бакчага керде, карт өрәңге ышыгына барып басты. «Ул мине күреп калмады микән, таныды микән?» дигән борчулы сораулар куркыткан иде аны. Кадыйр килгән якка кабат күз салу белән үк аңлашылды: Шәрәфә янына ашыгучы Кадыйрның кача-поса бакча буенда йөрүчеләрдә бер гаме дә юк. Ул эре-эре атлап бара иде.

Кадыйр кереп китәргә тиешле ишектән, иркә мияулавын суза-суза, кинәт Карахмәт сикереп чыкты. Шәрәфә, аны-моны белештермәстән, аңа тартылды. Песи башка вакытта урамга ялгыз чыгып йөрми һәм йөри дә белми иде. Бүген, хуҗасының уйлары чуалган арада, аңа дип ачылган ишек ябылган да песи тышта калган. Тик хәзер, шул ишеккә Кадыйр якынлашканда, Карахмәтне ничек тотып алырга соң?

— Пес-пес! Карахмәт, кил монда, пес-пес!

Шәрәфә бер Кадыйр ягына, бер ишектән чыгуга, салкын кар көртләре каршында нәүмизләнеп калган песигә карангалады. Кадыйр анымоны сизмичә, сабыр гына килә. Карахмәт әллә тавышны ишетте, әллә хуҗасын танып алды, туп-туры Шәрәфә ягына чапты. Хуҗасы сөялгән өрәңгегә житкәнче, песи урамның якты чатындагы бу якка чыгарга тиеш иде. Шул турыда аны Кадыйр күреп алды. Песи дә, Кадыйр да тукталдылар. Кадыйр артына әйләнеп, кара мәче кисеп үткән юлдан атларгамы-юкмы, дип, икеләнеп карап торды. Шикле мизгел тиз үтте, ир алга узды. Карахмәт исә, күз ачып-йомганчы, хуҗасы янына килеп җитте.

Песиен генә көткән диярсең, Шәрәфә аны кулларына алды да, Кадыйр кергәннән соң тагын да яктырып киткәндәй тоелган тәрәзәсенә карашын ташлап, бакча караңгылыгына таба атлады. Карахмәтне иркәли торган гадәттәге сүзләрен тезеп китте: «Нишләп кар арасында йөрисең әле син, ә? Ишегең ябылганмени? Керә алмый интектеңме? Кил әле монда, кил, җылытыйм әле үзеңне. Тәпиләрең туңгандыр?!»

Песи аның куенына ук кереп чумды, йомшак тун рәхәтендә эреп, мырауларга ук тотынды.

...Шәрә агачлардан да, йортларның караңгы күләгәләреннән дә, ак кардан да салкынлык, бары тик салкынлык кына бәрелә. Кайбер кичләрдә кар бөртекләре сибеп шаяручы җил дә, үзәккә үтеп, җанны суытырга теләгәндәй, Шәрәфәгә бары тик коры салкынлык кына өрә.

Шәрәфә, җан өшеткеч караңгылык шомлыгын сизмәмешкә салышып, адымнарын кызулата, атлаган уңайга, куенындагы җылы йомарламны күкрәгенә ныграк кыса бара иде.

## Камил Мостафин

### Хыял кошы

Күр әнә: онытып курчагын,
уйга калган сабыем.
Нинди сер, әкият сыман
биләгән аның уен?

Күр әнә, күр: карт бабаем
елмаеп утыра бүген.
Нинди хикмәт бер минутка
кайтара алган яшьлеген?

Ул — хыял! Ул —
гомеребезнең
тургае! Тынып-тынып,
шатлыгын чәчә җиһанга,
ал кояшка омтылып.

Без дәшәбез... Нинди якты
бу кошның җаваплары!
Нинди моңнарны күтәрә
кечкенә канатлары!

Без үткәч тә, без киткәч тә,
беткәч тә онытылып,
ул һаман балкыр биектә
бер серле нокта булып.

●

Су өстендә — агач күпер, иске күпер.
Такталары шыгырдыйлар, — яше күптер.
Карт күпергә иртә таңда бер кыз баскан, —
иелгән дә, кырыеннан карый аска.

Үсмер кызчык,— бар язмышы алда әле,
бар өмете, ышанычы — таңда әле.
Хәйран калган бала: суда күкләр ага,
ап-ак бите, бүрәнәләр, мүкләр ага.

Нинди кызык нәрсә икән — иске күпер...
Ә астында ул күпернең... — юк, су түгел!
Килер бер көн,— бу агымның тәмен татып,
кыз да аңлап алыр әле: ага Вакыт...

●

Учакта янган
агач кисәген
кисәү генә диләр.
Кулга алсаң
һәм, вакыт белән ярыша-ярыша,
алга омтылырга торган иптәшеңә
китереп бирсәң,
аны
эстафета диләр.

Бу җирдә иң кирәк кешеләр —
кисәүне эстафета итүчеләр!

●

Яңгыр коя, — ялтыр-йолтыр, —
хәнҗәрләре җирне телә.
Тайгак юлдан җигүле ат —
колынлы ат юыртып килә.

Нәни колын... Аяклары —
шырпы кебек... Тая-тая,
яшеннәрне исни-исни,
ул ашыга әллә кая.

Ул елыша әнисенә,
ә тәртәләр комачаулый,
нигә алар шундый салкын,
ник тәртәләр... — ул аңламый.

Ә әнисен камчы куа,
камчы кумый — тамчы куа,
үзе әнә башын борган,
карап нәни колынына.

Ә арбада — яшь-яшь малай, —
яшеннәргә карап көлә.
Күкнең салкын кулларына
рәхәтләнеп кулын бирә.

Аның әле татыйсы бар
яңгырларның моңын, тәмен,
үсеп җиткәч, аның әле
аңлыйсы бар колын хәлен...

●

Җирдә югалтсаң эземне,
диңгездән эзлә мине.
Әгәр диңгездә тапмасаң,
йолдыздан эзлә мине.

Йолдызда булмасам, эзлә
йөрәгеңнән. Анда да
тапмасаң, башка эзләмә, —
мин, юк, димәк, дөньяда.

## Кара аккош

Тып-тын күлдә — кара аккош, кара аккош —
төнбоеклар арасыннан йөзеп килә.
Кара аккош, кара бәхет, кара язмыш,—
аңа карап, яр буенда халык көлә.

— Исеме — аккош, аның каралыгы нигә?..
— Кара бит ул,— нигә аккош исемен йөртә? —
шулай сөйли төптән уйлый белүчеләр,
аңа таба бармак белән төртә-төртә.

Салмак кына бөгелеп китә кара муен,
акрын гына кагып куя кара канат.
Кабул ителмәгән сәнгать әсәредәй,
кара аккош йөзеп килә, безгә карап...

●

Чәчләреңә көзге кырау кунгач кына
һәм калыккач кына әни яткан кабер,
син аңлыйсың икән, дустым, йөрәк белән:
Ватан да — бер, Тукай да — бер, әни дә — бер.

## Нурмөхәммәт Хисамов

# ТӨРЛЕ ЕЛЛАР ДӘФТӘРЕННӘН

### Юлым буйлап йөгерә каеннар

Таң-иртәдән юлга ашкынам,
Урман буйлап чаба машинам.
Каршы яктан йөгерә каеннар,
Әйтерсең, гамь, бер-бер ваем бар.
Бәкәлләре җитез бөгелә —
Кай арада күргән хәстәрен! —
Кемнең шулай тигез йөгерә
Алмачуар атлы гаскәре?

Игенчегә янап салада,
Һөнәрчегә янап калада,
Хәвеф салып көньяк даладан,
Яу килгәнме Болгар иленә?
Яшел җилән элеп иңенә,
Булат кылыч алып кулына,
Күзне текәп дала юлына,
Яу чыгамы болгар ирләре,
Саклар өчен туган җирләрен?..

Үзем очам үрдән аскары,
Тасмаланып артта юл кала,
Офыкларга кереп югала
Каеннарның атлы гаскәре.

### Язгы шәфәкъ

Ник яратам шул яз шәфәгын?
Шау-шулардан җиһан тын кала.
Тереклеген күреп гүя ул
Үз яменә үзе соклана.

Син мәңгегә җиргә килгән күк
Юлың алда, өстә зәңгәр күк.
Карт атаң да, карчык анаң да
Үзгәрмичә мәңге яшәр күк.

Бар тарафта нурлы яшеллек.
Сирәк кенә сары чәчкәләр.
Ал сабаклы япь-яшь үләндә
Күк тәпиле сары бәпкәләр.

Язның шушы тере бизәген
Уяу саклап ана каз тора.
Укыласы серле китаптай
Башланмаган яңа яз тора.

Балкып яна — учак шикелле
Каршы якның тәрәзәләре —
Кичке кояш алга манчыган
Ямьнең барлык дәрәҗәләрен.

Җан җилкенә, күңел
һаман көр,
Көнең тоташ эшләп узса да.
Язгы җирнең салкын
дымыннан
Син атлыйсың кайнар мунчага.

Һай яратам язгы шәфәкъне,
Баеш түгел, туыш шәфәгын! —
Алда синең бөтен бер гомер,
Әле синең дәртле, яшь чагың.

## Туган якта

Үләннәрнең исе шул ук,
Чәчәкләрнең төсе шул ук,
Иләннәрнең шавы шул ук,
Үзәннәре, тавы шул ук.

Тик нилектән җанда — сагыш?—
Җилкенүле шат өннәр юк?
Тик тормаган вакыт-агыш:
Инде күпме якыннар юк...

●

*Ты дала красивое страданье.*
С. Есенин

Гәрчә рәхәт иде уяну,
Гел газаптан торды бу яну.

Үгетләдең һаман сүз белән,
Бүтән серләр түкте күз генәң.

Йә нурланды уйнак дулкыннан,
Йә тын калды тирән күл сыман.

Колагымда тынмый чыңлады
Тавышыңның якты чыңнары.

Син дөньяның гүзәл төсләрен
Көннәремә минем өстәдең.

Хәл ителгән синең язмышың,
Көннәреңнең тигез агышын

Бозуны мин синнән көтмәдем,
Корбаннар да өмет итмәдем.

Әзер идем үзем барсына.
Баскан килеш дөнья каршына,

Үтәп кырыс хөкем чарасын,
Күтәрергә гыйшкым җәзасын.

Тырышсаң да ләкин күпме син
Яшерергә миннән үз хисең,

Дәлилләрең булды күп синең —
Өстәлеңә ятып үкседең.

Син аңладың минем йөрәкне,
Юк, артыгы миңа кирәкми!

Үз дөньяма кире очамын,
Хуш, бәхетле була күр, җаным!..

Тугрылыкның җебен өзмәсен
Соңгы ярым — сөйгән хезмәтем.

●

Минсез узган сезнең кичәнең
Күреп калыйм диеп кисәгеп.

Яныгызга сезнең тукталдым,
Ягыгызга сезнең күз салдым.

Кызган чагы уен-көлкенең.
Кул чабасың син дә җилкенеп.
Үтеп шунда мәйдан арасын,
Миңа төште синең карашың.

Шул арада нинди үзгәрү:
Моңга тулган синең күзләрең!..

Бер караштан тойды күңелем
Минсез сиңа рәхәт түгелен.

## Җанда бөркет талпына

Тормышның вак шатлыгыннан
Эзләп яшәү мәгънәсен,
Һич кызыгып калма, күңелем,
Һәр узгынны ямьгә син.

Бу кичәләр үтәр-китәр,
Тик олы гамь мәңгелек.
Яшьлекнең һәр елы калсын
Илне бизәр ямь булып.

Юллар диеп, куллар җәеп,
Тагын гайрәт калкына —
Җанда бөркет үлмәгән ич,
Талпына ул, талпына.

# Зиннур Мансуров

## Шөгыль

*Буш вакытларында Каюм Насыйри — көзге ясау, Хәсән Туфан сәгать төзәтү белән шөгыльләнгән.*

I

Венеция остакуллары да,
Насыйри да көзге ясаган.
Ясаган ул — үзен-үзе күреп,
бер уйлансын өчен барча җан.

Чит шөгыльме? Ә бит уйлап баксаң,
шушы булган аның төп эше.
Чынны чагылдырган Насыйриның
материалистик көзгесе!

... Каюм эшли. Әнә «Кырык бакча»,
менә «Фәвакиһелҗөләсаә»[1]...
һәрберсенә исем куша-куша,
кешеләргә көзге өләшә.

Ә бирсен ул, серле тамга салып,
бүләк итәр Гөлнар ханымга[2]...
һич тутыкмый торган бу көзгеләр
көнләштерер Пти-Жанны[3] да.

Насыйринныкылар, рентген сыман,
күрсәтәдер рухны үтәли.
Каюм һаман ясый: чын йөзләрен
белмәүчеләр җирдә күп әле...

Көзге беркайчан да алдаламый,
һәм ул тиңдер туры сүзлегә.
Шуңадыр да кыек авызлылар
кайчак үпкәлиләр көзгегә.

---

[1] «Кырык бакча», «Фәвакиһелҗөләсаә» — К. Насыйри әсәрләре.
[2] «Гөлнар ханым» — татар һәм башка мөселман халыклары мәгърифәтен дөньяви нигезгә кору өчен көрәшкән шәрык белгече, К. Насыйрины якын күргән рус галимәсе О. С. Лебедева псевдонимы.
[3] Пти-Жан — яңа төрдәге көзге ясаган француз уйлап табучысы.

Менә шулар күпме көзге ваткан,
ә китаплар әллә аз янган?..
Насыйридай бөек көзгече дә
чак сөрелмәгән бит Казаннан.

Реакцион «бәгъзы адәмнәр»не
«урыс» Каюм үзе хур итә:
Унөч батыр[1], дию юлын бүлеп,
гүя, көзге-дәрья ыргыта...

Күпме битлекләрне салдыра ул,
мәгърифәтче күпме аң ача.
«Рус революциясе көзгесе»н
Каюм Насыйри да ясаша!..

Рәхмәтеннән күбрәк кыйналулар,
уч-тиргәүле хатлар алса да,
гомере буе, күз нурларын түгеп,
сукыр Каюм көзге ясаган.

II

Резедалар быел тагын
чәчәкләнгән көз якта.
Көн күзендә онытылып,
Туфан сәгать төзәтә.

Вакыт хәтеренә Җәлил
кайтып керә бүз атта.
Ап-ак чәче яктысында
Туфан сәгать төзәтә.

Инквизитор Галилейны
аклап бүген сүз әйтә...
Угын кире бора-бора,
Туфан сәгать төзәтә.

Сөембикә манарасын
Кисмиме вакыт-балта? —
Йөрәк тибешенә көйләп,
Туфан сәгать төзәтә.

Умырзая токымына
үлем-афәт күз ата.
Бакый җанга әйләнсә дә,
Туфан сәгать төзәтә.

Туфан сәгать төзәтә...

## Капка

Чисталыкка табынучы
җан булган ул асылда.
Беләсезме: юган хәтта
капка баганасын да.

---

[1] Унөч батыр — шул исемдәге татар халык әкияте герое.

Кыра-кыра юар өчен,
алган чыра пычагы...
Бер дә кулын селтәмәгән:
«Бетмәс, — дип, — мир пычрагы».

Ә бу сүзне аңа күпләр
әйтеп калган артыннан.
Көндез шундый эшне дә ул
башкарырга тартынган, —
кеше-кара күрмәсен, дип,
төнлә чыккан юарга.
Әнкәй капка чистартуны
санамаган юк-барга.

Ачык йөзле шул капкага
кер-пычракны кем яга?
Ә ул моннан кәвешен дә
сөртеп чыккан дөньяга...

Эчкерсез дус аяк тибеп
ачканда да тап кала...
Тәгәрмәчләр тәгәридер
саз чәчрәтеп капкага.

Онта сыман, куна тора
олы юлның тузаны.
Чәче белән җир себергән
капка юмый түзәме?..

Ярый кайчак җир пычрагын
яңгыр юа, кар ала.
Һәркемгә дә ачык капка,
әйе, тизрәк карала.

Бер уйласаң, бу гап-гади
капка гына түгел лә.
Бәлки, шуннан башланадыр
керү безнең күңелгә...

Фани дөнья пычрагыннан
ник бер генә тап калсын!
Каны белән юган кеше
Бранденбург капкасын...

... Кеше-кара күрмәсен, дип,
төнлә чыккан юарга.
Әнкәй капка чистартуны
санамаган юк-барга.

## Сандал

Кызган тимер, кызыл сут балчыктай,
әллә ничә төргә үзгәрә.
Сандал гына кала элеккечә,
типчесә дә үзен йөз яра.

Зәһәр елан сыман бөгәрләнеп,
богау беләзеккә әйләнә.
Ә югыйсә сандал шундый гади —
юк тылсым да, сер дә, хәйлә дә.

Тимерченең кайчак каны кыза,
сандал кызмый —
салкын акыл белән эш итә.
Тавышы да үзгәрүне белми —
гел бер төрле чыңын ишетәм.

Әкияттәге бүре тавышын ул
үзе әнә ничек нечкәртә...
Чүкеч эштән чыга,
ә сандалда
күп кыйналган саен көч арта.

Вакыт белән кеше туза хәтта,
ә ул картаймый да, армый да.
Үзгәртәдер төсле шушы сандал
тотырыклы кануннарны да.

## Чистару

Кер күтәрә алмас ак бүз
кабат ничек агара?

Терекөмеш туңар җилдә
катып-өшеп агара.

Кер күтәрә алмас ак бүз
кабат ничек агара?

Кар эчендә, көртлек сыман,
туңа-уңа агара.

Кер күтәрә алмас ак бүз
кабат ничек агара?

Тимер кертактаның сырын
ашый-ашый агара.

Кер күтәрә алмас ак бүз
кабат ничек агара?

Бәләк һәм таш арасында
мең кыйналып агара...

Бер тапланган күңел, әйтче,
кабат ничек агара?..

## Катыктан акча эзләү

Хак түгелме: кул шулай ук
эшли авыз өчен дә.
Авызга кул ярдәм итми
бары катык эчендә.

Кирәк чакта сандугачтай
сайрасын һәм кош тотсын,—
әйтү башка, эшләү башка —
авыз шуңа төшенсен.

...Табагы шул бигрәк тирән,
ә катыгы ап-ачы...

Авызыңа кирәм, диеп,
тормый икән акчасы.

Шул гап-гади эш рәтен дә
аңышалмый тиз генә,
ә катыкта акча түмән
авыз шундук сизенә.

Әйдә, авыз бер мәртәбә
үзе эшләп ашасын...

Ни әйтәсең икән, халкым,
шушы уен аша син?..

## Бер төнлек күбәләкне юату

Гомерне ник азсынырга?! —
Оптимист җан бул, әйдә.

Күз алдыңда Җирдән картрак
йолдыз мөмкин үләргә.

Эз калдырыр өчен кайчак
җитми йөз ел вакыт та.

Ә син, бәлки, төн яшәп тә,
уелырсың якутка!..

## Гасим Лотфи

# ПУМА БЕЛӘН КӘБЕРЛӘ

ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК



абан, тирес эшләре бетү белән, яңа мәктәп салу эшенә тотындылар. Атлылар урманнан агач ташыйлар. Такта яручылар, балта осталары аларны эшкәртәләр. Ун-унбиш кеше, нигезгә тезеп калдыру өчен, зират тавыннан ак таш чыгара. Бөтен авыл кызу эштә. Каты сукага кадәр төп эшләрне җиңеп чыгарга уйлыйлар.

Малайларга да эш табыла: йомычка җыябыз, агач каезлыйбыз, нигез урынын казыганда чыккан балчыкны носилка белән урам чокырларына чыгарып түгәбез. Морат абзый эшкә дәртләндереп тора, бер ару-талу белми эшлибез.

Ул елны инештә ташбаш, шыртлака тотып йөрүләр, беренче күке кычкыру белән, иреннәр күгәргәнче су керүләр онытылды. Су керергә бик теләсәк, кичкә таба төшеп, тиз генә бер-ике чумып алабыз да печәнлеккә менеп яту ягын карыйбыз: иртәгесен тагын таңнан торырга кирәк. Һәммә кеше эштә булгач, ничектер, тик йөрү килешми дә шикелле.

Пума белән Кәберләне дә я иртән көтү алып чыгып киткәндә, я кичен көтү кайткач кына күрергә туры килә. Бер көнне иртә белән көтү алып чыгып барганда Пума тәрәзәгә кычкырып китте:

— Әй, Карис, сес пер дә килми пашладыгыс песнен җанга! — Нәкъ безнең тәрәзә турында чыбыркысын бер шартлатты.— Пүген пес төш бахытында иске күпер урынына төшәбез, килегез!

Төш җитүгә, инеш буена йөгердем. Мин төшкәндә терлекләр туплауга кереп ятканнар, тик өч-дүрт кәҗә генә һаман, көтүдән чыгып ычкынырга чамалап, читтә йөри иде.

Пума шул кәҗәләрне куа: «Әй җахандамлыклар! Кәмәр карчык пакчасына кермәкче пуласызмыни?!» — дип кычкыра. Кәберлә чәй кайнатырга җыенып йөри, кизәк өеп, ут яккан, өреп, утны үрләтергә тырыша. Мине күрү белән, торып, көтүнең икенче кырыена китеп барды.

Мин учак янына килеп утыруга, Пума үзенең күпме балык тотканын, Кәберләнең ничә кием чабата ясаганын, ничә морда үреп сатканын сөйләде. Бу арада мордага балык бик күп керә, диде. Аннан:

— Яшел чикырткага алапуга пик шәп каба,— дип, кармакка ике кадаклы алабуга тотуы белән мактанды.

Мин мәктәп төзелешендә эшләвемне, бер дә бушамавымны әйттем. Кич су керергә генә төшеп менәм, ул вакытта инде сез монда булмыйсыз, дидем.

— Ай-яй, шәп школ салалар...— диде Пума.— Сес укыйсыз пит инде анда?!

— Укыйбыз.

Пума үзенең мәктәпкә йөри алмавы, бер хәреф тә танымавы турында бик кайгырып сөйләде.

— Мин бер-ике көн пардым школга,— диде ул.— Пестә крещенный чирмешләр өчен школ пар. Тик мин крещенный пулмагач, поп куып чыгарды. Грамыты пулса, көтү көтеп җөрмәс инем мин,— диде.

Мин аңа:

— Менә яңа мәктәп салынып беткәч, бездә укырсың, анда русча да укыталар,— дидем.

— Пелмим шул инде. Чирмеш малаен алырлармы икән татар школына. Мин намас уки пелмим бит!

Без шулай сөйләшеп утырганда, бер рус малае килде. Пума аңа бик шәп морда үреп биргән икән — шуннан дуслашып киткәннәр, бу малай көн дә килә ди. Коля исемле икән. Ул зират астындагы алты ташлы тегермәнне тотучы Захар малае. Әти белән борай өрдерергә төшкәч, күргәләгәнем бар иде минем аны. Кара күлмәк өстеннән киндерә кебек ефәк бау белән билен буган озын чәчле яланбаш бу малай үзен бик эре тота кебек иде. Ә бүген бөтенләй башкача — бергә уйнап үскән малай шикелле кул биреп күреште. Коля Өфе каласында учитель булып эшли торган абыйсында — Иван Захаричта тора икән. Татарча да яхшы белә.

— Сез менә русча өйрәнегез,— диде ул безгә,— русча белсәң, теләсә кая барырга була.

— Өйрәнер идек тә, безгә кем өйрәтә соң аны?!

— Школага йөрисездер ич!

— Морат абзый киләсе елдан русча да укырсыз дип әйтә әйтүен.

— Кайсы сүзләрне мин өйрәтермен. Аннан Иван Захаричтан сорарбыз. Ул бик яхшы укыта. Аны бик яраталар.

— Кем соң ул Иван Захарич? — дигән булдым мин, белмәмешкә салышып.

Коля азрак аптырап калды.

— Менә Фомага Гаврил кем була әле?

Бу сораудан мин аптырап калдым. Пуманың чын исеме Фома, Кәберләнең Гаврил икәнен белми идем.

— Ә!.. Ул сезнең абыегез була икән! — дидем мин.

Шул көнне үк без русча «дәресләрне» башлап та җибәрдек. Коля безгә русча сүзләрне әйтә, татарча аңлата да, без аларны кабатлыйбыз:

— Ат — лушатка, бүрек — шапке, сыер — куруба, юл — дуругы, чалгы — куса, ит — мәсы...

Пума да безгә үз телен әйрәтә:

— Кинде бу — ипи пир, хлеп тай; мари баты — мари хатыны, кушты каят — кая барасың, кута итешь, дип, миңа татарча, Коляга русча аңлатып бирә.

Аннан без шаярырга тотындык. Пума үзенең иске киез эшләпәсен Коляга киертте, аның фуражкасын үзе алып киде дә:

— Вәт мин русский малай, Коля — чирмеш малай булды,— ди. Аннан эшләпәне миңа киертте, үзе минем кәләпүшне алып киде.— Татар малай — чирмеш малай, чирмеш малай — татар малай,— дип көлде...

Көн кыздырганнан кыздыра барды. Пума чикмәнен, чабата һәм ыштырларын чишенеп ташлады.

— Әйдәгез, су керәбез.

— Әйдә.

Без озак кына су коендык. Коля бик яхшы йөзә белә икән. Үзләренең тегермән алдына хәтле йөзеп бара да, ял итмичә, кире борылып кайта. Судан чыкканда, мин шактый туңган идем, Пуманың чикмәнен кидем. Пума рәхәтләнеп көлде:

— Минем чикмәнне, ыштыр белән чәбәтәне кисәң, сине дә мари малае дип беләрләр ине,— ди.

Шулай шаярышып утырганда, көнбатыш яктан куе кара болыт күренде. Нәрсәдер буласын сизенгән кебек, терлекләр кузгалыша, кайсы кая таралыша башладылар.

Кәберлә:

— Малларны кара! — дип кычкыруга, Пума, озын чыбыркысын өстерәп, китеп тә барды. Аның:

— Кәзә-кәзә, ай җахандамлык кәзә...— дип кычкырып йөгергәнен бераз карап торгач, Коля да тегермәнгә таба кайтып китте.

Болыт тиз арада кояшны каплап алды. Салкынча җил исеп куйды. Чи салам янганда морҗадан ургылып чыккан аксыл куе төтен шикелле, болыт, ургыла-ургыла, югары күтәрелә.

Бер кат көтүне әйләнеп килгәч, Пума минем янда аз гына вакытка туктады да:

— Пос пулмаса ярар! — дип, югары күтәрелеп карады. Аннан, озын чыбыркысын еракган болгап, шартлата-шартлата, көтүне ашыктыра башлады. Ә мин тау итәге буйлап авылга таба йөгердем. Үзем йөгерәм, ә үзем: Пума белән Кәберлә нишләрләр инде, боз түгел, таш яуса да, көтүне ташлап китә алмыйлар бит алар дип кызганам.

Мин авылга кайтып кына кердем, давыл купты, өермә күтәрелде. Кемнәрнеңдер абзар түбәсе саламнарын очыртып алып китеп, бөтереп йөртә башлады. Озак та үтми, әле анда, әле монда коймалар ава, агачлар, тамырлары белән умырылып, юлга аркылы килеп төшә башлады.

Менә яшен яшьнәде, күк күкрәде. Яшен чаткылары, күк читенә бик күп мәкерҗә ураклары тезеп киткән кебек, кәкре сызыклар сызып үтәләр, дөбер-шатыр күк күкри. Коточкыч күренеш. Мин яңгырга кадәр кайтып җиттем. Ә көтү һаман күренми иде әле.

Коточкыч яшенле, боз катыш яңгыр башланып китте. Шул яңгыр астында, чыбыркысын җыеп җилкәсе аша муенга кигән, җеп бөртегенә кадәр чыланган Кәберлә, ыштыр чорнаган нәзек озын аягын көчкә күтәреп атлап, авылга кайтып керде. Аның артыннан боеккан сыерлар, күшегеп беткән кәҗә, сарыклар кычкырыша-кычкырыша кайтып киләләр.

Көтү кайтып бетте. Бераз вакыттан соң яңгыр да туктады. Ялтырап кояш чыкты. Байтак вакыт үтте. Ә Пума һаман юк та юк. Абыйсы да, кешеләр дә аптырап калдылар: ник кайтмый икән Пума?!

Кәберлә белән без, берничә малай, көтү кайткан юл буенча басуга чыгып киттек. Зират почмагыннан үтүгә, ни күрик, Пума юлда яңгыр суы эчендә сузылып ята. Елан шикелле чыбыркысы тәгәрмәч эзе буйлап сузылган, эшләпәсе берничә сажин читтә ята. Кәберләнең төсе китте:

— Пуманы яшен суккан!..

Кешеләр җыелды. Кызыл балчыкка чыкканчы казып, Пуманы җиргә күмеп куйдылар. Имеш, шулай итсәң, яшен кайта, ди. Ләкин берниндидә файда бирмәде бу: Пума үлгән иде инде.

Их, Пума, Пума! Нинди әйбәт иптәш идең бит син...

Пуманы үз авылына алып китеп күмделәр. Берничә көннән анасы килде, төшендә Пуманы күрүен елый-елый сөйләде:

— Пума яхшы бала ие ул. Шуңа күрә җөмо — кодай аны үзенә күчерлеккә алган. Сур капкадан кереп киткәннәрен күреп калдым. Пуманың өстендә җап-җанга ак тула чикмән, башында яңа көрән эшләпә, аягына яңа ыштыр чорнап, өр-яңа чабатасын кигән. Куслага утырган да атны чаптырып кереп бара.

Мин дә Пуманы, нәкъ анасы күргән кебек, төштә күрергә теләдем. Әгәр төшемә керсә, алар безнең авылда беренче тапкыр көтү көтә башлаган елны, «шадра чирмеш» дип, аның хәтерен калдыруым өчен гафу үтенергә уйладым. Ләкин ул минем төшкә кермәде. Ә яхшы күңелле, һәрвакыт шат, беркайчан да чыраен сытарга яратмый торган бу мари малае минем күңелемдә мәңге онытылмаслык, ләкин үкенечлерәк булып урнашып калды. Аның турында уйласам, әле һаман да күз алдымда торган шикелле тоела.

Пумадан соң Кәберлә дә озак тормады. Бер көнне җәмәгать җыенына кергән дә:

— Картлар, агайлар, ачуланмагыз мине. Пасуга чыктым исә, Пуманың өрәге каршыма килеп баса. Мин инде сездә көтү көтә алмыйм,— дигән.

Шуннан соң ул өй саен кереп саубуллашып йөрде, көтү чираты төшкән көнне яхшы кунак иткән хатыннарга:

— Җиңәй, синең ашыңны онытмам! — дип, үзенең рәхмәтен белдергән. Аннан, иске чикмәнен култык астына кыстырып һәм озын чыбыркысын Пума үлгән көндәге кебек иңбашы аркылы киеп, басу капкасыннан чыгып китте. Без аны озата чыктык. Бераз баргач, туктап, эшләпәсен салып селекте дә, итәге белән күзен сөртә-сөртә, зур-зур атлап китеп барды. Аннан аерылу бик авыр булды безгә. Баскан җирдән кузгалмыйча карап торабыз. Авылдан ике чакрымлап киткән иде инде, кинәт кире борылды. Борылды да җан фәрманга авылга таба йөгерә башлады. Аягы тигән җиргә тия, тимәгән җиргә юк, шундый тиз йөгерә.

Аптырап калдык: ни булган моңа?! Әллә инде бусы акылдан язамы?.. Көтәбез. Тишелгәләп беткән иске эшләпәсен кулына кысып тоткан, әлсерәп чабып килеп җитте. Билен буган сүс бауга бәйләп куккәккә кыстырган киндер янчыгын тартып чыгарды да бер тиен акча алды.

— Мә, Карис,— ди.

Аптырап калдым, алырга да, алмаска да белмим.

— И Карис, Карис! — ди Кәберлә.— Әйтмисең дә, Пуманың сиңа пер тиен пирәсе калган ич! Миңа көн саен әйтеп йөрде ул. Ә мин, үз буйлы акча тотарга өйрәнмәсен дип, пирмәгәнием. Үзем пер исәпләшермен тигәнием...

Аның күзләреннән яшь бөртекләре тәгәрәп төште:

— Энем рәнҗеп ятмасын, шуның бурычын түлим дип кире борылдым,— ди.

Әй.. Менә нинди бер тиен икән ул,— яңа исемә төште. Үзебезнең тиресләрне таратып бетергәч, җыенга азрак акча әзерләп булмасмы дип, сатучы Гыймайга кердем. Лапасында күкәй әрҗәләрен өеп йөри иде. Сәлам бирдем. Ләкин ул сәламемне алмады.

— Гыймай абзый, тирес таратырга юкмы? Бик әйбәтләп, бар җиргә тигез итеп таратыр идем,— дидем.

Бер сүз эндәшмәде. Тамак кыргалап, борын тарткалап карадым, шактый көттем. Әллә инде ул чыннан да минем кергәнне сизмәде, әллә эше бик кызу идеме, һаман җавап бирмәде. Аптырагач, тагын сорадым:

— Гыймадетдин абзый, тиресләрегезне тараттырдыгызмыни?

Шуннан соң ул бөкре гәүдәсен азрак турайтты, каешланып беткән кәләпүш кигән уймак башын борып, кечкенә күзләрен миңа текәлдерде дә коры гына:

— Бар. Зират тау башына чыгарган ун олау тиресне тарат. Кара аны, яхшылап тарат. Биш тиен көмеш бирермен! — диде.

— Ун олауга биш тиенме?!. Бик аз ич ул!..

— Күбен ходайдан сора, ул бик бай. Ә миндә Әндри казнасы юк.

— Я, Гыймадетдин абзый, саранланма инде, башка кешеләр олавына ике тиен бирәләр, ичмаса бер тиен ярым бир инде!..

Гыймай тагын телен тешләде, кибетенә үк кереп китте. Бер чыгып китәргә дә җыенган идем, тагын калдым. Тиздән Акташ каршы җыены була. Кесәндә биш-алты тиен дә булмагач, җыенмыни ул?..

Шуңа күрә тагын берәр сүз кушып карарга булдым. Кибет ишегеннән башымны тыгып:

— Ярар, Гыймадетдин абзый, олавын бер тиеннән таратырмын. Хәзер кайтып ипи белән сөт ашыйм да басуга йөгерәм,— дидем.

— Сигез тиен бирермен,— диде Гыймай.— Олау дигәч тә барысы да бер мише тулы олаулар түгел алар, кайсылары арба ящигыннан гына иде,— ди.

Чыгарыр инде Гыймай кулак арба ящигыннан гына итеп! Аның бер олавы кешенең ике олавы хәтле була. Беләм мин аны...

Ләкин нихәл итәсең. Карун белән сатулаш-сатулашма, артыгын ала алмассың аннан. Риза булдым. Шул көнне үк тиресен таратып кайттым да сигез тиенен алдым. Ун тиен булса, бәлки, җыенга кадәр, җыеп та куяр, юкка-барга тотып бетерергә кызганыр идем, сигез тиен генә булгач, ничектер җәл тоелмады, этәч булып кычкыра башлады бу акчалар.

Ни булса булыр, дип уйладым мин, алдагы базарда башкарам инде бу сигез тиенне. Җыенга хәтле тагын бер җае чыгар әле.

Базарга бару белән, балык рәтенә киттем. Кипкән воблалар арба тәртәләрендә эленеп тора, кап-кап булып җирдә аунап ята. Авыздан сулар килде минем аларны күргәч. Бер тиенне кесәдән тартып чыгарганны сизми дә калдым. Шунда ук, кыштыр-кыштыр әрчеп, ашый да башладым. Ашадыңмы, балык дигәнең су сорый. Эчәсе килә. Шуны сизгән кебек «Әмма да салкын әйрәннәре! Әйрәнгә, әйрәнгә!..» дип, як ягымнан әйрәнче малайлар сырып алдылар. Әллә инде минем кипкән балык ашаганны күреп артымнан йөри килгәннәр?!

Шулай итеп, тагын бер тиен ычкынды. Менә сиңа, ике тиен китте дә барды... Тирес тараткандa кабарган кулларыма карап алдым: акчаны уч төпләрен суймыйча табып булмый, ә тота башласаң, бернигә ярамый...

Аяклар үзләреннән-үзләре арткы урамга өстерәделәр. Анда җәй булса — арбага, кыш булса — иске чыпталардан чанага балаган корып, Әхмәди карт борчак кесәле сата. Тар гына улак белән борчак кесәле алып чыга да, вак-вак телемнәргә кисеп, малайларның тиеннәрен янчыгына тутыра. Малайлар гына түгел, хатыннан яшерен сыйланып йөрергә яратучы сакаллы сабыйлар да кереп иреннәрен ялап утыралар анда. Күрән төстәге, дерелдәп торган борчак кесәле янынан һич кенә дә тыныч үтеп булмый. Их, тәмле дә була иде соң ул борчак кесәле!..

Мин барып җиткәндә, чыпта кырыеннан эчкә сак кына күз салга-

лап, ләкин керергә кыймыйча, Пума басып тора иде. «Һайт!» дип кычкыруга, сискәнеп китте.

Кәберлә атна буе, буш вакытларда чабата ясап, базарга кадәр өч кием чабата өлгерткән. Шуны тиз генә сатып кайтырга дип, Пуманы җибәргән. Бер киемен сигез тиеннән ким сатмаска кушкан икән. Ләкин базар базар инде ул. Анда син дигәнчә генә булмый. Пума тугызар тиенгә сатарга уйлап килгән. Шулай булса, өч тиенгә урын табар иде ул. Тик ике киемне генә сигезәр тиеннән сата алган. Ә өченче киемне көчкә җиде тиенгә озаткан. Чабаталар уйлаганнан артык киткәнме, кимрәкме, нәфеснең анда эше юк. Нәфеснең киндер мае белән чәпелдәттереп, борчак кесәле ашыйсы килә. Менә шул теләк китергән аны монда.

Кесәсендә егерме өч тиен байлыгы булган кешенең, монда килеп, ике-өч тиенлек кесәл ашап чыгуы гаҗәп түгел түгелен. Тик чабатаны ким саткан өчен абыйга ничек җавап бирермен, дип курыккан Пумага бу җиңел булмагандыр. Ул менә шуңа икеләнеп тора булса кирәк! Бер генә телем кесәл кистереп алса да, болай да исәбе тулмаган акча тагын бер тиен кимиячәк, ике тиен өчен җавап бирергә туры киләчәк. Ә Кәберлә энесенә карата шактый каты куллы иде. Озын чыбыркының сабы белән малайның башын төйгечләргә дә күп сорамас!

— Нишләп торасың монда, Пума, ник кермисең? — дидем мин.

— Әй, әллә кирәсе, әллә җук! — диде ул, бераз чигенә төшеп.— Чәпәтәнең бер киемен очсыз саттым ла. Кесәл дә ашасам, Кәперлә пирер кирәкне!.

Кесәл ашыйсы да килә, абыйсыннан да курка. Ничектер кызганыч кебек тоелды ул миңа. Кесәгә кулны тыгып, акчаларны капшап карадым.

Әле бит минем алты тиен акчам бар, алар турында беркемгә дә исәп бирәсем юк. Ике тиенлек үземә алсам, бер тиенлек Пумага алып бирсәм, кармаклар алырга тагын өч тиен кала...

— Әйдә, үзем түлим акчаны!..

— Ә аннан?!

— Бер җае белән түләрсең...

Малайның авызы колагына җитте.

Арба янына килеп бастык. Әхмәди агай күз кырые белән генә карап алды. Акчалары бармы икән соң бу малайларның, янәсе.

— Миңа ике пурсы, бу малайга бер пурсы! — дип, өч тиенне суз гач, картның җыерчыклы йөзендә аз гына елмаю күренгән кебек булды. Кесәл кисә торган пычагын майга катып беткән алъяпкычына бер ике ышкып алды да кул яссуы кебек такта кисәкләрен безгә сузды:

— Мә, тотып торыгыз!..

Аннан кәгазь калынлыгында гына кисеп, минем тактага ике, Пума тактасына бер телем кесәл салды. Йөри-йөри каралып, кереләнеп беткән каз канатын китек чүлмәктәге киндер маена тидереп, чәп-чәп итеп, кесәл телемнәре өстенә бер-ике сугып алды. Чырадан ясалган, белмим, кайчаннан бирледер, юылмаган ике чәнечке дә сузды.

Их, тәмле дә соң борчак кесәле!.. Телеңне йотарсың. Тик ашый башламас борын бетәргә торуы гына бик начар. Кесәдән бер кыерчык ипи чыгарып, яртысын Пумага сындырып бирдем дә, кесәлне кечкенә кечкенә генә итеп берничә тапкыр капкалагач, такталарны тагын картка таба суздык.

— Әхмәди агай чәпелдәт әле!..

Әхмәди абзый, ризасызлык белдергән кебек күзләрен ямьсезләндереп, бер күтәрелеп карады, ләкин бер сүз дә әйтмәде. Каз канатын май чүлмәгенең кырыена гына тиереп алды да тагын бер-ике тапкыр чәпчәп иткән булды. Шул дым белән кесәлне капкалап та бетердек. Аннан

Пума кайтып китте, ә мин, кармак алырга дип, кырык тартмачы Шәрәфи «кибетенә» таба атладым.

Пума, бер җай табып, үзенең миңа ничек бурычлы булуы турында Кәберләгә сөйләгән, миңа түләр өчен акча сораган. Ләкин Кәберлә акча бирмәгән. Нигә юкка акча әрәм итеп йөрисең, дип ачуланган. Чыбыркы белән дә берәрне тартып алмадымы икән?!

Бер көнне көтү куганда Пума миңа, шул бурыч өчен булыр дип, бик озын итеп кылдан ишелгән кармак җебе бирде.

— Атлардан киртәгә эләгеп калган кылларны җыям мин,— дигән була. Беләм инде, алар болында йоклап яткан атларның койрыкларын йолкып, әллә никадәр кармак җебе ишәләр. Анысы нигә кирәк соң миңа?! Базардан чабак кармаклары алып кайткан идем, шәп булды әле бу җепләр!..

Пуманың энесе бурычын онытмавы ошады миңа. Акчаны алмадым, әлбәттә. «Миңа бурычын түләде инде ул,— дидем.— Пума бурычка алмый, алса, көттерми торган иде», дип тә өстәдем.

— Ничек түләде ул сиңа?

— Шулай... Кармак җебе бирде.

Бу сүзне әйткәч, Кәберлә кечкенә балалар шикелле, авызын җәеп, елап җибәрде.

— Пәйрәмгә авылга кайткач, түтәй малаена бүләк пирәм, дип ишкән ие бит ул җепне. Мин акча пирмәгәч, шуны сиңа пиргән икән! — дип, көйли-көйли елады.— Пелмәдем шул, пелмәдем энемнең кадерен. Кыерсыткан вахытларым да пулды минем аны. У-у-у!..

Елады, елады да Кәберлә, кинәт бар көченә йөгереп китеп тә барды. Шул китүдән ул югалды. Озак вакытлар күрә алмадым мин аны...

## Укучының күңел дәфтәренә

### Немец мәкальләре һәм әйтемнәре

*Диңгездә батып үлүдән, бокалда бату күбрәк.*
*Башта һәр эш авыр диеп, карак сандал урлаган.*
*Иң соңгы өйләнүдән соң бик аз кеше үкенә.*
*Әйткән һәрбер ант чәнечсә, күп ант итмәсләр иде.*
*Бозау әле суймаган, нәфес инде ит чәйни.*
*Карак тамам шомарып җиткәч, аны аксак шымчы тота.*
*Ашатып кемне симертсә, итче шуны суячак.*
*Тычкан булып күренгәнне мәчеләр тотып ашар.*
*Җирне кем яхшы сыйласа, җир шуны түгрәк итә.*
*Тире югалса, койрык та калмый.*
*Кайрамаган — кисми дә.*
*Тәҗрибә — иң шәп остаз, тәҗрибә — иң озын юл.*
*Начар хәбәр бик тиз тарала.*
*Җилкәңә алсаң — башыңа менәр.*
*Диңгезне макта, коры җирдә тор.*
*Читтә янган утлардан — үз өең түгене якты.*
*Фараз иткән җиңүдән ышанычлы тынычлык артык.*
*Бөркетләр чебен тотмыйлар.*

Диләра Зөбәерова,
Моисей Баинов,
хакас шагыйре

# ТАҢ ҖЫРЫ

Мондагы таңнар, чыннан да, гаҗәеп серле җыр сузалар кебек. Калкулыклар, үзәнлекләрдәге таш сыннар, йөгерек инешләр — барысы да я зыңлап, я җил белән серләшеп, я челтери-челтери үз көен яңгырата. Түбәсе болытларга тоташкан Саян тауларын әйткән дә юк. Ул яктан агылган моң хакасларның милли уен коралы чатхон кылларыннан чыга кебек. Тау араларындагы үзәннәрдә исә төрле-төрле чәчәкләр үсә, әкиятләрдәге сихри келәм диярсең! Җаннарны иркәләгән музыка шул чәчәк келәмнәреннән дә сирпелә бугай. Хәер, гадәти мәшәкатьләр белән ыгы-зыгы килеп йөргәндә, боларны сизмәскә дә мөмкин. Әмма ләкин бер мәлгә хыялга бирелсәң, тын калып уйлансаң, гасырлар эпосы дип йөртелгән Хакасия җиренең әзлексез җыр сузуын ишетми мөмкин түгел. Моны әле XVIII гасырда ук белгәннәр, хакас көйләрен Италия серенадалары белән чагыштырганнар. Бу якларның музыкасы күзгә күренмәс ераклыктагы дәрьяларның шавын да хәтерләтә, әллә кай гасырларда яшәгән борынгы кешеләрнең авазы кебек булып та тоела. Күк исә чалт аяз. Аның мәшһүр киңлегендә Җидегән йолдыз йөзә. Ул һәр таңда тагын да яктырак була бара шикелле. Әйтерсең лә, күк киңлегендә озаграк хәрәкәтләнгән саен, аның бәллүр җемелдәге камилләшә төшә.

Кем син, һөнәрең нинди — моның һич әһәмияте юк. Бу якларның матурлыгы һәркемне таңга калдыра. Монда океан ерак, әмма хакаслар күңелендә иксез-чиксез дәрья шаулый. Җылы көннәр дә аз була бу җирдә, тик кешеләрнең йөрәгендәге кайнарлык бөтен дөньяны җылытырга җитәр кебек. Ул кайнарлык, ул көч, ул сабырлык тарихның буеннан-буена сакланган. Тарихы исә җиңелләрдән булмаган аның. Уйлый китсәң, аптырап каласың: ничек барысына да чыдады икән бу җир?! Хуш исле чамбыр каплаган курганнар буенда күп таш сыннар — балбаллар бар. Алар, йөзләрендәге җыерчыклар күплектән оялгандай, кыяр-кыймас кына биниһая биек электр баганаларына карап утыралар. Борынгылыклары йөзләренә чыккан булса да, аларны табигать кырыслыгы да, яулар да харап итә алмаган. Таш сыннар тептөз утыра бирә. Аларның кайберләрендә төрки телләрне өйрәнүдә уникаль кыйммәткә ия руник Орхон-Енисей язмалары очрый.

Таш сыннар — бу җир өстендә булып үткән канлы фаҗигаларның җансыз шаһитлары. Алар йөзендәге сагыш, курганнарга күмелеп калган шәһәрләр, затлы сарайлар, кешеләрнең гасырлар буе берәмтекләп җыйган культура байлыгының канлы сугышларда исраф булуы турында да сөйлидер, мөгаен. Ләкин алар дәшмиләр. Җыр сөюче җанда шигырь уяна.

...Бездә шундый бер риваять яши,
Миңа кече яшьтән таныш ул:

Айда бер кыз, ак каенны кочкан,
Елый үксеп, тоташ сагыш ул.

Ай туганда әллә шуңа микән
Далам минем кала боегып,—
Сабый чакта тойган күренешләр
Күңелләргә калган уелып.

И җиркәем минем! Чал башкаең
Нинди кимсетүләр кичергән!
Чыгармаган ләкин халкым минем —
Бар хәсрәтен эчкә яшергән.

...Үткәннәрең ачы хәсрәт булса,
Ә бүгенгең — серле таң җыры.
Күз алдымда — чәчәк бөреләрең
Гомереңнең яңа яз чоры.

Хакас мифологиясе Енисей елгасын ат менеп чабучы кояш йөзле кыз итеп сурәтли. Республиканың далалы ягында яшәүче кешегә елганы бу рәвешле тасвирлау сәер тоелырга да мөмкин. Дала киңлегендә агучы Енисей күбрәк сабыр юргага охшый. Әмма таулар арасыннан, ташларны әйләндереп каплый-каплый акканда Енисей нәкъ менә әбиләр сөйләгән риваятьтәге кебек икән. Ул монда шундый дәһшәтле көч белән шаулап ага ки, ирексездән, аның тау-таш эченнән, тайга караңгылыгыннан котылырга омтылуы турында уйлап аласың. Елга моннан атылып чыгып, шаулап юл ала да тын дала киңлегендә иркенләп, матураеп ага башлый.

Без Карлов борылышында аның нәкъ шундый агышын күзәтеп тордык. Бу урынга килүебезнең сәбәбе дә бар иде. Илебезнең галимнәре, белгечләре, озак уйланулардан, эзләнүләрдән соң елганың нәкъ шушы төшендә гидростанция салырга мөмкин санныйлар. Нәкъ шунда ук Владимир Ильич Ленинга мәхәбәт һәйкәл куярга да хәл кылына. Саян-Шушенск ГЭСы үткән гасыр азагында В. И. Ленин сөргендә булып киткән тарихи Шушенск авылыннан йөз чакрым чамасы ераклыкта гына төзелеп ята.

Башта әле бу җирдә шулкадәрле шаулы төзелеш булырына ышануы да кыен иде. Барыйм дисәң, җитәр хәл юк: «Саянск» исемле бердәнбер иске катер йөри. Шул катерны яратып, беренче төзүчеләр яңа шәһәргә дә шул ук исемне кушмакчылар иде. Күптән түгел бары хыял гына иде әле бу. Төзүчеләр шундый халык инде — бер яктан план төзи тордылар, икенче яктан яңа шәһәр дә калка башлады. Бүген инде монда яп-якты кала гөрләп утыра. Исеме — Саяногорск. Сокланып туя алмыйсың. Әле кайчан гына Енисейның бу ярында кечкенә генә йортлар тезелеп киткән иде. Аларда, станция сала башлаганчы, кирәкле мәгълүматлар җыючы белгечләр яшәде. Өйләр янына еш кына керән аюлар, гүзәл боланнар килеп йөриләр иде...

Уберенче бишьеллыкның төп тезисларында мондый юллар бар: «...Саян территориаль-производство комплексының алдагы үсешен тәэмин итәргә: «Саян-Шушенск ГЭСы төзелешен нигездә тәгәлләргә, Абакан вагон ясау һәм Саян алюминий заводларын сафка кертергә, Минусинск шәһәрендәге электротехника предприятиеләрен салуны дәвам итәргә...»

Саян-Шушенск гидроэлектростанциясен бу территориаль производство комплексындагы төп энергия чыганагы саныйлар.

Станциянең километрга сузылган буасы 245 метр биеклектә булачак. ГЭСның машиналар залы да, ачык җирдәге бүлү җайланмасы да уйлап табучыларның иң яңа ачышларына нигезләнеп салына. Бу корылмалар тышкы күренешләренең искиткеч матурлыгы, эш өчен гаҗәеп җайлы булулары белән отачак. Монда кулланылачак механик һәм энергетик җиһазлар, автоматик җайланмалар замананың иң әйбәт үрнәкләрен эченә алган.

Елга борылышының үзенчәлеге, ярларының биниһая текә булуы, буасының гаҗәеп биеклеге, су агышының искиткеч тизлеге — моңарчы салынган су станцияла-

рен, әйтик, Красноярск, Братск, Усть-Илим ГЭСларын корганда тупланган тәҗрибәгә дә күп яңалыклар кертергә мәҗбүр итә. Элеккеге алымнарга таянып эшләгәндә, Саян-Шушенск станциясенең беренче гидроагрегатын, елганы буганнан соң 38 ай үтүгә үк эшкә җигү һичничек мөмкин булмас иде. Мондагы проектлаучылар да, төзүчеләр дә станцияне тизрәк эшләтә башлауга, төзелешкә тотылган чыгымнарны тизрәк каплый торырга тырыштылар.

Саян-Шушенск ГЭСының беренче гидроагрегаты эшкә җигелгәч, буа буу, станция бинасын салу, гидрогенератор монтажлау эшләрен тизләтү буенча рәсми төстә берничә рекорд куелды. Шуларның берничәсен генә телгә алып үтик. Красноярск ГЭСы төзелешендә, елга буылганнан алып, беренче агрегат эшли башлаганчы 55 ай вакыт узган иде, монда — 38 ай гына. ГЭС бинасы төзелешенә беренче куб. метр бетон салынганнан башлап, агрегат сафка басканчы, Красноярскида 48 ай вакыт узган, Саянда — нибары 18 ай. Саян-Шушенск ГЭСында бетон эшләре зур тизлек белән баруы да таң калдырырлык.

Әмма Саян-Шушенск ГЭСы төзелешендәге күркәм яңалыкларны, зур җиңүләрне моңарчы күрелмәгән уңышларны куәтле машиналарга, фәнни ачышларга гына кайтарып калдырсак, без тирәннән ялгышкан булыр идек.

1978 елның 19 декабрендә, станциянең беренче гидроагрегаты эшли башлаган көнне, КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Л. И. Брежнев төзүчеләргә, монтажчыларга, фәнни-тикшерену институты коллективларына һәм бу төзелешкә катнашкан барлык кешеләргә җибәргән котлавында: «...менә шушы төзелештә хезмәткә коммунистик мөнәсәбәтнең яңа үрнәкләре барлыкка килү игътибарга лаек,— дип язды.— Хәзер бөтен ил Саян-Шушенск ГЭСы төзелешенә Ленинград шәһәренең 28 предприятиесе һәм оешмасы ярдәм итүен белә... Себерлеләр белән ленинградлылар арасында урнашкан хезмәт дуслыгы социалистик ярыш тәҗрибәсен тагын да баетты. Бу яңалык халык хуҗалыгын үстерү программасын тормышка ашырганда киң кулланыш табарга тиеш»...

Хикмәт шунда ки, Саяндагы зур эшләр башлангач, Ленинград предприятиеләре һәм Саян-Шушенск ГЭСын салучы оешмалар үзара социалистик ярыш килешүе төзегәннәр иде. Килешү төзелешне тизрәк һәм яхшы сыйфатлы итеп башкарып чыгарга юнәлтелде. Шундый ук килешү Красноярск краеның 43 предприятиесе белән дә төзелде. Күркәм башлангыч КПСС Үзәк Комитетында да хуплау тапты.

КПССның Хакас өлкә комитеты Саян-Шушенск ГЭСы төзелешенә ярдәм итәргә теләгән оешмаларның үзара дуслашып, ярышып эшләвен җайга салып тору өчен өлкә күләм Координацион Совет булдырды. Ленинградның Социалистик Хезмәт Герое В. С. Чичеров җитәкләгән металлчылар бригадасы Саяндагы Социалистик Хезмәт Герое В. А. Поздняков җитәкчелегендәге бетончылар коллективы белән килешү төзеде. Ленинград металл заводындагы В. Г. Антонов бригадасы станциянең турбинасын урнаштыручы В. С. Демиденко җитәкчелегендәге монтажчыларны ярышка чакырды. Антонов егетләре ГЭС өчен эшче тәгәрмәч ясыйлар иде. Монтажчы В. С. Демиденко, бетончы В. А. Поздняков, С. Е. Коленковлар арасында үзара ярышлар да бара иде.

Саян-Шушенск ГЭСын салучыларга илнең төрле ягыннан ярдәмче төзүчеләр агылды: Усть-Илимнан, Зеядан, Колымадан, Кавказдан, Урта Азиядән, Идел буйларыннан... Бу фидакарь кешеләрнең Енисей эпопеясына үз юлларын салып калдырасы килә иде.

«Красноярскгэсстрой» идарәсе төзүчеләре арасында илнең нинди генә милләт вәкиле юк?! Данлы хезмәт эчендә алар су станцияләре салу эшенең чын осталарына әйләнделәр. Ерак себер авылында туып үскән рус егете Илья Васильевич Кожура, социалистик ярышта җиңеп чыгып, Енисейны ябу башлангач, үзенең авыр йөк машинасында кырлы зур гранитны елгага беренче булып чумдырды.

Төзелешкә Днепрогэстан килгән кешеләр арасында инженер украин Олесь Грек та бар. Ул үз вазифасына өстәп, тагын бер эш алып бара. Олесь — талантлы әдәбиятчы. Шуңа күрә аңа идарәдәге яшь иҗат көчләрен әдәби берләшмәгә тарту бурычы йөкләтелгән. Олесь моны бик рәхәтләнеп башкара.

Коллективта гидростанцияләр салу буенча зур тәҗрибә туплап өлгергән әрмән инженеры Армен Мартиросян аеруча зур авторитет казанды. Осталыклары белән ил күләмендә дан яклаучылар арасында С. Коленков, Б. Поздняков, М. Полторан, М. Мащенко, А. Решетников бригадалары бар. Идарә начальнигы С. И. Садовскийның: «Безнең төзүчеләрнең төп максаты — байлык туплау да, җиңел кәсеп эзләү дә түгел, алар, җаннарын аямыйча, станцияне тизрәк көйгә салырга тырышалар. Бу аларның яшәү мәгънәсенә әйләнеп бара»,— дигән сүзләре нәкъ әнә шул егетләргә төбәп әйтелгән кебек.

Анатолий Решетников бригадасы беренчеләрдән булып «КБГС 1000А» маркалы зур краннарда эшли башлады. Бу урында Саян-Шушенск ГЭСы төзелешенә катнашучы Татарстан егетләрен дә телгә алырга кирәк. Алар шактый күп монда. Мидхәт Мөдәррисов, мәсәлән, төзелешнең беренче көненнән бирле тырышып эшләүче ветераннардан исәпләнә. Зәйнулла Халиков исә Анатолий Решетников белән бергә Красноярск ГЭСыннан килгән. Бетончылар беравыздан: «Халиков — безнең иң оста бетончыбыз ул!»— диләр. Егетнең уңганлыгы сокландыра. Шундый авыр хезмәттә булуына карамастан, ул читтән торып политехник институтта да укый, бригаданың партия оешмасын җитәкли.

Шушындый зур эшләрдә бай тәҗрибә туплаган өлкән туганнары белән бергә хакас егет-кызлары да хезмәт итәләр. Иң беренче итеп ирле-хатынлы Алексей һәм Ольга Капсаргиннарны телгә алася килә. Аларның икесенең дә әтиләре Бөек Ватан сугышында һәлак булган. Иң авыр еллар кичергәндә үскәннәр алар. 1945 елда, Совет хөкүмәте сугыш китергән кыенлыкларга карамастан, Абакан шәһәрендә өлкәкүләм хакас милли мәктәбе ачыла. Мәктәпкә әтиләре фронтта һәлак булган балалар беренче чиратта кабул ителәләр. Мондагы укучыларны һәрьяклап дәүләт тәэмин итә. Алексей Капсаргин тормыш путевкасын нәкъ әнә шул мәктәптән алып чыга. СССР Фәннәр Академиясенең Себер бүлеге хезмәткәре техник фәннәр докторы Иннокентий Чичинин да, илнең атаклы Атом үзәге хезмәткәре физика-математика фәннәре кандидаты Сидор Капчигашев та, философия фәннәре кандидаты Виктор Анжиганов та, филология фәннәре кандидатлары Валентина Майнагашева, Гавриил Котожеков, Ольга Шоева да шул ук мәктәптә канат ярганнар. Алексей Капсаргин су буе төзелешләре белгече булырга хыялланган. Хәзер ул — тәҗрибәле гидроинженер инде. Ольгасы төзелешнең оператив штабында инженер булып эшли. Ул төзелешкә килә торган бетонның сыйфатын билгели, әлегә кадәр бернинди ялгыш та җибәргәне юк.

Бу хәлләр Хакасия халкының үткәнен белгәннәргә акыл җитмәслек зур җиңү булып күренә. Чөнки Бөек Октябрь революциясенә кадәр бу халыкның үз әлифбасы-фәләне генә түгел, хәтта исеме дә булмаган. Аларны аз санлы башка халыклар белән беррәттән «инородецлар» дип кенә йөрткәннәр. Бүген Хакасиянең тулы хокуклы гражданнары иң катлаулы техниканы үзенә буйсындыра, иң кирәкле фәнни ачышлар ясауда катнаша, сәнгатьтә, әдәбиятта яңадан-яңа уңышларга ирешә.

Саян-Шушенск ГЭСының шавы Хакасиянең данын еракларга алып китте. Зур төзелеш әллә кай заманнарның канлы көрәшләре шаһиты булган бу борынгы җиргә өр-яңа сулыш өрде. Саян территориаль производство комплексын тәшкил иткән төзелешләрнең иң зур күпчелеге Хакасия җирендә корыла. Черногорскидагы сукно комбинаты Абакан трикотаж фабрикасы тулы куәтләренә эшлиләр инде. Саян алюминий заводы һәм Абакан вагон ясау заводы зур тизлек белән төзелеп ята. Алар Бөтенсоюз удар төзелеше дип игълан ителгән. Шул рәвешле, һәр карышы музей экспонаты булырдай республика бинниһая киң төзелеш мәйданына әйләнеп китте.

Абаканның тарихи музее янында курганнардан китерелгән таш стена бар. Борынгы заманның билгесез бер рәссамы бу ташта, хатын-кыз кыяфәтенә кертеп, күз чагылдыргыч якты кояшны сурәтләгән. Рәсемдәге кояшның нурлары безгә борынгы көтүчеләрнең, тимерчеләрнең, ювелирларның тыныч көннәр, дуслык, муллык хакында гомер-гомергә хыялланган өметләрен китереп җиткергән. Бүген исә Енисей өстендә Совет халкы дип аталучы бөек рәссам тудырган Хезмәт кояшы балкый. СССР төзелүгә 60 ел тулган көннәрдә аның нурлары аеруча якты, аеруча еракларга тарала.

Энҗе Мөэминова

# БЕЗ ДӘ ҮСЕП ҖИТТЕК...

Көннәрдән бер көнне капка төбенә кечкенә генә автобус килеп туктады. Андагы кешеләр таныш та кебек, түгел дә сыман.

Алар бер-бер артлы төшә башладылар. Хәтерем яктырып киткәндәй булды. Төшүчеләргә исемнәре, фамилияләре белән эндәшеп кулымны суздым.

— Павел Матвеев.

— Әйе...

— Рим Газизов.

— Шул үзе.

— Шәүкәт Хәсәнов.

— Таныдыгыз.

— Илдус белән Булатны мин бик еш очратам. Менә бусы?..

— Әзәл бит минІ..

— Ә-әә, Әзәл Кәримов! Әйдәгез, өйгә рәхим итегез!

— Юк, без ашыгыч киңәшмәне машина эчендә генә үткәреп алыр идек,— диде Павел.— Аны, оештыру комиссиясе председателе буларак, мин ачып җибәрәм.— Павел ягымлы гына елмаеп куйды.— Таныш булыгыз, Илдус Әхмәтшин белән Булат Мөхәммәдиев — минем урынбасарлар. Без, мәктәпне тәмамлавыбызга егерме биш ел тулу уңае белән очрашып, тантаналы линейка үткәрергә булдык. Безнең үзебезгә бәйле хәзерлек эшләребез инде тәмамланып килә. Сезнең дә киңәшләрне ишетәсе иде!..

Бу сөйләшүдән соң күп тә үтмәде, чакыру хатлары килеп төште.

Кояшлы июль иртәсе. Мәктәп ишегалды, моңа кадәр бер вакытта да булмаганча, төрле маркалы машиналар белән тулы. Ишек төбенә бәйрәмчә киенгән күңелле төркем җыйналган. Алар килүчеләрне гөрләшеп каршы алалар.

— Кара әле! Сине гел танырлык түгел! Начальник булып алгансыңдыр, мөгаен...

— Нигә ирең белән таныштырмыйсың?..

— Хатының белән килдеңме?..

— Ничә бала үстерәсең?..

— Кодалар булышасыбыз бар икән әле болай булгач...

— Бәйрәмебез котлы булсын, чәчәкләремне кабул итеп алыгыз әле...

Хуш исле чәчәк бәйләме күңелемне тетрәндереп җибәрде. Әллә нинди матурматур шигъри сүзләр әйтәсем килде. Тик күңелем тулып, гадәти «Рәхмәт»тән башка сүз әйтә алмадым.

Залда күңелле шау-шу. Бер төркем теркәү өстәле янында мәж килә, икенчеләре анкета сорауларына җавап тутыра, башкалары «Үзеңне таныйсыңмы?» исемле фотостендтан тырышып-тырышып үзен эзли.

Бераздан, бәйрәмнең тантаналы өлешен башларга вакыт җиткәнлеген белдереп, укучыларны классларга чакыргандай, звонок яңгырады. Очрашуга җыелганнар, аңа берсүзсез буйсынып, актлар залына юнәлде.

— Кадерле укытучыларыбыз, сәхнәгә, безнең каршыга рәхим итсәгез иде!..

Бу минутларда мин үземне бәйрәм кунагы итеп тоюдан туктаган идем инде. Ихтыярсыздан, моннан 15-20 еллар элек Татарстан Язучылар союзы председателе Афзал ага Шамовка үтенеч белән язган хатым исемә төште.

«Мине чирәм җирләргә иҗат командировкасына җибәрегез әле. Анда минем укучыларым эшли...» — дип язган идем мин ул хатымда.

Уйларымнан үземне трибунага чакыру тавышы айнытып җибәрде.

— Сезгә, бер еллык срок белән, менә бу анкеталарны тапшырабыз. Хезмәтегезнең нәтиҗәләре белән ныклабрак танышыгыз әле. Сез бит класс җитәкчебез идегез.

Ул көнне мин үземне кабат утыз яшемә кайткан сыман хис иттем. Шагыйрьләрнең, артист яки композиторларның гына түгел, укытучыларның да иҗат кичәләре була икән бит! Ул очрашу минем шундый кичәм иде. Ул көнне мин үземнең өч дистә елдан артыкка сузылган укытучылык эшемә күзәтү ясадым.

**...Тиңләп булмый аны башка хезмәт белән.**
**Үлчәнми ул минут белән, сәгать белән.**
**Укытучы!**
**Синең хезмәт айлык түгел,**
**еллык түгел,**
**Яз чәчелеп, көз өлгергән**
**орлык түгел.**
**Хезмәтеңнең нәтиҗәсен**
**күрер өчен,**
**Дистә еллар түгәсең син**
**күңел көчең.**

Алдымда — анкеталар. Арадан берсен сайлап алам да җавапларын укыйм.

«Матвеев Павел Гурьевич. Мәктәпне тәмамлагач, Мәскәүнең нефть һәм газ институтында укыдым. Нефть һәм газ машиналары буенча инженер-механик һөнәре алдым. Хәзер «Татнефть» берләшмәсендә транспорт бүлеге начальнигы булып эшлим. Хатыным Анна исемле. Өч кыз үстерәбез: Люда, Света, Ира. Бергә укыган иптәшләрнең барысын да искә алам. Бигрәк тә Ханнанов Ринатны. Тору урыным — Әлмәт шәһәре. Тагын биш елдан очрашсак иде».

Мин Павелның мәктәптә укыган чагын күз алдына китерергә тырышам.

Озын буйлы физкультура дәресләрендә һәрвакыт беренче рәттә басып торучы, кызлар кебек тыйнак, басынкы табигатьле, җәмәгать эшләрендә башлап йөрүче укучым иде ул.

Һәм шунда ук ул сурәтне таза, киң җилкәле чигә чәчләре инде көмешләнә башлаган ир уртасы кеше алмаштыра. Аның зур коңгырт күзләре уйчан-җитди караш сирпи. Калын иреннәре аның киң күңелле, эчкерсез булуын аңлата сыман. Маңгаендагы озын-озын сызылган сырлар бүген ирешелгәннәре аңа җиңел генә бирелмәгәнлеген сөйлиләр. Миндә аның үзен кабат күреп туйганчы сөйләшү теләге уянды.

...Ишекне Анна ачты. Безне күргәч, аның болай да сөйкемле йөзе тагын да нурланыбрак китте.

— Әйдәгез, түргә узыгыз. Павел хәзер кайтып җитәр,— дип сөйләнә-сөйләнә ул безнең өс киемнәребезне салырга булышты.— Кече кызыбыз больницада иде. Павел шунда китте.

— Бала авыру үзең авырганга караганда да читен инде ул,— дидем мин, аның хәленә керергә тырышып.

Звонок тавышы безнең сөйләшүләребезне өзде.

Ишектә аксыл чырайлы, нәфис чәчәк кебек кызчык пәйда булуга, өй эчен күңелле шау-шу билəп алды.

— Кайттыңмы, бәбекәем?

— Ирочка, үскәнем, сагынып беттек үзеңне...

— Әйдә үзебезнең бүлмәгә!

— Минем помидор ашыйсым килә...

— Берне генә ал, кызым, сиңа тозлы ризыкны күп ашарга ярамый бит әле. Әтиең кая соң, кызым?

— Машинасын урнаштыра...

Кызлар шаулашып зал аша үз бүлмәләренә үткәндә, Ирочканың күңелен күтәрергә теләп, мин дә берничә сүз әйтеп калдым:

— Ирагыз терелеп беткән инде! Мондый зур, матур кыз больницада озак ятамы соң?!

Айдай балкып, Павел кайтып керде.

— Анна өстәл әзерләгәнче, семьябыз белән танышa торыгыз,— дип, ул безгә альбомнар бирде.— Күбесен үзем эшләгән. Әллә ни шәп чыкмагандыр да. Менә бусы безнең Анна белән өйләнешкән елгы рәсем. Безнең бит өйләнешүбез дә ашыгыч килеп чыкты. Солдат киемнәрен дә салырга өлгермәгән идем әле. Эшли генә башлаган чак. Абый бер көнне: «Паша, Аннушкаңнан колак кагасың бит, аны кияүгә сорап килгәннәр. Киләсе атнага туйга әзерләнәләр икән»,— диде. Уйлап-нитеп торыр ара юк. Абый белән иртүк ат җиктек тә юлга чыктык. Егерме елга якын яшибез инде менә. Гаилә мәшәкатьләренең күп өлеше Аннага төшә: элек әни сукырайды, Анна аны тәрбияләде. Аннан соң кызларны үстерергә кирәк иде. Институтка укырга керүемә дә сәбәпче булды әле ул, рәхмәт төшкере! Нигә миңа укырга кермәскә?! — дим. Бер башлагач, барды тагын үзе. Тел мәсьәләсендә генә шактый кыен булып алды алуын. Ун ел буе татар мәктәбендә укыгач... Җитмәсә, керәшен булганга, исем-фамилиям русча, үзем русча сөйләшә дә белмим, оялдыра...

Чит тел белән дә эшләр бик шома гына бармады. Без бит мәктәптә кыскартылган программа белән немец теле өйрәнеп маташтык, монда — инглиз теле. Текстның эчтәлеген дә аңлыйм. Тәрҗемәсен дә маташтырам. Ә менә укырга тел әйләнми генә бит. Бер иптәш: «Син аны кызу-кызу укы, нәрсә әйткәнеңне аңларлык та булмасын!»— дип, өйрәтеп тә караган иде, алай гына барып чыкмады, төннәр буе йокламыйча утырырга туры килде...

Безнең сөйләшүләрне күрше бүлмәдән ишетелгән музыка авазлары бүлде.

— Света уйный,— диде, әчке горурлык белән Павел. Кичә берләшмәдә үткәрелгән ярышта фортепьянода уйнау буенча беренче урынны алган.

— Әтиләре, шуның уйнавын тыңлап, төннәр буе утырырга риза инде,— диде Анна зур канәгатьлек белән.

— Оста уйный. Әллә үзегезнең дә берәрегездә музыкага сәләт бармы?

— Безнең чорга нинди сәләтең булуны белергә дә җае чыкмады бит аның...

— Теләкләрегез балаларыгыз язмышында тормышка ашсын инде! Света кем булам ди соң?

— Башта музыка укытучысы булам дип йөри иде, Ирочка авырып киткәч, врач булам, дип хыялланa. Икесе дә әйбәт, еллар гына тыныч булсын!

— Үзеңнең эшең ничек бара, Павел? — дим.

— Анысы өчен берәр көнне минем эш урынына килегез. Шунда барысы турында да иркенләп сөйләшербез...

Ике очрашу арасында шактый вакыт үтте.

Лифтка кереп, кнопкага басам, һәм күз ачып йомган арада мин Павел кабинеты урнашкан унынчы каттa! Тормыш биеклекләренә алай җиңел генә күтәрелеп булмый, дип уйлап куям. Аның өчен кешегә дистә еллар кирәк. Һәм моңа ирешүнең авырлыгын һәр кеше үзе генә җиңә.

Мин Павел менгән үрдә торам. Ул миңа үзенең мәктәп капкасыннан башланган юлы буйлап атлаганда ниләр кичерүен сөйли.

— ...Минем хезмәт юлым армиядән соң «Әлмәтнефть» идарәсенең транспорт конторасында автослесарьлыкка өйрәнүдән башланды. Квалификацияле слесарь булгач, уналтынчы автохуҗалыкка күчерделәр. Кичке институтка укырга кердем. Беркөнне деканыбыз Николай Моисеевич Косьянов:

— Лаборант кирәк иде безгә. Кулы эшкә ята торган кеше булсын ул. Слесарьлык эшен дә белсен, машина да йөртсен, приборларны да аңласын. Кайсыгыз шуны булдыра ала? — диде.

— Мин! — дип, «Нефть чыгару һәм катлам физикасы» лабораториясендә эшләргә ризалык бирдем.

— Павел Гурьевич! Безгә техник хәзерлек буенча инженер кирәк иде. Күчегез безгә! — диде миңа бишенче курста укыган чагында «Әлмәтнефть» идарәсенең транспорт конторасы баш инженеры Николай Монаков.

Кучтем. Бер елдан техник производство булегендә инженерлык вазифасын үти башладым, аннары шул ук конторада автоколонна начальнигы булырга туры килде. Мәнә шунда инде мин кешеләр белән эшләүнең ни кадәр авыр һәм җаваплы икәнлегенә төшендем.

Шул коллективта мине партия сафларына кабул иттеләр. Шул елларда мин диплом якладым. Квартира алдым. Кешеләрне яратырга өйрәндем. 1966—67 еллар иде бу. Эштә, никадәр генә тырышсаң да, бөтенесен алдан күрү кыен икән. Мин ял йортында вакытта бер авария булды. Кешеләр төялгән вахта машинасы әйләнгән. Бу күңелсез вакыйга бер өзлексез минем җанымны кыйнап, миемне бораулап торды. Ахыр чиктә мин бу эштән бөтенләйгә китәргә булдым. «Татнефтестрой»га. Механик булып. Партком секретаребыз Наилә Закировна китүемә каршы булды. Инде эшкә урнашып өлгергәнлегемне белгәч кенә ризалашты. Аның шул вакытта әйткән сүзләре әле бүген дә хәтеремдә. «Син безгә бик кирәкле кеше. Сине бит без үзебез укыттык, тәрбияләп үстердек. Бер елдан соң үзебезгә кайтасың!» — диган иде ул. Шул сүзләрен ул үзе дә исеннән чыгармаган.

— Павел Гурьевич! Кайтасыңмы инде безгә? Бер ел үтте бит. Катлам басымын саклау буенча смена начальнигы кирәк безгә,— диде ул миңа бер киңәшмәдә очрап.

Ризалаштым...

— Шушы урында сине аз гына бүлим әле, Павел. Наилә Закировна турында син нәрсә әйтә аласың?

— Улмы? Ул — безнең әниебез кебек кеше. Мәнә шуннан үзегез аңлагыз инде...

Ул чакыргач, яңа урында эшли башлаган гына көннәрем иде. Трассалар буйлап йөрергә чыктым. Күрәм: Акташ юлы буендагы трассаның тау итәкләп сузылган өлешендәге торба җир өстендә ап-ачык күренеп ята. Кар-яңгыр сулары юып шәрәләндергән икән. Аңымнан: «Монда авария булуы ихтимал!» — диган уй үтеп китте. Тизрәк кайтып, аварияне булдырмау чарасына керешергә кирәк. Ком белән каплатыйк,— дидем ул вакыттагы цех начальнигына.

— Юкка расход чыгаруның кирәге юк, минемчә. Торбалардагы су утыз сигез атмосфера басым көче белән агып тора. Аккан суның туңганын белмим мин. Мондый тизлектә температура аермасы да хасил булмый,— дип кырт кисте ул.

Мин үз фикеремне фәнни нигезләп яклый алмадым. Тәҗрибә дә аз. Без бит нефть табу һәм эшкәртү ысулларын эш барышында камиллаштерә барган кешеләр. Эзләнүчеләр. Алдан юл ярып килүчеләр. Шуңа күрә хаталарыбыз булмады түгел. Шуларны төзәтә-төзәтә эшкә өйрәндек. Бу чорда без катламга Кама суын кудыра идек. Техник сыекчалар белән эш итә белми идек әле.

Авария озак көттермәде. Колач җитмәс юан труба бер урыннан өзелгән. Су ташкыны бәрә. Тау елгасыннан бер дә ким түгел.

Эшне камераларга урнашкан томалау краннарын — задвижкаларны ябудан башладык. Ике як кранны япканнан соң да әле су тагын ике тәүлеккә якын акты. Краннар арасы кырык чакрымнар чамасы бит. Шуннан соң гына эретеп ялгау эшенә керештек.

Тышта чатнама суык. Аяк асты юеш. Киез итек киеп булмый. Күн итек белән аяк өши. Чыдар хәл юк, ә эшне туктатырга ярамый. Ярый әле камера эчендә җылы. Шунда чәй кайнатып, кабыклы бәрәңге ашап алабыз да тагын эшкә тотынабыз. Өйгә кайтуны, вакыт төшенчәсен бөтенләй оныттык.

Ул турыда уйлаган кеше дә, телгә алучы да булмады. Бөтенебез скважиналарның туктап торуына хафалана. Күпме зыян бит!

Безнең хезмәт шундый инде ул.

Хәзер трассаларда андый зур аварияләр булмый да диярлек. Чөнки профилактик чаралар үткәрелә. Моның өчен махсус кешеләр, агрегатлар бар. Элекке цех үзе зур идарәгә әйләнде инде.

Бер елдан соң мине «Татнефть» берләшмәсенең баш механик бүлегенә өлкән инженер итеп күчерделәр. Анда җиде ел эшләдем. Аннан соң шушы эштә инде мәнә — транспорт бүлеге начальнигы...

Ул очрашуда сүз тәмамланды безнең. Кабат күрешергә сүз куештык, телефон аша хәбәрләшергә булдык.

— Башлап мин шалтыраттым.

— Ало! Миңа Павель Гурьевич кирәк иде.

— Ул бу атнада булмаячак. Гражданлык оборонасы буенча шәһәр күләм занятиеләр үткәрәләр. Ул шунда транспорт белән идарә итә,— диделәр.

Тагын эзлим.

— Ало! Матвеев юкмы анда?

— Халык контроле инспекторы да бит ул, әле шул эш белән йөри...

Берничә көн үтә.

— Ало! Павел! Бүген миңа вакыт чыгара аласыңмы?

— Юк шул!.. Бүген политуку үткәрәсем бар.

— Иртәгә?

— Иртәгә — мастерлар хәзерләү мәктәбендә лекцияләрем...

Ниһаять, ул үзе шалтыратты. Очраштык.

— Тыңлыйм сине, Павел, сөйлә,— дидем.

«...Гомердә булмаганча салкын булды ул кыш. Салкыннар илле өч градуска кадәр җитте. Шәһәрдә транспорт хәрәкәте тукталды. Халык яңа ел каршыларга әзерләнә. Өйдә телефон шалтырады. Берләшмәнең ул чактагы начальнигы Булгаков икән. Тиз генә җыенып эш урынына килеп җитәргә кушты.

— Павел Гурьевич, катастрофик хәл. Шәһәргә дә, барлык скважиналарга да энергия килү кимегән. Шәһәрнең бер өлешендә котельный эшләми. Зәй ГРЭСында — авария. Сезгә хәзер үк пар белән җылыту җайланмаларыбызны көйгә салырга кирәк. Хәзер үк кирәкле кешеләрне җыегыз да эшкә керешегез.

— Бәйрәм бит, кешеләрне ничек табарбыз икән?..

— Бөтен мөмкинлекләрдән файдаланыгыз! Башка чара юк!

Дүрт сәгать вакыт үтүгә, утызлап агрегат өч йөз градуслы кайнар пар өрдереп, үз вазифасын үти башлаган иде инде.

Төп көчне «Дуслык» нефть үткәргеченә куйдык. Салкында нефть бик нык куера. Тоткарлык чыкмасын өчен, торбаларны җылытырга кирәк. Су кудыра торган берләшкән насос җайланмаларын да туңудан сакларга кирәк иде.

Эш җайланды дигәндә, тагын бер көтелмәгән хәл килеп чыкты. Нагрузканың кинәт артуы сәбәпле, ГРЭСта яңа авария булды. Тагын скважиналарның тибеше салмакланды.

Шулар артыннан йөри-йөри, Яңа елга чыкканыбызны сизми дә калганбыз. Өйгә кереп тамак ялгарга да вакыт булмады. Анна ризыкларны эш урыныбызга алып килде...

— Истәлекле Яңа ел икән — дим.— Инде бүгенге эшең белән дә таныштыр, Павел!

Ул сөйли бирде.

— ...Мин хәзер махсус җайланмалы техника һәм технологик транспорт идарәсендә эксплуатация бүлеге начальнигы вазифасын башкарам. Хәзер минем кул астында ун меңнәрчә машина. Алар, егермедән артык транспорт хуҗалыгына бүленеп, республикабызның газ һәм нефть промышленностена хезмәт күрсәтәләр. Ә минем төп бурыч — шуларның эшен координацияләү һәм даими күзәтү астында тоту.

Транспорт дигәч, күп кешеләр асфальт буйлап чабучы машиналарны гына күздә тоталар. Бездә махсус җайланмалы техник транспорт зур урын тота. Икенче төрлерәк иттереп әйтсәк, безнең тәгәрмәчләр өстендә заводлар, цехлар, мастерскойлар, лабораторияләр дә йөри. Җиңел машиналар да бар, уналты тонна йөк күтәрүче автокраннар да, җир кисүче машиналар да — безнеке. Элек без юллар буйлап чаба гына идек. Хәзер канат ярдык. Ил буйлап очабыз да. Себер нефте ачылу безгә яңа бурычлар өстәде. Андагы эшкә бәйле бурычларны һава транспорты башкара. Безгә Казан, Бигеш, Бөгелмә аэропортлары хезмәт күрсәтә...

— Синең рационализаторлык тәкъдиме өчен дә бүләкләнгәнең бар бит әле, Павел? Нинди яңалык иде ул?

— Алай зурдан кубып сөйләрлек эш түгел инде ул. «Әлмәтнефть»нең транспорт конторасында баш механик булып эшләгәндә, хәрәкәтне күчерүче тешле тәгәрмәчләргә кечкенә генә деталь өстәдем. Шул нәрсә уннарча машиналарның запас частьлар көтеп, көннәр буе эшсез ятуларыннан коткарды. Аннары ремонтлау эшен

җиңелэйтә торган гади генә бер җайланма ясадым. Эш үзе шуны таләп итте.— Павел елмаеп җибәрде.— Кешеләр арасында үз кулларым белән нәрсәдер башкару рәхәт иде. Монда ярым автоматка әйләнеп бетәсең.

— Зур коллектив белән идарә итәсең бит! Эшне белүең, кешеләрне белүең, аларның сиңа булган ышанычы, ихтирамы күтәрә бит сине бу биеклеккә. Һәм шулар ук тотып та тора сине, Павел!

— Мин бит кешеләрне ачулана белмим.

— Аның кирәге дә юк, Павел.

— Кайчак кирәк ул. Мин Сезгә тагын бер вакыйга сөйләрмен әле, өйгә рәхим итегез. Монда вакыт тар.

Заманча итеп, зәвык белән җиһазландырылган өй эчендә бер нәрсә дә үзгәрмәгән. Шкафтагы китаплар гына артып киткән дә, эчкә сыймаганнары башына ук менеп кунаклаганнар. Өстәл өстендә Ирочканың төсле фоторәсеме куелган. Колагында телефон трубкасы тоткан килеш, гөлләр арасында басып тора ул. Кыйгач кара кашлары астыннан акыллы коңгырт күзләр карый. Чем кара чәчләре, ике яктан күе кызыл тасмалар белән күбәләкләп бәйләнгән. Бөтен торышы белән ул гүзәл чәчәкне хәтерләтә.

Уйларым кабат мәктәп капкасыннан башланган олы юлга барып тоташа. Әлегә мин бер укучым — Павел Гурьевич Матвеев турында гына мәгълүматлар тупладым. Мин алда да үземнең элекке укучыларымны барлап, язмышлары белән кызыксынып торырга булдым. Бу шөгылемнең яшьләргә һөнәр сайлаганда файда китерәчәгенә дә ышанам.

Кулыма укучыларым тапшырып калдырган анкеталарны алам. «Ханнанов Ринат»— дип укыйм. Ринатның тугызынчы класста төшкән фоторәсеменә текәләм...

## Укучының күңел дәфтәренә

**Немец мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Агачны җимешеннән, кешене эшеннән бел.*
*Күз — мәхәббәт илчесе.*
*Куркак эт күбрәк өрә.*
*Кара төндә барча мәче соры.*
*Намуссызлык үлемнән яман.*
*Кешенең бәлешеннән үз сохариең артык.*
*Башсыз калганчы, аягың сынсын.*
*Эш белмичә тырышу — яктысы булмаган ут.*
*Барча кешегә ярасаң, юләр булырсың.*
*Намуслы булган дошман — ялган дустан яхшырак.*
*Бер тиенне саклый белү — ике тиен эшләп табу белән бер.*
*Эшкә — соңгылардан артта, ашка — алдыңгыдан алда.*
*Иң көчленең буласы юк, аннан да көчлеләр бар.*
*Иң кирәк нәрсә — ирек.*
*Дуслар өчен ут-су кичә бел.*

## Шамил Рәкыйпов

# СӨЕНЧЕГӘ—АЛТЫН СӘГАТЬ...

### Бер эзләнүнең тарихы



Бу вакыйганы миңа туган якларында кунакта булып кайткан бер танышым сөйләде. Ярыйсы гына кызыксындырды ул. Тикшерүче сыман төпчено-төпчено сораулар бирдем. Ләкин аның җаваплары — хәтер җимеше генә иде.

— Гаделлекне табудан өмет өзгән кеше язмышы турында сүз бара. Ул үзен Советлар Союзы Герое дип уйлый. Раслый алмый. Рәсми кәгазьләрдәге буталчыклык тәмам гайрәтен чигергән. Аның гозерен менә хәзер сезгә сөйлим. Документалист-язучы буларак, битараф калмассыз дип уйлыйм,— диде танышым.

— Сөйләгез, тыңлыйм сезне.

Ул йомшак кәнәфигә иплә6рәк утырды да ашыкмыйча гына сүз башлады:

— Авыл зур безнең.

Ирләре әзмәвердәй гәүдәле, зур куллы, имәндәй бирешмәс биллеләр, аз сүзләләр. Күбесе — механизатор. Кыз-хатын да ирләрдән калышлы түгел: нык бәдәнле, мул күкрәклеләр. Печәнен дә чаба, урманын да ега, вакытында җиләк-җимешен, чикләвеген дә җыя, мал-туарын да, бала-чагасын да һаман үзе бага. Хезмәттән тәм таба белгәнгәдер, битләре янып тора, хорлыклары юмарт, күңелләре киң. Өй саен кимендә дүрт-биш бала.

Онытканчы тагын шуны әйтим: почтасы, әйбәт китапханәсе, радиоузелы, ике катлы клубы, кибете, урта мәктәбе бар мең ике йөз хуҗалыклы бу авылның.

Түбән оч Сөенче Дәгъвәсе килененең бәби туе үткәреләчәге хәбәр ителеп мине дә шунда дәштеләр. Мин бармаска исәпләдем.

Әнинең күзләрендә сәерсенү чагылды:

— Яшьтиең җыйган мәҗлескә бармый калырсыңмы? Уйлама да. Кайту хәбәрең килгәч, бәби туен бер атнага кичектерде ич ул.

— Миннән башка да узар әле...

— Узмас, балам, узмас. Шул чаклы көтеп...— Әни, тастымал белән чынаяклар сөртә-сөртә, сүзенең өстәвен дә әйтеп бетерде: — Яшьтиеңнең бу мәҗлесенә бармый ярамас. Болай да гомере буе эчтән кимерелеп яши. Җитмәсә тагын яңа туган нарасыйның солдат-атасыннан ике ай инде хәбәр юк. Әллә үле, әллә тере...

— Тере! Тере минем малай! — диде шул чак бусагада калын тавыш.— Хаты, заказ биргән шикелле, нәкъ көненә килеп җитте. Нәкъ көненә!

Без Дәгъвә белән гадәттәгечә кочаклап күрештек. Ул, радиодан еш тапшырыла торган билгеле бер көйне хәтерләп:

— Оныттың бугай! Оныттың бугай!— дип көйләп мине әйләндергәләде. Мин аңа игътибар иттем: шул ук алыптай зур гәүдә, шул ук таудай текә киң маңгай, чак кына кәкреле озынча борын, йөнтәс сары каш астында — соргылт, әрсез күзләр.

— Тикшерүчеләр кебек тишәрдәй булып карамасана!— диде Дәгъвә.— Картайдым инде, яшьти, картайдым. Дөнья картайтты үземне, дөнья. Шулай да, бөтенләй үк бирешергә исәп юк әле. Күрәшәбез...

— Кайтуың әйбәт булды. Рәхәтләнеп бер сөйләшеп утырырбыз.

Мәҗлес истәлекле булды. Өстәлләрдә ризык мул, әче бал кымырҗап тора торган гайрәтле иде. Безнең авыл элек-электән кибет аракысы белән дус түгел. Йорт саен 10—15 оя умарта корты тоткангадыр, күрәсең, бәйрәмнәрнең олысына-кечесенә атап, мичкә-мичкә бал әчетәләр.

Табындагылар кызып җиткәч, Дәгъвә үгезнекедәй калын муенын чалшайтып, кече якка ымлады. Анда, кетәклеккә бур керүен сизенгән кош-корттай, хатын-кыз тынычсызлана башлады.

Дәгъвә кулын күтәрде дә боеручан тавыш белән:

— Килен!— диде.

Чаршау артында тагын пыш-пыш килделәр. Дәгъвәнең һавада асылынып торган кулы йодрыкланырга өлгермәде, кече яктан челтәрле ак биләү тоткан, алсу яңаклы, чибәр яшь хатын чыкты да кулындагы баласын кайнатасына бирде.

— Җәмагать,— диде Дәгъвә, күзләрен биләүгә текәгән килеш.— Күр тавышын ишетәсездер бу баһадирның. Чыннан да баһадир ул: биш кило ярым тартты! Алма агачыннан ерак төшми. Атасы да туксан биш кило аның. Бу бала да солдат атасы кебек үк герой булыр!— Дәгъвә ак биләүдә тыпырчынган сабыйга таба иелә төште.— Син үсеп ир булганда, җирдә сугыш куркынычы калмасын иде инде, улым. Хезмәт Герое булырга насыйп итсен үзеңә. Атаң теләгәнчә, исемеңне Азамат дип куярбыз...

Ияген күреккә салып утырган гармунчы түзмәде, дәртле көй уйнап җибәрде, өстәл артындагыларның бер ишләре кул чаптылар. Хуҗа яңа сүз башлады:

— Җәмагать,— диде ул.— Үзегезгә мәгълүм: безне Сөенечнекеләр диләр. Шәп кушамат бит, мәгънәле исем. Мәрхүмә әнкәй шулай дия торган иде. Ул, бәгырькәем, сугыштан хатым килгән саен почтальонга сөенче биргән. Кара пичәтле язудан соң исән икәнлегемне хәбәр итүчегә, бер әйбере дә булмагач, көмеш беләзеге белән чулпыларын салып биргән. Хәзергесе көндә матур гадәтне мин дәвам итмимме? Итәм! Баһадир оныгым тууын конторга килеп хәбәр салган Хәбирәгә — чылбыр муенса! Прастуй чылбыр түгел, пробалы. Пробасыз малны без бу йортка кертмибез инде. Мә, сеңелем, игелеген күр!..

Гармунчы янә дәртле кыска көйне уйнап алды, башкалар шаулатып кул таптылар. Ләкин хуҗа урынына утырырга ашыкмады:

— Җәмагать,— диде ул кабат,— хәзергесе көндә, әгәр рөхсәт итсәгез, сүзем бетмәде әле минем. Кәттәсен әйтмәдем әле. Бүген әйтәм. Көне шундый. Барчагызга мәгълүм: сугышка хәтле мин алтын приискаларында эшләп кайткан кеше. Шуннан алып кайткан ярты кадаклы алтын сәгатем дә бар. Әнкәй-мәрхүмәгә рәхмәт, саклаган сәгатемне, ач булса да сатмаган... Шушы, әйтергә кирәк, тарихи сәгатьне, беләсезме нишләтәм? Белмисез? Сөенчегә бирәм! Бер сүзсез, күземне дә йоммыйча бирәчәкмен. Советлар Союзы Герое икәнлегем тәмам расланып, шул хәбәрне китерүчегә булыр ул сөенче — алтын сәгать! Хакыйкать барыбер өстен чыгар, тантана итәр. Вакыты шундый.

Хуҗабикә түзмәде, тастымалга кулларын сөртә-сөртә, ире янына килде:

— Утыз алты ел тантана итә инде ул хакыйкатең... Су тегермәне тарта башласа, туктау белми ул. Тыел берүк, кунакларның кәефен җибәрмә.

— Утыз алты ел тыелам инде мин, хатын. Утыз алты ел астыртын гына әр-хур күтәрәм.— Дәгъвә, өстәлгә капланып, үксеп елап җибәрде.— Тиешенчә хөрмәт күрсәтәсе чакта, мыскыл ишетеп яшә. Имеш, медале дә юк Дәгъвәнең. Ә миңа Алтын Йолдыз медале тиеш! Тиеш!.. Севастопольны алганда полк кәгазьләре янып беткән иде. Дәгъва Валиев геройларча сугышып үлде, аңа зур батырлык күрсәткән өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелде дип әнкәйгә хат җибәрергә мин куштыммы? Әнәтерә шкафта полктан килгән ул хат...

Кунаклар, аяк очларына гына басып, таралыша башладылар. Мин дә өйдән чыгып киттем. Ләкин ишегалдында Дәгъвә дулап килеп, җиңемә ябышты:

— Юк, яшьти, син китмисең! Рәнҗетелгәнне рәнҗетмә. Салкынча бүлмәгә кереп, куе итеп мәтрүшкә генә эчәрбез...

Салкынча бүлмәгә ак чәйнеккә салынган хуш исле мәтрүшкә килде.

— Тыңлыйм,— дидем мин.

— Ярдәм ит, яшьти, булыш. Так минем күкрәккә закунный Алтын Йолдызны. Заманалар үзгәрде, яхшыга үзгәрде. Пленда булгансың дип тормыйлар хәзер. Әгәр батырлык күрсәтүең хак икән, орденын да тагалар, медален дә табалар.

— Син дәгъвалаган Алтын Йолдыз медале сугышта үлеп калган икенче бер Вәлиевнең хатынына тапшырылган бит...

— Ялгыш тапшырылган! Ялгыш!..

Без таң атканчы шулай бәхәсләшеп утырдык. Ниһаять, мин хакыйкатьне эзләп табуда хәлемнән килгәнче булышырга сүз бирдем. Шуны үтәү максатыннан менә бүген сезнең белән сөйләшеп утырабыз...

Әйе, танышым сөйләгән бу вакыйга мине тирәнтен дулкынландырды. Сугыш беткәннән соң тапшырылган Алтын Йолдыз медаленең асылда кемгә бирелергә тиешлеге белән кызыксынырга булдым. Укучылар мине гафу итсен: алга таба үземне тикшеренүче дип атап язачакмын. Шулай кулайрак.

Өстәлнең икенче ягына тикшеренүчегә каршы яшь галим Мөнир утырган. Менә ул, портфеленнән саргаеп беткән бер бит кәгазь алды да, аны сак кына тотып, тикшеренүчегә бирде. Әлеге кәгазьне укып бетергәч, тикшеренүче:

— Вәлиев Леонид мин төзегән Геройлар исемлегендә бар,— диде.— Атасының исеме — Геонаевич. Монысының ялгыш язылган булуы ихтимал.

Тикшеренүченең сүзен яшь галим тиз-тиз җөпләде:

— Мин дә шулай уйлыйм. Рәсми кәгазьләрдә Вәлиевнең исеме дә дөрес күрсәтелмәгән. Ләкин сез төзегән исемлектәге Вәлиев... Дәгъвә Вәлиев булырга тиеш.

— Тиешме яки ихтималмы?

Яшь галим чак кына уңайсыз хәлгә калды, кызарды, яулыгы белән маңгаен сөртәсөртә:

— Мин өйрәнгән документлардан чыгып фикер йөртсәк, аларның уннан сигезе Дәгъвә Вәлиев файдасына сөйли,— диде.

— Ә безгә, хөрмәтлем, барлык документларның да бер генә Вәлиев файдасына сөйләве кирәк.— Тикшеренүче өстәл тартмасыннан катыргысына: «16 апрель 1965 ел» дип язылган сырлап имза салынган кенәгә алды да аны актарырга кереште. Эзләгәнен тапты һәм яшь галимгә сораулар бирә башлады:

— Дәгъвә Вәлиев сугышта нинди званиедә булган?

— Өлкән сержант.

— Вазифасы нинди?

— Отделение командиры.

— Кайда хезмәт иткән?

— Утыз өченче укчы дивизиянең туксан беренче укчы полкында.

— Бу мәгълүматларны кайдан алдыгыз? 1945 елда фронттан җибәрелгән бу хатта хәрби часть дип кенә язылган!

— Саннар белән аталган хәрби частьны әнә шундый дивизиядәге полк икәнлеген СССР Оборона Министрлыгы архивыннан сорап белдем.

— Яхшы. Моны кабат тикшерергә туры килер.

— Ихтыярыгыз. Монда бернинди хата юк.

Тикшеренүче әңгәмәдәшенең хәлен аңлый иде. Шуңа күрә гадәтирәк сөйләшергә тырышты.

— Вәлиевнең милләте дә туры килә менә...

Яшь галим шунда ук җанланып китте:

— Туры килә торган тагын бер мөһим деталь бар әле.

— Нәрсә ул?
— Вәлиевнең үлеме.
— Кайсы Вәлиевнең? Соң, ул исән ич!
— Бүген исән. Ә ул чакта сугышта үтерелгән саналган.
— Моны ни белән раслыйсыз?
— Менә 1944 елда хәрби частьтан җибәрелгән рәсми документ. Анда өлкән сержант Дәгъвә Вәлиев 1944 елның 18 апрелендә Севастополь өчен барган сугышларда батырларча һәлак булды диелгән. Мөһере басылган, имзалары салынган...

Тикшеренүче йөзенә аптырау кунды:

— Әйе, бу белдерү кәгазе төп нөсхә. Һәм мин төзегән исемлектә Советлар Союзы Герое Леонид Вәлиев тә 1944 елның 18 апрелендә сугышта үтерелгән...
— Димәк...
— Юк, иптәш, тәгаенләп нәтиҗә чыгарырга иртәрәк әле. Өстәвенә Дәгъвә Вәлиев исән бит!..
— Әйе, исән. Азмыни сугышта кителмәгән хәлләр! Дәгъвә Вәлиевне үлгәнгә санаганнар һәм шулай дип әнисенә язганнар. Ә ул авыр яралы хәлдә әсирлеккә эләгә. Үзебезнең санитарлар алып киткән булса, бәлки, мондый буталчыклык килеп чыкмас иде.

Тикшеренүче килеште:

— Ярый, сугышта мондый хәлләр очрый дип фараз итик. Инде Дәгъвә-Леонид Вәлиевнең туксан беренче укчы полкның өлкән сержанты булганлыгын раслаучы нинди рәсми кәгазебез бар? Аның хәрби билетында бу мәгълүматлар язылгандыр бит?

Яшь галимнең чырае караңгыланды. Ул, көрсенеп:

— Язылмаган,— диде.— Аннары Дәгъвә Вәлиев хәрби исәптә тормый бит инде.
— Тормаса ни? Район хәрби комиссариаты архивындагы исәп карточкасын гына күтәреп карыйсы.
— Әйткәнебезчә, анда бу мәгълүматлар юк.
— Нәрсәгә таянып әйтте соң ул аларны?
— Хәтеренә таянып...
— Хәтерне эш кәгазьләренә теркәргә мөмкин түгел.
— Шул мәгълүматларны һәммәсен сез раслый алмассызмы икән дип өметләнгән идек без.
— Кемнәр ул «без»?
— Авыл халкы. Һәм, беренче чиратта, билгеле инде, Дәгъвә Вәлиев үзе, балалары. Сер түгел: рәнҗеп яшиләр, бездә хакыйкатьне табарга мөмкин түгелмени диләр. Бәлки архивта эзләнеп, Дәгъвәнең чыннан да Герой икәнлеген раслый алырсыз?

Тикшеренүче яңә аяк естенә басты:

— Эзләгез, раслагыз дип әйтү генә ансат ул. Моның өчен Оборона Министрлыгы архивына барып, атналар буе казынырга кирәк. Әгәр расланмаса? Ә нишләп әлегә кадәр Дәгъвә Вәлиев архивка үзе мөрәҗәгать итмәгән?
— Иткән.
— Соң?
— Өлкән сержант Дәгъвә Вәлиев 1944 елның 18 апрелендә һәлак булган, бүтән мәгълүматлар сакланмаган дип җавап биргәннәр...
— Үзенә... һәлак булган дип?
— Әйе.
— Мин исән дип язмаганмы соң?
— Юк. Моннан ни файда?
— Әйе шул. Архив хезмәткәрләре сугыш кәгазьләренең күчермәләрен генә җибәрәләр... Ә госпитальдә дәвалануы турында белешмәләре юкмы?
— Кызганычка, андый белешмәләре юк,— диде яшь галим.
— Миндәге Советлар Союзы Геройлары исемлегендә Леонид Вәлиев 1942 елдан партия членылыгына кандидат, диелгән.

Яшь галим елмаеп:

— Дәгъвә Вәлиев тә шул вакыттан кандидат булган,— диде.

— Ләкин нәтиҗә чыгарырга барыбер ашыкмыйк әле. Партиялелек мәсьәләсе безгә киләчәктә күп нәрсәләрне ачыкларга ярдәм итәр дип уйлыйм мин.

— Ай-һай шул...

— Ни өчен алай дисез?

— Дәгъвә Вәлиев кандидатлык срогын үткәндә әсир ителгәнлектән...

— Туктагыз әле, Дәгъвә Вәлиев ике елдан артык вакыт кандидат булып йөргәнме әллә? Ул кырык дүртнең 18 апрелендә каты яраланудан һушсыз килеш әсирлеккә эләккән түгелме? Фронтта, минем белүемчә, кандидат булып шул чаклы йөрмәгәннәр.

— Гафу итегез,— диде яшь галим, бер карарга килеп.— Бу буталчык тарихка һәрьяклап ачыклык кертеп, соңгы ноктаны кую — турыдан-туры сезнең вазифа түгел. Әнә төп хезмәтегез таләп иткән ничаклы мәшәкать көтә сезне. Кайберәүләр шундый төп хезмәтләрен дә тиешенчә үтәмиләр. Ә биредә кадерле ял вакытларын ала торган, берни белән грантияләнмәгән ялыктыргыч эш... Рухы белән бай кешеләргә генә ышанып таянырга мөмкин... Сезнең адресны бирүче шулайрак әйткән иде. Ярый, хәерле булсын.

— Туктагыз әле,— диде тикшеренүче.— Яхшылык эшләү, игелек кылу турындагы фәлсәфәгезне куеп торыгыз. Ай ахырында мин архивка барам. Телефоннан шалтыратып, Дәгъвә Вәлиевнең 1944 елда нинди частьта хезмәт иткәнлеген белешә алмассызмы?

... Дәгъвә Вәлиев үзе хезмәт иткән дивизиянең номерын хәтерли иде: утыз өч. Ул дивизиянең гвардияче исеме бар идеме, юкмы — әйтүе кыен. Әйтелештә истә калмаган... Ике икең дүрт диган шикелле, солдатның калебенә сеңгән булыр иде бу. Димәк ки, Дәгъвәләр полкы кергән ул дивизиянең гвардияче исеме булмаган. Дөресрәге, Дәгъвә сугышка килгәндә булмагандыр ул. Ә инде ике ел сугышып, каешланып беткәч, андый шөһрәтле әйтелешләр колак артыннан гына үткәреп җибәрелгәндер, күрәсең.

Дәгъвә Вәлиевтән килгән телеграмма:

*«Безнең 91 нче укчы полк гвардияче иде. 33 нче дивизиябез турында хәзергә кистереп әйтә алмыйм. Кәгазьләремнән эзләп тапкач, өстәп хәбәр итәрмен.»*

Яшь галим тикшеренүче алдына шул кәгазьне куйды.

Телеграф тасмалары китергән сүзләр тикшеренүчегә уңай тәэсир итмәделәр.

— Бөек Ватан сугышында полкка гвардияче исеме бирелеп тә, дивизиясенең озак вакыт гадиләр рәтендә йөрү очраклары бар,— диде ул.

Тикшеренүче менә янәдән СССР Оборона Министрлыгының Үзәк архивында. Соңгы тапкыр ул биредә моннан ике ел элек булган иде. Шул арада матурлап эшләнгән тимер рәшәткәле койманың теге ягында биек-биек ике таш йорт өлгерткәннәр: берсендә архивның идарә аппараты урнашып, икенчесендә — тикшеренүчеләргә хезмәт күрсәтү бүлмәләре.

Әнә коралны солдат янәшәсендә зифа буйлы кыз атлый. Аның кулында баян футлярына охшаган тартма. Әлбәттә, хатын-кызга хөрмәт күрсәтү йөзеннән, солдат юлдашы кулындагы әйберне бик-бик теләп үзенә алыр иде дә, катгый инструкция моны тыя. Ул — сакчы. Тартмада — сугыш сөремен үзенә сеңдергән, елар үткән саен кыйммәте арта барган төп нөсхә кәгазьләр. Изге язулар. Алар — күп милләтле совет халкының Бөек Ватан сугышында күрсәткән тиңдәшсез батырлыгын гасырларга раслаучы бирәгәйле шаһитлар.

Тикшеренүче белә: коралны сак астында китерелгән, катыргы тышларының артына сургыч мөһере басылган, ә алдына «Мәңге сакларга!» дип язылган бу мәгълүматларны махсус җиһазлы бүлмәләрнең берсендә кемдер кул куеп алачак, көне буе өйрәначәк, кирәк җирләрен аерым дәфтәргә күчереп язачак һәм, сәгать алты ту-

луны белдереп, кыңгырау шалтырый башлагач, барлык кәгазьләрен җыештырып, әнә шул кыз кулындагы кебек үк тартмага салып пломбалап, иртәгә чаклы саклык камерасына тапшырачак. Кәгазьләрен тапшырачак, ләкин күңеле барыбер көне буе өйрәнгән мәгълүматлардагы исемнәр, саннар, вакыйгалар шаукымыннан арына алмаячак, әлбәттә...

Аның пропускасына, кыеклап, кызыл сызык төшерелгән, сул як почмагына «Папка белән» дигән шәмәхә буяулы озынча мөһер басканнар. Димәк, ул хәзер шушында ай буена тулы хокуклы «иптәш тикшеренүче», аның үзенчә әйтсәк, тау куышындагы тылсымлы мәгарәдә гыйлем эстәгән Әбугалисинага тиң сәер бер дәрвиш...

Менә ул, тиз-тиз атлап, идарә йортына керде, архив начальнигының урынбасары бүлмәсендә үзенә яхшы таныш, урта яшьләрдәге ыспай гәүдәле полковник белән күреште, аңа үзенә йөкләтелгән йомышлар турында язылган кәгазьләрне сузды. Китте шуннан сорашулар, телефоннан сөйләшүләр, үтенечләр, боерыклар... Соңгысы, әлбәттә, тикшеренүче өлешенә тия торган көмеш түгел. Ул биредә үтенә генә ала. Әмма шунысы куанычлы, аның гозерен архивтагылар мөмкин чаклы тизрәк үтәргә тырышалар. Чөнки ул — тикшеренүче.

— Советлар Союзы Герое Вәлиев Леонид Геонаевич?..— Сөйләшү җайланмасыннан ишетелгән яңгыравык тавыш иясе азрак сабыр итүне сорады һәм, өч-дүрт минут үтмәгәндер, хәрбиләргә хас булганча кистереп, тәгаенләп:

— Бүләкләнүчеләр картотекасында андый Вәлиев бар. Мәгълүматлары болай...

— Бланкка язып китерегез!..— Монысы начальник урынбасары полковник Фәйзуллин әмере иде. Аны бер папирос тартып бетергәнче үтәделәр. Шунда ук чагыштыру башланды.

— Фамилиясе туры килә. Исем...

Тикшеренүче мәсьәләгә ачыклык кертүне кирәк тапты:

— Бу кешеләрнең исемнәре, икесенеке дә, иптәш полковник, русчага үзгәртеп язылган.

— Һәм, кагыйдә буларак, аталарының исемнәре дә төгәл күрсәтелмәгән. Әйеме?

— Әйе шул...

— Дөреслекне табу күп вакыт алачак.

Вакыт, әлбәттә, бик кадерле нәрсә. Тик, нишләмәк кирәк, сабырлык белән коралланып, эшкә тотынмый чара юк. Гади нәрсә турында түгел, хөкүмәтебезнең иң зур бүләге — Алтын Йолдыз медаленең кемгә тиеш булуы турында сүз бара бит. Бу, ахыр чиктә, бездә хакыйкатьнең тантана итүен расларга тиеш.

Әнә Дәгъвә Вәлиевнең бөтен гаиләсе, туган-тумачасы дөреслекнең табылуын шик астына куеп, моңа өметсез эш дип карый башлаганнар инде. Алар фикеренчә, 1944 елда «Правда» газетасында басылып чыккан Указда күрсәтелгән Герой Леонид Вәлиев ул — Дәгъвә Вәлиев. Моны, Дәгъвә әсирлектә йөреп кайтканлыктан, расларга, исбатларга теләүче генә юк... Ә сүз һәрнәрсәдән кадерле ышаныч турында бара...

Шул изге хис Ватан иң авыр көннәр кичергәндә тылдагы халыкка, фронттагы гаскәрләргә бетмәс-төкәнмәс көч бирде. Шунысы бәхәссез: бу изге хис, яшь кәләш өстендәге туй күлмәгедәй, бөртек тузансыз, тапсыз булырга тиеш. Аннары ул бер бөтен коелма һәйкәлдәй гел мәгърур, гел буй җитмәс, ерактан гына карый торган нәрсә дә түгел. Ышаныч — көндәлек тормышыбызда, гамәлебездә һәр минут, һәр секунд саф һава кебек кирәк нәрсә. Ул мәгърур да, кансыз-мәрхәмәтсез дә була алмый, ул гади, мөлаем һәм мәҗбүриятсез... Һәйкәлләр какшый, һәйкәлләр ава, ә ышаныч бүген дә, алмаш буыннар гомерендә дә чатнамас нык булырга тиеш.

— Авырлыгын шулай белеп җигелгәч, әйдә, тартыгыз бу йөкне зарланусыз. Бүләк тә өмет итмәгез...

— Һәр авыр эш өчен дә бүләк бирелми, иптәш полковник...

— Алдыгызга куелган беренче мәсьәлә?

— Гвардия капитаны Елизар Абрамович хәбәр иткән 44085-«К» хәрби частен ачыклау.

Шифрлау бүлегенә кичекмәстән белдерү юсадылар. Аннан җавап килгәнче эшсез утырмас өчен архивта саклана торган Вәлиев Леонидны бүләкләү кәгазе белән Вәлиев Дәгъвә ата-анасына капитан Абрамовичтан килгән хатның эчтәлеген чагыштырырга булдылар.

Хатта болай язылган иде:

«17.9.44 ел.

Хәерле көн, кадерле анакай!

Улыгыз Дәгъвә турында Сезгә икенче хатымны язарга булдым. Ул бездә өлкән сержант иде, разведка отделениесе белән җитәкчелек итте. Сугышта искиткеч кыю, батыр иде, халкыбызга хисапсыз кайгы-хәсрәт китергән немец илбасарларына мәрхәмәтсез иде. Севастополь өчен барган сугышларда ул үзен татар халкының батыр улы итеп танытты: фашистлар траншеясына беренче булып бәреп керде һәм йолкыш фрицларны арсландай теткәләп ташлады. Бу сугышта ул, автоматтан атып, граната ыргытып, 60 фрицны дөмектерде һәм шул тигезсез сугышта батырларча һәлак булды. Совет хөкүмәте улыгыз Дәгъвәнең бу зур каһарманлыгын югары бәяләде һәм без май аенда чыккан барлык газеталарда гвардия өлкән сержанты Вәлиев Леонид Шәяхметовичка Советлар Союзы Герое исеме бирелү турында СССР Верховный Советы Президиумы Указын укып шатландык.

18 апрельдә без аны Севастополь тирәсендә җирләдек. Хәзер ул, Герой буларак, безнең часть исемлегенә мәңгегә теркәлде.

Сез, кадерле анакай, өзгәләнмәгез. Улыгыз өчен без дошманнан һәркөн үч алабыз һәм сезне һәрвакыт күңелебездә тотарбыз, һәрьяклап булышырбыз.

Исән-сау булыгыз.

Сезгә хөрмәт белән 44085-«К» хәрби частенең командир урынбасары гвардия капитаны Елизар Абрамович».

Үз нәүбәтендә СССР Оборона Министрлыгы архивы начальнигының урынбасары полковник Фәйзуллин көр тавыш белән Советлар Союзы Герое Леонид Вәлиевне бүләкләү кәгазен укый башлады:

«Бельбек елгасының сулъяк ярындагы дошман ныгытмаларын өзү өчен барган сугышларда, 1944 елның 16 апрелендә иптәш Вәлиев, башка сугышчыларны да үзенә ияртеп, отделениесе белән беренче булып дошман өстенә ташланды. Дошман ныклы каршылык күрсәтте, әмма гвардиячеләр, ут давыллары аша үтеп беренче ныгытмаларга бәреп керделәр, 18 фашистны дөмектереп, бер ДЗОТны алдылар. Иптәш Вәлиевнең сул кулы яраланды, ул винтовкасын гранатага алмаштырып, отделениене алга әйдәде. 17—18 апрельдә иптәш Вәлиев, үз отделениесен алты мәртәбә һөҗүмгә күтәреп, гранаталар белән дошманны юк итте. 18 апрельдә көн ахырына иптәш Вәлиев отделениедә үзе генә калды, икенче кат яраланды, ләкин барыбер өченче траншеяга барып җитте. Фашистлар иптәш Вәлиевне урап алып, әсир итәргә теләделәр. Иптәш Вәлиев, бөтен тәненнән кан аккан килеш, үзенә таба ыргылган немецларны юк итә торды, ә гранаталары беткәч, дошман гранаталарын эшкә җикте.

Кат-кат җәрәхәтләнгән герой дүрт сәгать буена дошман һөҗүмен кире какты, ләкин дошман пулясы аның гомерен өзде. Аңа ярдәмгә килгән гвардиячеләр Герой саклаган траншеялар янында дошман солдатлары һәм офицерларның 60 тан артык мәетен санадылар.

Ватаныбызга чиксез мәхәббәте, тиңдәшсез батырлыгы өчен иптәш Вәлиев Советлар Союзы Герое исеменә лаек.

91 нче гвардияче укчы полкның командиры гвардия майоры Завьялов.

21 апрель 1944 ел.»

Һәр ике документтагы уртак мәгълүматларны санадылар. Йөз процентлы охшашлык! Замполит Е. Абрамович хәтта Леонид Вәлиевнең Дәгъвә Вәлиев икәнлеген дә ап-ачык итеп язган. Ул үзенең бу хатында Дәгъвәнең әтисенең исемен дә дөп-дөрес күрсәткән.

Мәшәкатьле чакта вакыт дигәнең аргамакка атланып чаба: шифрлау бүлегеннән җибәрелгән белешмә күптән килгән икән. Аны укып гаҗәпкә калдылар. Белешмәдә: «44085-«К» дип йөртелгән хәрби часть ул 33 нче гвардияче укчы дивизиянең 91 нче гвардияче укчы полкы. Хәрәкәт вакыты — 1942—1945 еллар. Полк командиры майор Завьялов, замполит — капитан Абрамович»,— дип язылган иде.

— Котлыйм,— диде полковник,— хәзергә эшләр Дәгъвә Вәлиев файдасына тәгәри.

— Бәхәсле моментлар да арта,— диде тикшеренүче.

— Бу мәгълүматлар бер сугышчыга карыйлар. Бәлки, Леонид Геонаевич Вәлиев — легенда гынадыр?

— Андый сугышчы бөтенләй булмагандыр дисезме?

— Әйе.— Полковник Фәйзуллин сөйләшү җайланмасының зәңгәр төймәсенә басты.— Ватан сугышында катнашучылар исемлегеннән Леонид Геонаевич Вәлиев турында белешмә бирегез...

Ун-унбиш минут үтмәгәндер, андый белешмә полковник өстәлендә иде инде. Чагыштыру тәмамлангач, полковник:

— Шик юк, болар икесе ике кеше,— диде.

— Ә белешмәләрдә ничаклы уртаклык: милләте белән икесе дә татар, икесе дә отделение командиры, икесе дә өлкән сержант, икесе дә 91 нче полк сугышчысы, икесе дә партия членлыгына кандидат, икесе дә яраланган. Ниһаять, икесе дә Севастополь өчен барган сугышларда 1944 елның 18 апрелендә үтерелгән санала.

— Ләкин хөкүмәтнең Бүләкләү кәгазе ике кешегә бирелә алмый. Чын Герой берәү генә.

— Кайсысы?

Полковник кулларын җәйде:

— Моны ачыклау — сезнең эш. Сирәк очрый торган катлаулы төен. Ә аны чишәргә кирәк.

— Әйтүе ансат. Мин инде, иптәш полковник, бу бәхәстә Дәгъвә Вәлиевнең җиңүен тели башладым.

— Тели бирегез. Ләкин тиешенчә раслагыз гына.

— Дөресен әйткәндә, чагыштыруларда мәгълүматларның шул чаклы туры килүендә шик тә уята.

— Сез һәр мәгълүматны шик астына алып карарга тиеш.

— Беренче адым ук ялгыш юлга ясалган булса?

— Ялгыш юлга?

— Замполит Абрамовичның полктагы бер фамилияле ике сугышчының өй адресын буташтыруы ихтимал. Нәрсә дә булса хәтерләмиме икән ул?

— Каян хәтерләсен инде?! Адресларны буташтыруын белсә, икенче хат язмас иде. Менә бит Дәгъвә Вәлиевнең анасына шулай дип яза ул. Сезгә хәзер,— дип сүзен дәвам итте полковник,— үлеп тә исән калган Вәлиев биргән мәгълүматларны архивтагылар белән чагыштыру әһәмиятле. Иң әүвәл аңардан кайсы җире яралануын сорагыз: сул кулымы? Бүләкләү кәгазендә шулай дип теркәлгән. Аннары дивизия командирының фамилиясен хәтерләмәсме? 33 нче дивизияләр икәү. Дәгъвә Вәлиев шуларның кайсында хезмәт иткән? Әгәр ул гвардияче исеме булмаган дивизиядә сугышкан икән, замполит Абрамовичның хатны ялгыш адреска җибәргәнлеге ачыкланачак.

— Тегe гомуми исемлектән Дәгъвә Вәлиевнең кайсы дивизиядә сугышуын үзеннән сорамасак та белә алабыз түгелме, иптәш полковник?

— Әлбәттә. Ләкин безгә аның үзеннән килгән хәбәр әһәмиятлерәк: тере кеше хәбәре, кәгазь түгел. Сугышта кәгазьләр төрле кешеләр тарафыннан төрле шартларда язылган. Ялгышлык китүе мөмкин. Менә хөкүмәт документы — Леонид Вәлиевне Бүләкләү кәгазенә игътибар ит: беренче биткә акка кара белән «33 нче гвардияче укчы дивизия» дип язылган. Ә менә биредә, икенче биттә комдив имза салган җирдә — «63 нче гвардияче укчы дивизия» диелгән. Кайсысы дөрес? Ачыклагыз!. Сезнең карамакта тулы бер архив...

Әйе, тулы бер архив. Бу архивта уники миллион берәмлек кенәгә. Һәр кенәгәгә уртача 800—1000 эш кәгазе теркәлгән. Менә әзлә шуннан... Һаман ярдәм сорау да килешми. Начальник урынбасарының үз мәшәкатьләре муеннан ашкан. Ул гел синe кулыңнан җитәкләп йөри алмас...

Дәгъвә Вәлиевкә телеграмма китте.

һәм Дәгъвә Вәлиевнең йокысы качты. Архивтагы тикшеренүче аның беренче тапкыр кайсы җире яралануы һәм бу хакта нинди белешмәсе барлыгын сораган иде.

Дәгъвә иреннәрен турсайтты: яздылар ди анда сиңа белешмә! 1942 елның август ахырларында чолганышта яраландым, моны раслаучы кәгазь юк дип җавап суксаң

Белов турында әйтергә туры килмәгәе. Белов — буталып беткән Дәгъвә эшенә нур өстәүче бәндә түгел. Киресенчә...

Дәгъвәнең беренче яралануы болай булды.

Кичке ашны ашауга алар взводын рота командиры землянкасы янына чакырдылар. Кояш баеган булса да, бөркү иде әле. Ишетелеп тора: Цимлянск дигән шәһәрчек тирәсендә каты сугышлар бара. Взвод безнең шундагы егетләргә ярдәм күрсәтергә тиеш. Бер уйласаң, нәрсә инде ул взвод? Ләкин белеп сугышканда, бер солдат та зур көчкә ия бит ул.

Дәгъвәләргә немец солдатлары киемнәрен бирделәр... Кораллар да аларныкы. Ни өчен болай дип сораучы булмады. Киттеләр. Дәгъвәнең йөрәге, нидер сизенеп, хәвефләнеп типте. Чит кием беләкләрне, күкрәкне чылатылган киндер капчыктай кыса иде. Хәвефләме болай киенүнең ахыры, дошман солдатлары дип белеп, үзебезнекеләр үк харап итеп ташламаслармы?

Ниндидер елганы кичеп, төнлә немецларның тылына үттеләр. Таң атканда безнең артиллерия эшкә керешкәч, шуңа ышыкланып хәрәкәт итә башладылар. Дәгъвә отделениесендә Белов фамилияле бик җилле бер егет бар иде. Үрмәләп барып, ике сакчыны чәнчеде, йокыдан уянып йөгерешкән унбишләп фашистны автоматтан атып, кырып салды. Башкалар да тик тормады, билгеле. Зур бер склад шартлатылгач, шуның яктысында немец киемендәгеләрнең утны сүндерәсе урынга үрчетеп йөрүен күргәч, хәлне аңладылар. Отделение яшеренгән куаклыкка мина ява башлады. Дәгъва белән Белов снаряд чокырына үрмәләделәр.

Дәгъвәнең сул кулы яраланган иде. Җәрәхәтне тиз-тиз бәйләп куйдылар. Белов:

— Бу тәбедән чыгу юк безгә!— диде һәм френечен салырга керешге...

Телеграммага нәрсә дип язарга соң? Юк, капчык төбен селкеп бетерергә ярамый. Сул кул яраланган иде диярге дә вәссәлам. Кайда, кайчан — монысы турында май кап...

Тикшеренүче телегрмманы өстәлгә полковник алдына куйды.

— Күрәм, бу мәсьәлә дә Дәгъвә Вәлиев файдасына чишелде. Котлыйм, хөрмәтлем, эшләрегез әйбәт тәгәри сезнең!

Шул чак сөйләшү җайланмасында мөлаем таныш тавыш ишетелде:

— Иптәш полковник, кичә Сез эзләткән өлкән сержант Леонид Геонаевич Вәлиевнең 1942 елда әсирлектә булуы ачыкланды...

Полковник Фәйзуллинның ачуы йөзенә бәреп чыкты:

— Бу нинди тамаша! Шайтан белсен — ни бу!.. Әйтерсең, ниндидер сихерләнгән божра! Немедленно Дәгъвәдән сорагыз: кайсы елда әсирлеккә эләккән?

Аптыраган кыяфәтле тикшеренүче:

— Бу безгә билгеле, иптәш полковник. Менә замполит Абрамович хатында язылганча, 1944 елның 18 апрелендә... Шул көнне Дәгъвә Вәлиев сугышта үтерелгән, дөресрәге, каты яралы килеш әсир ителгән,— диде.

— Барыбер сорап языгыз.

Дәгъвә Вәлиевкә янә телеграмма җибәрелде.

Һәм Дәгъвә Вәлиевнең янә йокысы качты. Архивтагы тикшеренүче аның кайда, кайчан һәм ничек әсирлеккә эләгүе белән кызыксына иде. Ул бит бер генә түгел, ике рәт татыды бу ачы язмышны? Язаргамы моны хәзер, эшне бозып куймасмы тәмам ачылып китеп? Вакыт-вакыт болай да күзне ачырмыйлар, икенчесен әйтеп ычкындыргач, каш ясыйм дип күз чыгару булмасмы? Яңа тикшерүләр кузгатмасла рмы? Дөрес, Ватан алдында намусы пакъ-чиста аның. Беренче тапкыр эләгү 1942 елның август ахырларында Миус участогында сугышканда булды. Антына хыянәт итмәде, фашист үкчәсен яламады. Бөтен уй-фикере һаман үзебезнең якта иде. Шуңа күрә әсирлектән тизрәк качу әмәлен эзләп яшәде. Бу телеге яңа елда кабул булды аның: фронт сызыгын үтеп, үзебезнекеләр ягына чыгып егылды ул. Дөресен сөй-

ләде. Ышандылар аңа. Билгеле, тикшермичә генә үз ротасына кайтарып җибәрмәделәр инде. Ярый, бәхеткә, полк штабындагы кәгазьләр исән-имин иде әле.

Әйе, немец солдаты киемнәрен киенеп, төнлә дошман тылына киттеләр. Тәмам мәхшәр кузгалып, камауда калдылар. Дәгъвәнең сул кулы яраланды. Җәрәхәтне Белов бәйләде. Аннары ул френечен салырга кереште.

— Нишлисең?— дип гаҗәпләнде Дәгъвә.

— Җәһәннәмгә кергәндә, нichмаса өстемдә булмасын!..

— Бәлки әле...

— Бетте! Амба безгә! Кемлегебезне фашист белде һәм күрде, үзебезнекеләргә без бу кыяфәттә...— Белов итекләрен, чалбарын салырга тотынды.

— Болай син ак таракан кук. Тере мишень! — диде Дәгъвә.

— Булсын...

Нишләргә соң Дәгъвәгә? Чишенергәме? Чишенмәсә, үзебезнекеләр ук расходка чыгарырга мөмкин. Һөҗүм итүчеләрнең һәммәсенә алар взводы турында әйтеп тордыларммы икән соң? Взвод уңга каерды, Дәгъвәләр менә биредә.

Дәгъвә икенче итеген салырга өлгермәде, якында гына немец пулеметы ата башлавын ишетте. Безнекеләрне чалгыдай кисә иде ул. Онытты Дәгъвә үзе турында. Соңгы ике гранатасын барлап, алга шуышты. Әнә ул ут ноктасы. Фашистлар бу якка сәлам дә бирмичә аталар да аталар. Секунд саен ничә кешенең гомерен өзәдер бу пулемет.

Дәгъвә, итексез уң аягына нык басып, гранаталарын дошман өстенә томырды. Ату тынды. Шул чак баш очында яшен чытырдагандай булды, күзләре чагылып китте. Башына гүя күсәк белән ордылар...

Аңына килгәч, фашистларда әсирлектә икәнен күрде. Колагы ишетми, башы бертуктаусыз селкенеп тора. Эчке күлмәк-ыштаннан калуын шәйләп, нигәдер җиңел сулап куйды. Ул үзен үлемгә хөкем ителгән дип санады. Немец киемнәрен киеп, үзләренә ничаклы зыян китергән совет солдатының башыннан сыйпамыйлар инде алар. Ләкин Дәгъвәне атмадылар. Аны Белов чишендергән булган икән...

Дүрт айдан соң Ростовтагы хәрби әсирләр лагеренда таныды ул аны. Дәгъвә азрак рәтләнеп килә иде инде. Егетне кочып, шатлыктан елап ук җибәрде. Дәгъвә фронт хәлләре белән кызыксынды.

— Безне сытып узган фиргавеннәр Идел янындагы зур шәһәр читендә «капчык»ка эләккәннәр,— диде Белов.— Бүген-иртәгә аларга амба! Чыгу юк аларга ул камаудан...

— Ә безгә, Иван? Бәлки, кайтып җиткәнче генә теге чактагыча киенергә буладыр?

Белов беравык эндәшмәде. Кичерешләрен сиздермәскә теләп, тешләрен кысканга, арык битендәге яңак сөяге шыксыз булып калкып чыкты, озынаеп калган муеннан бөкредәй кабарып торган кәдиге аска-өскә хәрәкәт итте. Ахырда ул:

— Миңа анда чыгу юк инде,— диде.

— Ник булмасын? Әмәлен генә табыйк...

Иван авыр сулады:

— Мин бит чукындырылган кеше,— диде.

Дәгъвә, сәерсенеп, Беловка текәлде.

— Тугач та чукындырганнарын әйтмим. Мондагысын...— Белов, кул селтәп, китеп барды.

Бүтән очрашмадылар. Белов юкка чыкты. Кабат «чукындыруның» ни икәнен Дәгъвә лагерьда үз күзләре белән күрде.

Әсирләрне тукмый-тукмый сафка тезделәр. Куркә кыяфәтле эсэс офицеры суярга мал сайлаган кебек текәп карап, әсирләр алдыннан бер узды да, борылып, калкурак гәүдәле өч әсиргә ымлады. Тегеләрне шунда ук сөйрәп китерделәр. Һәм билгә чаклы чишендерелеп, бер читкә сафларга аркасы белән утыртылган ябык төнле кешеләр янына төртеп китерделәр.

— Болар кызыл комиссарлар,— диде эсэсчы.— Өч әсиргә тугыз комиссар. Муен тамырларына атыгыз. Атмасагыз, үзегезне...

Әсирләрнең берсе кулына тоттырылган пистолетны офицерга төбәргә ниятләгән иде ахры, ләкин сизгер сакчы автоматы аны бер селтәнүдә җиргә сылады. Ул, гырлап:

— Ерткычлар!— диде дә тынды.

Икенче әсир калтырый-калтырый дүрт тапкыр, өченчесе биш тапкыр атты. Аннары аларны лагерьдан алып чыгып киттеләр.

— Безне чукындыра алмаслар!— диде Дәгъвә.

Көтеп йөри торгач, лагерьдан качу җае чыкты. Ләмиганың бәхете булгандыр, совет гаскәрләренең бөтен фронт буйлап һөҗүм иткән көннәренә туры килде. Сораштырдылар, җиз иләктән үткәргәндәй, кат-кат тикшерделәр дә, гаебе табылмагач, үз частена кайтарып җибәрделәр.

Шуннан соң бер елдан артык вакыт үтеп китте. Начар сугышмады Дәгъвә. Шулай да теге якта булу — кунакта булып кайту түгел бит инде ул. Зур җаваплылык сораган заданиеләргә билгеләмәделәр, шуңа күрә орден-фәлән тәтемәде. Моңа эчтән азрак кимерелсә дә, түзде ул. Ватанга ихлас бирелгәнлеген күрсәтәсе сәгатьнең сугуын көтте.

Сәгать сукты сугуын, ләкин язмыш дигәнең, кара сакалын салындырып, алдыңа чыгып утырса, бәхетеңә кырау төшә икән ул. Дәгъвә янә әсирлеккә эләкте. Хәер, тикшеренүче ничә рәт эләктең дип сорамый иң. Белемнәре бар, монысын укып та белерләр: үлгән дип саналган көн — әсир төшкән көн...

Дәгъвә телеграммага болай дип язды: «Беренче тапкыр әсир төшүем 1942 елның августында Миус участогында булды».

Архивта:

— Димәк, Дәгъвә Вәлиев ике тапкыр әсирлеккә эләккән,— дип нәтиҗә ясадылар. Аның нинди частьларда сугышуын тәгаенләргә чират җитте.

Дәгъвә хәтер йомгагын сүтте дә сүтте.

Полкка гвардияче исемен бирү тантанасы вакытында ул дивизия командирыннан күзләрен алмыйча карап торган иде. Ыспай полковник әч кенә адымда иде. Яшь иде ул, чибәр иде. Кыяфәте — бәркетнекечә. Аның сул яңагыннан сузылып төшкән тар гына җәрәхәт эзе бу охшашлыкны ничектер арттыра иде сыман. Юк, дивизия командирының исемен әйтмәделәр ул көнне. Солдатларга аны белүнең хаҗәте юк дигәннәрдер, күрәсең. Тукта, дивизия командирының фамилиясен барыбер белде бит Дәгъвә, белде. Болай булды бу.

15 апрельдә, караңгы төшәр чакта, рота командиры аңа пакет тоттырды да штабка җибәрде. Ярдәм сорап. Каршыбыздагы елганың биек ярында ут нокталары бар, шуларны туптан атып туздырыгыз дигән ярдәм сорап. Мина алмый — фашистбәдбәхет тирән казып кергән. Снаряд бетте...

Килеп җитеп, пакетны биргәч, күп вакыт узмады, штабның үзен туздыра башладылар. Бер зуррак өйдә иде ул штаб. Күктә парашютка эленгән фонарьлар кабынды. Шулар яктыртуыннан файдаланып, фашист самолетлары бомбаларын төп-төгәл чәпәп китәләр иде.

Полк командиры Завьялов, тамагы ярылыр дәрәҗәгә җитеп, телефонга кычкыра. Әй дөрләп яна, ә моның ник керфеге селкенсен! Өйдән чыкмый кычкыра да кычкыра. Дивизиядән ярдәм сорый. Бомба шартлап, кодрәт белән генә эләгеп торган түшәм янып, ишелеп төшәр чакта, киемнәре пыскый башлагач кына килеп чыктылар.

Әллә кайдан, тау итәгеннән генә, самолет пәйда булды. Ул үкереп үткәндә җиргә, яңгыр сибелгәндәй, пуляләр яуды. Өйдән чыгучылар барысы, чалгы белән селтәнгәндәй, авып төштеләр.

Адъютантлар селкенмәде. Дәгъвә полк командирына ярдәмгә ташланды. Гаҗәп: аңа пуля тимәгән, контузия зәхмәте кими төшкән иде. Ул баягы әмерен янә кабатлады. Дәгъвә берни аңламыйча:

— Кем соң ул «Ромашка»?— дип сорады.

— Комдив. Петр Михайлович Волосат...— Майор сүзен әйтеп бетерә алмады, янә бер самолет өскә ташланды. Аннары икенчесе, өченчесе... Майор Завьялов белән Дәгъвәгә аларның зыяны тимәсә дә, полкның сугыш кирәк-яраклары урнаштырылган келәттер, лапастыр кебек нәрсәләр шартлый-яна иделәр. Бу мәхшәргә җидеме-

сигезме очкыч сәбәпче булып, алар полк штабы урнашкан авылны һәм биредәге күпчелек сугышчыларны юк итеп киттеләр. Полкның барлык кәгазьләре шул төндә янган икән...

Йорт хуҗсы янына иминлекне уяу саклаучы зур йонлач эт килде. Азыр башын баскычта утырган Дәгъвәнең тезенә салды.

— Менә бит ул ничек килеп чыкты, Акбай,— диде Дәгъвә.— Син йонлачны сыйпаганга искә төштеме икән әллә командирның фамилиясе? Вәт бит нинди могҗиза! Волосатых... Бу фамилияне шулай төн йокламый хәтер зиратында казынмыйча да искә төшерергә мөмкин иде югыйсә: кырык дүртнең башында Леонид Вәлиев исеменә бирелгән рәхмәт кәгазендә борчактай түм-түгәрәк хәрефләр белән басылган бит ул. Әле атна кич кенә укыды. Шул кәгазьдә үк хәрби часть номеры да бар. Исән-сау булсак, иртәгә үк аны почтага илтеп салырбыз. Мәрхүмә әнкәйгә тагын бер кат рәхмәт, фронттан җибәргән һәр кәгазьне төсем итеп саклаган, җанкисәгем.

Телеграмма архивка шул көнне үк килеп иреште. Шуны тотып, тикшеренүче полковник бүлмәсе ишеген шакыды. Эчтән: «Керегез!» диделәр.

— Исәнмесез, иптәш полковник...

— Исәнмесез... Күрәм: телеграмма алгансыз. Так-так, укыйк: «Безнең утыз өченче гвардияче укчы дивизиянең командиры Волосатых иде. Кырык дүрттә миңа бирелгән рәхмәт кәгазендә П. М. Волосатых дип аның фамилиясе язылган. Вәлиев».

Полковник, урыныннан торып, ишек катыннан әйләнеп килде. Хром итекләре шыгыр-шыгыр иттеләр.

— Телеграммасына караганда, түбән белемле дип булмый моны.

— Бухгалтер ул, иптәш полковник.

— Сизелә шул. Әйдәгез, хәзер комдивлар исемлеген тикшереп карыйк.

Сөйләшү җайланмасына басып, әмер бирелде һәм күп тә үтмәде, хәрбиләрчә кырыс, таныш тавыш бүлмә эчен яңгыратты:

— Утыз өченче гвардияче укчы дивизиянең командиры полковник Петр Михайлович Волосатых булган...

— Рәхмәт, капитан,— диде начальник урынбасары Фәйзуллин. Ул үткер карашын тикшеренүчегә төбәде.— Димәк, Бүләкләү кәгазенең икенче битенә 63 нче гвардияче укчы дивизия дип ялгыш язганнар. Шулай итеп, бу масьәлә дә, ничек әле исеме...

— Дәгъвә Вәлиев файдасына чишелде. Ә нишләп ул үз исемен Сашка яки Димка дип түгел, Леонид дип үзгәрткән?

Тикшеренүче галстугын төзәтеп куйды.

— Монда да мондый сорау туган иде. Гомумән, исемнәрне үзгәртү буталчыклыкка китерә. Дәгъвә Вәлиев моңа үкенеп бетә алмый икән.

— Бу җавап мине канәгатьләндерми. Үзе ничек аңлата ул бу хәлне?

— Алар ротасында Сашкалар, Димкалар күп булган. Теш сындырырлык тоелган Дәгъвә сүзен русча әйтә алмагач, аңа Лешка дип исем кушканнр.

— Аңлашыла. Инде, хөрмәтлем, уелып утырып, 33 нче гвардияче укчы дивизиягә кергән 91 нче гвардияче укчы полкның кәгазь диңгезенә чумыгыз. 1944 елда полк командиры урынбасары замполит Абрамович язган кәгазьләрнең төп нөсхәләрен табарга кирәк. Уңыш телим, хөрмәтлем!

Тикшеренүче янәшә бинадагы эш урынына китте. Махсус басылган бланкка язып, иртәнге көн өчен кирәкле мәгълүматларны эзләп китерүне сорады: политдонесениеләр, рапортлар, җыелыш беркетмәләре, бүләкләү кәгазьләре, үлем хәбәре җибәрелү турындагы белдерүләрнең тупламалары... Аның фикеренчә, катыргы тышларына сургыч мөһер басылган шушы кенәгәләр кайсы Вәлиевнең Советлар Союзы Герое булуын һичкем кире какмаслык дәлилләр белән тәгаенләргә тиешләр иде.

Инде өметсезлеккә бирелә башлаган, дистә еллар буена кимсенеп яшәп, дәреслекнең тантана итүенә тәмам ышанычы какшаган кешегә югалган шатлыгын табып биргәч, нишләр ул? Ярый ла, агаебыз исән-сау калса! Кинәт ескә ишелгән хәвеф, хәсрәт кебек үк, зур сөенеч тә бер мизгелдә чәчеңне агарта яки йөрәкне яра диләр.

Хәер, Дәгъвә Вәлиев кебек утны-суны кичкән адәм калынрак тиреле буладыр ул. Аңа билгесезлекнең бетүе кирәк. Дәгъвә һәр ике нәтиҗәгә риза, ниһаять.

Әлбәттә, күңел дигәне Алтын Йолдызны өметләнә. Сөенечгә ярты кадаклы алтын сәгать тә җәл түгел. Фәкать гаделлек кенә өскә чыксын. Аннары инде ничә ел бәгырьне телүчеләр алдыннан уза белер иде Дәгъвә Вәлиев! Шулай булмый ни: ничә ел түзеп, нинди авырлыклар белән эзләп алган Алтын Йолдыз бит ул!

Чынлап та, эзләнүләр, чагыштырулар нәтиҗәсе хәзергә Дәгъвә Вәлиевнең Герой икәнлеген дәлилләр. Шул дәлилләр 91 нче гвардияче укчы полкта Севастополь тирәләрендә язылган мәгълүматлар белән расланса, эш бетте. Аннары матбугатта игълан итәсе кала. Күп булса, тагын ике-өч көн казынырга туры килер. Һәм яшь галимгә: «Дәгъвә Вәлиевнең Советлар Союзы Герое икәнлеге тулысынча расланды»,— дип телеграмма бирербез. Раслаучы мәгълүматларның фотокүчермәләрен моннан алып кайтырбыз.

Дереслек, шифалы суы ташып торган тау чишмәсе кебек, барыбер өскә бәреп чыга дигән сүз бит бу!

Тикшеренүче әнә шундый тойгылар кичерде. Ашкынып, дулкынланып, иртән эшкә килде. Өстәле янына утырып, кораллы сакчы күзәтүе астында килгән тартмалы кызны сабырсызланып көтте. Ләкин кыз килмәде.

Сәгать унда аны мөдир янына чакырдылар. Ул, бу эштә үз гаебе бар кеше сыман уңайсызланып, күңелсез хәбәр җиткерде:

— 91 нче гвардияче укчы полкның 1944 елдагы эш кәгазьләре сугыш хәрәкәтләре вакытында штабта янып юкка чыккан. Дивизиягә җибәрелгән финанс мәгълүматлары гына бар...

Нишләсен тикшеренүче акча кәгазьләре белән?! Сумнар, тиеннәр берни сөйләми. Бу очракта алар ярдәмендә бернәрсә дә раслап булмый. Тукай әйтмешли, бетте көч, сынды кылыч...

Архив начальнигы урынбасары янына керергә читенсенде. Әйбәт хезмәт курсәтүдән тәм табып, рухланып йөргәндә нигә полковникның бүгенгедәй кояшлы көнен болытлы итәргә? Ул җитәкче кеше, аңа карап микроклимат барлыкка килә. Аның биш минутлык караңгы чырае бүтәннәрдә биш атнага сузылырга мөмкин.

Бүгенге уңышсызлык фәкать тикшеренүченеке генә һәм бу ачы хәсрәтне ул үзе генә йотарга тиеш.

Түбәләрдән чулт-чулт итеп тамчылар тама, бакчада чулт-чулт килеп кошлар сайрый, күктә көләч кояш нур сибә. Яз, яз килә! Тамчылар тамуында һәм кошлар сайравында күңелне төшермәскә, очынып-канатланып яңа үрләргә өндәү ишетте ул; ә юмарт кояш-тереклекне җылы керфеге белән назлап уятучы нур һәм яктылык чыганагы — и адәми зат, бу кадәр өметсезләнмә, менә күрерсең, барысы да рәтләнер, дип юата кебек иде.

Төнне ул кунакханәдәге бер кешелек бүлмәсендә уйланып үткәрде. Иртән шимбә иде, өйләгә чаклы урын өстендә ятты. Тәрәзә пәрдәләрен күтәрми генә чәй кайнатып эчте дә тагын уйланулар дәрьясына чумды.

Бирегә килергә тикшеренүчене остазы, гаять тә сабыр һәм акыллы әдип Гази Кашшаф беренче тапкыр кодалаган иде. «Үкенмәссең, шул юлга кертеп җибәргән өчен гомерең буе рәхмәт әйтерсең әле»,— дигән иде ул. Протез аягы тәнен әрнетүдән йөрәгеп учына кысып, ул шушы архивка ничә рәт килде дә килгән саен эзләгәнен табып кайта алдымы икән соң? Еллар буе эзләнүнең нәтиҗәсе — Муса Җәлил турындагы бер китап.

Сугыштан илгә исән-сау әйләнеп кайткан әдипләр ничәү бездә? Санарга мөмкин. Шуларның ничәсе бирегә килеп казынды икән соң?..

...Тикшеренүче тәрәзә пәрдәләрен ачып җибәрде. Бүлмә эче тагын көләч нур белән тулды.

Тагын калды тикшеренүче, кайтып китмәде. Үзеннән түземсезләнеп җавап көткән Дәгъвә Вәлиевне киләчәктә тагын билгесезлектә яшәтмәс өчен, аның кылган батырлыгына кешеләр гамьсез карый дип әйттермәс өчен, хакыйкатькә баруның мең дә бер юлын эзләде, сукмагын сызды.

Ял көне әнә шулай үтте.

Дүшәмбедә аны начальник урынбасары үзе чакырып алды.

— Сез нәрсә, хөрмәтлем?— диде ул.— Ял итмәдегезме әллә? Чыраегыз нурсызрак шикелле күренә. Начар бу! Ял итмәгән солдат белән ерак китеп булмый.

— Бөҗра йомылды бит, иптәш полковник...

— Бу хакта миңа хәбәр иттеләр. Безгә хәзер икенче юл белән китәргә кирәктер.

— Үзем дә шундый фикергә килдем. Хакыйкатьне хакыйкать белән раслап булыр бәлки.

— Ягъни?

— Ягъни Леонид Геонаевич Вәлиевне Бүләкләү кәгазенең хата түгеллеген раслап.

— Идея бу, хөрмәтлем. Әйдә, әйдә, дәвам итегез...

— Геройны Бүләкләү кәгазендәге уникe төп пунктның сигезе үлгән һәм исән калган Вәлиев өчен уртак, дөресрәге, уңай нәтиҗәле. Икенче төрле итеп әйткәндә, фамилияләре, званиеләре, вазифалары, милләтләре, партияле булулары, кайсы фронтта күпме сугышулары, үлемнәре, әлеккерәк бүләкләнмәүләре, кайчаннан армиядә булулары, дивизия һәм полк командирлары — һәммәсе дә һәр икесенең архивтагы мәгълүматларына таңгал килә. Туры килми торган нәрсә әлегә бер генә...

— Нәрсә ул?

— Туган еллары. Леонид Вәлиев — 1910 елда, ә Леонид-Дагъвә Вәлиев 1923 елда туган.

— Моңысының, хөрмәтлем, дивизия номерының Бүләкләү кәгазендә ике урында ике төрле язылуы кебек, гади хата гына булуы да ихтимал. Ә Бүләкләү кәгазендәге уртак ялгышлар ничә пунктта?

— Ике пунктта.

— Нәрсәләр алар?

— Армиягә җибәргән хәрби комиссариат һәм гаилә адресы.

— Шулай, шулай,— полковник Бүләкләү кәгазенә карап алды.— Решнтилов хәрби комиссариаты, Решетилов районы, Плошан авылы... Шулар ялгышмы?

— Татарстанда андый район, андый авыл советы юк һәм булмаган, иптәш полковник.

— Бу пунктларның кайсысын тикшереп карарга уйлыйсыз?

— Алтынчы һәм сигезенче пунктларны.

— Димәк, партиялелек һәм яралану.

— Әйе. Менә Леонид Вәлиев 1941 елның 6 декабрендә беренче тапкыр яраланган, икенчесе 1942 елда, өченчесе 1944 елның 16 апрелендә, дүртенчесе — үлем китергәне — 18 апрельдә.

— Ә Леонид-Дагъвә Вәлиев ничек? Моны кайдан беләбез?

— Үзеннән. Аңа Бүләкләү кәгазендәге бу мәгълүматлар берсе дә билгеле түгел.

— Әйе. Бәлки, ул бер тапкыр гына җәрәхәтләнгәндер... Бүген үк аңа телеграмма җибәрегез. Ә үзегез Леонид Вәлиевнең шәхси эше кәгазьләрен эзләтү чарасына керешегез. Ул я Мәскәү архивында, я... Шунысы бәхәссез: партия документлары тегәл, алар озак саклана̄лар. Ярый, хәерле юл сезгә!

Дагъвә Вәлиев архивтан җибәрелгән телеграмманы кичке якта алды. Һәм тагын төн буена керфек какмыйча үткәрде. Ни дип җавап сугарга? Тикшеренүче аның ничә тапкыр яралануы хакында төпчнә. Контузия булдымы дип сорамаган. Сорамаганны кузгатырга кирәкмәс, ахры...

Тикшеренүче көндез килгән телеграмманы тотып, полковник бүлмәсенә керде. Анда болай диелгән иде: «Авыр яралануым бер генә тапкыр булды. 1944 елның 18 апрелендә. Вәлиев».

— Тәбрик итәм,— диде полковник.— Эшләр, ниһаять, үзенең төп юнәлешенә китте шикелле. Үлгән Вәлиев дүрт тапкыр яраланган. Димәк, әерма үлгән Вәлиев файдасына.

— Анысы шулай... Ләкин барыбер Бүләкләү кәгазендә язылган бу мәгълүматларны архивтагы чыганаклар белән раслыйсы бар әле.

Полковникның кашлары җыерылды:

— Сез, хөрмәтлем, анда Вәлиевнең яралануы хакында да ялгышлык җибәрелмәгәнме дип шикләнәсезме?

— Исән Вәлиевне инандыру өчен кирәк бу. Үз күңелемдә беренди шик-шөбһә калмасын өчен кирәк.

— Аңлашыла. Ошый миңа сезнең болай нечкәләп тикшеренүегез. Ошый. Әйдәгез, хәзер бүгенгә чаклы булган эзләнүләрегезгә йомгак ясап алыйк. Безнең кулда Советлар Союзы Герое исеменә дәгъвә белдерүче Вәлиевнең үз күрсәтмәләренә нигезләнгән һәм аңа ук каршы булган өч мәгълүмат бар: беренчесе — Дәгъвә Вәлиев бер тапкыр гына каты яраланган. Бүләкләү кәгазендә бу дүрт тапкыр дип теркәлгән; икенчесе...

Шулчак телефон шалтырады. Полковник сөйләшү җайланмасына таба иелде. Аппаратта калын тавыш:

— Иптәш полковник, Советлар Союзы Герое Леонид Геонаевич Вәлиевнең партиягә кабул ителүе турындагы личное делосы табылды,— диде.— Анкетасында шундый язма да бар: ул 1942 елның августында әсирлеккә эләккән. Әсирләр лагереннан качып кайткан...

— Рәхмәт, капитан.— Полковник бая бүленгән сүзен дәвам итте:— Дәгъвә Вәлиевкә каршы икенче мәгълүмат — ул әсирлеккә ике тапкыр эләккән. Ә Леонид Вәлиев 1942 елның августында гына; 1944 елның 18 апрелендә ул сугышта үтерелгән, каты яралы Дәгъвәне исә фашистлар сөйрәп киткәннәр; өченче каршы мәгълүмат — туган елларындагы аерма. Хөкүмәт Бүләкләү кәгазендә Леонид Вәлиев 1910 елда туган дип язылган, ә **Дәгъвә Вәлиев 1923 елгы**...

— Ләкин, иптәш полковник,— дип каршы төште тикшеренүче,— Леонид Вәлиев файдасына сөйләгән бу мәгълүматларны да Дәгъвә һәм мин ышанырлык итеп расламыйсы иде бит.

— Яхшы әйттегез. Егерме алтынчы съезд барган көннәрдә хакыйкатьнең һичшиксез табылачагын көткән дәгъвәче һәм бары тик хакыйкатьне генә эзләгән тикшеренүче ышанырлык дәлилләр кирәк безгә! Боларны без өлкән сержантны партиягә кабул итү делосыннан табарбыз дип уйлыйм.

Дәгъвә икенче тапкыр әсир ителүен исенә төшерә башлады.

1944 елның 18 апрелендә, Бельбек елгасының аргы як ярында отделениесен яңа һөҗүмгә күтәреп, дошман траншеяларын алгач, бер ялгызы калды ул. Фашистлар, аны «тел» сыйфатында терелэй эләктерергә ниятләп, кат-кат якын ук килделәр. Белеп ыргытылган гранаталар тетте генә фрицны. Үзебезнекеләр ярдәмгә ташлангач, арттарак торган пехота барлык төр кораллардан ут ачты. Дөнья ут-төтен эчендә калды. Полкташлары аны үлгәнгә санаганнар. Ә ул... янә әсирлектә аңына килә. Бу юлы аны еракка озаттылар. Шыксыз һәм кырыс Германия...

Яңармагыз хәтердә, әсирлектә күргән шомлы әр-хур, мәсхәрә ителүләр, ачлык-ялангачлыкка түзүләр! Китегез, кит күз алдыннан, кайчыдай колаклы, бүредәй усал этләр, ялтыравык итекле аякларын киң аерып баскан, резин тукмак тоткан эсэсчылар, күзләре эчкә баткан әсирләр белән тулы үлем бараклары, сасы төтенле зәһәр крематорийлар!..

Дәгъвәнең тәне калтырады, йөрәге күкрәк читлегенә сыеша алмый дулап тибә иде. Карасана, шомлы үткәннәрне искә төшерергә теләдеме ул бу сәгатьтә? Коточкыч саташулы куркыныч төш сыман, әрсез теләнчедәй, капкаңны шакымый-нитми керә дә күңел түреңә менеп утыра алар!

Теләнче... Тукта, бу сүзнең ни аңлатуын хәзерге яшьләр, әйтик, аның балалары, беләләрме? Юктыр, юктыр!

Ә Дәгъвә белә. Сабый чагында аны нэпманнар бер телем ипигә тилмертеп теләнче итте, егет чагында сугышта солдат намусына дегет ягылгач, немец фермерлары теләндерде. Чәнечкеле тимер чыбык киртәле лагерьдан басуга алып китеп, җан тирләре чыкканчы бил бөктереп һәм көнгә бер чүмеч бурда ашатып...

Дәгъвә, үләргә теләмичә, тилмереп, арык кулын сузып янә хәер сорады:

— Брут, битте, фрау Берта...

Бричкадагы фрау Берта карачкыдай сәләмә әсиргә мәсхәрәле итеп бер карады да кизәнеп, үз артына охшаган мул ботлы атларына сукты. Тимер кыршаулы зур көпчәк әсирнең агач башмаклы ялангач аягын сытып узды, каеш чыбыркы, еландай бөтерелеп, чыжлап битне телде...

Ничә елдан соң, менә хәзер, иягенә таянып, бер ялгызы як бүлмәдә утырганда, бәти йонлы кәвеш эчендәге аягы сыкрап куйды, бите чәнчеште. Дәгъвә ирексездән учы белән яңагын каплады. Җөй эзе чыннан да уттай яна иде.

Ни дип, ни дип яңадан шул яман үткәннәр хәтердә тора соң? Онытылырга тиешләр ләбаса инде алар. Юк, һаман онытылмыйлар. Тәмам үзәкләргә үткәнгәдер, күрәсең, шунда баштан кичкәннәрнең хәзер менә азрак әҗерен татыйсы килә. Урынлымы бу теләк? Әллә... Юк инде, Дәгъвә хакы булмаганны дәгъваламый.

Дәгъвә гомере буе тормышта үз урынын, үзенә тиешлене генә дәгъвалап яшәде. Кеше хакына кермәде... Малны юкка сарыф итмәде, ипинең чын кадерен белде... Инде дә белмәсә — ике рәт теләнче булгач! Ә кеше гомере гөнаһсыз сабыйлык, ару-талу белмәс ир-егет чак һәм картлык дигән өлешләрдән тора ул. Терек үсемлекләр дөньясы да шулай: шытып чыга, чәчәк ата, нәсел калдырып, орлык бирә.

Дәгъвә тормышының да менә инде хәзер үзе бик ачык белгән сабый һәм егет чагын искә төшерсәк... аларда ипи өчен җан аткан һәм ипинең кадерен бел дип, туктаусыз искәртеп торган теләнчелек беренче булып өскә калкып чыга. Сабый һәм дә егет чагында муеннан буып тоткан теләнчелек Дәгъвәгә картлык көнендә дә килер дип, бүгенге мул тормышта хәвефләнер урын һич тә юк, әлбәттә. Йорт-җир бар, терлек-туар җитәрлек. Хәстәр-запаска салып куйган мал да бар. Бала-чага үсеп җиткән, пенсиясе килә торса да, шекер әле, җимерттереп эшли бирә. Бәлки, теге көнне яшь галим Мөнир әйткәнчә, рухи теләнчелегедер бу аның? Шөһрәт эзләү, әйеме? Мин Герой дигән булып, кешеләрне бимазалап. Үз фикерен чыңга юрап. Юкны, бәлки, барып чыгар дип?! Тисә — тиенгә, тимәсә... Юк, юкка түгел, нигезсез түгел миңа тиешле шөһрәт. Аны эзлисе, табасы раслыйсы гына бар!

Менә аңардан ничә тапкыр җәрәхәтләндең дип сорап язганнар. Юкны чүкеп ясап булмый бит. Булмаганны — булмый... Җиде төн уртасы җитеп, әтәчләр кычкырганга да биш былтыр. Әнә хатыны, ят инде дип күзләрен челт-челт йомып, йокы бүлмәсеннән яңа чыгып килә. Ә уй киләбе тәмам чуалган, һич очы-кырые юк әле аның.

— Сиңайтәм, башыңа кан савар. Йокың качты бит. Бел ахыр чиктә: синең бу эзләтүләрең — кысыр хәсрәт, ниңә кирәк ул йолдызың картаеп беткәч? Йокла рәхәтләнеп...

— Калган йокы планын тутырырбыз аны, тутырырбыз, хатын. Тегендә баргач...— һәм төн эчендә сакал-мыегы җиткән Дәгъвә, җилкәсенә тунын салып, кесә фонарен учында басып ыжылдата-ыжылдата, ишегалдына чыкты. Туфрагы катып беләүләнгән җиргә басты. Караңгыга күз текәде. Маллар пош-пош сулап йоклый. Сөт исе, тирес исе борынны кытыклый. Бу тагаракны аяк астына ук куймасалар, урын беткән микәнни? Караңгы төшкән саен карап әйләнмәсәң, хуҗа юк бу йортта... Акбай үз оясыннан кузгалуга, читән артындагы казлар тын гына кыйгаклашып алдылар. Сезгер дә кош инде, мин сиңайтим, бу каз дигәнең. Ни йомшак тәпиле этнең урыныннан торганын сизделәр... Күктәге йолдызлар нинди җете, нинди тереләр. Күз кысуларына бак син. Мут кызлар мени?! Ул «үлгән» 18 апрель төне дә нәкъ менә бүгенгедәй аяз һәм җылы иде. Сугыш кәгазьләрендә Дәгъвә Вәлиев кен азагында һәлак булды дип әйтелә. Димәк ки, ул җир өстенә караңгылык иңгәнне бүтән күрмәгән. Димәк ки, үнҗиденче апрель төне, менә бүгенгедәй таңка-тоңкә йолдызлы төн Дәгъвәнең соңгы төне булып чыга. Документларда шулай икән, синең бүгенге яшәвең яшәү түгел инде ул... Шулай, Акбай дус, син менә моннан утыз алты ел элек сугышта һәлак ителгән хуҗаңның тезләренә акыллы башыңны салып, ул сыйпаганга иркәләнеп ятасың. Кешеләр белән шундый сәер хәлләр дә була икән шул. Хуҗаң, чын исемен язып, архивка хат җибәргән иде, аннан, дустым, нинди җавап килде дип беләсең? Әкәмәт җавап! 91 нче полкның 1 нче ротасындагы өлкән сержант Вәлиев Леонид 1944 елның 18 апрелендә сугышта үтерелгән дип. Леонид дигәннәре мин ул, Акбай дус. Мулла кушкан исемемне әйтә алмагач, ротада мине Лешка дип йөртәсе иттеләр. Үзем дә шуңа күнегеп киттем. Юләр, күнмәскә кирәк булган икән, күнмәскә. Шуның арка-

сында, мин сиңа әйтим, ничаклы буталчыклык менә. Шулай булмаса, үземә син үлгәнсең дип язмаслар иде. Кәгазьләрдә Леонид Вәлиев үлгән саналгач, җавапны да үлгән дип бирәләр инде аны. Ә хуҗаң синең исән, теттереп яши. Әйдәле, Акбай, хуҗаңның закон таныган соңгы төнен тагын бер кат искә төшерергә тырышыйк. Бәлки, икеләнүле уйлар бетеп, архивка чын дөреслек турында телеграмм сугарга диган карарга киленер...

Ул төн дә шундый җылы иде. Монысы хак. Апрельдә анда, Акбай, Кырымда дип әйтүем, бездәге августтагыча җылы була. Чөнки ул, йөземнәр пешә торган як. Күктә йолдызлар шулай ук тере, анасына баккан сабый күзләредәй җемелдәделәр микән, юк микән — менә монысы турында уйларга кирәк әле. Нигә дигәндә, Акбай, ул төбәктә атна буе атышлар барды бит. Гади атышлар гына түгел, мең төрле кораллардан берьюлы атышу — молотилкада көлтә суккандай дисәм, әнә, кушәп яткан сыерны чебен зурлыгына калдырган кебек, киметкән булырмын. Мәхшәр иде инде. Мәхшәрне син аңламыйсың шул. Дөньяны ут та төтен генә каплаган. Шартлаулар — харап. Тирә-якта таулар анда. Каф таулары дигәннәре шулдыр инде. Минем отделение Бельбек елгасының биек ярына урнашкан иде. Фашистлар биредә үзләренә биш бөртек кенә сугышчы каршы торуын тиз абайлап алдылар. Язгы кар сулары кебек, ишелеп-ишелеп килделәр өскә. Ташудан соң җирдә чүп-чар утырып калгандай, тирә-як соры киемле мәет белән тулды. Тегеләр чигенә башлагач, мин, хуҗаң, түзмәде: «Алга егетләр!» — дип, окобыннан сикереп чыкты да автоматтан ут сибәсибә үргә таба йөгерде. Траншеяларда кул сугышы башланды. Бугазларын чәйнәп, мылтык яки автомат түтәләре белән бәреп алыштык. Качты фашист. Аннары тагын килде. Тагын... Бу чакта мин үзем генә калган идем инде. Барыбер чигенергә исәпләмәдем. Алдымда унлап граната. Ләкин шуларның алтысын гына ыргытырга өлгердем — атып ектылар. Аңыма килгәндә цемент идәндә ята идем. Фашист башка салкын су коя... Әх, Акбай, күрсәтте фашист синең хуҗаңа газапның әчесен. Күрсәтте!..

Бүгенге яшьләр шундый кара язмышка тап булмасын иде. Бер нәрсә кирәкми, дөньялар гына имин торсын. Моның өчен, әлбәттә, һәрбер намуслы кешенең үз-үзен аямыйча эшләве, гаделлек сафында нык басып атлавы кирәк. Ә хуҗаң соңгы вакытта нишли? Үткәнен яшерергә теләп, кешеләрне тинтерәтә! Кичәге телеграмманы алгач, архивта тәмам аптыраганнардыр. Юк, күргәннәрем — минеке, алардан берничек тә котыла алмыйсың. Чал кергән чәчләреңә ил нәләте, зур хурлык төшмәсен дисәң, хакыйкатьнең күзенә туры кара! Юкса, әкәмәт килеп чыга: ничә ел буе хакыйкатьне эзләгән бәндә үзе үк шуны яшерә. Мәкерлек бу! Оятсызлык! Ярамый болай! Ярамый!..

Тикшеренүче төнлә үзенә килгән телеграмманы архив начальнигы урынбасары өстәленә куйды.

«Беренче яралануым — контузия, 1941 елның ахырында, икенчесе — 42 елның августында, беренче тапкыр әсирлеккә эләгүем 42 елның август ахырында Ростов янында, икенче тапкыры Кырымда 1944 елның 18 апрелендә. Үлгәнгә саналуым да шул көннән. Вәлиев».

— Эшләр тирәнәя,— диде полковник.— Исән Вәлиев бу юлы ачыла төшкән.

— Чынлап та: теге телеграммасында ул бер тапкыр гына яраландым, дигән иде.

— Димәк, намусына көч килгән...

Телеграмманы Бүләкләү кәгазендәге мәгълүматлар белән чагыштырырга керештеләр. Беренче яралану туры килә иде: исән Вәлиев 1941 елның ахыры, ди. Бүләкләү кәгазендә 1941 елның 6 декабре дип язылган.

— Монысы аның файдасына.

— Сабыр. Үлгән Леонид Вәлиев менә дүрт тапкыр яраланган. Ә исән Вәлиев ике генә тапкыр. Җитмәсә, ул контузия ди, Бүләкләү кәгазендә — пуля җәрәхәте.

— Әйе шул. Аннары: үлгән Вәлиев 1944 елның 16 апрелендә дә яраланган. Дәгъвә Вәлиев исә әсирлеккә эләгер алдыннан 18 апрельдә генә...

— Болар бик мөһим нәрсәләр, хөрмәтлем,— диде полковник.— Сездә Дәгъвә Вәлиевнең үз кулы белән язган хаты бармы?

— Яшь галим исеменә язган хаты бар.
— Яхшы.
— Ләкин чагыштырыр өчен үлгән Вәлиевнең дә үз кулы белән язган хаты кирәктер бит. Ул — юк.
— Хат булмаса, гаризасы табылыр. Партиягә кабул итү делосында булырга тиеш.
— Дөрес. Личное делоны тизрәк китерсеннәр иде.
— Бәлки инде китергәннәрдер дә.

Чынлап та, тикшеренүчене эш бүлмәсендә сакчы солдат белән хезмәткәр кыз көтә иде. Тышлыгы урынына фронт газетасының бер бите тегеп куелган юка гына делоны кабул иткәнлеккә имза алдылар да, алар китте... Тикшеренүче, гаять дулкынланып делоны ачты. Беренче биткә үк 33 нче гвардияче дивизия составына кергән 91 нче гвардияче укчы полкның өлкән сержанты, отделение командиры Вәлиев Леонид-Габделәхәт Ганиевичның партия оешмасына гаризасы теркәлгән иде. Атасының исеме Геонаевич түгел, Ганиевич. Вәлиев үзе шулай дип язган. Тигезле-тигезсез хәрефләр, кайбер сүзләрдә хаталар...

Тикшеренүче Бүләкләү кәгазенә игътибар итте: анда Вәлиев Леонидның белеме өч класс диелгән иде. Әлбәттә, түбән белемле кеше генә чебен йөрген төсле итеп һәм хаталар белән яза аладыр ул.

Гариза янәшәсенә Дәгъвә Вәлиевнең кайчандыр яшь галим исеменә юллаган хаты куелды. Җир белән күк арасыдай зур аерма бар иде бу язмаларда! Дәгъвәнең хәрефләре борчак шикелле түгәрәк, матур, тигез. Хаталары да юк дәрәҗәсендә. Белгеч булмасаң да, бу хатны урта белемле кеше язган дип нәтиҗә чыгара аласың.

Гариза 1944 елның 25 февралендә язылган. Һәм 91 нче гвардияче укчы полкның коммунистлары аны шул көнне үк үзләренең гомуми җыелышларында тикшергәннәр. Өлкән сержант Вәлиев бертавыштан партия сафларына член итеп алынган. Партия оешмасы секретаре Зубков гариза почмагына шул хакта язып үз кулын куйган.

Шәхси эш кәгазьләренең икенче бите — партиягә член булып керүче анкетасы. Леонид-Габделәхәт Ганиевич Вәлиев турындагы кыскача барлык төгәл мәгълүматлар шул кәгазьгә тупланган. Монда каһарман сугышчының Чистай районы, Кутлушкино авылында тууы, өч класс күләмендә белеме барлыгы, унҗиде яшеннән алып төрле шәһәрләрдә эшләве, Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән башлап нинди хәрби частьларда хезмәт итүе, камалышта калып әсирлеккә эләгүе, аннан качып кайтуы, партия членлыгына кандидат булып керүе — һәммәсе ачык теркәлгән.

Тикшеренүче өч класс белеме бар дигән сүзләрне игътибарга алды да янә беренче битне ачты. Әйе, бернинди шик юк: бу гаризаны түбән белемле кеше язган.

Инде Л. Г. Вәлиевкә Советлар Союзы Герое исеме бирү өчен башкалага җибәрелә торган Бүләкләү кәгазендәге тагын бер мәгълүматны, ягъни яралануны расларга кирәк. 1 нче гвардияче укчы рота командиры лейтенант Кравченко язган сугышчан характеристикада Л. Г. Вәлиевнең батыр сугышчы булуы белән беррәттән, 1944 елның 25 февраленә чаклы ике тапкыр яралануы да әйтелә. Шулай итеп, Бүләкләү кәгазендә язылганча, Л. Г. Вәлиев 1944 елның 16 апрелендә өченче кат, 18 апрельдә исә дүртенче кат яраланган булып чыга...

Ниһаять, тагын бер саллы дәлил ачыклана: Дәгъвә-Леонид Вәлиевнең атасының исеме бөтенләй башкача. Ә биредә хөкүмәт Бүләкләү кәгазендә күрсәтелгән белән туры килә: Ганиевич.

Тикшеренүче кичен яшь галимгә Дәгъвә Вәлиевнең Советлар Союзы Герое исеменә дәгъвасы урынсыз булуы, моның архивтагы мәгълүматлар белән тулысынча раслануы турында телеграмма сукты.

Укучы бу четерекле эзләнүгә соңгы нокта куелуын көтәдер, әлбәттә. Бактың исә, моны күптән эшләгәннәр инде: Вәлиев Леонид Геонаевичка СССР Верховный Советы Президиумының 1944 ел 16 май Указы нигезендә Советлар Союзы Герое исеме бирелү турындагы Грамота күптән инде мәрхүмнең гаиләсендә саклана. Вәлиев, ар-

хив кәгазьләрендә теркәлгәнчә, Чистай районының Кутлушкино авылында туган кеше. Чын исеме — Габделәхәт, атасының исеме — Габделгани...

Четерекле эзләнүгә нокта куелган дип әйттек әйтүен, әмма бер эш икенчесен китереп чыгара бит ул. Герой гәүдәсенең кайда күмелүе билгесез, аның турында Кырымда хәбәрдар түгелләр. Севастопольдә шәһәрне немец-фашист илбасарлардан азат итү сугышларындагы батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое исемен алучылар хөрмәтенә салынган Дан стенасына да Герой якташыбызның фамилиясе язылмаган әле.

Димәк, алда бу юнәлештә эшлисе эшләр бар...

Авыл урамы буйлап, каз-үрдәкләр, тавык-күркәләрнең котын алып кычкыра-кычкыра, бер малай йөгерә. Аның уң кулында таяк, сулында — зәңгәр кәгазь. Ул, күзләренә төшеп йөдәткән зур бүреген маңгаена таба этә-этә, сөрән салуын дәвам итә:

— Сөенче!.. Сөенче!.. Кәнсәгә Мөнир абый телеграмм суккан: Дәгъвә агаемның Алтын Йолдызы хәл ителгән...

Аны туктатасы килә. Алып килгән хәбәреңнең расмы, түгелме икәнен тәгаен белмичә оран салуның аяныч икәнлеген төшендерәсе килә. Малай, сулуы кабуга карамастан, чабуын белә. Әнә ул койма, стеналары, түбә калайлары яшелгә буялган нык-таза йорт янына килеп җитте һәм, кулындагы кәгазен селки-селки, баягы сүзләрен кабатлады. Тиз арада бала-чага, күрше-күлән җыелып өлгерде. Йорт хуҗасының вәгъдәсен — сөенче китерүчегә ярты кадаклы алтын сәгатен бирәчәген искә төшереп, малайга көнләшеп карадылар. Дәгъвә сүзендә тора торган кеше, ул ике сөйләми. Менә хәзер болдырда ул күренер һәм халык алдында алтын сәгатен малайга бүләк итеп бирер.

Өйдән малай елап чыкты:

— Мине алдаганнар!..

Йорт хуҗасы, урыныннан гаять авырлык белән кубып, түрдәге зур шкаф янына килде, пыяла капкачны ачып, саргаеп беткән, ничә ел буена буш өметләренә, ачы хәсрәтенә сәбәпче булган хәерсез хатны алды, теше сызлаган вакыттагыдай ыңгырашып, ярсып, кәгазьне вак-вак кисәкләргә ерткалады, аннары тәрәзәдән очырып җибәрде.

## Укучының күңел дәфтәренә

**Немец мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Уртак булган куркыныч кешеләрне якын итә.*
*Бармак бирсәң, кулыңны тешли.*
*Дәү кошка зур оя кирәк.*
*Зур бүләктән яхшы сүз артык.*
*Кабыгы ачы булса да, җимеше татлы.*
*Кыска буйлы җитеннән озын җеп эрләп була.*
*Телем — дошман: баштан алда сөйли.*
*Үз казың үз күзеңә аккош булып күренә.*
*Бер эшләпә бөтен башка да ярамый.*
*Чамалы булу — иң яхшы дәва.*
*Ялкаулыкка сырхау ияра.*
*Чүчка пычрак тапмый калмый.*
*Үз-үзеңне җиңә белү — иң авыр сәнгать.*
*Тузан күкләргә күтәрелсә дә, тузан булып кала.*
*Чүлмәк казаннан көлә — икесе дә каралар.*

Разил Вәлиев

# ХАЛЫК ИСЕМЕННӘН СӨЙЛИМ ДИСӘҢ...

*(1981 ел поэзиясе турында уйланулар)*

Республикабыз вакытлы матбугатында һәм аерым китаплар булып та бик күп шигъри әсәрләр дөнья күргән. Алар күңелдә күп төрле уйлар уяталар, күп кичерешләргә дучар итәләр. Шулай да үткән ел басылып чыккан шигъри әсәрләр турындагы сүзне, гадәттәгечә, өлкән буын шагыйрьләр иҗатыннан башлыйсы килә.

Сибгат Хәким «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дип, бар дөньяга ишетелерлек, бар кешеләрнең җанына барып кагылырлык итеп әйткән иде инде. Аның өчен бу тема, бу бөек образ — мәңгелек илһам чыганагы, фикер, хис һәм уй юлдашына әверелгән, иҗат кыйбласына әйләнгән икән. Шагыйрьнең яңа шигырьләрен укыгач, аның иҗат ялкынына сокланмау мөмкин түгел.

Билгесез миңа бу Себер,
Миңа, җырчы-шагыйрьгә.
Мин киттем кереп, нәреп
Шул бөек мөсафиргә.

Сибгат Хәким бөек мөсафир артыннан гади генә ияреп йөрми, аның кылган эше белән, аның хыялы, аның идеалы белән үз идеалын чагыштырып карый, үз тормышын, үз язмышын Ильич бизмәне белән үлчи. Бер карагандa бу бик гади булып тоелса да, бөекләр белән каушамый-нитми, тавышың һәм тез буыннарыңны калтыратмый сөйләшә алу сирәк затларга гына бирелә торган бик олы мәртәбә. Зур шагыйрь, тавышыңны халыкка ишеттерерлек шагыйрь булу өчен, табигый талант һәм чиксез зур тырышлык янына тагын мәгънәле горурлык, үз бәяңне белү, үз-үзеңә нык ышаныч та кирәк.

С. Хәким шигырьләренең нигезендә — хәрәкәт, вакыйга, конкрет бер хәл яисә истәлек була, ә үзәктә — күңел күзе белән генә эзләп табарлык серле үзәктә — идея, төп фикер ята. Билгеле, бу — иҗат итүнең бердәнбер ысулы түгел, иҗатта һәркемнең үз юлы бар. Әмма бу юл — классик поэзиядә һәм шигъриятнең мең еллык тарихи тәҗрибәсендә иң күп һәм иң асыл җәүһәрләр табылган юл. Шәрә идея-фикерне нинди генә чапаннарга төрсәң дә, нинди генә соуслар белән табынга китерсәң дә, ул барыбер кибет манекены яисә майда кыздырылган иске чабата кебек кенә булачак.

С. Хәким шигырьләрендәге бәләкәй тыкрыкларны, карт әнкеләрне, сиреньнәрне, авыл күперләрен, сарык кәтүләрен, читән буендагы кычыткannarны, үткән гомерне сагыну, күңел географиясенең тарлыгы белән аңлатучылар да булган. Баксаң, шагыйрь бүгенге дөньяга шул әнкеләр, шул тыкрыклар аша караган, шулай итеп, бик ерак тоелган әйберләрне үзенә якынайткан. Еллар буе бер телескоп төбе сагалап яңа йолдыз ачкан астроном кебек, Сибгат Хәким дә олы дөньяга гомере буе

үз тыкрыгы аша караган, шул «телескоп» ярдәме белән башкалар күзенә күренмәгән шигъри юлдызлыклар ачкан икән.

Халык исеменнән сөйләү өчен үзеңне халыкныкы санау гына җитми. Халыкның синә үзенеке итеп хисаплавы, сине үз итүе, үзенең бер өлеше итүе зарур. Ә халык үзенең бар сыйфатларын бер җанга, бер күңелгә туплаган шагыйрьләргә генә мондый миссияне ышанып тапшыра.

Чаллыда узган иҗат кичәсендә Сибгат ага Хәкимгә залдан: «Фазыл чишмәсе кайсы авылда ул? Барып карар идек...» — дип сорау бирделәр. Бер карауга үтә беркатлы тоелган бу сорауның төбендә зур мәгънә ята. Димәк, әлеге кеше шагыйрьгә ышана, үзенә ышанган кебек ышана, Фазыл чишмәсенә ышана. Сибгат агай, тел ачкычы көткән кебек, шактый вакыт тын торгач, әйтеп куйды: «Фазыл чишмәсе — һәр авылда бар. Үз авылыңа кайт, энем»,— диде. Шушы минутта берничә сүз белән ул әдәбиятның асылын, шагыйрь миссиясенең мәгънәсен әйтеп бирде. Менә ни өчен мин сүземне С. Хәкимнән — Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан күзләре белән безгә сынап карап торучы, алар әманәтен безгә җиткерүче аксакал Сибгат Хәкимнән — башламый булдыра алмадым.

Илдар Юзеевның «Очты дөнья читлегеннән» дип аталган шигъри трагедиясендә укучыны иң нык тетрәткән, аның күңел түрендәге бар кылларга берьюлы кагылган һәм аны иң ышандырган урыны — Тукайның патша белән сөйләшү эпизоды. Әсәрнең беренче юлларыннан башлап ук Илдар Юзеев Тукае үзен халык улы булырга, халык исеменнән сөйләү хокукын яуларга әзерли башлый. «Уртада — сиртмәле бишек. Ул гүя «Тәфтиләү» көенә тирбәлә. Көй бишек җырына күчә. Шагыйрьне халык тудырэ сыман»,— дип яза И. Юзеев иң беренче ремаркада ук. Юк, Илдар Юзеев Тукайны халык арасыннан аерып, купайтып өскә күтәрми. Киресенчә, башкалар шау-шу килгәндә, Тукай бер читтә тын гына тора, бүтәннәр арлы-бирле чапканда, артык каударланмый, ә инде иң кирәк чакта, кешеләр аптырап сүзсез калганда, ул барысы исеменнән дә сөйли, барысының да еллар буе әйтергә теләп тә әйтә алмый килгән уйларына иң кулай сүзләр таба. Әйе, И. Юзеев Тукае — халыкның бәгыре, үзәге, аның күңел ярасы һәм тарих җилләрендә ныгыган ышерен иманы.

**Халкым күпме ким-хурлыкта интекте,**
**Аның рухы кабул итми читлекне.**
**Чит-ят күрә җаным мондый дөньяны,**
**Юк, танымыйм яшәү диеп мин аны.**
**Туган идем бәхет, шатлык чәчәргә,**
**Мәҗбүр булдым кайгы җырлап яшәргә.**
**Килми калмас, чынлык диган чор туар,**
**Халык бәхете турында да җыр туар.**
**Бар милләтләр тигез булыр — мин беләм...**
**Әммә ачык белмим — нинди юл белән.**

Бу юлларда Тукайның бөтен биографиясе, иҗат газаплары, язмыш михнәтләре, иманы, күңел кыйбласы. Бу юлларда — Илдар Юзеев әсәренең төп фикере.

«Очты дөнья читлегеннән» әсәренең жанрын кайберәүләр пьеса дип билгели. Башына «шигъри трагедия» дип куелган бу әсәрне шундый ук ышаныч белән поэма яисә опера өчен либретто дип тә атап булыр иде. Чынлыкта исә, «Очты дөнья читлегеннән» трагедиясендә И. Юзеевның шагыйрь, драматург, прозаик таланты өчесе бергә укмашкан. Нәтиҗәдә, әдәбиятыбызның мактанычы булырлык әсәр дөньяга килгән.

Спортта биеклеккә сикерүчеләр арасында ике төрле рекорд бар: аның берсе — ябык бинада сикерү, икенчесе — ачык һавада сикерү буенча. Гаҗәпкә каршы, бер үк спортчы ачык һавада бина эчендәгегә караганда берничә сантиметрга биегрәк сикерә икән. Югыйсә, күпме сикерсә дә, түшәмгә башы тими бит инде аның! Як-ягында — иркенлек, баш өстендә биек күк булу спортчы булып спортчыга тәэсир итмәч, иң сизгер күңелле шагыйрь һәм язучы затларына киң мәйдан кирәклеге турында әйтеп тору зарур микән? Шуңа күрә безгә Тукай белән Җәлил һәйкәлләренә генә сокланып калмыйча, бүгенге шагыйрьләребезне дә илкүләм олы мәйданга кыюрак чыгару турында нык лап уйланырга вакыт җиткәндер.

Үзенә үзе юл салып, тез җимерә-җимерә, терсәк каната-каната илкүләм поэзия мәйданына чыгып барган Равил Фәйзуллин иҗаты турында уйланганда бу өлкәдәге эшләрнең әле үзагымына куелганын аңлап әрнисең.

Р. Фәйзуллин турында кем ничек фикер йөртәдер, ә минем үзем өчен ул иң әүвәл — көчле шәхес, кызыклы шәхес. Аның иҗат энергиясе, туктаусыз эзләнүләре, үз язмышын һәм әдәбият язмышын кайгыртып янулары һич тә эзсез югалып кала алмый. Киресенчә, Равил Фәйзуллин исеме халык арасында көннән-көн ныграк тарала, илкүләм масштабта танылa бара. Р. Фәйзуллин бүгенге дөньяның эш стилен һәм фикер сөрешен тирәнтен үзләштергән шәхес буларак, кайбер талантлы шагыйрьләребез кебек, аткан шигырь угы артыннан хәерле юл теләп карап кына калмый. Угыннан да алда мишень янына йөгереп барып җитеп, аны иң үзәккә тидерергә тырыша, ә инде тимәсә, яңадан элекке урынына кайтып, максатына ирешкәнче, тидергәнче ата. Р. Фәйзуллин шигырьләрен, дөньяга килү белән, үз кенәгезнә үзегез күрегез дип, ташлап китми, аларны йөрергә, сөйләшергә, кешеләр белән аралашырга өйрәтә, ә инде «балалары» аякка баскач, үзе дә игелеген күрә.

1981 елда күләм ягыннан да, шигъри егәрлеге ягыннан да күпләрне көнләштерерлек булып китап киштәләренә менеп баскан «Кошлар юлы» җыентыгын ачып укый башлаганчы ук күңелгә шундый уй-фикерләр килгән иде. «Шигырь китапханәсе» сериясендә чыккан бу җыентык иң әүвәл үзенең пөхтә төзелеше, эзлеклелеге белән аерылып тора. Бу китап — Р. Фәйзуллинның 20 еллык иҗат юлы, бу китап — шагыйрьнең үз укучысы һәм халкы алдында биргән хисабы.

Равил Фәйзуллинның 15 яшьлек чагында язылган шигырьләрендә ук инде ил язмышы, җир язмышы турында кайгырту кебек иң олы хисләр ярала башлаган икән. Ә берничә елдан соң ул үткән афәтләрнең мәгънәсен һәм мәгънәсезлеген аңларга тырышып, фронтовик авызыннан мондый сүзләр әйттерә:

> **Әле иртә,**
> **әле караңгы,**
> **әле буран шыңшый, тынмаган...**
> **Бер сыңар кул ялгыз урам көри,**
> **таң атканын көтеп тормаган.**
>
> **«Улым торып мәктәбенә китәр,**
> **капка төбе булсын көрәлгән...»**
> **Җил үйнаклый.**
> **Нидер әйтмәк булып,**
> **көнбатышка буш җиң төбәлгән.**

«Кошлар юлы» җыентыгына кергән шигырьләрнең шактый өлеше беренче тапкыр басыла. Билгеле, шагыйрь аларны күләм өчен генә алмаган, ул үз иҗат биографиясен эзлекле төстә күрсәтергә теләгән. Әлеге шигырьләр арасында Фәйзуллинның «алтын фондына» керерлекләре булган кебек, арада Равилнең шәхси архивын гына бизәрлекләре дә юк түгел.

Гомумән, Равил Фәйзуллин иҗатын ике өлешкә бүлеп карарга була: беренчесе — көйле шигырьләр, икенчесе «ирекле» дип аталган көйсез шигырьләр. Шагыйрь, әйтерсең, юри, мин сезнең шикелле шома гына, көйле генә дә яза беләм, дип ымсындыра кода тагын үзенең колак өйрәнмәгән җырын җырларга тотына. Әйтерсең, ул башта лакка да җанга да якын җырына нәртеп бара-бара да сиздермичә генә үзенең күңел карурманына кертеп адаштыра. Син инде телисеңме-теләмисеңме, шул карурман сукмакларын табарга, шунда үзеңә җан азыгы юлларга, сусыныңны басарга — кыскачы, шул карурман тормышы белән яши башларга мәҗбүр буласың. Әлеге сүз чытырманлыклары арасында адашып йөри-йөри күңелең һәм җаның талкынып беткәч, «Аккошлар», «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга...», «Башны салларга сакып...», «Дошман сигез, без — тугыз...» дип аталган якты шигъри аланнарга килеп чыгасың да тагын сөенеп бетә алмыйсың...

Әйе, Р. Фәйзуллин иҗаты тоташ бәйрәм түгел. Күп вакытта аның тавышына кушылып җырлап та булмый, көен таба алмый тилмерәсең. Ләкин тора-бара без аның җайсыз көенә дә ияләшә барабыз. 60 нчы еллар башында «табышмак» дип мөһер сугылган шигырьләр дә хәзер инде ул кадәр башваткыч булып тоелмый.

Р. Фәйзуллин иҗатының көче дә, көчсезлеге дә — аның үз принципларына тугрылыклы булып, һәрвакыт үз йөзен, үз сүзен саклап килүендә. Әлеге яхшы мәгънәсендәге иҗат үҗәтлеге аның балачактан башланган, табышларын көннән-көн ишәйтә барса, шул ук үҗәтлек үзе артыннан калдырмыйча «дегет чиләкләрен» дә ияртеп йөри. Равил Фәйзуллин, инде алда әйткәнемчә, бер темага, бер әйбергә каныкса, аның төбенә төшмичә, аның үзәгенә үтмичә туктамый. Аның шагыйрьлек һөнәре, иҗат газаплары, дус-дошман, җан-күңел-бәгырь-йөрәк кебек үзе яраткан шигъри даирәләре бар. Шагыйрь алар турында әйләнеп кайта-кайта, кат-кат яза, шул язганнарының барысын да диярлек дөньяга чыгара. Бу нәрсә миңа театрга барырга җыенган көяз хатын-кызның көзге алдында дистәләгән күлмәк сайлап изаланганын хәтерләтә. Ләкин көяз хатын да, нәтиҗәдә, бер күлмәк кенә киеп бара бит. Ә шагыйрь үзенең кайсы «күлмәге» үзенә иң нык килешкәнен яхшы белергә халык алдына, иң матурын үзегез сайлагыз дип, кырык кат киенеп чыгарга тиеш түгел. Бу урында сүземне йомгаклап шуны әйтәм: җыентык төзегәндә үз иҗатына таләпчәнрәк (әйтергә кирәк, хәтта — рәхимсезрәк) килеп, бер ноктага бәрә торган шигырьләрнең иң үткерләрен генә калдырганда «Кошлар юлы»нда аккошлар белән янәшә әрсез чыпчыклар да күренмәс иде. Моны, бәлки, санның сыйфатка әйләнүенә исәп тотып, күләм артыннан куу белән аңлатырга кирәктер. Ләкин бу мәгълүм теория ике яклы бит: сан арткан саен, сыйфат яхшы якка гына түгел, кире якка да үзгәрергә мөмкин.

Шагыйрьгә бәя биргәндә аның иҗат җимешләрен үз күңел тәлинкәңә салып үлчәү, аның уй-хисләрен үзеңнеке белән янәшә куеп чагыштыру, аның күңел көен үз күңелеңә күчереп карау гына җитми икән. Ренат Харис шигырьләрен укыганда ул булып уйларга, ул булып фикер йөртергә, ул булып көйләргә, аның хисләре белән хисләнергә тырыштым. «Замана эзләре» дип аталган шигъри йортта үткәргән бер көнемне мин Ренат Харис булып яшәп карадым. Бу эксперимент тора-бара миңа шулкадәр ошап китте ки, мин әле тагын берничә көн рольдән чыга алмыйча интектем: гади генә сүзләргә дә катлы-катлы мәгънәләр өеп аныңча сөйләштем, сүз сөрешендә көтелмәгән борылышлар ясап, кешеләрне гаҗәпкә калдырдым, көн саен аяк астында уралып йөргән гадәти әйберләрдән ил-җир язмышына бәйле фәлсәфәләр сыгып чыгардым... Җәрьәт итеп кабыгына кереп карасаң, Ренат Харис булып фикер йөртү, Ренат Харис булып ярату, Ренат Харис булып нәфрәтләнү — кыскасы, Ренат Харис булып бу дөньяда яшәү шактый ук кызык икән.

Р. Харис иҗаты полемик характерда. Ул һәрчак кем беләндер килешми, дөнья белән, җиһан белән, тиран белән, мещан белән, хәтта үз-үзе белән бертуктаусыз бәхәсләшә. Ренат Харис — катлаулы шәхес, аның күңел багажы бай, аның күңеленә төрле традицияләр, алымнар, сурәтләр, принциплар, юлалар, әдәбиятлар, халыклар, илләр сыйган. Менә шул гаҗәеп бай чималны шигырь итеп эшкәртеп чыгару өчен табигый талант өстенә бик күп көч һәм осталык та кирәк. Миңа калса Ренат Харис үзен зуррак жанрларда, бигрәк тә поэма жанрында, иркенрәк хис итә. Узган елны дөнья күргән «Җәлилчеләр» поэмасында ул үзенең зур фикерләр әйтә алырга сәләтле киң диапозонлы шагыйрь икәнен тагын бер тапкыр раслады.

Шагыйрьнең иң зур максаты кеше ышандырырлык, кеше инандырырлык итеп сөйләү үзе артыннан кешеләргә иярә алу, кеше күңелендә бөреләнгән уй-фикергә өстәмә импульс биреп, аны куәтләп җибәрү булса кирәк. Бу яктан караганда, Ренат Харис белән гади укучы арасында беркадәр дистанция сакланып килә бирә. Соңгы елларда халык арасында популярлашып киткән җырлары бу аралыкны киметә төшсә дә, кайбер шигырьләрендәге салкын акыл бозын эретү өчен, Ренат Хариска әле шактый йөрәк утын сарыф итү кирәк булачак.

Телдәге саксызлыклар, сүзнең дистәләгән төсмерләренә игътибар итмичә, бер төсмерен генә күздә тотып сөйләшү, сүз агышында очраган чатаклыклар — боларын инде Ренат Харисның иҗат йөзе дип түгел, ә, Тукайча әйтсәк, «ялан кул эше» дип кенә карарга кирәктер.

Без шагыйрьне:

Күзләремә туры кара...
Сау бул... Киттем... Күзең буйлап
Ят бер егет үтеп бара,

— дип бары тик үзенчә һәм шул ук вакытта безнеңчә дә әйтелгән юллары, Әнвәр Давыдов истәлегенә язылган «Кәбисә» атлы тетрәндергеч шигырьләре, халкыбыз каһарманнарына багышланган поэмалары, һәр авыл өенә үтеп кергән җырлары буенча рәссам шагыйрь, философ шагыйрь буларак беләбез, аның киләчәк үсешен шул тарафта күрәбез...

Хуш инде, яшьлек, хуш инде,
Күчәсең бүтәннәргә.
Миңа калды юл читендә
Сүгенеп ютәлләргә.

Гайрәтле заманнар үтте,
Син миннән киңәш сора.
Кызларың үзеңә булсын,
Акыллы картлык юра.

Гамил Афзалның «Урләрдә имәннәр шаулый» җыентыгыннан алынган бу юлларга шагыйрь үзе ук җавап та бирә. Гомере буе асылда юморист, сатирик шагыйрь булып, намуссызларга намус табышып, имансызларга иман иңдереп сорыкортларның тешләренә кереп йөдәткән кычыткан телле Гамил Афзалга, чыннан да, төпле акыл утырган, лабаса. Җитдирәк тонга күчеп әйтсәк, шагыйрь тәнкыйть итеп үстергән кешеләре белән үзе дә үзгәргән. Әйтерсең, ул «минем геройларым әлек кем иде дә менә хәзер кем булды» дип, алар турында хөрмәт һәм ихтирам белән зурдан кубып сөйли.

Җыентыкка кергән шигырьләрнең күбесенә моңсу юмор белән сугарылган җитди уйланулар тормыш мәгънәсенә, яшәеш мәгънәсенә төшенергә омтылу хас. Туры сүзле булуы, халыкчанлыгы нечкә юмордан алып — кәчле сатирага, гаҗәеп лирик шигырьләрдән алып — лозунг итеп парламентлар түбәсенә эләрлек киң диапазонлы шигырьләре белән Гамил Афзал үзенең Тукай варисларыннан икәнен искә төшереп тора.

Ак тастымаллар җилферди, сабантуйда атлар,
Ак моң булып җанда йөри Тукай туган яклар,

— дип яза ул «Тукайны сагыну» шигырендә. Тукай турында инде күп язылды һәм моннан соң да язылыр. Әмма Сибгат Хәким иҗатындагы, Илдар Юзеевның шигъри трагедиясендәге һәм Гамил Афзал шигырьләрендәге Тукай башка әдипләр хыялындагы Тукайдан аерылып тора. Бу өч шагыйрь Тукайны әдәбиятыбыз үткәненнән, халкыбыз тарихыннан гына эзләмиләр, алар Тукайны киләчәктән, алдагы көнебездән эзләп табалар, аңа халкыбызның мәңгелек символы, киләчәк юлындагы маягы итеп карыйлар. Алар өчен Тукай татар реалистик әдәбиятына юл ярган бөек шагыйрь генә түгел, ә үзләреннән күп алда — гасыр башында ук — мәңгелек юлга чыккан һәм шуңа күрә бик еракка алга — киләчәккә киткән бөек мөсафир. Әле һаман Тукай бишмәтеннән мәдрәсә кандаласы эзләп изаланучы кайбер каләмдәшләребез өчен бу иҗат үрнәкләре бик гыйбрәтле өлге була алыр иде!..

Гамил Афзал, башкаларга таләпчән булу белән бергә, үз-үзенә дә объектив бәя бирү, хәтта ки күп очракларда артык тыйнакланып китү сыйфатларыннан да мәхрүм түгел.

Йолдызлар янган төнемдә
Энҗеләр җыйганым бар.
Арыслан ята күңелдә,
Кулымда куяным бар,

— ди ул бер шигырендә. Кулындагы куянның шактый ук батыр һәм йөгерек куян икәнен белгән хәлдә, без укучылар, күңелдәге арсланның дөньяга чыгуыннан да өмет өзмибез, тик ул арслан күңел читлегенә озак ятып зоопарк баһадир сыман үшәнләнеп бетмәсен иде дигән теләктә генә калабыз.

Рәшит Гәрәйне татар шигъриятендә беркем белән бутап булмый. Юк, мин һич тә аны башкалардан аерып алып, ачыш ясагандай, күккә күтәреп чөяргә җыенмыйм. Ләкин Р. Гәрәйнең бөтен кан тамырлары, бөтен нервлары белән җиргә береккән, шул җир өчен җанын бирергә әзер торган фидакарь шагыйрь икәнен, бүгенге авыл кешесенең җанын аңлаган шагыйрь икәнен әйтми дә булдыра алмыйм. Шулай ук аның кимчелекләрен дә күрәм: гел җиргә карап, тирә-юньдәге зур дөнья белән бәйләнешын югалтып куйгалавын вакыт-вакыт гел уҗымнар турында җырлап, шул тирәдә генә әйләнүен дә күрәм. Шагыйрьнең яңа шигъри ачышларын очратып тагын сөенәм.

**Йолдызларга карап уйга калдым:**
**Ничек якты алар бу чаклы!**
**Бар диеп тә алар белмиләрдер**
**Мин сукмакка яккан учакны.**

**Иртән тагын чыбык өстәп киттем —**
**Күңел тели озак көйрәвен...**
**Учагымнан әлек сүнәр булсаң,**
**Тибүеңнән тукта, йөрәгем!**

Бу юлларны инде үз борынынан ары җир күрмәгән кеше яза алмый, бу инде — гражданин шагыйрь, иҗат эшенә үтә җаваплы караган шагыйрь йөрәгеннән өзелеп төшкән сүзләр.

Рафаил Төхфәтуллин Әдип Маликовның «Туган як җиле» китабына язган кереш сүзендә аны «кырыс моңлы шагыйрь» дип атый. Моның шулай булуы бик табигый да. Чөнки Ә. Маликов шигырь һәм поэмаларында үз башыннан кичкәннәрне, үзенең катлаулы биографиясен яза. Ә аның биографиясе — автомат түтәсенә куеп, ерактагы туганнарга һәм сөйгән ярларга хатлар язган, шигырьләр язган кырыс чор биографиясе белән аерылгысыз. Ә. Маликов шигъриятькә халык иҗатыннан, халык җырларыннан килә. Халык иҗатының мең еллар буе чарланып килгән калыпларына ул бүгенге мәгънәне, бүгенге уйларны, Әлмәтнең вышкалы офыкларын, Ерак Көнчыгышның өмет төсле түгәрәк күкләрен кертеп утырта. Әйтерсең, ул халык уеп биргән кечкенә һәм тыйнак тәрәзәсеннән олы дөньяга, моңсу гына көлемсерәп карап тора.

**Атлыйм баскан эзләреннән,**
**Җырлары арасыннан.**
**Сикерепләр төшәр сыман**
**Күзләрем карасыннан.**

Ә. Маликовның бу шигыре дөньядан иртә киткән шагыйрәбез Саҗидә Сөләймановага багышланган икәнне белгәч, йөрәк ирексездән сулкылдап куя.

Үзе исән чакта ук Саҗидә Сөләйманова талантлы шагыйрә, халык кабул иткән шагыйрә булып танылган иде. Ул соңгы елларда көчле бер йодрык булып укмашып килгән шагыйрәләребез иҗатының баш бармагы булды, дисәк, шәт каршы килүче табылмастыр. «Сабыр канатлары» исемле күләмле җыентыгы белән танышып чыккач, мөлаем йөзле шагыйрәбезнең күңеленә күпме вулканнар сыйганын, тел очында күпме тылсымлы сүзләр торганын, аның гомере буена ут-ялкын эчендә борчылып һәм янып яшәвен аңлап, таң каласың. Юк, ул башкаладагы кайбер «модный» шагыйрәләр кебек ирдәүкәләнеп, үзенең базарын да төшермичә хатын-кыз булам дип, авыз читен яулык очы белән каплап, пышылдап та сөйләшми. Ул үз-үзенә ныклы ышаныч белән һәм үз биеклегеннән торып дөньяга аваз сала, иҗатка көн күрү һөнәре итеп түгел, җан авазы итеп, намус эше итеп карый. Йокысыз төннәр һәм михнәтле иҗат газаплары кичеп дөньяга килгән шигырьләренә ул үзенең бар йөрәк җылысын, күңел яктысын сала.

**Ачылмаган кара чәчәкләрем —**
**әй төннәрем минем, төннәрем!**
**Сагынып искә алыр кемнәрегез,**
**хуш исе юк йомык гөлләрнең.**

**Мин үзем дә әле төсмерләмим,**
**кемгә ачылыр, кемне сихерләр...**
**Төннәремнең бигеи ачып чыга**
**таң нурыннан тамган шигырьләр.**

Таң нурыннан тамган шигырьләр калдырып киткән оптимист рухлы шагыйрәбезне сагынып, киләчәктә без әле аның иҗатына һаман саен ешрак әйләнеп кайтырбыз, дип уйлыйм.

Клара Булатованың «Гел кояшка карап» җыентыгына, нигездә, инде моңа кадәр дөнья күргән һәм бәя алган таныш шигырьләр кергән. Шагыйрәнең чәчәнлек рухы белән сугарылган җиңел телле, йөгерек көйле иҗаты үз кыйммәтен югалтмаган. Китап үзенең пәхтәлеге, иң интим хисләрне дә яшермичә ачык күңел белән сөйләве ягыннан яшь кызларның истәлек дәфтәрен дә хәтерләтеп куя. Шуңа күрә анда К. Булатованың эчкерсез моң тулы шигырьләре дә, чыннан да истәлек дәфтәрләрендә генә калырга тиешле куплетлары да очрый.

**«Зәй» кырлары быел коры калмас,**
**Кар мул ятса — уңыш буласы.**
**Шундый уйлар белән йөрисең син —**
**Зур колхозның тырыш хуҗасы.**

Мондый юллар шагыйрәнең үзенә дә, китап редакторына да мактаныч була алмый.

Флера Гыйззәтуллина, тегүче буларак, шигърияткә энә белән кое казыгандай, озак һәм авыр килде. Әдәбиятка дөбер-шатыр чабып кереп, күзенә ак-кара күренмичә шундый ук тизлек белән чабып чыгып та киткән кайбер каләмдәшләребезгә караганда, җирдәге һәр калкулыкны җан тире түгеп яулаган, үз уңышларының кадерен белгән шагыйрьләрне мин өстенрәк саныйм. Ф. Гыйззәтуллина шигырьләре — хис һәм уйлардан еллар буе үрелгән пәхтә челтәр кебек.

**Кеше чагыштыра иң вак әйберләрне**
**Энә күзе белән.**
**Мин — тегүче...**
**Энә күзе аша**
**Бар дөньяны күрәм.**

Дөньяга һәркем үз каланчасыннан карый, аңа тегүче энәсе күзеннән карау да бик мәгъкуль. Әмма хатын-кызның тавык чүпләп бетерә алмаслык көндәлек вак мәшакатьләренең һәммәсеннән шигъри фәлсәфә чыгарырга омтылу Ф. Гыйззәтуллинаның «Сәлам хаты» җыентыгында да сизелә. Бүгенге дөньяның бар ямен зурлау һәм кеше күңелендәге җөйләрне җөйләү өчен аңа әле, үзенең «шахтер атлары» белән бергә җигелеп, поэзия йөген шактый тартырга туры киләчәк.

Сибгат ага Хәким кайчандыр: «Әдәбиятка кызлар күп килә, әмма калучылар сирәк», — дигән иде. Менә шул калучылар исемлегенә керергә дәгъва белдергән яшь шагыйрә Нурия Измайлованың узган ел «Яшь шагыйрьнең беренче китабы» сериясендә «Яратам» исемле җыентыгы басылып чыкты. Исеменнән үк күренгәнчә шагыйрә дөньяга, кешеләргә гаҗәпләнеп һәм сокланып карый, язмышның гел кояштан гына тормаганын белгән хәлдә кешенең төп максаты бәхеткә омтылу, бәхеткә ирешү икәнен яхшы аңлый.

**Дәртем таша. Юлга чыгам.**
**Озын торна — хыялым.**
**Аккош булып йөзәр әле**
**Бер күлендә дөньяның!**

Бу юлларда инде шагыйрәнең нык кулы, профессиональ кулы сизелә. Аның шигырьләре күбесенчә якты буяуларга, нарасый хисләргә бай булса да, шигырь артында торган шагыйрәнең шактый ук катлаулы шәхес икәне, дөнья базарындагы товарны сатулашмый-нитми генә күз йомып ала торган беркатлы җан түгеллеге сизелеп тора. Н. Измайлова әле күбрәк үзе турында яза, дөньяга үз «мин»е аша карый, шуңа күрә

шактый шигырьләре күз яшьле хисләрдән, интим тойгылардан мөлдерәмә тулып тора. Ләкин ул баскан урынында бер сүзне кабатлап тик тормый, бертуктаусыз эзләнә, яза. «Эндәшмәүчеләр турында» дигән шигырендә ул:

**Үз сүзен әйтмәгән кеше**
**Ул беркем дә түгел әле,**

— ди. Һәм без яшь шагыйрәнең киләчәктә дә үз сүзен әйтүенә, тагын да кыюрак һәм үтемлерәк итеп әйтүенә ышанабыз.

Узган ел дөнья күргән шигырь җыентыкларының күбесенә моңа кадәр шагыйрь үткән иҗат һәм тормыш юлына йомгак ясап уйлану, үзенең шигъриятгә һәм җәмгыятьтә тоткан урынын ачыкларга омтылу хас. Бу нәрсә өлкәннәрне генә түгел, әле әдәбият мәйданына яңа нык басып килгән шагыйрьләрне дә читләп үтмәгән. Шамил Маннаповның «Кайту» җыентыгындагы шигырьләренең төп лейтмотивы — үткән юлга борылып карап, эшләнгән эшләргә бәя бирү булса, аның шулай юлда туктап уйлануларын киләчәк иҗат өчен мая туплау чоры, киләчәккә ориентир ачыклау чоры дип карарга кирәк. Шагыйрьнең авазы көннән-көн көррәк яңгырый, күңел күзләре үткерләнә, фикри мәгънәсе саллырак була бара.

**Килер беркөн картлык,**
**Барысын да өлгералмам татып.**
**Калырмыйдыр тик берсендә генә:**
**Җилдә генә,**
**Яки силдә генә.**
**Күктә генә,**
**Яки Җирдә генә.**
**Кайсында да ярый,**
**Булсын бары**
**Туган илдә генә,**
**Туган илдә генә.**

Ватанга, Туган илгә мәхәббәт кебек хисләрне шулай җанга ятарлык итеп әйтеп бирә алган Ш. Маннаповның көн кадагына бәләкәй чүкеч белән суккан шигырьләрен укыгач, бераз аптырабрак та каласың. Аш — ашка, урыны башка, дигәндәй, газета өчен ниндидер вакыйгага уңае белән язылган кайбер шигырьләрен монда кертмәгән булса, җыентык, күләм ягына зыян китереп булса да, сыйфат ягыннан откан гына булыр иде.

Чаллы шагыйрьләренең узган ел басылган җыентыклары турында сүз башлаганчы, кирәкле сүзләр таба алмый шактый иза чигәргә туры килде. Мактасам, үзенеке — үзәктә, дип әйтерләр кебек тоелды, йөгереп кенә узып китсәм, хакыйкатькә һәм үземнең иманыма хыянәт итәрмен сыман иде. Ә чынлыкта Кадыйр Сибгатуллинның «Авазлар», Хәниф Хөснуллинның «Алтын тояк», Ямаш Игәнәйнең «Сәфәр чыгам» җыентыкларының нигезен бүгенге поэзиябез йөзен кызартмаслык, күпмедер дәрәҗәдә аның киләчәген күзалларлык шигырьләр тәшкил итә.

Шагыйрьләр провинциядә туа, башкалада үлә, диләр. Бу сүзләрдә беркадәр хаклык бар кебек. Казанның мемориаль такта куярга урын калмаган стеналарында үзенә урын сайлап каңгырып йөрүгә караганда, илнең-җирнең үзәгенә әйләнгән, ил-җир язмышы хәл ителә торган урыннарда яшәү һәм иҗат итү, шул бөек үзгәрешләрнең уртасында кайнаган кешеләрнең күңелен көйләү, аларга рухи азык, җан азыгы табышу күпкә мәртәбәлерәк эштер. Бер яктан, андый җирләрдә әдәби сүзнең кирәклеге һәм бәһасе бермә-бер артык булса, икенчедән, гигант эшләр эшләнгән төбәктә шагыйрьнең хис һәм фикер масштаблары да киңәя.

Бездә шагыйрьләргә авылныкы яисә шәһәрнеке дип ярлык тагу гадәткә кереп бара. Кадыйр Сибгатуллинны да моңа кадәр авыл буразналарын, арыш шауларын җырлаучы — аманәте һәм үз гаме булган шагыйрь дип атап йөртәләр иде.

**Иске Чаллы бетми.**
**Ул үзгәрә.**

Искесеннән үсә яңа Чаллы.
Елмая таш безнең куллар тигәч,
таш та аңлый безнең уйны, җанны.
Җимерүче итеп белми дөнья,
таный безне тик төзүче итеп.
Игенчеләр идек, терлекчеләр,
ташчылар да булып үсеп җиттек.

К. Сибгатуллинның шигърият кыры буйлап ярып килгән буразнасы менә шулай, бара-бара Чаллының киң проспектларына кереп тоташты. Ул элеккеге дәрт һәм илһам белән яңа шәһәр урамнары буйлап җырлап үтте, һәм, әйтергә кирәк, үзен авыл җырчысы гына дип түгел, ә катлаулы заманның үзәгендә кайнаучы, шул заман уйларын җырлаучы шагыйрь итеп танытты. Юк, К. Сибгатуллин иҗатына тематик яктан гына килеп карау һич тә дөрес булмас иде. Аның: «Үткән гомер биктә, капкаларга типмә»,— дип, теләсә кайсы төбәктә яшәүче теләсә кайсы һөнәр ияләре ятлап алырлык фәлсәфи гыйбарәләре дә өч-дүрт җөмлә белән сурәт-образ ясап куя торган, рәссамнарга хас шигырьләре дә бар. Ләкин безнең өчен иң куанычлысы — ул заман җилләренә йөз куеп, заман авазына колак салып яши һәм иҗат итә.

Яңа Чаллы көн дә яңа җырын
көйләп тора,
үйнап,
җырлап тора.
Басу аны башак шавы белән
заводларга илтеп тоташтыра.

К. Сибгатуллинның соңгы еллардагы иҗаты да, нәкъ шул башак шавы кебек, үткән белән бүгенне, авыл белән шәһәрне тоташтыра, Чаллы биеклегеннән үрелеп, киләчәккә карый.

Ф. Гыйззәтуллина дөньяны энә күзе аша күзәтсә, Хәниф Хөснуллин аны теодолит күзләре белән манзара кыла.

Теодолиттан карый еракка ул,
Юнәлешне эзли турыга.
Безгә кирәк, кешеләргә кирәк
Геодезистлар кебек булырга.
Бас та үзең җирнең бер читенә,
Күңел күзең аша кара син:
Уртадамы, әллә кырыйдамы
Бу тормышта атлап барасың!

Хәниф Хөснуллин Чаллы төбәгендә туып үскән, шунда каләм чарлаган шагыйрь. Шуңа күрә дә ул бу якларга читтән килгән кайбер кешеләр кебек аһ-ваһ итеп шаккатып кына карамый, үз ягының, шул як кешеләренең язмышы турында борчылып кайгыртып һәм горурланып яза.

Сабыр холыклы, һәр сүзен үлчәп, тамызып кына сөйләшә торган тыенкы хисле Ямаш Игәнәйнең беренче җыентыгы чыгу белән үк матбугатта аның турында төпле генә берничә мәкалә басылды. Әйе, Я. Игәнәй — сүзнең кадерен, тәмен, исен, төсен сизә торган, хисләрдә чама белә торган шагыйрь. Ул үз йөрәгенең иң нечкә кылларына кагылган нәрсәләр турында гына яза, борчылып, янып, тетрәнеп яза. Аның сигез юллык бер шигырен генә мисал итеп китерик.

Балачак. Кыш. Сугыш. Тәрәзәне
Бодай башаклары кумә иде.
Шул башаклар арасында йөргән
Әти күз алдына килә иде.

Сугыш бетте. Әти кайталмады.
Кырда күптән шаулап бодай үсә,
Тәрәзәгә генә бизәк булып
Бомбалар һәм ракеталар төшә.

Соң чиккәчә тыгыз эшләнгән бу шигырьгә Я. Игәнәйнең үз язмышы да, ил язмышы да, сугыш китергән афәтләр дә сыйган.

Вакыт-вакыт артык тыйнакланып китеп, Я. Игәнәй авыз тутырып бар куәткә кычкырасы урында ишетелер-ишетелмәс пышылдауга күчә, авылдан килеп, беренче тапкыр шәһәр театрына эләккән агай кебек, югалып кала. Сергей Михалков үзенең бер шигырьшында: «Скромность — кратчайший путь к неизвестности»,— дигән иде. Бу сүзләр турыдан-туры Я. Игәнәйгә атап әйтелгән кебек.

Рөстәм Мингалимовның үткән ел басылган «Ике авыл арасы» дигән әсәренә «поэма» дип язып куелмаган булса да, ул идея һәм фикер йөге ягыннан шул жанрга туры килә. Шагыйрь бу әсәрендә дә зур тема һәм проблемаларга теше үтүен, аларны уңышлы чишә алуын исбат иткән, бүгенге дөньяның бар кайгы-борчуын, сөенеч-шатлыгын бер авыл карты җилкәсенә салып, аның җаны аша үткәреп күрсәткән.

Марс Шабаевның аксакаллар тавышы иңә башлаган мәгънәле уйланулары, Кави Латыйпның «Тел өчен» дигән фәлсәфи тукымалы шигыре, Фәнис Яруллинның тормыш матурлыгына, кеше батырлыгына, мәхәббәт сафлыгына дан җырлаган оптимистик мәдхияләре, Нури Арслановның бар яктан камил, төгәл эшләнгән традицион шигырь үрнәкләре, Гәрәй Рәхимнең бәләкәй генә әйберләрдән зур гомумиләштерү ясаган, бөҗәк белән җир шарын янәшә куеп сөйләштергән әсәрләре узган ел поэзиясенең никадәр күп кырлы һәм бай икәнен күрсәтеп, аны бизәп торалар.

Иҗатында борылыш чорын, яңарыш чорын кичерүче Рәдиф Гатауллинның «Иезуитләр» һәм «Бабич» дип аталган озын шигырьләрен дә укучылар үзенчәлекле эзләнү, яңа кыйммәтләр, ачышлар табарга теләү юлындагы бер баскыч буларак кабул итәрләр дип уйлыйм.

Бүгенге шигърияттә Роберт Миңнуллин һәм Марсель Галиев исемнәре дә башкалар арасында аерылып тора. Аларның беренчесе халык җырларына тартым йөгерек стиль белән үтә җитди фикерләрне дә җылы юморга төреп бирә белсә, һәм шуның белән укучыны да, тамашачыны да үз авызына каратып тора алса, икенчесе исә, яшерен бер вакарь белән, үз бәясен бик тә яхшы аңлап акварель буяулар белән фәлсәфи үзәкле рәсем-шигырьләр ясый.

1981 елда яшь буын шагыйрьләр иҗаты да байтак кына үсеш кичерде. Рафикъ Юнысов, Газинур Моратов, Ркаил Зәйдуллин исемнәренең көн үткән саен колакка ятышрак була баруы, иҗат йөзләре ачыклана килүе әнә шул турыда сөйли. Яшь шагыйрьләр үтә образлы язалар, аларның шигырьләре сабантуй сөлгесе кебек чуар, сабантуй сөлгесе төсле җете ачык төсләргә бай, аларның шигырьләре сабантуй сөлгесе сыман һәрчак бик югары эленгән була. Арада дөнья гаме сеңгән шигырьләр белән бергә ил-җир язмышын бер селтәнүдә хәл итәргә кыҗрап тотынганнары, үзеңне җир йөзендә кылынган һәр нәрсәгә: искән җилгә дә, тузган тузанга да, яуган кар-яңгырга да җаваплы итеп тоярга тырышкан әсәрләр дә шактый еш очрый. Яшь шагыйрьләр үткән тарих белән артык мавыгып, бүгенгене һәм киләчәкне дә онытып җибәргәлиләр. Әйтерсең, киләчәкнең ачы җиленә җилкә куеп, үткәнгә йөз белән борылалар да, артка караган килеш алга таба баралар. Тарих турында язу бүгенгене җырлауга караганда җиңелрәк, чөнки үткән вакыйгаларга инде анык бәя куелган, алар инде тарихи факт буларак та укучыда кызыксыну уяталар. Ә бүгенгене аңлау, бүгенге дөнья матавыкларыннан сөземтә чыгару шактый катлаулы нәрсә. Тарих ул иярләнгән ат булса, бүгенге көн — чабып барган кыргый юртак, аның сыртына бары кыюлар — куш йөрәкләр генә менә ала.

1981 елда басылган шигъри әсәрләрнең бер өлешен без менә тиз-тиз генә булса да авыз итеп чыктык. Арада телгә һәм җангa ятышлыларын, куңелне кузгатырдайларын да күрдек, шулай ук тамактан үтмәстәйләрен, теш сындырырлыкларын да очраттык. Монысы әле авыз итеп карау, разведка ясау гына булды. Ул шигъри продукция арасында халык үзенең күңел сандыгына салып куярдайлары, үз исеменнән сөйләтердәйләре, үзе белән мәңгелеккә алып китәрдәйләре, һичшиксез, бар. Бу инде бүгенге поэзиябезнең ил гаме белән, ил язмышы белән яшәүче чын халыктан поэзия икәнен, чын шагыйрьләргә бай поэзия икәнен тагын бер тапкыр раслый.

Салих Маннапов

# ДӘВАМ

**БАБАМ СӨЙЛӘГӘННӘРДӘН (ул ике бөтендөнья сугышында катнашкан, немец илбасарга каршы алты ел көрәшкән):**

**...Герман җиренә кергәч, сугыш бетәрәк, ниндидер эч пошу басты. Балаларны сагынуга чик-чама калмады. Күзне йомдисәм, төшкә керәләр... Күңелем тулып, немец малайларын башларыннан сыйпый идем...**

...Ул сугышның яшеннәре ялтыраганда, безнең буынның әле дөньяга киләсе бар иде. Безне аның күкрәүләре куып җитте. Сугышның әле дә калган авырлыгын без әниләребез иңендә күтәрештек, сугышның сүнеп өлгермәгән утын әтиләребез күкрәге белән каплаштык. Хәзер дөньяга алар хәтере аша, алар бүләк иткән күңел күзләре белән карарга өйрәнәбез. Үз бурычыбызны аңларга теләп, барасы юлларыбызны тәгаенләргә дип. Шуңа күрә кайчагында үзгәрәк фикерлибез, үзгәрәк бәя бирәбез икән,— Сезгә каршы килү булып аңлашылмасын, өлкәннәр. Ул — яшьлектән, тормыш асылын төшенеп бетмәүдән дә түгелдер. Ул — Сезнең фикер-хөкем йөртүнең дәвамы, яңа буынныдыр, мөгаен.

**ХӘТЕРГӘ КЕРЕП КАЛГАН: «Сугыш кешелекнең күкрәге аша узган пуля шикеллерәк. Ярá эзен үзе үк көйдереп, аруландырып калдыра...»**

...Фронтовиклар ашыга-ашыга бер-берсен эзли, таба. Сугышчан дуслар очраша. Әтиләре васыятен үтәп, аларның уллары килә. Хәзер илебездәге һәр өч кешенең икесе — сугышны китаплардан гына укып белгән буын вәкиле. Сугыш яшененең соңыитынрак килеп киткән күкрәүләре сыман — бүгенге әдәбиятны яңа сыйфатлар белән баетучы «хәрби» әсәрләр... Аларның авторлары арасында 45 нче елдан соң туганнар күбәя бара. Сугыш темасы бер үк вакытта заман темасы да булып кала...

Шулай да әлегә ул әсәрләрнең күпчелеген үзләре ут эченнән чыккан ирләр иҗа. Алар бүген дә сугыштагы кеше турында күзгә карап сөйләшүне дәвам итәләр, шул чорның гадәти һәм тетрәндергеч тормыш йомгакларын сүтәләр. Бу хакта күпме генә язылса да, үз сүзләрен әйтә алуларына ышаналар. Чөнки әлеге әсәрләрнең нигезендә — сугышны үз язмышың, тормышыңның аерылмас кисәге итеп тою. Бер сүз белән әйткәндә — шәхси кичерешләр. Шәхси кичерешләр аша сугыш дөреслеген аңлау юнәлешендә янә бер биеклек яулана. Монда башкаларны кабатларга мөмкин түгел: һәркемнең үз язмышыннан сугыш үзенчә узган. Монда кабатланырга да мөмкин түгел: һәркемнең гомере бер генә.

Менә шуңа күрә дә, әйтик, Хисам Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә» романы утыз елдан соң шартлаган минаны хәтерләтсә дә, автор, соңармадым микән дип шикләнми. Ул сугышны бары тик «үзенчә» генә тасвирларга тырышмый. Шаккаттыргыч вакыйгаларга, тарих китабына кергән исемнәргә таянмый, көтелмәгән сурәт чаралары белән мавыкмый. Унсигез яшендә күргәнен ул бүген аяз һәм борчулы күк астында күз алдыннан кичерә. Дәһшәтле чынбарлыкны —

кешеләрнең үз-үзен тотышын, вакыйгалар сурәтен мөмкин кадәр конкрет-төгәл иcкә төшерергә омтыла. Аның өчен тормыш һәм әдәбият дәреслеге әнә шунда. Шуңа күрә Хисам Камалов һәр детальнең үзәгенә үтеп сурәтли, һәр күренешне тәфсилле. Кайчакта шул траншеяларда адашып калырсың кебек... Ләкин, элемтәче Әнвәр сузган телефон җебе буйлап баргандай, бер деталь икенчесенә килеп ялгана, бер герой язмышы башкаларныкы белән үрелә башлый. Ул — зур Җиңүгә өлеш керткән сугышчыларның берсе икән; аның, үзгәлекләреннән бигрәк, типик, уртак сыйфатлары истә кала, меңнәр белән берләштергән язмышы калкып чыга. Бу геройлар, бу бәрелешләр, бәлки, олы сугыш стратегиясе күзлегеннән караганда, зур игътибарга да лаек түгелдер. Әмма алар халык батырлыгы Бөек Ватан сугышының катлаулы чынбарлыгыннан аерылгысыз дип дәлиллиләр, совет кешесенең авыр сынаулардан җиңеп чыгуы турында безнең белгәннәребезне тулыландыралар, сугыш дәреслегенең тагын бер үзенчәлекле ягын ачалар.

Әйе, сугыш турындагы әдәбиятның үзәгендә — дөнья борчулары һәм өметләре белән яшәүче герой. Һәр гамәле, һәр йөрәк тибеше ил язмышы, халык киләчәге белән бәйле кеше образы. Бу персонажларның очраклы гына, ярдәмче генә дип саналганы да гади һәм очраклы түгел.

Без сугыш дигән зур дөнья, сугыш дигән гаять катлаулы образ белән еш кына очрашабыз. Сугыш һәм аерым бер кеше драмасын, теләк һәм мәҗбүрилек нисбәтен бөтен тирәнлеге белән аңлау, аңлату искиткеч авыр. Бу бурычны үтәү өчен безнең язучылар, бөтен ил әдәбиятындагы кебек үк, тынгысыз эзләнүләр юлыннан китәләр, олы проблема нигезенә тоташкан иң мөһим детонатор җебен эзлиләр. Сугыш чынбарлыгы аша кеше табигатен, халык язмышын аңларга омтылалар. Алар өчен барыннан да мөһиме замандашларыбызны рухи һәм әхлакый мәсьәләләр турында уйлануга җәлеп итү, һәр әсәр белән шушы юнәлештә бер генә адым булса да алга таба атларга омтылу. Сугыш темасына язылган әсәрләрнең иҗтимагый-фәлсәфи колачы, заманчалыгы менә шундадыр. Аларга күчкән тормышның катлаулы драмасын, идея-әхлак юнәлешен тарихи җирлектән аерып кабул итү мөмкин түгел. Анда чорның бөтен вакыйгалары, бөтен буыннары кисешә, аларның бәйләнешы ачылып китә.

Әлеге әсәрләрнең иң уңышлы дигәннәре кырыс тарихи концепциягә таяна — сугыш чорының кешелекле таләпчәнлеге турындагы хакыйкатьне яклап килә. Икенче яктан, алар фаҗигале һәм шанлы үткәннән безнең көчебез, киләчәккә ышанычыбыз нинди нигезгә корылган дигән сорауга җавап эзли, бүгенге көнне безнең дәверләр чылбырындагы урыныбн, әһәмиятен тоярга булыша.

...Сугыш үзенең гадәтенчә, бу юлы да бик вакытсыз башлана. Ул зәһәр теллé Васфикамалларга кадәр: «Яши белмәдек, тормышның кадерен белмәдек»,— дип әйттерә, аларны ирләренең сөялле учларына сыенып өзгәләнерлек итә. Тыныч көннәр бик тә кадерле булып кала. Һәм сугыш беткәч тә, «бомба шартлап түгел, сандугачлар сайрап уяткан» таңда да: «Сугыш кичмәгән булсаң, шушы матурлыкны күрә белер идең микән?» — дип уйландыра Мөхәммәт Мәһдиев үзенең героен. Әле аңа кадәр озын-озак елларга сузылган көрәш һәм авыр эш көннәре бар, җиңүне якынайтасы бар. Солдат — Константин Симонов әйтмешли, иң авыр вакытта, иң авыр урынга һәм иң авыр хезмәткә куелган кеше. Атҗабар Хисмәте дә моны яхшы аңлый, авырлыктан курыкмый, әмма алдагы сугышның нәрсә икәнен күңеле белән сизә: «Фашист дигән эт чылбырдан ычкынган. Ә ул — бик хәтәр эт... Без кая барганыбызны беләбез. Безгә кайтулар булмас инде. Әйе, кайтулар — едвали...» Бу сүзләрдә — котылгысыз фаҗигане тою, аның якынлашып, изәргә ашкынып килүен күрү. Шул ук вакытта — җиңүгә, тыныч киләчәккә тирән ышаныч: «Бәхил булыгыз. Тату яшәгез».

Үлем тырнагыннан үлемсезлеккә атлаган Муса Җәлил күз алдына килә. Аның, мәсәлән, «Сугыштан соң» дигән шигыре. «Май аенда тагын җыйналырбыз... Кайберәүләр булмас бу табында... Без шәрабтан түгел, ә шатлыктан җырлашырбыз, бәлки...» Киләчәккә өмет белән карау сугыш сиратыннан горурлыкны һәм намусны югалтмыйча чыгарлык көч биргән. Әмма үлем туеның бик күп ямьсезлекләрен һәм әшәкелекләрен күргән солдат ничек итеп кешелек сыйфатларын җуймый кала алган? Ничек итеп газраил хезмәтчесенә әверелмәгән? Әдә-

бият бу сорауга тормышчан характерлар һәм ситуацияләр аша чынбарлыкның үзеннән җавап эзли.

«Кеше китә — җыры кала» (Мөхәммәт Мәһдиев) һәм «Һәркемнең гомере бер генә» (Хисам Камалов) әсәрләре тормышның әнә шундый логикасына тугрылыклы. Аларда сугыш һәркемнең өенә, тормышына шәхси проблема булып керә. Ул, теләсә нинди авыр сынау астында калгандагы кебек, кешенең бөтен рухи көчләрен эшкә җигә, күңел төпкелендә яткан иң яшерен хәзинәләрен яктыга чыгара. Канлы көрәш һәм тормыш кырыслыгыннан, дошманга нәфрәттән тупаслана башлаган җан җылыга, яхшылыкка тартыла. Үлем ачысын тоеп яткан Айкилдиевның әле дә булса мәхәббәт утына үрелүе, комбат Алексей Баранов белән Фира арасындагы мөнәсәбәт әнә шундый. Окоп читендәге чәчәк кебек табигый, гүзәл һәм фаҗигале.

Сугышның кырыс холкына буйсынмаучы мондый геройлар һәр әсәрдә бар. Ләкин һәр очракта алар үзенчә ачыла.

Габдрахман Әпсәләмовның җете романтик төсләргә бай булган «Алтын йолдыз», «Газинур» романнарында мәсәлән, аларның рухи көче укучыны да тау елгасы кебек бөтереп алып китә. Хисам Камалов хикәяләвендә укучының игътибары Константин Симоновчарак — күбрәк сугыш күренешләренә юнәлтелә, кискен, хәлиткеч мизгелдә төрле характерлар, йөзләр чагылып үтә, кешенең фаҗигасе һәм рухи ныклыгы ачыла. Биредә бөтенләй капма-каршы диярлек — тыныч, эшлекле тон өстенлек итә, җәелебрәк, ашыкмыйчарак акканлыктан, вакыт-вакыт ярлар абайланмый башлый, бөтен агыш тукталып калгандай тоела, характер үсешен, геройларның рухи үсешен абайлау кыенлаша. Ләкин шушы сабырлык, басынкылык белән язучы сугыш хәлләренең драматик катлаулылыгын, тирәнлеген искәртергә тели төсле.

Миргазиян Юнысның «Биектә калу» әсәрендә вакыйгалар шулай ук ташкын булып акмый, геройлары бик уйчан һәм җитди. Повестьның эчке агымы, гомумән, укучыны иярткүдән битәр, бөтен юнәлеше белән аңа таба борылган кебек. өерелеп-өерелеп килүче авыр дулкыннарга каршы ишеп барырга мәҗбүрсең. Әмма бу — ялыктыра торган каршылык, ясалма катлауландыру түгел. Тормыш сөземтәсенең бик тирән катламнардан саркып чыгуын тояр өчен, чын фаҗиганең һәм чын бәхетнең янә бер чыганагын аңлый башлар өчен кирәк ул каршылык.

Геройларның хәрәкәт активлыгын сурәтләү дә һәр язучы өчен үз иҗат һәм тормыш принциплары белән бәйләнгән. Х. Камалов, мәсәлән, геройның үлеме дә һәрвакыт батырлык булырга, ниндидер файда китереп калдырырга тиеш дигән схемага буйсынмый. Алексей Баранов снаряд кыйпылчыгыннан һәлак була. Бөтен фронт буенча соңгы һәм хәлиткеч һөҗүмнәргә күтәрелгән вакытта. Сугыш бетәргә дә озак калмаганда. Очраклы үлем бигрәк тә үкенечле. Ләкин ул көчле характерның тормыш бәясен очсызландырмый, ә яшәү мәгънәсе турындагы сорауны тагын да катлауландыра, киеренкеләндерә.

Уйлап карасаң, Сәйрин Сәләховның да һәлакәте шактый очраклы. «Нибары» парашюты гына ачылмый... Шулай да М. Юныс героенда романтик канатлар, баллада чалымнары бар, батырлык аның бөтен тормышына бәһа булып аңлашыла. Бу яктан «Биектә калу» безнең «сугыш прозасы»н үстерүгә күп хезмәт куйган Г. Әпсәләмов әсәрләренә тартымрак. Шул ук вакытта ул — гыйнак, гадәти батырлык, кешенең күңелендә ясалган батырлык турында баллада. Героиканы җиргә якынайтып сурәтләргә омтылуы бу әсәрне Х. Камалов романы белән якынайта. Миргазиян Юныс җирне нык тою аша күкнең баш әйләнгеч биеклегенә сокландыра алган. Ул «түшәме» биек әсәр язган. Сәйрин Сәләхов тормышындагы иң киеренке мәлләрнең берсеннән башланган бу повесть азакка кадәр шул югары нотада кала.

...Сугышның соңгы көннәре якынлаша, җирдә яз тантана итә. Безнең геройларны нинди генә уйлар биләми! Алар инде сугыш турында гына уйлый алмыйлар. Татар егетен каклаган каз һәм аерыласы килмәгәнгә үбешеп калган кыз сагындыра, якут егетенең күз алдында боланнар йөгерешә...

Геройның үткәненә кайту һәм аның сугышчан батырлыгын бала чактан ук куркусыз, намуслы, шук яисә юаш булып үсүеннән күрү...— шактый сыналган һәм бигрәк тә документаль прозада очсызлана төшкән алым, әлбәттә. М. Юныс та үз юлының бер өлешен шундый әзер эздәнрәк үтәргә мәҗбүр. Тик биредә беркатлы нәтиҗәләр ясалмый, багланышлар гадиләштерелми.

Шундый катлаулы багланышларның бер канаты — әсәрдәге тыл күренешләре. Аларны ничектер зур тыл төшенчәсе белән берләштерү ихтыяҗы да тумаган. Аерым сугышчыларның — Сәйриннең, Максимның, Марсель Ялчинскийның рухи «тыл»лары күз алдына килә. Сугыш чынбарлыгы белән йөзгә-йөз калган шәхесләрнең көче, аларның тарих һәм ил язмышы алдында үз бурычларын аңлаулары һәм ахыргача үтәүләре шушы тыл белән бәйләнгән.

Якут халкы вәкиле Майнагашев сугыш кырына тамыры-туфрагы белән күчеп утырган төсле.

Көньяк егете Марсельнең юанычы — әнисен искә төшерү һәм музыка. Әнисе һәм музыка Марсельне бүтән кешеләр күңелендәге моңны да тирәннән аңларлык итеп үстергән. Шуңа күрәдерме, аның милләте дә аерып кына әйтелми бугай...

Сәйриннең дә сабырлыгы, сафлыгы, гаделлеге — эти-әнисеннән. Егетнең тылында тагын бер пакь күңелле изге җан бар: Сәйринем кайткач, коймак пешерермен, дип, үзе ач яшәсә дә, он саклап торучы Разия... Чын мәгънәсендә халыкның зур фәлсәфи һәм көнкүреш тәҗрибәсенә таянган көчле характерлар!

Яшәешнең тирән катламнарына үтеп керү ягыннан бу повесть Әмирхан Еникинең «Без дә солдатлар идек» дигән әсәре белән аваздаш. Ул уртаклык тышкы билгеләрдә үк күренә. Очучы егеткә әнисеннән килгән хат. Авыз гармуныннан сызылып чыккан татар моңы... Һәм Төхфәт абзыйга карчыгы юллаган күптин-күп сәламнәр. «Фашисттан тере калган җыр» дип авылына алып кайтырга исәпләгән көй... Ничек әле ул?

> Агач башкайлары тәсбих әйтә
> Әкрен генә искән җил белән;
> Сәвешеп-сәвешеп тә кауша алмаган
> Бер без генә түгел, ил белән...

Тормышының иң авыр көннәрендә, күңеленең иң тирән кизләвеннән тибеп чыга малай чагында ук әтисеннән ишеткән ул җыр.

Төхфәт абзыйның улы булырдай Сәйринне бүтән бер көй әсәртә. Басып торган җире кебек чал, оча торган күге кебек иркен-киң сулышлы «Гөлҗамал». «Шәмдәлләрдә генә утлар яна...» Халыкның тынычлыкка омтылуы турында сөйлидер бу җыр. Аны күп сугыш, күп михнәт күргән, күп сагыш кичергән татар кызлары чыгаргандыр, дип уйлана егет.

Безнең халыкта хәрби маршлар юк. Комсызлыктан туган сугышны ул гомербакый онытылмаслык итеп, тарих теле белән каһәрләгән.

> Корабларда килгән чакта ашамадым ашларын;
> Шул Николай патша гына сатты безнең башларны...

Әйе, үз тарихында сугышны күп күргән халкыбыз. Югалтулары күп. Түгелгәне — туфракта. Хәтта «Иосыф кыйссасы»н язган шагыйрьне дә ил намусын яклаучы яу башы итеп сурәтлиләр икән — без моңа ышанабыз. Чөнки әдәбият, гомумән, халыкның кайнар йөрәк тибешеннән яралган. Халык нинди генә югалтулар кичермәсен, йөрәген һичкайчан илбасар итегенә олтан итәргә юл куймаган. Тигәнгә тигенен калдырмаган. Яуда шәһит булган алыпларын да онытмаган. Зур иҗтимагый вакыйгаларда катнашу аның фикерләү рәвешенә яңа төсмерләр керткән. Ул изге көрәштә уртак Ватан байрагының җиңүен данлаган:

> Наполеонның эшләпәсе канга тапланган иде,
> Без сугыштан кайткан чакта илләр шатланган иде.

Менә ул — ил дигәндә яу булу, азатлык намына гомереңне дә кызганмаска әзер тору. Ватандарлык тойгысын бер тын беләң белдерү. Без бүген, яңа заман әсәрләрендә дә шул аһәңне ишетәбез, шул күркәм традицияләрнең лаеклы дәвам ителүен, аныклана һәм тулылана баруын күрәбез.

Сугыш турындагы әдәбиятыбызның иң төп кыйммәте, мөгаен, илаһи пакьлек, тугрылык һәм миһербанлылык идеясен гәүдәләндерүдәдер. Газинурлар, Сәйриннәрнең гөнаһсыз яшьлеген, үлемсез уй-хыялларын, өзелеп калган җырларын ул Рифкать Миргазизовлар буынына мирас итеп тапшыра. «Әхлакый идеализм»га алар туган җир моңы аша тоташкан («Бу тавыш, бу моң бары тик Симетбашта гына. Мондый тавышлы, мондый трельле бакалар Германиядә юк. Австриядә юк. Сайрагыз, авылдашлар, сайрагыз!» — М. Мәһдиев.) Ул аларга әниләр сөте белән кергән («Карт анам... Синең күңелеңә мин бары тик якты булып кына кайталам» — И. Юзеев). Гомерләре исемсез биеклекләр түбәсендә өзелеп калса да, бер уч көлгә әверелеп билгесез киңлекләргә сибелсә дә — ил бәхете өчен кан койган ир-егетләрнең бөек рухы үзләрен көтеп торучы хатын-кыз күңеленә кайта: ана, хатын, бер үбешми дә калган кыз бала күңеленә.

...Сәйрин Сәләховның әнисе сугыш беткән көнне карчыклар җыя. Улының һәлакәте турында әле хәбәр алынмаган. Аның исән калу шәрәфенә карчыклар җиренә җиткереп дога кылалар. Ананың күңелен күрик дип, егетнең дә «базарын күтәрәләр», күңел салган кызын да өзми-куймый мактыйлар. Ул ашка килүчеләрнең мәҗлес әдәбе, табын һәм гәп кору рәвеше, ул мөнаҗәт әйтешүләре! Бу — халыкның күңел догасы, гади сүзләр белән аңлатып булмый торган җаны, мәңгелек Моңы. Аны бары тик тоярга һәм, бәлки, Миргазиян Юныс язганча аңларга гына мөмкиндер. Тетрәндергеч финал. Сокландыргыч финал. Иҗатның «терек суы» белән җан иңдергәч тә биектә калган геройлар...

Фронт чынбарлыгы якты төсләрдән генә тормаган. Иңгә төшкән авыр йөк тә, билгеле, үзәкләре нык булмаганнарны тиз сафтан чыгаргандыр. Ә бит аларның да җиңүгә ниндидер өлеше кергән. Бөек эшләрне фәрештәдәй кешеләр генә эшләгән дип ышану — инде узылган дәвер. Сугыш авазы еракләшкан саен, аңа аек мөнәсәбәт тә артканнан арта һәм дошманны тар-мар итү өчен нинди зур көч кирәклеге турында әдәбият та кыюрак һәм ачыграк сөйли бара. Бик вакытлы сөйли. Чын шаһитлар кими барганда... Әле алар исән чакта...

Юк, дәһшәтле көннең кара төсләренә дә күз йоммый әдәбият. Шулар арасында бигрәк тә — сугыш вакытының, типик булмаса да, фаҗигале корбаннарына — төрле дәрәҗәдәге хыянәтчеләргә. Шулай, хыянәтне дә онытырга ярамый!

**ГАЛИЯ АПА СӨЙЛӘГӘННӘРДӘН** (укытучы, «икенче фронт» — тыл фронты ветераны): **...Гомер булмастай хәл: авылга дезертир кайтканлыгы беленде. Озакламый тагын бер хәбәр таралды: хыянәтченең хатыны йөкле икән! Ул тикшерүчеләргә: «Мари көтүчесе алдады»,— дип әйтергә мәҗбүр булган... Күрүчеләр булса да, дезертирның эзенә төшүе җиңел түгел иде. Аны бөтен халык эзләрекләде: иң хәтәр ерткычны тоткан кебек, мылтыклар, арканнар белән ауладылар... Бер ташландык өйнең идән астына оялаган булып чыкты. Кайтып-китеп йөрергә түш белән шуышып үтәрлек кенә «күсе юлы» казыган, нәгъләт. Бу өй калку җирдә, олы юлга якын булганлыктан, юеш нигезгә үрмәләп, авылны күзәтергә бик җайлы. Ә түш белән шуыша торган юлы идән астыннан... бәдрәф астына килеп чыккан. Хыянәтчене якты дөнья белән тоташтыручы бердәнбер ишек бәдрәф авызы булган...**

Яу кырын ташлап качкан бәндәгә әдәбиятта яшәү бирү никадәр авыр булмасын, аның да бит караңгы күңел төпкелендә үз табышмагы ята. «Җан көеге»н язганда Мирсәй Әмир дә нәкъ менә шундый уйлар кичергәндер. Ул, чынлап та, героеның җир бакасыдай салкын, шөкәтсез җанына кагылырга җирәнебрәк торган төсле; дезертирның рухи халәте күбрәк хатыны һәм әнисе драмасында ачыла. Икенче бер язучы — Валентин Распутин да үзенең шундыйрак язмышка дучар героена хатыны аша бәя бирә. Бу тикмәгә түгел... «Гомер буе исеңдә тот» («Живи и помни») әсәрендәге Андрей Гуськовның түбәнлеккә тәгәрәве Камәретдиннекеннән күпкә катлаулырак, каршылыклырак, әлбәттә. Әмма аларның

икесе дә ил каршындагы бурыч дигән нәрсәне җан саклау теләге һәм курку тойгысы белән кысрыклап чыгарган. Якын кешеләренең коточкыч ялгышуын күргән гөнаһсыз хатыннарга ни хәл итәргә?! Яшәү мәгънәсен һәм намус төшенчәсен алар башкача аңлый алмыйлар. Шуңа күрә аларның тавышы аеруча үзәк өзгеч. Ул — куркаклыкны, хыянәтне кире кагу, янә бер кат вөҗдан утында яну һәм сафланып чыгу.

Гадәттән тыш хәл дисәк тә, хыянәтнең төрле рәвешләре булган кебек, төрле сылтаулары да табылган. Нәби Дәүлинең «Җимерелгән бастион»дагы лагерь полицайларын, белорус язучысы Алесь Адамовичның «Җәзачылар»ын хәтерлисездер. Фашистка ялланган адәм актыклары да үз җинаятьләрен ничектер аклыйлар, аңлаталар бит.

Хыянәт трагедиясе әдәбиятта катлаулы әхлак проблемасы итеп карала, һәм бу — дөрес юл дигән тәэсир калдыра. Хисам Камалов, мәсәлән, әлеге мәсьәләләрне сугышка кадәрге тормыш мөнәсәбәтләре белән тыгыз бәйләнештә ала. Аның романындагы майор Мостафин кайчандыр үз йортына зур бәла-каза китергән берәүнең язмышын уңай якка хәл итә. Үч алмый. Уйлап карасаң, теге адәм әле икеләтә гаепле — гаделсезлекне чор исеменнән, власть исеменнән эшләп килгән. Күпләрнең ачуын, нәфрәтен уяткан. «Кимсеткән өчен гомер буе ачу саклый торган кеше булса? Шуны кайтарырга җай эзләп кенә йөрсә?.. Ә ачу иясе булмаса, сукыр ачу булса? Ачу бит яшен кебек, бушанырга җай, сугар нәрсә эзли... «Яшен» иң якын ноктага суга! Сугышта шундый нокта — Ватан...» Язучы, әнә шул рәвешле каршылыклар эченә чумырып, үз геройларының характерындагы, үз-үзен тотышындагы эчке механизмны табарга омтыла, аларның күңел төпкелен яктыртып җибәрергә җай эзли.

Сугыш иң гади инстинктларны көчәйтә, шуңа нисбәттән иң гади әхлакый кагыйдәләр искә төшә. «Ут чәчәге»ндәге Габделнурның үз-үзен тотышын нәкъ менә шул инстинктлар билгели. Табигать биргән курку тойгысы анда ил язмышы өчен җаваплылык хисеннән эстен булып чыга.

Мөхәммәт Мәһдиевтә андый «ике төпле» геройлар күп түгел, була калса да, ул аларны «әкрен-әкрен китерә көйгә». Габделнурның, «Евгений Онегин»ны тәрҗемә итеп, мәхәббәт хатлары язуын искә төшерик. Язучы шул чакларда ук, үз итеп кенә, егетнең «чөен төшереп» куя. Ләкин, белгәнебезчә, бу — шактый каршылыклы характер. Яу кырын һәм яралы иптәшен ташлап китсә дә, аны турыдан-туры фаш итү җиңел түгел. Язучы ихтыяры белән Габделнур үзен-үзе каһәрләргә дучар ителә. Иң әүвәл сугыштан «телен онытып» кайта. Бу шактый таныш күренешнең мәгънәсе көтелмәгән яктан ачыла: туган телдән, туган илдән аерылу фалы булып! Ана телендә эндәшмәкче булса, куркак җанның теле тартышыр күк. Ниһаять, мәгънәсез тормышның бердәнбер мәгънәле финалы: көчле яңгыр астында калган Габделнурга — инде онытылыр кебек тоелган — сугыш авазы дәһшәтле күк күкрәүләре булып кайта. Адәм баласының эчке һәм тышкы конфликтлары бергә кушыла — «күк йөзе соң тапкыр зыңгылдап, аның баш мие аркылы җир белән тоташа». Бу ни булды соң әле? Ул бит инде шундый ук гарасатта бер тапкыр җанын саклап калган иде! Намус әзәрлекләвеннән кача-кача, теленнән, туфрагыннан язды. Ләкин бөек күк астында качып калыр төш юк икән...

Фронтовик шагыйрь Михаил Луконинның «... Буш күңел белән кайтканчы, буш җиң белән — яхшырак» дигән юллары искә төшә.

Югалтулар ачысын үсмер иңнәрендә күтәргән, тормышка мөнәсәбәтен ул авыр көннәрдән саф көе алып чыккан буын шагыйре шул шигырьнең дәвамын яза кебек:

> Дөнья тыныч түгел,
> Юк, ярамый,
> Җебеп калып күзне йомарга.
> Буш җиңнәргә карап тешең кыс та,
> Исән кулларыңны йомарла.
>
> (Шәүкәт Галиев).

Шигъри аваздашлык кына түгел бу,— тарихтан бүгенге көнгә сузылган кү-

пер, сугыш кичкән солдатның гамәленә һәм рухына яңа заман, яңа буыннар бәясе. Габделнурлар, Андрей Гуськовларга сугыштан да авыррак әнә шул сират күперен кичәргә туры килә...

Әдәбият тарихы шаһит: «сугыш әсәрләре» өчен төп үзәк — Ватан каршындагы бурыч темасы,— Бөек Җиңүгә юл кыскара барган саен, тагын да ачыклана, конкретлаша төшә. Бүгенге әсәрләрдә ул катлаулы чорның катлаулы шәхесләрен аңларга омтылу, фашизмны җиңүнең иҗтимагый-тарихи һәм әхлакый тамырларын ачу юнәлешендә дәвам итә.

Ә сораулар... Алар һәр заманда бер төрлерәк яңгыраган. Сугыш кемгә кирәк? Ни өчен кешеләр кан коеша? Адәм баласы ничек яшәргә тиеш? Әдәбиятның катлаулы үсеш юлыннан, бөтен кешелек дөньясы тарихыннан сузылып килгән сораулар. Бөек Толстой исеменнән дә тарих шул сорауларны кабатлаган. Һәр чорның аларга үз җавабы бар.

Егерменче гасырның иң зур сугышында катнашып һәлак булган Сәйрин Сәләхов: «Сугышны комсызлык тудыра»,— дип саный. «Яшәү белән үлем арасында» йөргән язучы бу сугышта фашизмның коммунизм белән кылычка-кылыч килүен исбатлый. Россиягә каршы сугыш ачар алдыннан Гитлер үзе дә генералларына: «Бу — ике идеология сугышы булачак. Җир йөзеннән юк итү сугышы булачак»,— дип белдергән...

Сугыш белән бәйле вакыйгалар һәм язмышлар хәзерге әдәбиятта еш кына, рамга куелган иске рәсемнәр кебек, тыныч тормыш күренешләре белән уратып алынган. Ул әсәрләрнең геройларын беренче чиратта бүгенге дөнья проблемалары борчый. Җавап эзләп, алар кабат ут эченә керәләр — кордашларының әхлакый максимализмын, рух сафлыгын һәм бөеклеген сагыналар. Көлгә әйләнүе мөмкин булмаган хәзинәне!

«Мин сугышны күралмыйм, әмма бүген миңа сугыш вакытында очраган кешеләр җитми. Барысын да сагынам — яманын да, яхшысын да... Күп еллар үтте, тик мин шуннан бирле ул кешеләрдән дә яхшыракларны очрата алмавымны тойдым».— Ю. Бондаревның «Яр» романындагы Вадим Никитин төп югалтуларын әнә шулай, соңлабрак аңлый. Кешеләрне генә түгел, сугыш елларындагы саф-таза асылын да әкрен-әкрен җуя барган икән ул.

Лирик чигенешләр, искә төшкән эпизодлар рәвешендә сугыш авазының хәзерге чорны сурәтләүче әсәрләргә килеп керүе бик табигый. Ачыктан-ачык мондый күпер салынмаган очраклар исә (мәсәлән, «Һәркемнең гомере бер генә» һәм «Биектә калу» әсәрләре) икенче яктан кызыклы: безне ул көннәр белән тоташтыру ролен замандашыбыз — язучы үзе үти. Шулай итеп, сугышны үзләре кичергән кешеләр аның елъязмачыларына әверелделәр. Бүген язылган әсәрләр, тышкы формалары белән никадәр локаль, чикләнгән булмасын, аларда төрле чорлар бәйләнешы сиземләнә, сугыш чоры тудырган идеяләрнең Вакыт сынавын ничек үтүе чагыла.

Тормышка һәм әдәбиятка һәр буын үз язмышын алып килә. Сугыш турындагы әдәбиятның икенче дулкыны иҗат мәйданына «41 нче ел балалары» — Шамил Рәкыйповлар, Мөхәммәт Мәһдиевләрнең аяк басуы белән дә бәйле. Бу — Ватан сугышының халыкчан характерын, кешелекне яклаучы асылын яңа яклардан ачарга дип килгән буын. Каһарманнар язмышы аша. Тыл чынбарлыгы аша. Бу — гаҗәеп дулкын,— бер бездә генә түгел, бөтен ил әдәбиятында уртак күренеш. Аның эчке бердәмлеге, аваздашлыгы һәм шул ук вакытта образларда, язмышларда, интонацияләрдә кабатланмавы — нәкъ сугыш чоры әсәрләрендәге кебек. Чөнки әлеге уртаклыкның нигезе бер үк — илең турында уйлау, сугыш һәм тынычлык сулышын тоеп яшәү.

Гомумән, җитмешенче еллар әдәбиятында сугыш чорын үзенчәлекле тасвирлаган шактый әсәрләр иҗат ителде. Аларның үзенчәлеге — фронт һәм тыл тормышын ничек булганынча гына түгел, бүгенге позицияләребездән ничек күренгәненчә дә бәяләп язылуында. Аларның көче — гомумиләштерүләр зурлыгында.

Фани кичерешләр хөкемдары Вакыт, окоп эзләре җуела барган саен, сугыш турындагы әсәрләрнең тышкы төзелешеннән башлап төп рухына кадәр үтеп керә, аларның асылын билгеләүдә активлыгын арттыра. Геройлар яшәешенең үзен-

чәлекле әхлакый-фәлсәфи мәйданында — хәтер киңлегендә ул үзен аеруча кыю тота. Искә төшерә һәм оныттыра, ялгышларны төзәтә һәм яңа хаталарга сәбәп чыгара...

«Дошманның үз җирендә азау тешен җимерәбез. Ямьсез, күңелсез бу җир. Ят җир... Үзебезнең Идел буйлары белән дөньяның кай җирен чагыштырасың!» — Шушы ят туфракта, сугыш бетәргә санаулы көннәр калганда һәлак була Фатих Кәрим. Немецларны 37,8 биеклегеннән бәреп чыгаргач, аларның дулкын-дулкын булып килгән көчле һөҗүмнәрен бастырганда. Фашист биеклекне ала алмый, ул биеклектә татар шагыйре торып кала...

...Өстемдәге соры шинелем —
Авыр елда туган улы итеп
Биргән бүләге ул илемнең...

Юк, сугыш чоры поэзиясе турында кайберәүләр кебек: «Яралары ачык булса да, чын авыртуны сизми әле», дип әйтергә тел әйләнми. Чагыштырып карыйсың: бу — татар шигыренең җанлану чоры, яңа иҗат баскычына күтәрелү чоры. Шигырьдә хис чынлыгы, тормыш чынлыгы көчәя. Тыныч вакытта күңелдә бөреләнеп кенә килгән ниятләр яңа шартларда тирәнрәк, колачлырак төс ала. (Шул ук ашыгыч кына язылган хатларда никадәр зур иҗат теләкләре!) Сугыш күпләрнең йөзен, күзен ача, Әнвәр Давыдовлар, Хисам Камаловлар буынының бөтен язмышын билгели. Дөрес, бу буын прозаиклар зур әдәбиятка туплар тынгач кына килә. «Фронт миңа бик күп материал бирсә дә, иҗатымда төп сызыкны табарга булышса да, әдәби осталык биеклекләренә мендермәде, аларны бик авыр хезмәттә яулап аласы бар иде әле»,— дип аңлата моның сәбәпләрен Г. Әпсәләмов. Сугышка үпкәләп булмый. Әлеге буынга ул тормыш сабагын гомергә онытылмаслык итеп укыта. «Яра эзен үзе үк көйдереп, аруландырып калдыра...» Шуңа күрә, авыр сынаулар кичсә дә, сафлары нык сирәгәйсә дә, бу — «югалган буын» түгел,— изге көрәш утыннан, тыл сынауларыннан чыныгып, пакьләнеп чыккан буын. Ул үзенең яшәү рәвеше белән дә, әсәрләре белән дә сугыштан соңгы тормышка һәм әдәбиятка зур тәэсир ясый, яңадан-яңа буын яшьләрне ватандарлык рухында тәрбияли. Бу шәхесләр, бу әсәрләр үткән белән киләчәк арасында басканнар. Бөек Ватан сугышы турындагы әдәбият панорамасы да аларның иҗаты аша чагыла.

Нинди чор (сугыш алды, сугышның төрле дәверләре, сугыштан соңгы вакыт, җитмешенче еллар) ноктасыннан һәм нинди буын (сугышта катнашкан; тылда эшләгән яисә ул чакта үсмер бала булган; ниһаять, сугыштан соң туган яшьләр) исеменнән язылуына гына карасаң да, гаҗәп киң һәм төрле безнең ул темага иҗат ителгән әсәрләр. Тәнкыйтьче-галимнәребез хезмәтләрендә алар этрафлы итеп өйрәнелгән, бәяләнгән; чынбарлыкны дөрес чагылдыру буенча әдәбиятыбызның төп үсеш этаплары билгеләнгән.

Әдәби тәнкыйтьтә сугыш прозасының үсеш юлы әсәрләрнең иҗтимагый функцияләренә бәйләп өйрәнелә. Дан җырлау, анализлау һәм тәрбияләү вазифасы даими яшәп килсә дә, ди, мәсәлән, А. Бочаров, иҗтимагый фикер үсеше белән бәйле рәвештә авырлык үзәге берсеннән икенчесенә күчеп бара. Кайбер тәнкыйтьчеләр җитмешенче еллар прозасына бу өч функциянең бергә кушылуы хас диген карашта тора...

Сугыш чынбарлыгын сурәтләүдә реалистик төгәллекнең арта баруы, бу темага язылган әсәрләрнең аналитик һәм тәрбияви функцияләре көчәюе, әлбәттә, икесе дә бик мөһим һәм бер-берсенә бәйле казанышлар. Ләкин сугыш турындагы әдәбиятның тормышчанлыгы һәм тәэсир көче турында уйланганда, аның төп тенденцияләре, нигездә, кеше язмышын аңлау дәрәҗәсе белән билгеләнергә тиеш диген фикергә киләсең. Тормышыбыз катлаулана бара, кешеләр катлаулана бара. Әдәбият белән тормыш, әдәбият белән укучылар арасындагы мөнәсәбәтләр катлаулана. Сугыш турындагы әсәрләрнең сыйфат үзгәрешләре бүген әнә шундый багланышлар белән билгеләнә.

Сугыш турындагы әдәбиятка һәр буын үз язмышын алып килә. Хәтер җиле

аларның һәркайсына үзенчә кагыла. Ул, иске учак урыннарын туагытып, ямып бетмәгән күмерләрне көйрәтеп җибәрә. Расмый һәм кире кага. Кыска хәтерләргә бармак янап үтә.

Ветераннар сугыш эзләреннән йөри, ә сугыш аларның үзләрен эзәрлекләп килә. «Зинһар, сак булыгыз, иске, шартламый калган мина кырларында йөрисез!» — дип кисәтсәң дә, ишетмәсләр иде... «Китә, пенсиягә җитә алмыйча, бакчаларда гамьсез еллар өчен верандалы йортлар салмыйча...» (Әнвәр Давыдов). Сугыш әле дә йомылып бетмәгән яралар булып эзәрлекли — дөньялар тыныч булмаганда тәндәге иске ярчыклар кузгала. Сугыш әле дә төшләргә кереп интектерә. Мөхәммәт Мәһдиевнең Асафы да әнә, һәр иртәне йөгерү юлларына чыгып, саташулы төшләреннән дәвалана дәвалануын, әмма аңа карап хатирәләр авырлыгы кимеми — алардан йөгереп кенә китә алмыйсың шул. Әмирхан ага Еникиның исәлектән бер генә сәгатькә булса да котылу өчен хикәя язганын сөйләгәне бар... «Бер генә сәгатькә» дигән хикәясен.

Әйе, сугыш — аны кичергән буыннар өчен аерым бер хатирә, хәтта тормышның билгеле бер кисәге генә дә түгелдер: ул кеше гомеренең һәр күзәнәгенә таралгандыр кебек. Еллар үткән саен сугыш төсмерләре якыная, җителәнә генә бара. Сөйлиләр, язалар, дөньяга бәя бирәләр: бөтенесе шуңа нисбәтле. Космонавт һәлакәте дә разведкага киткән дус үлеменә тиңләнә (Ә. Давыдов)... КамАЗда да шагыйрь үз буынының ерак төсен эзли. «Ватан сугышы кешеләре»нә күбрәк өмет баглый, аларга күбрәк таяна. Сибгат Хәкимнең «Үрләр аша», «Дәверләр капкасы» поэмалары — халыкның изге сугыш вакытында ачылган асыл сыйфатларын барлап йөрү, алар нурының яңа буыннарга күчеп ышанану. Шуңа күрә шагыйрь заман яшьләрен үз итеп, фронтовикларча сәламли: «Яңа буын Теркиннарга сәлам!..»

Сугыш турындагы хәтер — безнең өчен рух һәм көнкүреш тәҗрибәсе, ул — бөек казанышларга яңа буыннарның хөрмәт күрсәтүе. Үлгәннәрнең түгел, онытылганнарның гына гомере кыска. Афәтле еллар хатирәсе безне күкләр аязлыгын, балалар елмаюын җитдирәк бәяләргә өйрәтә. Сугыш турындагы әсәрләрдә чынбарлыкның, кеше язмышының тирәнрәк чагыла баруы да — безнең тулырак, мәгънәлерәк итеп яшәргә өйрәнүебез билгесе ләбаса! Үз кадерен үзе белә торган халык көндәлек мәшәкатьләр кулагасена абынып китмый, үткәненә дә, киләчәгенә дә башын югары тотып карый. Менә шуңа күрә, эстафета торган саен яшьрәкләргә күчә барса да, Ватанны саклау кебек изге темага язылган әсәрләр ташкыны кимеми. Аның чишмәсе — халык хәтере: халыкның горурлык хисе һәм югалтулар әрнүе, бөек җиңүнең тыныч көннәрдәге лаеклы дәвамы. Аның төп юнәлеше, төп үзәне — заманның актуаль сорауларына җавап эзләү. Бу ташкынның бер ягы — сугыш һәм тыл ветераннары, икенче ягы — аларның уллары, оныклары. Сугыш турындагы әдәбиятка һәр буын үз язмышын алып килә.

АВЫЛДАН ЯЗГАННАР ИДЕ: «Бездә бер иналмык бар бит әле. Кырмавык Зәкиләрнең хәбәрсез югалган дип йөргән аталары табылмагае. Төш куйдырганда сакалы-мыегы җиткән килеш күргәннәр. Капка төпләрендәге бүрәнәгә кайтып утырган, имеш. Исән ул, кайтырга тиеш, дип юрыйлар...»

ЗӘКИУЛЛА АБЗЫЙНЫҢ УЛЫН КҮРДЕМ: «...Исән булуына ышанмыйбыз инде. Быел да менә Польшага барырга җыенам. Соңгы хаты шуннан килгән бабайның. Беләсең бит, чит илдә солдат зиратларыннан калә әйбер икенче күзгә күренми. Фамилияләп укыйм. Бабай каберен эзлим. Күп алар анда — безнең кара мәрмәр плиталәр...»

Безнең буын сугышның ни икәнен китаплардан гына укып белә дигән сүз дөрес түгел. Сугыш бүген дә һәйкәлләре һәм китаплары, ветераннары һәм толлары белән үзен искә төшереп тора. Без аның сулышын тоябыз.

Бүген сугыш безнең буынның төшләренә кереп сискәндерә. Игъми, Асафларның үзләре генә түгел, малайлары да үлем уены кайтавазларын тоеп яши. Киноданы, китаптан гына күчмидер, ияндидер күзәнәкләрдә саклапып киләдер, мөгаен, бу халәт?.. Сугыш ераклашкан саен, ул чор язмышлары, халык батырлыгы масштаблары күңел күзе белән ачыграк күренә төсле.

Иң әүвәл сугышны гаять катлаулы күренеш итеп тоярга кирәктер безнең

буынга. Әйтик, ут-кан эчендә дә, яшь-яшь сугышчы кызларның матур киенәсе, шаярасы, назланасы килмәгәнме? Ничек кенә әле! Аларның сөйләвендә, хатиреләрендә охшаш урыннар сизелә икән, ул да булса — авырлыкны ирләр белән тигез күтәргәндә дә күңелләре белән хатын-кыз икәнлекләрен онытмау. Тәмлекене шоколадка алыштырумы ул, яисә аяк чолгавыннан суырып алынган җепләрне манып, сөлге чигү белән мавыгумы...

Сугышның шундый күп төсмерле булуын аңлаган хәлдә, үзебезнең каһарманнарны, аларның һәркайсын — берсен дә калдырмый истә тоту кирәк. Гастеллоны белмәгән кеше юк — аның белән бергә үлемгә барган тагын өч сугышчы иничектер телгә кермәгән, онытылган. Яисә рейхстаг түбәсенә беренче булып Кызыл байрак кадаган Гази Заһитовлар батырлыгы... Җәлилчеләр... Өлкән буын каһарманнары — аларның балалары өчен дә герой. Аларга яшьләр иҗатында куелган һәйкәлләр дә шул хакта ачык сөйли.

Сугышта булмаган буынны утлы еллар сәхифәсен ачарга нәрсә мәҗбүр итә соң? Кайдан, нинди импульслар килә аларга? Халык тарихындагы катлаулы бәйләнешләрнең кайсы ягын ачарга омтыла ул әсәрләр?

Илдар Юзеевлар буыны өчен сугыш нужа камытын иртәрәк киюдән, өчпочмаклы солдат хатларыннан башлана: «Мин, ун яшьлек малай, капитан-артиллерист әтиемә шигырь белән хат язам...»

Разил Вәлиевләр буыны — «салкын сугыш» җилләре искән, ут-күз генә чыкмагае дип борчуга салган еллардан: «Мин — яшьтәше атом бомбасының...»

Сугыш хатирәсе менә шулай яңа буыннарга күчә. Илне яклап зур яуда катнашкан замандашлар безнең яшьләр әдәбиятына герой булып керә. Әхәт Гаффарны, мәсәлән, фронтта булган кешенең дөньяга җете күзләр белән карый алуы җәлеп итә. Аның соң дәрәҗәдә намуслы һәм гадел булуы. Язучы үзе дә өлкән буынны, аның кичерешләрен тасвирлауга җаваплылык белән килә. «Сугыштагы кеше»дән бигрәк «сугыш һәм кеше» турында яза. Гомер бәясенә торырлык бу рычларыбызны искә төшерә.

«Сугыш әдәбияты»ның бай хәзинәсе, зур психологик ачышлары яшь әдипләрне аеруча җитди булырга чакыра. Аның тирән агымында кителмәгән бусагалар аз түгел. Мәсәлән, яшьләр иҗатында, шулай ук кайбер документаль проза әсәрләрендә, еш кына обстановка тәгәллеге һәм тарихи чынлык белән геройларның китапчалыгы, психологик яктан чырайсызрак булуы каршылыкка керә. Ә. Гаффар да төгәл тасвирларга омтыла, геройларның үз тавышларын эзли. Аларны үзе теләгәнчә хәрәкәт иттерергә, үз ихтыярына буйсындырырга ярата. Метафоралы мәгънәсе белән күңелгә якын «Язмыш» исемле хикәя, мәсәлән, бер тын белән көйдереп алырдай. Ләкин «материал каршылыгы»н җиңел генә сындырып бару аны шактый суыткан. Тышкы эффект артык зураеп, язмыш кадәр язмышны абстракциягә әйләндерә башлаган, конкрет һәм зур мәгънәне томалый язган. Шунысы куанычлы: язучының сугыш һәм кеше драмасын ачкан соңгы әсәрләрендә декорация төгәллегеннән бигрәк эчке дәреслеккә омтылыш көчәя. Тормыш катламнарын тирәнрәк алган саен, «материал каршылыгын» җиңү кыенлаша аңа һәм ул үзе дә кызыклырак була бара.

Яшьләр иҗатында Бөек Ватан сугышына игътибар кешелеклелек, тынычлык өчен көрәш мәсьәләләре белән табигый үрелеп үсә. Рифкать Миргазизов турындагы повесте белән Разил Вәлиев бүгенге яшьләрдәге җаваплылык хисенең потенциаль мөмкинлекләрен сиздереп куйды. Фронтовик Асафлар буынының «Хәтер егетләр вакланды...» дигән сүзләренә җавап та, үз кордашларын тормыш мәгънәсе турында уйланырга чакыру да бар монда. «Яшисе килә!» — әсәрнең исеменә дә ук Абдулла Алишның соңгы хат-васыятеннән бер өчкын бар: «Без соңгы сулышыбызга кадәр халкыбызга тугрылыклы булып калабыз. Ах, нинди яшисе килә!»

Тамырлар тирән, бәйләнешләр тирән. Яшь әдипләр, эстафетаны үзләреннән алдарак килгән буыннан алып, үткән сугышның хис үзәген хатын-кыз, балалар күңеле аша ачуны дәвам итәләр. Хәтер көче аларда да үткәннән бигрәк килә-чәккә юнәлгән: «Әгәр дә Ватанга кирәксә — халкымнан калкачак мең Җәлил». Нәкъ сугыштан соңгы, сугыш вакытындагы, сугыш алды елларындагы кебек...

УЙЛАНДЫРГАН КҮРЕНЕШЛӘРДӘН: Кайсы гына чорга, кайсы гына халыкның тарихына барып чыксаң да, аңа яшәү көче бирүче чишмәләргә юлыгасың... Хазар-Каспий диңгезе буендагы Кыз каласы да шундый. Риваятьләр даны белән уралган шигъри кальга ул,— беркайчан да, бер яуга да бирелмәгән горур Кыз-кала. Нигезендә — кое. Тарихның үзе кебек тирән, үзе кебек карт: инде сигез гасыр буе агып ята икән. Калын диварлар, таш кыялар аша үтеп, саф чишмәләргә тоташкан. Суы әле дә чәйгә яраулы. Камалышта калган алышларга сихәт биргәндер, вакыты белән, бәлки, иң соңгы корал сыман да булгандыр ул...

«Фазыл чишмәләре», «Сагыну» көйләре, авыр көннәрдә халыкның таянычы булган җыру-мөнаҗәтләр күңелгә килде. Теле, тылы...

Герман җире яшел үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм...

Латвиядә, Саласпилс үлем лагере урынындагы амъ-яшел чирәм уртасында калгач, башлар әйләнеп китәрлек итеп кабат шул җыр искә төште. Яшел үлән — вакытсыз өзелгән йөз мең җан тирбәнеше, яшел үлән — сугыш авызына яшьли кергән җиде мең бала гомере. Аларның башларын сыйпагандай, сабый чәче кебек йомшак үләннәрне аралый-аралый, әкрен генә җил исә:

Туктале, җил, исмәле җил...
Кисмә гөлнең чәчәген...

Сугыш — кешелеккә каршы иң зур җинаять. Ләкин безнең ата-бабаларыбызга ул сабыйлар бишеген афәттән, кешелеклелекне ерткычлыктан саклау өчен көрәш булган. Менә шуңа күрә Асаф тыныч көннәрдә дә «кеше өчен көрәшеп кан түгә» — малаен яклап, үзен куркыныч астына куя. Менә шуңа күрә «кырык беренче ел балалары» үзләренең «сугыш вакыты урта мәктәбе» турында кайта-кайта сөйлиләр — бүгенге яшьләргә көн күрү, кеше халенә керү сабагы бирәләр.

Сугыш турындагы әдәбият — бик күп фаҗигаләрдән тезелгән дисбе. Ул тоташ авырту-әрнү тойгысыннан гына торадыр төсле. Авырту — кеше тәненең сәламәт тойгысы. Шул тойгыны югалтсак, без зарарланган төшебезне табып дәвалый алмас идек. Күп каны коелган кеше, әнә шулай, авыртуны тоймый башлый икән...

Сугыш турындагы әдәбият безнең кешелекле асылыбызны яклап, кара көчләргә каршы яуга күтәрелә.

Сугыш турындагы әдәбият — безнең авырту тойгыбыз. Ул безне «кан коелу»дан — зур рухи югалтулардан саклый.

# КАЗАН АЛАРНЫ МӘҢГЕ ОНЫТМАС

Рәис Сабиров

## ЗИРАТТА БУЛГАН ВАКЫЙГА

Апрель. Табигать кышкы йокысыннан уяна башлаган, агачларда бөреләр бүрткән чак. Крестьянның йөрәге, үзен туйдыручы җир-ана белән тиздән кавышачагын сизенеп, ашкынып тибә башлаган көннәр, кешеләрнең беренче сыерчыклар сайравын ишетеп, күңелләре нечкәргән ай. Ләкин 1861 елның апрелендә табигатьнең гомер-гомердән килгән бу гармониясе, күңелне җилкендерүчән шатлыгы җан тетрәткеч хәбәрдән тәкселәнгәндәй, бозылгандай булды. Казан губернасы Спас өязе Бездна авылында патша галиҗәнапләренең флигель-адъютанты граф Апраксин солдатлары бөтен төбәктән шушында җыелган крестьяннарга ут ачканнар. Йөзләрчә кеше корбан булган. Аларның бөтен «гаепләре» — патшаның бу тикле гаделсезлеккә баруына ышанмауда. Алар, бирдәге властьлар патша әмерен үтәргә, крестьяннарга җирне бушлай бирергә теләмиләрдер, дип уйлыйлар, шуңа күрә җир турындагы патша манифестының чынын, патша үзе кул куйганын күрсәтмиләрдер. Ниһаять, крестьяннар ата-бабаларының тире түгелгән җирне үзләренеке итеп күрергә телиләр...

Бездна вакыйгаларының бөтен Россиядә, бөтен җир шарында нинди куәтле кайтаваз булып яңгыравын, аларга Герценның Лондонда чыга торган «Колокол»ының нинди зур бәя бирүен без инде урта мәктәп дәреслекләреннән укып ук беләбез. Ләкин болар барысы да бераз соңгарак була. Казан губернасының, Казан шәһәренең үзендә, төрле катлам кешеләре бу вакыйгага ничегрәк караганнар? Төрлечә. Казан аристократиясе, губернаның төрле өязләрендә җир биләмәләре булган һәм «кара халыкның» аяк терәп җир даулавыннан куркып яшәгән дворян-алпавытлар өчен бу көн үзенә бер төрле бәйрәмгә әйләнгән. Бу вакыйгаларны үз күзләре белән күргән кешеләрнең сүзләренә караганда, Воскресенская (хәзерге Ленин) урамы бөтенләй танымаслык төскә кергән. Аннан губернатор сараена таба атлы колясскалар, сиртмәле арбалар, бизәнгән-ясанган байбикәләрен һәм байбәтчәләрен ияртеп җәяүле чиновниклар бертуктаусыз үтеп торган. Алар үз шатлыкларын губернатор белән уртаклашырга, патша галиҗәнапләренә карата тугрылыкларын белдерергә ашыкканнар.

Казанның демократик карашлы кешеләре, аерым алганда студентлар исә, бу вакыйгаларга бөтенләй башка бәя бирәләр. Безднадан килгән кайгылы хәбәр аларда тыелгысыз ачу һәм нәфрәт уяткан.

Үзенең революцион эшчәнлеген Казанда башлаган, соңрак РСДРПның икенче съездын оештыручылардан берсе булган А. М. Стопанинның истәлекләрендә мондый юллар бар: «Эшчеләр Казаны һәм интеллигентлар Казаны ул чакта бер-берсеннән нык аерылган... «2 нче Казан»ның тормыш үзәге — студентлар...» Бу сүзләр беркадәр соңгы чорга караса да, үткән гасырның алтмышынчы елларындагы хәлне шактый төгәл тасвирлый. Демократик карашларны алга сөрүчеләр, азатлык һәм социаль үсеш өчен көрәшүчеләр нәкъ менә студентлар булганнар.

---

Дәвамы. Башы 4, 9 саннарда.

Бездна авылындагы җан өшеткеч фаҗига турында хәбәр алынгач тә шундый хәл туган. Казан университеты һәм руханилар академиясе таяк тыгылган кырмыска оясыдай гөжли башлаган. Студентларның чиктән ашкан нәфрәте, бу юлы күңелләргә генә сыймыйча, икенче көнне үк бик әйбәт оештырылган һәм азатлык хәрәкәте тарихына «Куртина җеназасы» дип кереп калган политик төстәге демонстрация булып тышка бәреп чыккан.

Менә хәзер инде безгә бу вакыйгаларның төп герое һәм рухландыручысы Афанасий Прокопьевич Щапов белән танышырга кирәк.

«Кайгысыз-гамьсез яшәешнең» дошманы булган бу кеше Казанга 1852 елда егерме ике яшьлек егет чагында Иркутск губернасының Анга авылыннан руханилар академиясендә укыр өчен килә. Россиядәге дини уку йортларының шактый зурларыннан саналган бу академия Арча кырында, безнең көндә алтынчы шәһәр больницасы карамагына бирелгән бинага урнашкан була. 1856 елда академияне уңышлы тәмамлаганнан соң А. П. Щапов шунда ук укытучылык эшенә калдырыла. Ә 1860 елның көзендә Афанасий Прокопьевичны Казан университетының Россия тарихы кафедрасына җитәкчелек итәргә чакыралар. Һәртөрле дини догмаларның дошманы булган студент яшьләр «поплар арасыннан килгән» бу яңа профессорны бик сагаеп каршылый. Афанасий Прокопьевичның беренче лекциясен: «Мин Россия тарихы кафедрасына дәүләт турындагы фикерем белән, үзәкләштерелгән власть идеясе белән түгел, бәлки халыкчанлык һәм өлкәләргә мөстәкыйльлек бирү идеясе белән менәм»— дип башлый. Мондый урыннарда әлегә кадәр әйтелмәгән нәрсә түгелме соң бу? Император университетының рәсми кафедрасыннан торып, студентларны патшалар һәм императорлар тарихын түгел, халык тарихын өйрәнергә чакыру түгелме? Бәлки ялгыш ишетелгәндер? Юк, һич ялгыш түгел. Ике сәгатькә сузылган лекция ахырынача нәкъ шул рухта дәвам ителә. Щапов халыкның үзидарә хокукы турында, конституция турында сөйли, Г. М. Плеханов сүзләре белән әйткәндә, «университетларыбыз тарихында беренче тапкыр буларак», рәсми уку йортларында катгый рәвештә тыелган темага кагыла, декабристлар турында, аларның азатлык көрәшендә тоткан урыны турында сөйләп китә.

Лекция тәмам. Актлар залында бер мәлгә тынлык урнаша. Һәм кинәт зал шартлагандай була — бина көчле алкышларга күмелә.

Щаповның авторитеты, популярлыгы лекциядән лекциягә үсә бара, ул студентларның иң яраткан профессорларына, легендар шәхескә әйләнә. Аның лекцияләрен шыгрым тулы зал тыңлый. Фикерләренең кыюлыгы, эчкерсезлеге, һәр нәрсәне үз исеме белән атарга омтылуы аңа зур уңыш казанырга ярдәм итә.

Демократ галим үзенең бу кыю фикерләрен рәсми лекцияләрендә әйтү белән генә чикләнмәгәндер дип уйларга кирәк. Аның тирәсенә демократик карашлы күп кенә студентлар тупланган булырга тиеш. Һәрхәлдә, Щапов аларның уй-омтылышларыннан самодержавиегә карата ризасызлыкларыннан, яшерен эшләреннән, планнарыннан хәбәрдар булган. Ул хәтта аларның артык сак эш итүләре һәм хәрәкәтләрендә оешканлыкның җитенкерәмәве белән килешеп бетмәгәнлеген, сүздән эшкә күчәргә вакыт икәнлеген җае туры килгән саен әйтә килгән. Юкса, Бездна вакыйгалары турында ишеткәч, аның яшь дусларына әйткән түбәндәге сүзләрен без ничек аңлар идек:

— Менә бу эш ичмасам! Сез әле авылларда үз агентларыгызны булдырырга җыенып кына йөрисез, шрифтлар, литография станоклары булдырып маташасыз, а тормыш чишмә булып үзенчә ага...

Кем белә, бәлки нәкъ менә шул кинаяле сүзләр студентларны кыюландырып җибәргәндер! «Куртина җеназасы»н оештыруның төп сәбәпләреннән берсе булгандыр? Ничек кенә булмасын, 1861 елның 19 апрелендә Арча кырындагы Куртина зираты чиркәвендә «иреккә омтылганнары һәм ватанны сөйгәннәре өчен үтерелгәннәр»нең җеназасы (панихидасы) була. Җеназа уку патша хөкүмәтенә каршы юнәлдерелә һәм политик характердагы чыгышка әйләнә. Анда демократик җәмәгатьчелекнең нигездә студентлардан торган дүрт йөздән артык вәкиле катнаша. Вакыйганың үзәгендә үтерелгәннәргә багышлап дини дога уку түгел, Афанасий Прокопьевичның ялкынлы политик речь тора. Аның бернинди гөнаһсызга атып үтерелгән Бездна крестьяннарына мөрәҗәгать итеп әйтелгән түбәндәге сүзләре патша строена буйсынмаска, аңа

каршы көрәшергә өндәү кебек яңгырый: «Сез беренчеләрдән булып безне йокыдан уяттыгыз... халкыбыз политик хәрәкәттә инициативага сәләтсез, диган ялгыш шикләнүләребезне җимереп ташладыгыз... Сез гомерегез буе эшкәрткән, җимешләре белән безне туендырып килгән, хәзер... үз кочагына алган җир халыкны баш күтәрергә һәм азатлыкка чакырыр... Авыр туфрагыгыз җиңел булсын. Яшәсен демократик конституция!»

Бу сүзләрне әйтүнең ул заман өчен гадәттән тыш кыюлык икәнлегенә басым ясауның кирәге бар микән? Мондый «коточкыч куркынычлы чыгышның» властьлар игътибарыннан читтә калмаганлыгын әйтеп тору да урынсыз булыр. Казан губернаторы икенче көнне үк барысы турында да патшаның үзенә хәбәр итә һәм ул җибәргән телеграмма кәгазенә Александр II нең «Щаповны кулга алырга кирәк...» дигән резолюциясе салына.

Вакыйганың нечкәлекләрен ачыклау һәм урында чаралар күрү өчен Казанга генерал-адъютант Бибиков кебек зур түрә җибәрелә. Ләкин ул, тиешле вәкаләтләре булуга карамастан, Щаповны Казанда ук кулга алу турында әмер бирергә җөрьәт итми, эшнең зурга китүеннән, студентларның тагын хәрәкәткә килүеннән курка. Университетта исә, Бибиков кушуы буенча, хәйлә коралар: Афанасий Прокопьевичка пайтәхеткә барып, хәлне аңлатырга, «мөнәсәбәтләрне ачыкларга» киңәш бирәләр. Бу тәкъдимдә нинди мәкер яшеренгәнен сизенмәгән Щапов 29 апрельдә чыннан да Казаннан чыгып китә. Казанка елгасы буйлап пароходка кадәр аны йөзләрчә студентлар озата бара. Алар профессор белән иң кадерле кешеләре, остазлары, киңәшчеләре белән саубуллашкандай хушлашалар. Жандармнар Афанасий Прокопьевичны тик Нижний Новгородка җиткәч кенә, 1 майда кулга алалар. Ул берничә ай жандармериянең өченче бүлекчәсе төрмәсендә утыра. Август аенда җәмәгатьчелек таләбе белән аны азат итәргә мәҗбүр булсалар да, аны эзәрлекләүдән, һәр эшенә тыкшынудан, һәр адымын күзәтеп торудан туктамыйлар, демократ-профессордан үч алу фикереннән кайтмыйлар, уңай форсат килеп чыкканны гына көтеп торырга карар кылалар. Тиздән патша аны монастырьга сөрү турында карар кабул итә. Щаповны яклап, җәмәгатьчелек яңадан күтәрелә. Бу хәрәкәтне В. Г. Чернышевский җитәкли. Щаповны сөргенгә җибәрү турындагы карарга каршы протест кәгазенә Россиянең йөзләрчә алдынгы эшлеклесе кул куя. Тик шуннан соң гына Александр патша күпмедер вакытка Афанасий Прокопьевичны «гафу итәргә» була.

Н. А. Добролюбов һәм Н. Г. Чернышевский кебек революцион-демократик хәрәкәтнең күренекле эшлеклеләре, шулай ук Николай Гаврилович тарафыннан чыгарылып килгән «Современник» журналының идея йогынтысы белән Щапов әкренләп үзенең патшага ышану иллюзияләреннән котыла бара, халыкның мул тормышы «яхшы дәүләт учреждениеләренә һәм дәүләт тарафыннан үткәрелә торган реформаларга бәйле» дигән уйларының ялгыш икәнлеген икърар итә. Соңрак ул үзенә карата искиткеч таләпчәнлек, хәтта кырыслык белән болай дип яза: «Тормышының соңгы өлешендә газаплы һәм тәшвишле уй-шикләнүләр көрәшен, гакыл төзелешенең җимерелүен кичерү сирәк кешедә була. 20—25 яшендә туплаган бар белемен, дөньяга карашын һәм фикерләү рәвешен 30—33 яшьтә шик астына алу сирәк кешедә генә була. Бөтен гомере буе һәр нәрсәне шик астына алуга, үзенең хаталарын һәм ялгыш фикерләрен төзәтүгә... сирәк кеше генә сәләтле».

1861 елның көзендә Щапов эмиграциядәге рус демократиясенең иң күренекле вәкиле Александр Иванович Герцен белән элемтәгә керә. «Колокол» журналының нәшире Герцен Лондоннан аңа: «Сезнең саф, куәтле һәм чиста тавышыгыз — хәзергә бүгенге рус язучыларының хәлсезләнгән һәм карлыккан тавышлары арасында күңелләргә куаныч өстәп яңгыраучы бердәнбер тавыш» дип яза. Аталарча кайгырту белән сугарылган бу җылы хат Щаповны канатландырып җибәрә.

Афанасий Прокопьевич бу елларда, патша властьларының төрлечә чикләүләренә карамастан, бик күп эшли. Җир реформасыннан соң күп тә үтми, каты реакция башлана. Россиянең иң алдынгы акыл ияләре, шул исәптән Н. Г. Чернышевский һәм Д. И. Писарев Петропавловск крепостена ябылалар. Алар чыгарып килгән прогрессив журналлар тыела, университетлар, кичке мәктәпләр ябыла. Шул вакытта Щапов үзенең «Гражданлык сагышы» дигән атаклы публицистик әсәрен яза. Анда ул Россиядәге социаль-экономик мөнәсәбәтләрнең ялганга корылган булуын, крестьяннарның

гаять авыр хәлдә яшәүләрен, «наданлыкка батып калган» көнчыгыш халыкларының хокуксызлыгын фаш итә.


Казанның Куртина зиратындагы вакыйгалардан соң өч ел үткәч, 1864 елда властьлар барыбер үз дигәннәрен эшлиләр: Щаповны Себергә сөргенгә җибәрергә карар кылына. Шундый бер деталь: Себер тракты безнең Казан аша үтсә дә, жандармнар Щаповны шәһәр буйлап көндезен алып барырга җөрьәт итмиләр. Ул Себердә башта үзенең туган авылында яши, тик бераздан гына аңа хатыны белән Иркутскига күчәргә рөхсәт итәләр. Афанасий Прокопьевич Щапов кырык биш яше тулар-тулмас, коточкыч бөлгенлектә , ӭ авыруыннан үлә. Патша властьлары аның үлеме турында хәтта газеталарда язуны да тыялар.

Ә соң Казан, биредәге демократик хәрәкәт, студентлар хәрәкәте нишли? А. П. Щапов кулга алынгач, студентлар иң якын киңәшчеләрен, рухи остазларын югалталар. Куртина зиратындагы политик демонстрацияне оештыруда актив катнашкан студентлар кулга алына. Ләкин хәрәкәт тукталмый. Щаповның тырышлыгы, ялкынлы речьләре, аталарча биргән киңәшләре бушка китми. Аның яшь дуслары күңеленә салып калдырган чаткылары бераздан көчле ялкын булып тагын кабынып китә. Властьлар Куртина вакыйгаларыннан соң аңнарына килергә дә өлгерми кала, Казан император университеты тарихына «Октябрь бунты» исеме белән кереп калган чуалышлар башлана. Бу юлы студент яшьләр Щаповның куылуында актив роль уйнаган жандармерия агенты инспектор Вяземскийның университеттан китүен таләп итәләр. Полиция университетны ябарга мәҗбүр була. Кырык алты кеше, студентлар исемлегеннән сызылып, сөргенгә җибәрелә. Алар арасында соңрак патшага каршы һөҗүм оештыруда гаепләнеп җәзалап үтерелгән Дмитрий Каракозов та була.

Ватаныбызның ялкынлы патриоты, демократ-галим Александр Прокопьевич Щаповның якты истәлеге 1863 елда университет студентлары катнашында башланган һәм «Казан заговоры» дигән исеме белән мәгълүм булган хәрәкәттә катнашучыларның күңелендә дә яшәгән. А. П. Щапов истәлеге 1887 елда Казан университетында беренче революцион сходкага күтәрелгән студент яшьләрне дә кыюлыкка рухландырган.

Александр Прокопьевичның якты истәлеге казанлылар йөрәгендә бүген дә яши. Алар, бу кешегә тирән ихтирам йөзеннән, шәһәр урамнарының берсенә Щапов исеме бирделәр.

---



Равил Фәхретдинов

# ХАЛЫК КӨЙЛӘРЕ ҺӘМ ИЛҺАМ ШАКИРОВ

*Ишеттем мин кичә: берәү җырлый*
*Чын безнеңчә, матур, милли көй:*
*Башка килә уйлар төрле-төрле,*
*Әллә нинди зарлы, моңлы көй.*

Халкыбызның борынгы җыры «Әллүки»не ишетеп язган Габдулла Тукайның әлеге сүзләре Илһам Шакиров җырлавына да бик туры килә. Аның башкаруында бу илаһи моң күңел түренә үтеп керә, гаять хисләндерә.

Халкыбызның иң моңлы көйләреннән шактыеның Тукай сүзләренә җырлануында зур бер мәгънә, символика бар. Халык күңеле сизгәнне әзелеп-әзелеп әйтеп бирә алган бөек Тукай сүзләреннән башка без борынгы көйләребезне, аларның бөтен гүзәллеген аңлап бетерә алмас идек кебек. Бу җырларда гасырлар буена изелеп килеп тә, үз йөзен, үз моңын югалтмаган халыкның рухи батырлыгы яңгырый. Әйе, һәрберсеннән нечкә сагыш, тирән моң бәреп торган, халкыбызның үзе кебек үк озын гомерле «Әллүки»ләребез, «Зиләйлүк»ләребез, «Тәфтиләү»ләребез, «Туган тел»ләребез бар безнең.

Ә халыкның үз сүзләренә җырлана торган, буыннан-буынга тапшырылып килгән борынгы җырларыбыз күпме! «Кара урман», «Гөлҗамал», «Кәләү Гайшә», «Зөбәрҗәт», «Тәзкирә», «Салкын чишмә», «Бөдрә тал», «Сакмар», «Уел» һәм башка гүзәл җырлар. Тукай сүзләре белән әйткәндә, «бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр», «халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер. Бу — бертекле сихри көзгедер. Чөнки халыкның бер генә җыруын тотып нечкәләсәң, шөһбәсез, аның халәте рухиясен, нәрсә уйлаганын вә ни хакында нинди фикердә икәнен белеп буладыр».

Хак әйтелгән, бөек сүзләр. Нәкъ менә борынгы көйләр халкыбыз тормышының катлаулы үсеш баскычларын, аның социаль-политик аңы һәм психологиясенең формалашуын, иҗтимагый көрәшен чагылдыралар. Борынгы җырлар — бай һәм катлаулы тарихы булган халкыбызның, аның рухи культурасының кадерле ядкарьләре, энҗе-җәүһәрләре генә түгел, ә шул культураның тирән тамырларын ачыклауда, халыкның этник һәм психик үзенчәлеген билгеләүдә зур роль уйнаучы кыйммәтле чыганаклар да.

Бер генә җырга мөрәҗәгать итеп карыйк. Ул да булса халкыбызның иң гүзәл җырларыннан саналган «Кара урман» («Иске кара урман»).

Кара да гына урман, караңгы төн,
Яшь атлар кирәк лә үтәргә.
Кара урманны чыккан чакта,
Кисәл алдым кушкаен,
Ай, аерылмаек, дускаем.

Җырның ачыну белән тулы сүзләренә һәм тирән моңына карагандa, ул шактый борынгы булырга ошый һәм халык өчен иң авыр заманда, тарихның иң дәһшәтле, иң әрнүле чорында тугандыр дигән фикер уята. Кара урман төшенчәсе тирән философик, социологик төшенчә итеп, халыкның авыр көннәрдәге шомлы, караңгы тормышын чагылдыру символы булып кабул ителә.

Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк гомер итәргә,

— дигән сүзләрне нәкъ менә шундый фаҗигале заманда барлыкка килгән дип кенә аңлап була. «Төн караңгысы басып яткан кара урман эченнән нинди үзәк өзгеч авыр моң, нинди дәһшәтле ялгызлык бәреп чыга»,— дип язган иде бу җыр хакында өлкән язучыбыз Гомәр ага Бәширов. Әйе, ялгызлык күңелдә авыр яра булып калган. Тик бу халыкның киләчәккә өметләре зур әле:

Кара да гына урман, караңгы төн,
Нинди юллар белән лә үтәрбез.
Дус-иш белән бергә эш иткәндә
Теләкләргә тизрәк җитәрбез.

«Кара урман» көе күпме генә җырчы һәм музыкантларны, башкаручы коллективларны илһамландырмаган! Зөләйха Әхмәтова җитәкчелегендәге Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең хор группасы шушы җырны башкаруның бик матур үрнәген биргән иде. Ансамбльнең «Кара урман»ын тыңлаганда, халыкның үткәндәге шомлы көннәре дә, аның киләчәккә булган якты хыяллары да күз алдына килә. СССРның халык артисты, композитор Нәҗип Җиһановның «Татар халык көйләренә сюита» сының икенче кисәге дә «Кара урман» көенә нигезләнгән. Симфоник оркестр башкаруында бу көй кара урманның кырыс табигате фонында халыкның үткән тарихына бер күз салу һәм якты тормыш символы булып яңгырый. Илһам Шакиров соңгы елларда бу җырны бернинди аккомпонементсыз, ялгызы гына җырлап, аңа икенче бер төсмер һәм яңгыраш бирде. Илһам тавышы караңгы төндә калын һәм кара урман аша атка утырып барган ялгыз егетнең моңлы авазы булып ишетелә, халык әйтергә теләгән уйларны, аның нәзек хисләрен ачып бирә.

Илһам Шакиров турында китап басылып чыгу уңае белән олы шагыйребез Сибгат ага Хәким мондый сүзләр әйткән иде: «Шигырь тирәсендә күпме бәхәс ишетмәдем мин. Шигырьдә фикерме, имеш, хисме? Шундый чакта минем кешеләрне бәхәстән бүлеп, Илһам Шакировтан «Кара урман»ны җырлатасым килә. Тыңла, оныт. Бәхәсләр мәгънәсез булып кала... Бер дә үз урынына кайта, ачыклана».

Хор җырлыймы, симфоник оркестр яки ялгыз җырчы башкарамы — «Кара урман»нар гади тыңлаучыда да, профессиональ музыканың нечкәлекләрен аңлаган сәнгать кешеләрендә дә тирән эстетик тойгы уяталар. Ә халыкның мондый үлемсез әсәрләрен башкаручылар олы ихтирамга лаек булып кына калмыйлар, бәлки искиткеч тирән эчтәлекле һәм катлаулы музыкаль алымнарга бай булган мондый җырларны башкарып, үзләренең осталыкларын тагын да үстерәләр.

Татар халык көйләрен, бигрәк тә борынгы җырларны башкаруда Илһам Шакиров аерым бер урын алып тора. Үзенә генә хас моңлы һәм көчле тавыш, туган халкының рухи дөньясын бөтен йөрәге белән аңлау һәм шуны җыр аша ачып бирә белү, ниһаять югары башкару осталыгы — менә бу сирәк очрый торган сыйфатлар Илһамга татар көйләренең бөтен тирәнлеген һәм эмоциональ матурлыгын җиткерә алырга мөмкинлек бирделәр. Илһам Шакиров иҗатын татар халык җырларын башкаруда, шиксез, аерым бер чор итеп карарга була. Гомумән, Илһам халык җырларының фәлсәфи тирәнлеген, эстетик югарылыгын, кайнар хисен һәм моң-сагышын ачып бирүдә моңарчы беркем дә ирешмәгән, гаҗәеп зур уңышларга иреште.

Татар халык көйләре һәм Илһам Шакиров иҗаты турында сүз алып барганда, тагын бер мәсьәләгә тукталып үтәсе килә. Халык иҗатыннан көч һәм илһам алып, борынгы җыр-көйләребезне туплау һәм кире халыкка кайтаруда заманында Габдулла Тукай, Заһидулла Яруллин, Фәттах Латыйпов, Фәйзулла Туишев, Исмәгыйль Мусин, соңрак Александр Ключарев, Җәүдәт Фәйзи, Гөлсем Сөләйманова, Фәйзи Биккинин, Заһид Хәбибуллин, Рокыя Ибраһимова һәм башка шагыйрьләр, композиторлар, музыкантлар, җырчылар ифрат мактаулы, изге эш эшләделәр. Бу күркәм традицияне Илһам Шакиров дәвам иттерде. Моңлы тавыш белән җырлау һәм киң популярлык, халыкның сөйгән җырчысы булу Илһамга борынгы җырларыбызны яңадан халыкка җиткерүдә гаять зур мөмкинлекләр тудырды. «Син сазыңны уйнадың», «Туган ил», «Кораб», «Карьят батыр», «Җиһанша», «Бик ерακта идек без», «Әнкәм кабере янында», «Маһирә», «Озын су өсте» кебек бүгенге тыңлаучы өчен яңа булган, әмма заманында халык арасында киң таралган, тик ниндидер сәбәпләр аркасында онытылып торган җырларны Илһам үзе яки башка җыр сөючеләр ярдәмендә эзләп тапты, беренче булып башкарды һәм халык тарафыннан җылы кабул ителгән бу матур көйләребезгә икенче тормыш, яшәеш бирде. Моның белән ул җыр-музыка иҗатчыларны гына шатландырып калмады, ә профессиональ музыкантлар, композиторлар иҗаты өчен, гомумән, сәнгатебез һәм рухи культурабыз өчен иҗтимагый әһәмияткә ия булган зур, мактаулы эш эшләде.



Илһам Шакиров иҗаты турында сөйләгәндә, бер хатирәгә урын бирәсе килә... Җылы август киче иде. Без, Кама елгасы буенда борынгы истәлекләрне өйрәнеп йөрүче бер төркем археологлар, көне буе эшләгәннән соң, лагерьга кайтып киләбез. Лагерь дигәнебез, өсте ябулы бер машина да, аның янындагы ялгыз палатка. Ерактан күренгән учак төтене безнең арыган аякларыбызга хәл кертеп җибәргәндәй итте. Килеп җиткәндә, шоферыбыз мәж килеп, кичке аш пешерү эшләрен хәстәрләп йөри иде. Тиз генә елга суында юынып алдык та аш белән ботка да пешереп ташладык. Без ашап бетергәнче караңгы төшеп өлгерде. Әмма аңа карамыйча, учак яктысында гына чәй эчәргә тотындык. Билгеле, чәйне аны эчмәгән кеше юк, ләкин менә елга үзәнендә, учак янында кырын ятып, калай кружкалардан авызны пешерә-пешерә эчкән чәйдән дә тәмлерәге булыр микән? Җитмәсә, бөтен тирә-юньне ниндидер бер моң чолгап алган. Тукта, нәрсәсе генә моңлы соң әле бу кичнең — тау өстендәге зиратның карт каеннарымы, бормаланып аккан елгамы, әллә күтәрелеп килүче тулган аймы? Әйтерсең, ул бөтен нурын безнең өскә генә яудыра...

Ул арада Казаннан кичке концерт башланды. Татар халык көйләре. Менә сиңа ма — моң өстенә моң! Килсә дә килеп тора бит...

Фортепьянода ярсулы кереш. Аңа җырчының көчле тавышы кушыла:

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер...
Җилкәнен киргән кораб!

**Төн вә көндез**
**Ул йөзәдер:**
**Юл бара, ят ил карап...**

«Кораб» җырының үзәгендә күп газапларга дучар булган язмыш... Аны икенчесе алмаштыра. Бусын инде баяннар башлап җибәрә, аларны шул ук җырчының ягымлы, моңлы тавышы күтәреп ала:

**Китми күңелемнән минем һич**
**Шул сөекле илкәем;**
**Анда минем сөйгән халкым,**
**Анда сөйгән әнкәем...**

«Туган ил». Туган җиреңне өзелеп сөю, ярсып сагыну хисе. Бу көйләрне чит илләрдә каңгырып йөреп тә, бәхет таба алмыйча, үз илләрен сагынып кайткан татар егетләре алып кайтканнар. Туган якларын, җирен сагынып газапланган кешеләр мондый көйләрне чыгарганда юкка гына Дәрдмәнд һәм Исәнбәтнең гыйбрәтле сүзләрен сайлап алмаганнардыр. Илһам башкаруында шушы ике җыр бер бөтен булып кабул ителделәр, алар туган ил, туган туфрак төшенчәсен бөтен тулылыгы белән ачып бирделәр сыман тоелды. Күзгә йокы кермәде. Әле лагерь йокыга яткач та, елга буйлап озак кына йөрдем...

Ай тагын да югарыга менде, үзәнне сыек томан каплап алды. Бөтен тирә-юньне ниндидер сихри тынлыкка чумды. Ерактарак, тау итәгендә урнашкан Укмас авылында да утлар сүнде.

Укмас — шагыйрь Укмасыйның туган авылы. Ничек дигән әле ул:

**...Җырлар идемме җырымны,**
**Ил өчен җан янмагач!!**

Ил өчен җан янмагач! Гаҗәеп мәгънәле сүзләр! Алар, әйтерсең, бөтен йөрәге белән илен һәм халкын сөюче Илһам җырларына карата язылганнар. Әйе, ул җырлаганда, туган ил бөтен гүзәллеге белән күз алдына килеп баса. Туган ил ул — иң әүвәл туган туфрак, газиз ата-ана, син дөньяга килгән авыл, аның гөрләп үскән иген басулары, шау чәчәкле болыннары, серле кара урманнары, тау астында челтерәп аккан чишмәләре, суларында колач салып йөзгән елга-күлләре, моңсу таллар әйләндереп алган тегермән буалары, айлы төндә ат саклаганда сөйләгән тылсымлы әкиятләре, кояш нуры белән тулы зәңгәр күге, күңелләргә дәрт өстәүче иртәнге тургайлары, моңсызларга моң бирүче кечкенә сандугачлары, чиләкләп койган җылы җәйге яңгырлары, колак яфракларын өшетерлек кышкы салкыннары, күз ачкысыз бураннары. Ул — авылның күпне күргән әби-бабайлары, дөнья җимертеп эшләп йөрүче агайлары, апалары, яшь егетләре һәм кызлары, ул аның нарасый балалары. Ул — тирә-якны шау китергән җәйге сабан туйлары. Ул — тальян гармуннарының үзәк өзгеч моңнары...

Илһам Шакиров иҗаты турында сүз барганда, аның башкаруында кабатланмас яңгыраш тапкан авыл көйләрен дә искә алмый мөмкин түгел. Әйе, безнең күңелләргә балачактан кереп урнашкан, һәрвакыт туган-үскән җирләребезне искә төшереп һәм шунда чакырып торучы, җанга якын, газиз авыл көйләре... Борын-борыннан җыен һәм сабан туйларында, аулак өй һәм мәҗлесләрдә, бәхет эзләп чит җирләргә һәм солдатка чыгып киткәндә, туган илләргә кайтып кергәндә җырланган моңлы да, дәртле дә авыл көйләре. Шул авыл көйләренә җырлап печәнгә төшкәннәр, тула сукканнар, каз өмәләре үткәргәннәр, кыз биргәннәр, өйгә килен төшергәннәр. Кайчан гына, кайда гына җырланмаган да һәм хәзер дә кайда җырланмый ул авыл көйләре!.. Менә кичке айлы төндә авылның бер башында кемдер авыл көенә тальянын сызып җибәрә, аңа кушылып җыр башлыйлар, урамны иңләп узалар. Йоклый алмый яткан һәм йокыларыннан уянган әби-бабайлар, апа-җиңгиләр яшьлекләрен искә төшереп, бер моңаеп алалар, күз читләрен сөртеп куялар. Сөйгән ярлар исә, булачак кавышу хыялына чумып, әкрен генә тагын йокыга киталар. Элек тә шулай булган, хәзер дә шулай. Миңа калса, безнең агай-энедә җыр-музыкага мәхәббәт әлеге шул тальян моңнарыннан, җанга якын авыл көйләреннән башланган. Нинди генә авыл көйләре

булмаган һәм юк бездә, санап очына чыга алмассың! Әле теге яки бу авылга, аның тирә-юнenә генә таралган көйләрдән башка, бөтен халыкка мәгълүм җырлар булып киткән «Сарман»нар, «Минзәлә»ләр, «Шөгер»ләр, «Арча»лар, «Әтнә»ләр, «Наласа»лар... Аннан килеп «Күн авылы», «Өнсә», «Безнең авыл» көйләре. Болары инде — чын мәгънәсендә «Илһам җырлары», ул күтәреп алып җырлый башлаган һәм башкаларны авыл көенә җырларга кабат дәртләндергән җырлар. Әйе, әйе, Илһамнан отып алып, шушы җырлар җырланмаган авыл һәм шәһәр сәхнәләре, сабан туйлары, кунак ашлары, туй мәҗлесләре юктыр хәзер. Гомумән, авыл җырларын зур театр һәм концерт залларында, телевизор экраннарында яңгыраткан, радио дулкыннарында тибрәткән Илһамга туган-үскән җиренә мәхәббәт саклаучы һәр изге җанның рәхмәте чиксез зур.

Халык көйләрен башкаручыларны һәм иң беренче чиратта Илһам Шакировны тыңлаганда, ирексездән, Габдулла Тукайның «Халык әдәбияты» дигән мәгълүм лекциясендә сөйләгән сүзләре искә төшә: «Безнең халыкның җырлау вә көйләвендә, минемчә, үзенә бертөрле хосусият бар кеби.

Башка милләтләрдә булдыгы кеби, бездә калын тавыш илә вә мөмкин кадәр көчләнеп һәм авызны бик зур итеп ачып җырлау бер дә мәгъбул түгел. Бездә җырланган чакта тавышның йомшак булуы вә бераз үен коралы авазына охшашрак булуы вә иреннәрнең дә мөмкин кадәр аз ачылуы мәкъбул вә мөхтәхсән (кабул ителгән һәм күркәм) күренә. Мәсәлән, мин дөм чукрак булып та, җырлап утыручы бер татарның авызына карасам, мин аны җырлый дип белмәс, бәлки бернәрсәне кызу-кызу сөйли икән дип хөкем итәр идем.

Минем исемдә калган: мәдрәсәдә чакта бер шәкертнең хөсне тәвәҗҗеһен җәлеп иткән (яхшы карашын казанган) бер җырлаучы, үзенең иренен каты кәгазь сыярлык итеп кенә ачып, озын вә кыска көйләрне җырлап җибәрә иде. Аның шулай мыек астыннан гына җырлавы безнең хушыбызга бигрәк китә иде.

Безнең бер көйне руслар арасында бик яхшы тавышлы саналган бер кешедән җырлатсаң, әллә ничек шуның безнең күңелгә охшарына күңел ышанмый. Көебезнең алтынын кояр шикелле тоела»[1].

Бөек шагыйрь булуы һәм халык иҗатын тирәнтен белүе өстенә, Тукай үзе дә кече яшьтән җырчы булган, моңлы итеп җырлаган; аның җырлавын ярата, кат-кат җырлата торган булганнар. Шуңа күрә дә халык көйләрен башкаручыларга карата аның таләбе зур булган. Ул моңлы, матур итеп җырлаучыларга зур бәя биргән, ә инде «бер тыңласаң, мәче тавышы, бер тыңласаң, майланмаган арба тәгәрмәче тавышы» китереп җырлаучыларны каты тәнкыйтьләгән. Шулай дип фараз кыласы килә: әгәр дә Тукай исән булса, көйләребезнең «алтынын коймыйча» җырлаучы Илһамны тыңлап, чиксез шатланыр иде, аның башыннан сыйпап, олы рәхмәтен әйтер иде.

Татар халык көйләре һәм аларны башкару осталыгы турында сүз алып бару, иң беренче чиратта Илһам Шакиров иҗаты турында сөйләү булыр иде. Яки киресенчә: Илһам Шакиров турында сөйләү — халкыбыз җырлары һәм аларны башкару осталыгы белән бәйле проблемалар турында сүз алып бару булыр иде. Әлбәттә, татар халык көйләре һәм аларны башкару белән бәйле булган мәсьәләләр күп һәм барысы да хәл ителгән дип уйларга һич тә ярамый. Әйтик, безнең татар җырларына хас булган моң проблемасы. «Моң» төшенчәсенә әле берәүнең дә төгәл генә аңлатма бирә алганы юк. Бу төшенчәгә бер-ике сүз белән генә билгеләмә бирү, гомумән, мөмкин булмаган нәрсә. Моң-ул, бәлки, халыкның рухи халәтенең бер хосусияте, үзенчәлегедер. Алай гына да түгел, бу моң шул халыкның бөтен яшәеше, рухи байлыгы белән билгеләнәдер. Тукай да бит үзенең кыска гына гомерен мөкатдәс бер моңлы саз дип атаган. Фашист палачлары алдында тез чүкмәгән, корыч ихтыярлы батыр Муса Җәлил: «Гомерем минем моңлы бер җыр иде», дип язган. Әгәр дә җыр язмышы ил язмышы белән бәйләнә икән, әгәр дә шул җыр ил язмышында булган әрнүле һәм шатлыклы вакыйгаларны дөрес чагылдыра һәм халык күңеленә кереп урнашкан хисләрне бөтен тулылыгы белән әйтеп бирә ала икән, ул җыр зур бер моң булып кабул ителә. «Көй — күңелнең моңы», дип юкка гына әйтмәгән безнең

---

[1] Г. Тукай. Әсәрләр, 2 том, Казан, [illegible], 271–272 битләр.

халык. Хәлбуки, ул моңны бөтен тулылыгы белән бирә алу өчен җырчы тавышының моңлы булуы да бик зарури. Ни өчен Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов, Зифа Басыйрова, Фәридә Кудашева, Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Габдулла Рәхимкулов, Таһир Якупов, Зөһрә Сәхәбиева, Флера Сөләйманова, Рафаэль Ильясов җырлары халык күңеленә аеруча үтеп керәләр? Чөнки аларда моң бар, чөнки алар халык күңеленең көзгесе булган халык көйләренең рухын, шул рухны тоеп язган Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключарев, Заһид Хәбибуллин, Сара Садыйкова, Рөстәм Яхин һәм башка композиторларыбыз әсәрләрендәге моңны бирә алалар.

**Тыңласаң җыр, тыңла моңлылардан,**
**Моңлы җырлар кала ла йөрәктә,**

— дип дөрес әйткән безнең халык.

Гомумән, моң ул — ата-бабаларыбызның күңеленнән, үзебезнең туган җир һәм туган туфрагыбыздан шытып чыккан, гасырлар буена сөйгән халкыбыз тарафыннан кадерләп үстерелгән олы хис. Моң — кешенең күңелендә булган шул олы хисне әйтеп бирә белү. Ә җырчы тавышы өчен — шул көйне «алтынын коймыйча» башкара алу.

Шушы зур булмаган язмабызның ахырына якынлашканда, тагын бер-ике мәсьәләгә игътибарны юнәлтәсе килә. Илһам Шакиров халкыбызның күп кенә җырларын бик яхшы башкарды, аларның язмалары алынды. Әмма Илһам җырламаган, аның тавышын көтеп ятучы җырлар шактый әле. Әйтик, «Гөлҗамал», «Сибелә чәчәк», «Зөбәрҗәт», «Ишкәкче карт җыры», «Шахта», «Су буйлап» («Идел бит ул») һәм башка шуның кебек гүзәл җырларны аның башкаруында ишетәсе килә. Инде булган язмалар өстенә яңалары өстәлеп, халкыбыз җырларын классик башкаруның зур бер җыелмасы эшләнер иде һәм ул язмалар, һич шик юк, Татарстан радиосы һәм телевидениесенең алтын фондын тәшкил итәрләр иде. Бу киләчәк буын тыңлаучылары өчен дә, сәнгать белгечләре һәм фольклорчылар өчен дә халык җырларын нәкъ менә классик башкару үрнәкләре булып калыр иде.

Бик яхшы хәтерлибез: 1968 елның язында, Тукайны искә алган көннәрдә, радио аша Илһам Шакировның бөек шагыйрь сүзләре белән исемләнгән «Халык җырлары — халык күңеленең көзгесе» дигән концерт-әңгәмәсе яңгырады. Үзе язган, үзе алып барды, үзе җырлады. Бая телгә алынган «Корабълар», «Туган иләләр», «Маһирәләр кебек уннан артык җыр яңгырады, һәрбер җырның табылу тарихы яки үзенчәлеге турында кызыклы мәгълүматлар бирелде. Халык моңнарына искиткеч зур мәхәббәт белән үткәрелгән ул әңгәмәдән соң радиокомитетка, Илһамның үзенә меңтөрле рәхмәтләр әйтеп, дистәләрчә хатлар килде. Бер ел да узмады, 1969 елның гыйнварь аенда Казанның театр һәм культура сарайларында Илһам Шакировның «Татар халык җырлары» исемле концертлары булып узды. Гаҗәеп салкын көннәр булуга карамастан, концертларга халык агылып торды, артык билет табып булмады. «Бис»кә чакырып җырлатуларны да санасак, концерт саен 30 лап җыр җырланды. Исең китмәле: бер тын алу белән дип әйтерлек җырланган 30 лап җыр! Борынгылары да, яңалары да. Һәрбер башкарылган җырдан әйтеп бирә алмаслык тирән моң бәреп торган шушы онытылмаслык концертлардан халык тыныч кына тарала алмый иде. Ул вакытта Илһам Шакиров иҗаты турында яза башлаган бер кеше буларак, мин кызыксынып, халыкның мөнәсәбәтен, фикерен белергә теләп, концерт барышында әкрен генә тирә-ягыма каранып ала идем — бөтен зал «тын да алмый» тыңлап утыра, күпләрнең күзләрендә соклану билгесе, шатлык яшьләре; концерт тәмам булып, халык таралышканда, шунда буталган булып, сүзләренә колак салам — җырчы адресына чын күңелдән, йөрәк түреннән чыккан рәхмәт сүзләре, җырларыбыз белән горурлану хисләре. Татар җыр сәнгате тарихында беренче тапкыр эшләнгән, бик озакка истә калырлык тапшыру һәм концертлар булдылар алар.

Ул көннәрдән соң 13—14 ел вакыт үтеп китте. Хәзер инде халкыбыз яңадан андый җырларга сусап өлгерде. Ул темага әйләнеп кайтырга, халык җырларына багышланган концертларны яңартырга да вакыт җитте төсле. «Ул заманда Илһамга 32—33 яшь иде, хәзер 45 не узып китте, аның өчен зур концертлар бирү авыр индер»,— дип шик-шөбһә белдерүчеләр дә булырга мөмкин. Әмма алар фикере белән килешү кыен. Илһамның потенциаль мөмкинлекләре әле бик зур, һәм ул халык җыр-

ларына багышланган махсус концертлар биреп, меңләгән тамашачыларны, җырга гашыйкларны кабат шатландырыр, әлбәттә.

Әйтеп үтелгән тапшыру һәм концертлардан соң бераз ара калдырып, радиодан Илһам Шакировның тагын бер концерт-әңгәмәсе яңгырады. Дөресрәге, бу — Илһамның үз концерты түгел, ә танылган җырчы Фәридә Кудашева турында ул әзерләгән тапшыру булды. Халыкның мәхәббәтен казанган җырчы турында бик матур, җылы хисләр белән язылган, аның күп кенә язмаларын керткән әйбәт концерт-очерк булды ул. Иң әһәмиятлесе шунда — халык җырчысы турында халык җырларын башкаруның бөтен нечкәлекләрен үзләштергән оста сөйләде. Мондый тапшыру, әлбәттә, тыңлаучыга бик көчле тәэсир итә.

Ниһаять, соңгысы. Шул ук 60 нчы елларда Илһам Шакиров республикабызның газета-журнал битләрендә җыр-музыка, башкаручы коллективлар һәм аерым җырчылар турында очерк-мәкаләләр белән бик еш чыгыш ясады. «Халык моңнары», «Дусларга бер-ике сүз», «Эзләнү — иң яхшы юлдаш» исемле һәм башка язмаларында татар һәм башкорт көйләрен пропагандалау, аларны башкару үзенчәлеге белән бәйле булган мәсьәләләрне күтәреп чыкты. Ул язмалардан Илһамның халык җырларын өйрәнү өлкәсендә киң эрудицияле, оста каләмле белгеч икәне дә күренде. Еллар үткән саен, тәҗрибә туплана, фикер камилләшә, каләм шомара. Шуңа күрә, ул мәсьәләләргә кабат әйләнеп кайтып, күләмлерәк әйберләр эшләргә вакыт җитте кебек. Әйтик, классик көйләр булып киткән әсәрләр, бигрәк тә борынгы җырлар, аларның туу һәм халыкка таралу тарихы, татар халык җырларының үзенчәлеге һәм аларны башкару осталыгы белән бәйле булган мәсьәләләрне күтәреп язган китап тумас микән?

Халык көйләрен башкару үзенчәлекләре хакында сөйләгән һәм югарыда китерелгән сүзләрен тәмамлап, Г. Тукай мондый фикер әйтә: әгәр дә бу турыда күп сөйләшүгә кителсә, музыка һәм аны аңлау мәсьәләләрен күтәрергә туры килер иде, ди. Ул әлегә бу өлкәдә үзенең тиешенчә хәзерлеге юклыгын әйтә һәм фикерен болай тәмамлый: «Юк аның тоткан нәрсәсен куптарырлык кулы. Юк аның уйлаган вә сизгән нәрсәсен дәлилләр белән сөйләрлек теле. Юк аның караган нәрсәсен аркылы тишәрлек күзе»[1]. Тирән юмор белән әйтелгән бу сүзләрдә, әлбәттә, шагыйрьнең зур тыйнаклыгы сизелә. Коеп куйган шагыйрь булу өстенә, Г. Тукайның бөек гыйлем иясе дә булуы бервакытта дә шик тудырмый. Аның «Халык әдәбияты» исемле әсәре генә дә халык иҗатын, халык җырларын өйрәнүчеләрнең ничәмә-ничә дистә еллар инде юл башы булып тора һәм озакка шулай булып калыр да. Тукай әлеге әсәре белән генә дә канәгатьләнмәгән, шул эшен дәвам иттереп, халык җырларының тарихын ачыклауга багышланган зуррак хезмәт язуны күздә тоткан: «Җырларыбыз вә көйләребезнең тарихын вә мәнбәгъләрен (чыганакларын) тикшерергә бер заман махсус хезмәт куярмын да, шаять шул турыда әсаслырак (төплерәк) мәгълүмат бирермен дигән өметем бар әле»[2]. Шуннан бер ел узгач, С. Сөнчәләйгә язган хатында Г. Тукай шул яңа хезмәте өчен бик яхшы материаллар тапканын, шуны җыйнап бирергә нияте булганлыгын әйтә. Әмма 2 елдан соң, 27 яшен тутырганда дөнья куйган шагыйрь бу хезмәтен тәгәлли алмый калган, һәм ул эшнең язмышы да хәзергә билгеле түгел.

Әлбәттә, Тукай үзенең махсус музыка белеме булмаганлыгын яхшы аңлаган. Бу өлкәдә хәзер кытлык юк инде. Профессиональ һәм халык музыкасының нечкәлекләрен аңлаган белгечләребез, талант ияләребез күп. Шулар арасында музыка буенча югары белемле, халык җырларының, халык көйләренең үзенчәлекләрен яхшы белгән, гаҗәеп моңлы тавышка ия халык җырчысы Илһам Шакиров та бар.

Әйе, халыкның рухи идеалларын бөтен җаны-тәне белән тоя белгән һәм шуларны йөрәгенең иң нечкә хисләре аша ачып бирә алган, халыкның чын мәхәббәтен казанган якты шәхес һәм кабатланмас талант иясе, РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясе лауреаты Илһам Шакиров сөйгән халкын яңа, зур уңышлары белән тагын да шатландырыр.

---

[1] Шунда ук, 272 бит.
[2] Шунда ук, 256 бит.

## ГАЛИ ХУҖИНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

# ҖЫРЫ АТЛЫЙ БЕЗНЕҢ САФЛАРДА



Хәзер аңа алтмыш яшь тулган булыр иде. Әмма шагыйрьнең гомер озынлыгы еллар белән түгел, аның халыкта калган җырлары белән үлчәнә. Ә шагыйрь Гали Хуҗи, белгәнебезчә, шактый зур әдәби мирас калдырды. Поэзия сөючеләр аның шигырьләрен һәм поэмаларын яратып укыйлар, тормыш һәм иҗат юлы белән якыннан кызыксыналар.

Гали Хуҗи 1912 елда Татарстанның элеккеге Кайбыч, хәзерге Апас районы, Карамасар авылында крестьян гаиләсендә туа. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, ул Казанга килә һәм башта югары уку йортында хәзерлек курсларында, аннары, эштән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогия институтында укый. Булачак шагыйрь 1929 елда комсомолга керә һәм шул көннән башлап, үзенең бөтен гомерен сафларында Корчагиннар тәрбияләнгән комсомол белән бәйли. 1932—1934 елларда Гали Хуҗи «Кызылармеец» газетасында әдәби хезмәткәр, 1934 елдан ул вакыттагы «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасында җаваплы секретарь һәм редактор урынбасары, 1941—1942 елларда ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре булып эшли. Шул елларда яшь шагыйрьнең «Шатлык», «Комсомолка», «Яшьлек тавышы» һәм «Тургайлар» исемле шигырь җыентыклары басылып чыга.

Үз урынын һәрвакыт алгы сызыкта итеп тойган шагыйрь, туган җиребезне баскынчылар итеге таптаганда, тылда кала алмый: сәламәтлеге бик үк шәптән булмауга карамастан, 1942 елда үзе теләп яу кырына китә. Сугышта ул Воронеж һәм Беренче Украина фронтларында татар телендә чыгып килгән хәрби газетада Риза Ишморат, Мөхәммәт Садри, Госман Бакиров һәм Габдулла Шәриповлар белән бергә эшли, газетаның җаваплы секретаре була.

Йөрәгендә дошманга карата нәфрәт уты дөрләгән шагыйрь карлы-бозлы поход юлларында да, салкын окопларда тән уздырган чакларында да үзенең икенче автоматын — дуслар күңеленә җылылык бирүче каләмен бер генә минутка да кулыннан төшерми, сугышчыларны җиңүгә рухландырган күп санлы шигырьләр, балладалар, поэмалар, очерклар яза. Ул әсәрләрдә тыныч таңнарның яңадан килеп туачагына ышаныч та, солдат күңеленә хас моңаю-сагышлану да, бер үк сафта иңне иңгә куеп атлаган дусларына булган эчкерсез мәхәббәт тә мул чагылыш таба. Бу чорда язылган кайсы гына шигырен укып карама, шагыйрьнең бөтен барлыгы белән посттагы солдат булып калуын тоясың.

Мин солдатың әле — һаман сафта,
Бу — намуслы хезмәт итүем.
Үкендермәс, күзем йомган чакта,
Яшь гомернең болай үтүе.

— дип яза ул 1945 елда «Австрия Альпларында» дигән шигырендә, туган илгә мөрәҗәгать итеп.

Сугыштан соңгы елларда шагыйрьнең иҗаты тагын да активлаша, камилләшә. Бу елларда ул бер укуда күңелләрдә ятланып калырлык бик күп лирик шигырьләр, даһи юлбашчыбызның тормышын, кешелек дөньясына аны биргән Россиянең җирдә азатлык маягы булып балкуын, Бөек Ватан сугышында һәлак булган каләмдәш дусларының батырлыгын, интернациональ бердәмлекнең җиңелмәс көчкә ия булуын, сокланып туймаслык тормышыбызның күркәмлеген, совет кешеләренең рухи бөеклеген шактый тулы һәм калку гәүдәләндергән «Идел хикәясе», «Россия», «Гражданин, солдат, шагыйрь», «Безнең Муса», «Испания улы», «Янар йөрәкләр», «Күңел яктысы», «Каенсар», «Салават күпере», «Тормышка кайту» поэмаларын, «Сергей Чекмарев белән очрашу», «Капитан Русанов», «Ә ул җырлый» балладаларын иҗат итә. Совет патриотизмы һәм гражданлык хисе белән сугарылган әлеге әсәрләрендә дә ул үзен яңа шигъри офыкларга җилкендереп, чакырып-әйдәп торган темаларга, тормышчан вакыйга-күренешләргә тугрылыклы булып кала. Иделдә янган утларга күзен текәп шагыйрь менә болай уйлана:

**Текә үрләр — тормыш үрләренә**
**Гел чакырып яна ул утлар,**
**Күз төбәгән туар көннәремә**
**Гел яктырып яна ул утлар.**

Тормышка баштанаяк гашыйк, һәрвакыт көр күңелле, йөзеннән беркайчан да елмаю китмәс шагыйрь үзенең иҗатында әнә шулай «гел яктырып янган утлар»га карап барды, шигырьләрендә һәм поэмаларында үз чорының сулышын тоеп, замандашларының уй-тойгыларын, көрәшле еллар аша узганда туган хис-кичерешләрен җырлап, зур корбаннар һәм беркайчан да кайтарып ала алмаслык югалтулар бәрабәренә яуланган имин тормышының кадерен белергә өндәп яшәде. Менә шуңа күрә дә аның әсәрләре бүген дә үзләренең актуальлекләрен югалтмыйлар, киләчәк көннәргә безнең белән бер сафта атлап баралар.

Гали Хуҗи турында сөйләгәндә, аның тагын бер характерлы ягын искә алып үтүне йөрәк үзе таләп итә. Ул — әдәбият мәйданына әле яңа гына аяк басарга әзерләнүче яшьләрнең иң якын дусты, акыллы киңәшчесе, рыясыз ярдәмчесе һәм аруталуны белмәс тәрбиячесе иде. «Татарстан яшьләре» газетасының редакторы булып эшләгәндә дә, Язучылар союзының әдәби консультанты итеп билгеләнгәч тә аның бүлмәсеннән яшь авторлар өзелеп тормады. Ул, аларның кульъязмаларын укып кына калмыйча, иң уңышлы дип табылган хикәя-шигырьләрен укучыларга мөмкин кадәр тизрәк җиткерү чарасына керешә һәм моның өчен кулыннан килгәннең бөтенесен эшли иде. Хәзерге көндә «урта буын» дип аталып йөртелә торган язучылардан кайсыбыз гына үз иңендә аның җылы кулын тоймаган икән дә, каләмебезне кысыбрак тотарга ярдәм иткән һәм иҗатка дәртләндергән сүзләрен ишетмәгән икән! Аның яшьләрне яратуы, үз энеләредәй якын күрүе тикмәгә түгел иде. Яшь язучыларга, аларның киләчәктәге иҗатларына ул зур өмет, зур ышаныч баглады. Бу өмет, бу ышаныч шагыйрьнең «И шигърият, изге эшебез» дигән шигырендә аеруча ачык чагыла. Шигырь менә мондый юллар белән тәмамлана:

**Без егылсак, эстафетаны**
**Яшьләребез алып китәрләр;**
**Алар аны бездән арырак —**
**Киләчәккә дәвам итәрләр.**

Шунысы куанычлы, шагыйрь әле үзе исән чагында яшь язучы дип йөртелгән бик күп эдипләребез аның бу васыятенә тугрылыклы булып калуларын үзләренең иҗатлары белән расладылар, укучыларга менә дигән матур-матур әсәрләр бүләк иттеләр һәм итәләр.

Гали Хуҗи белән соңгы тапкыр очрашуым әле бүгенгедәй хәтеремдә. Татарстан китап нәшриятында эшләгәндә миңа аның «Җил тула җилкәннәргә» дигән җыентыгын

редакцияләргә туры килде. Үз иҗатына карата болай да бик таләпчән шагыйрь белән кульязма өстендә кат-кат эшләдек. Ул инде типографиягә тапшырырлык хәлгә килгән иде. «Җыентыкка кермичә калган тагын берничә яңа шигырем бар,— диде Гали Хуҗи шунда,— аларын иртәгә иртүк китереп җиткерермен, кульязманы тапшырмый торыйк». Бу аның безнең белән актыккы тапкыр саубуллашуы булган икән. Иртәгәсен без аны соңгы юлга озаттык.

Бөтенләйгә китәм, димәдең ич,
Күрешербез, дидең, иртәгә.
Шигырьләрем белән киләм, дидең...
Әзер идек йотылып тыңларга.
Күзләребез талды, карый-карый
Син киләсе ерак юлларга.
Ае да бит аның син туган ай:
Кичтән аяз, иртән болытлы.
Таш яуса да барыбер килер, дидек,
Беләбез ич синең холыкны.
Җәяү килер... «Такси» чакыртмыйлар
Походларны кичкән бу ирләр.
...Ишекләрне түгел, нишләп әле
Йөрәкләрне шакый бу җилләр!!
Нишләп тели алар «үлем» дигән
Салкын сүзне телгә алуны.
Сүнми шагыйрь, шагыйрь сүнә белми,
Ул дөрләүне белә, януны.
Син әйтергә хаклы: «Шигырь өчен
Бик күбебез иртә яндык бит».
...Синс сөюем калыр гомерлеккә,
Шул антымны минем алып кит!

1966 елның 13 октябрендә мин шагыйрь белән әнә шулай хушлаштым. Вафат булганда, аңа илле дүрт яшь тулырга дүрт көн калган иде.

Рәшит ГӘРӘЙ.

# БӘЙРӘМНӘР ДӘВАМ ИТСЕН



Татар культурасы тарихында зур борылыш ясаган аеруча истәлекле вакыйгаларның берсе, мөгаен, ул милли театрыбызның барлыкка килүедер. Моның шулай булуына җуелмас дәлилләр бар: XX йөз башындагы татар вакытлы матбугаты сәхифәләре, шул еллардагы әдәби тәнкыйть һәм Г. Камалның «Беренче театры»... Халкыбызның мәгърифәткә, дөньяви белемгә һәм азатлыкка омтылышы яңарган тарихи бер чорда туып, татар театры үзе дә революцион күтәрелеш дулкынын иҗтимагый һәм эстетик аңыбыз үсешен әйдәгән сугышчан трибунага әйләнде. Һәм аның инде сигезенче дистәне тутырып килүче бай һәм данлы тарихы бар. Якты маяклары — драматурглары, режиссерлары, актерлары бар.

Әлеге якты маякларны, театрның үсеш этапларын күз алдыннан кичергәндә, шушы бай тарихка яктылык һәм нур сирпеп торган фидакарьләр — сәхнә һәм драматургия тәнкыйтьчеләренең олы эшчәнлегенә ихтирам хисләре уяна. Г. Тукай һәм Ф. Әмирханның беренче сәхнә тәҗрибәләребезгә игътибар һәм таләпчәнлеген күрсәтеп торган дистәләгән рецензияләре, драматургия һәм театрыбызның беренче профессиональ тәнкыйтьчеләре Г. Кәрам һәм К. Бәкер хезмәтләре театр тарихында гына түгел, милли эстетик фикер үсешендә дә әһәмиятле нигез булып торалар. Соңрак бу җаваплы эшне Г. Гали һәм К. Тинчурин, Ф. Сәйфи-Казанлы һәм Ф. Бурнашлар дәвам итә, М. Җәлил һәм Г. Кашшаф күтәреп ала...

Бу көннәрдә гомеренең бишенче дистәсен түгәрәкләргә җыенган театр һәм драматургия тәнкыйтьчесе Азат Әхмәдуллинның иҗат эшчәнлеге һәм әдәби-эстетик эзләнүләре хакындагы сүзне башлар алдыннан әлеге традицияләрне, йөгереп кенә булса да, искә алып узу урынлы булса кирәк. Моның белән, беренчедән, драматургия һәм театр сәнгатебез өлкәсендәге данлы традицияләрне хәтергә төшерсәк, икенчедән, драматургия тәнкыйтьчесе булуның үз өстенә ни дәрәҗәдәге җаваплылык һәм бурычлар йөкләү икәнлеге дә ачыклана төшә кебек.

Илле яшь — язучы өчен күп гомер түгел, иҗаты һәм эшчәнлеге төпле юнәлеш алып ныгыган әдипнең, художник һәм гражданин буларак, тәмам җитлегеп өлгергән чоры. Ә инде тәнкыйть жанрында эшләүче әдипләргә килгәндә, бу караш хакыйкатькә тагы да якынрак булса кирәк. Чөнки тәнкыйтьче өчен талант һәм югары зәвыкка ия булу гына аз, бары тик тәҗрибә һәм озакка сузылган даими хәзерлек нәтиҗәсендә генә ирешелә торган зирәклек, сизгерлек һәм кайгыртучанлык сыйфатларының да

булуы шарт. Шуңа күрә тәнкыйтьченең илле еллыгын билгеләп үткәндә, әле йомгак ясау нәтиҗәләр ясау ихтыяҗы ул кадәр үк зур түгел.

һәр әдип һәм тәнкыйтьченең аеруча үз иткән бер иҗат юнәлеше яисә темасы була. Азат Әхмәдуллин өчен ул — Фәтхи Бурнаш иҗаты. Күренекле драматург һәм шагыйрь, тәнкыйтьче һәм җәмәгать эшлеклесе Ф. Бурнашның әдәбиятыбыз культурабыз үсешендә кабатланмас олы урыны бар. Яңа тормыш һәм социалистик эчтәлекле яңа әдәбият өчен көрәш елларын аның калку шәхесе һәм үзенчәлекле иҗатыннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Илленче еллар уртасында беренче иҗади тәҗрибәләрен ясаган яшь тәнкыйтьчене менә шушы фигураның иҗаты бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән булу үзенә җәлеп итә. һәм тора-бара А. Әхмәдуллин Бурнашның әдәби эшчәнлеге белән чын мәгънәсендә мавыгып китә: әдипнең драматургиясен өйрәнеп, кандидатлык диссертациясе яклый, аның иҗаты һәм әдәби-эстетик эзләнүләре хакында дистәләгән мәкалә һәм хезмәтләр язып, республика матбугатында һәм төрле фәнни җыентыкларда бастыра. Ә инде 1967 нче елда китап нәшрияты аның монографик хезмәте — «Фәтхи Бурнаш» дип исемләнгән беренче китабын дөньяга чыгара. Бу — тәнкыйтьче һәм галимнең дистә елга якын сузылган җитди эзләнүләре һәм фидакарь хезмәте нәтиҗәсе була. Китапның әдәби һәм гыйльми җәмәгатьчелек тарафыннан, тулаем, туплап каршы алынуы авторны яңа һәм тагы да зуррак иҗади эзләнүләргә рухландыра.

Язмышын фән һәм әдәбият-сәнгать дөньялары белән бәйләгән А. Әхмәдуллин ул елларда инде Г. Ибраһимов исемендәге Тел әдәбият һәм тарих институтында гыйльми секретарь булып эшли. Ә тагы берничә елдан, кешеләр белән мөгамәләдә үтә мөлаем һәм зур оештыру сәләтенә ия булган галим шул ук институт директорының фәнни эшләр буенча урынбасары итеп билгеләнә. Ләкин хезмәте һәм вазифалары никадәр генә катлаулы һәм җаваплы булмасын, ул үзенең эшен берөзлексез әдәби һәм гыйльми иҗат белән гармонияле төстә чиратлаштырып бара. Ф. Бурнаш иҗатын өйрәнүдән башланган кызыксыну аны тора-бара тулысы белән диярлек бер жанр — драматургия белән бәйли. Ләкин инде бу кызыксыну, вакыт һәм пространствода берөзлексез киңәя һәм зурая барып, татар совет драматургиясен тулаем колачлап ала. Тәнкыйтьчене татар драматургиясенең Г. Камал һәм Г. Колахметовлардан килгән реалистик традицияләре рухландыра, К. Тинчурин, М. Фәйзи һәм Т. Гыйззәтләр алып килгән новаторлык чалымнары уйландыра, Н. Исәнбәт, Р. Ишморат һәм Х. Вахит әсәрләренең характерлы үзенчәлекләре җәлеп итә. Ул да түгел бүгенге драматургиябезнезен билгеләүчеләрнең иң күренеклесе Т. Миңнуллинның һәр яңа әсәре, аларда күтәрелгән заманча актуаль проблемалар аны янә кулына каләм алырга мәҗбүр итә. А. Гыйләҗев, И. Юзеев, Г. Ахунов һәм Д. Вәлиевнең иҗат индивидуальлекләре, татар драматургиясенең алар мисалында торган саен киңрәк аудитория яулый баруы куандыра. һәм драматургиянең әдәбиятыбызда иң актив жанрларның берсенә әверелә барып, аның сафларына Р. Батулла, Ә. Гаффар, Р. Хәмид, Ф. Садриев, Ю. Сафиуллин кебек яшьләрнең күпләп килүе тәнкыйтьченең киләчәккә ышанычын тагы да үстерә төшә.

«Ничек сурәтләргә сине, замандаш?» (1976) һәм Б. Гыйззәт, И. Илялова белән берлектә язылган «Татар совет театры» исемле хезмәтләре галим һәм тәнкыйтьченең торган саен киңәя һәм фәнни-теоретик җәһәттән тирәнәя барган иҗатының чираттагы дәлилләре булды. Бигрәк тә аларның беренчесе оригиналь хезмәт булуы белән аерылып тора. Традицияләргә игътибарлы булган хәлдә, автор бүгенге көн драматургиясе һәм сәхнә сәнгатен аеруча борчыган проблеманы — заман герое проблемасын үзәккә алып тикшерә. Шуңа күрә дә аның әһәмияте конкрет әсәрләргә бирелгән бәя һәм аерым драматурглар иҗаты турындагы уйланулар белән генә чикләнми, ә, барыннан да элек, драматургияне жанр буларак тулаем күзаллап, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында җитди кайгыртып язылган булуы белән игътибарга лаек.

Сәхнәдә замандаш образын күрсәтү проблемасы хакындагы уйланулардан гыйбарәт булган бу хезмәт — формасы җәһәтеннән оригинальлеге белән дә җәлеп итә. Татар совет драматургиясе һәм аның аерым жанрлары үсешендә традицияләр һәм новаторлык, аларның үзара мөнәсәбәте, сәхнә әсәрләренең сюжет, конфликт, композиция һәм стиль үзенчәлекләре турында сөйләшүнең фәнни-теоретик югарылыкта алып барылуы китапның мавыктыргыч һәм җиңел укылуына зыян китерми. Тәнкыйть-

че моңарга ничек ирешкән соң? Ул тегә янсә бу теоретик мәсьәлә уңаена уйланганда, укучы һәм тамашачының турыдан-туры үзенә мөрәҗәгать итеп аңарга таныш булган сәхнә әсәрләреннән җанлы мисаллар китерә-китерә, үз иткәндәй гади генә фикер алыша белә. Аны мавыктыра һәм уйлануларга чакыра.

Әлеге стиль үзенчәлеге һәм иҗат алымы Азат Әхмәдуллинның башка хезмәтләре һәм мәкаләләрендә дә дәвам итеп, березлексез камилләшә һәм байый бара. Моны бигрәк тә аның соңгы китапларыннан «Сәхнә әдәбияты һәм тормыш» (1980) мисалында искәрергә була. Бүгенге сәхнә проблемалары һәм драматургия язмышына битараф булмаган укучы өчен мавыктыргыч һәм җанлы тел белән язылган бу җыентыкта уйлану, фикер йөртү һәм хәтта автор белән бәхәсләшү өчен дә мул җирлек бар. Миңа калса, боларның соңгысы — тәнкыйть хезмәтендә бәхәс өчен җирлек булу — аеруча әһәмиятле. Күптән мәгълүм хакыйкать сөйләүдә генә түгел, ә менә үз укучыңны бәхәскә чакыру, аны мөстәкыйль уйлануга, нәтиҗәләр ясауга җәлеп итү, иртүдә дә булса кирәк бүгенге тәнкыйтьнең бурычы.

А. Әхмәдуллин рус, татар һәм башкорт телләрендә басылган йөзләгән фәнни-теоретик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы, дистәләгән җыентыкларның төзүчесе, фәнни редакторы, татар әдәбияты классикларыннан байтак кына әдипләрнең сайланма әсәрләре укучыга аның сүз башлары белән тәкъдим ителгән. Гомумән, тәнкыйтьче һәм галим соңгы өч дистә ел эчендә березлексез әдәби процессның уртасында, үзәк артериясендә булган. Моны аның иҗатында гына түгел, ә тынгысыз җәмәгать эшчәнлеге мисалында да ачык күрергә мөмкин. Зур фәнни институтның җитәкчеләреннән берсе булган тәнкыйтьче 1974 елдан бирле Татарстан Язучылар союзы идарәсе Президиумы члены һәм СССР литфондының Татарстан бүлеге председателе вазифаларын да намуслы рәвештә башкарып килә һәм төрле характердагы күп кенә башка җәмәгать эшләре алып бара.

Бер үк вакытта ул — мәктәпләр өчен татар әдәбиятыннан дәреслек һәм хрестоматияләр төзүчеләрнең дә берсе. Җитмешенче еллар башыннан ук бу үтә җаваплы һәм җитди эшне намуслы тестә башкарып килә. Тормышның һәм әдәбиятның бүгенгесе белән генә мавыгып түгел, ә киләчәген дә кайгыртып эшләгән һәм иҗат иткән А. Әхмәдуллинның әле соңгы елларда гына В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире булып билгеләнүе дә һич очраклы түгел. Чөнки тормышка, социалистик чынбарлыгыбыз һәм әдәбиятка бөтен җаны белән гашыйк булган, халыкка һәм партиягә хезмәт итүне үзенең намус эше саналган галим һәм тәнкыйтьче һәрчак һәм һәр урында үз-үзен аямыйча эшләргә күнеккән. Әдәбиятыбыз һәм культурабызга яшь талантлар тәрбияләүгә аеруча зур өлеш кертеп килгән кафедра җитәкчесенең бүгенге татар әдәби тәнкыйтендә җитди сүз әйтеп килгән, әдәбиятның үткәненә ихтирамлы, киләчәгенә зур өметләр һәм ышаныч баглаган әдип һәм галим булуы — куанычлы, матур күренеш.

Татар телендә беренче сәхнә әсәре куелу, үз вакытында, бөтен Казанны шаулаткан вакыйга булган (Г. Камалның «Беренче театр»ында шул кеннәрнең шау-шулы тантанасы чагылыш тапкан.). Бүген дә республикабыз шәһәрләре һәм авылларында театрга, сәхнә әдәбиятына мәхәббәт әйтеп бетергесез зур. Заллар гадәттә шыгрым тулы була. Яңа сәхнә әсәре язылу, аның сәхнәләштерелүе әле дә республика матбугатында куанычлы факт буларак билгеләнә бара. Мондый шатлыклы вакыйгаларга театр сәнгатебез киләчәктә дә зарыктырмас, бәйрәмнәр кабатлана торыр. Тамашачы яңа бәйрәмнәргә җыена, яңа тантана көтә. Менә шул бәйрәм көннәрендә, барысын да энә күзеннән үткәргәндәй күңелдән кичереп, сәхнә әдәбияты һәм сәнгатенең чорга һәм халкыбызга лаеклы булуын дәгъвалап иҗат иткән әдипләр дә барлыгын без еш кына искәрмибез кебек. Алар — театр һәм драматургия тәнкыйтьчеләре. Әйдәгез, бүген — 50 еллык бәйрәме көннәрендә аларның берсенә һәм, мөгаен, иң күренеклесенә — Азат Әхмәдуллинга яңа иҗат уңышлары телик!

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ

# ӘШРӘФ СИНЯЕВАНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ



Әшрәф Синяева Рязань губернасының Касыйм шәһәрендә туган. Атасы Гатаулла Вятка губернасында алпавытка эшкә кергәч, алар шул губернада тора башлыйлар. Әшрәф Алабуга гимназиясендә укый, аннары Петербургта артист Петровскийның сәхнә сәнгате курсларын тәмамлый. Режиссер Мейерхольд җитәкчелегендә* һәм Александринский театрында беркадәр тәҗрибә туплагач, ул Петрозаводск шәһәрендәге рус театрында эшли башлый.

1917 елның көзендә Г. Кариев Әшрәфне «Сәйяр»га чакырып ала. Ә. Синяеваның «Сәйяр»га килүе труппа эшенә шактый зур йогынты ясый. Ул тәрҗемә әсәрләрендә дә, татар пьесалары буенча куелган спектакльләрдә дә кызыклы образлар иҗат итә.

«Татарның сәхнә һәм әдәбиятын бик сөйгән, рус һәм Европа сәнгатен нык тикшереп, үзенең театр сәнгатен теория һәм практический яктан югары мәктәп тәрбиясе белән ныгыткан Синяева үзенең беренче чыгышларында ук дикъкатьне җәлеп итәрлек иде. Һәм тиз вакыт эчендә ул татарның күздә тотылган беренче уйнаучыларыннан булып танылa. Сәхнә галәмендә тулы мәктәп тәрбиясе белән коралланып җитешкән булу ягыннан ул безнең театрда беренче кеше иде» — дип яза Ф. Бурнаш. («Кызыл Татарстан» газетасы, 1925 ел, 2 апрель.)

«Сәйяр» труппасы «Галиябану», «Таһир-Зөһрә», «Мещаннар», «Чия бакчасы», «Соңгы сәлам» кебек катлаулы пьесаларны сәхнәгә куя алган икән, биредә Ә. Синяеваның шактый зур тәҗрибә белән килүе нәтиҗәсе дә бар. К. Тинчуринның «Соңгы сәлам» драмасындагы Ольга образы Әшрәф ханым өчен әеруча уңышлы рольләрнең берсе була. Кешегә бик тиз ышанучан, сөю тойгысын әле яңа гына татый башлаган кызның ягымлы образы артистканы да, тамашачыларны да дулкынландыра, үзенә җәлеп итә.

1918 елның көзендә Казанда Коммунистлар бюросы янында төзелгән яңа труппа кызыл гаскәр сугышчылары һәм эшчеләр өчен спектакльләр куя башлый. Ә. Синяева шушы труппада эшли. Артистканың ул еллардагы иҗади эшчәнлеге, гомуман, хәрби частьләр каршында оештырылган сәхнә коллективлары белән бәйле. Әшрәф ханым үзенең күпкырлы таланты белән әлеге труппаларның уңышлы чыгыш ясавына зур өлеш кертә.

Оештыру-иҗат эшчәнлеге белән бәйле сәхәтләрнең берсендә Ә. Синяева тиф авыруы белән чирләп китә. Сәламәтлеге таман какшауга да карамастан, тәҗрибәле артистка яшьләр арасында театр эшен дәвам иттерә. 1925 елның 30 мартында Әшрәф ханым вафат була.

Хәсән ГОБӘЙДУЛЛИН.

# ОНЫТЫЛМАС ОЧРАШУ

Немец-фашистлар үзләренең явыз Барбаросс планы нигезендә, Бөек Октябрь революциясенең бишеге Ленинградны җир белән тигезләү, аны диңгезгә күмдерергә хыялланган көннәр иде.

1942 елның январенда рота политругы булып атакага барган чагымда мин каты яраландым. Пермь өлкәсенең Чусовой шәһәре госпиталендә аңыма килдем. Дошман пулясы уң як кулбашымны үтәли тишеп чыккан, үпкәгә тигән. Врачларның алтын куллары ярдәмендә яңадан сафка бастым һәм мин тагын Волхов фронтына элэктем. Әмма, ярам ныклап төзәлеп бетмәгәнгә күрә, алгы сызыкка җибәрмичә, Политидарәнең кадрлар бүлегенә билгеләделәр.

Кояшлы март һәм апрель көннәре күген дошман самолетлары бик еш бозыпямьсезләп торды. Кая карама — янгын, җимереклек. Шунысы бигрәк тә хәтердә калган: икенче апрель таңында, фашист самолетлары Малая Вишера поселогы өстендә козгыннар өере булып очты. Үзем торган йортның гөрселдәп җимерелүенә куркып уяныл киттем. Өйнең почмагы юк, дүрт кеше кан эчендә ята, ә читтәрәк свастикалы самолет янып ята...

Май аенда да хәлләр җиңеләймәде. Политидарәдә эш туктаусыз кайнап тора: политхезмәткәрләрнең шәхси эшләрен өйрәнәм, үтә җитди махсус заданиеләр үтим.

1942 елның март азагында Муса Җәлиловны очраттым. Көннәр җылына, карлар эреп, урамда гөрләвекләр чылтырап ага башлаган чак иде. Госпитальдән кышкы киемдә килгән идем, аяктагы киез пима эзе баскан саен ярылып ятып арттан кала. Складта аяк киемен алыштыру өчен бер кәгазь язып бирделәр. Иң әүвәл, кулга талон тотып, ашханәгә киттем. Андагы кешеләрнең күбесе йолдызлы политработниклар иде, шулар арасында Муса да бар иде. Аяктагы пимага карап, минем яңа кеше икәнемне тиз күрделәр.

Уртача буйлы, ачык йөзле өлкән политрук миңа табан бер-ике адым атлап, монда да безнең якташлар — татар егетләре бар икән дип, миңа кулын сузды.

— Таныш булыйк! Мин Татарстаннан — Җәлилов Муса булам. Бирелә март башыннан бирле, әле резервта, тиздән назначение бирәчәкләр.

Мин үз ризыгымны тиз генә ашап чыгуга, алар ашханә янында юк иде инде.

1942 елның өченче апрель көнендә кичкә табан ул политидарәнең кадрлар бүлегенә килеп керде. Кадрлар бүлеге начальнигы полк комиссары Патрушев белән йомышларын юллады да безнең бүлмәгә керде. Һәркем белән елмаеп күреште, аннан соң минем яныма килеп күрешкәч:

— Гафият, теләгең булса, әйдә, үзем кайда торганымны күрсәтәм. Монда якында гына. Кирәк булуы мөмкин,— диде.

Ул чакта Малая Вишерада штаб кешеләрен төрле өйләргә куеп торалар иде. Муса абый мине Набережный урамындагы бер йортка алып килде. Мин дә шуннан ерак түгел тора идем. Юлда барганда ул минем кайчан, кайда политмәктәп тәмамлавымны һәм сугышчан хәзерлегемне сорашты. Кыскача сөйләп бирдем. Шулай ук шушы елның январь ае башында Чудово тимер юл станциясе янында һөҗүмгә барганда каты яраланып, госпитальдә дәваланганнан соң яңадан бу фронтка кайтуымны әйттем. Игътибар белән тыңлады, үзе дә Казандагы гаиләсе — хатыны һәм Чулпан исемле кечкенә кызын сагынуы турында сөйләде.

— Беләсеңме, Гафият,— диде ул,— мин берничә көн генә элек алгы сызыкта

булып кайттым. Солдатларыбыз батыр, куркусыз. Дошманга нәфрәтләре чиксез-чамасыз зур.

Апрель башы иде. Минем начальнигым Иван Тимофеевич иртән киңәшмәдән кайтты да:

— Синең якташың, әлкән политрук Җәлилов Икенче Удар Армиягә билгеләнгән,— дип хәбәр итте.

Күп тә үтмәде, Муса Җәлил бик җәһәт кенә безнең бүлмәгә килеп керде. Кәефе күтәренке иде. Сөйләшеп утырдык.

— Мин эшне «Отвага» газетасында дәвам итәрмен, ахры. Редакция «Лесной Бор» дигән зур бер пунктка якындагы урман эчендә урнашкан. Кирәк була калсам, «Полевая почта»га язгыгыз,— дип саубуллашты ул.

Мин озата чыктым.

Күп сөйләшеп торырга вакыт бик тар иде.

Бу чорда Армиянең политбүлек начальнигы бригада комиссары И. И. Гарус, хәрби совет члены дивизия комиссары И. В. Зуев иде, Апрель азакларына чаклы Икенче Удар армиянең командиры генерал-лейтенант Н. К. Клыков булды.

Армия хәрби советы карамагындагы «Отвага» газетасы гаскәриләрне дошманны тар-мар итүгә рухландырып зур тәрбия эше алып барды.

Ил өчен иң авыр бу көннәрдә Муса Җәлил газета битләрендә совет сугышчыларының батырлыгын сокланып укырлык итеп күп саен язып тора. Ул көннәрдә төп бурыч Ленинград, Псков, Новгород өлкәләрен дошманнан азат итү иде. Синявино, Мга станцияләрен азат итү беренче бурычтан саналды.

...Урман һәм чокырлар кар сулары белән тулды, сазлыклар үтә алмаслыкка әйләнде. Автомашиналар белән узарга һич мөмкин түгел. Азык-төлек, сугыш кирәк-яракларын сугышчылар күбесенчә күтәреп ташырга мәҗбүр иде.

Ләкин немец фашистлары, яңа көчләр туплап, Икенче армия узасы бу юлны да кисте. Эшләр яңадан чамасыз авырлашты. Шуңа күрә Филева Луггтан алып Мясной Борга чаклы тар колеялы тимер юл төзелде. Төзелеш сазлык эчендә, дошманның көчле уты астында барды. Бу үзе бер зур батырлык иде. Эш май башында тәгәлләнде. Частьларга азык-төлек һәм сугыш кирәк-яраклары кертү беркадәр җиңеләйде. Ун меңнән артык яралы госпитальгә озатылды.

Муса Җәлил бу көннәрдә, үзен һич аямыйча, көне-төне диярлек алгы сызыкта булды.

Әнә шундый авыр көннәрнең берсендә, ягъни май аеның беренче яртысында бик ашыгыч һәм кыска гына вакытка Малая Вишерага килгәч, Муса Җәлилне тагын очраттым. Аның бил каешында кабуралы «ТТ» пистолеты, командирлар сумкасы таккан, аерым сумкада Ф-1 гранаталары. Бик алҗыган, арган-талган кыяфәтле күренә — хәтсез вакыт ял итмәгән, күрәсең.

— Менә шулай, Гафият дус,— диде ул,— канлы көрәш юлында очрашулар көтмәгәндә дә килеп чыккалый икән әле. Кичә генә алгы сызыкта идем, бүген сезнең белән күрешәбез. Сугышчыларның батырлыгына сокланып туялмыйм. Бүгенге алгы сызыктагы һәр сугышчыга герой исеме бирерлек,— дип елмаеп куйды. Очрашу шулай берничә генә минут дәвам итте. У-2 самолеты янына килеп җиткәндә Муса Җәлилнең кул сәгатенә карап алуыннан аерылышу минутлары җиткәнен аңладым. Муса агай, кулымны бик каты кысып: «Киләсе очрашуга кадәр»,— диде дә самолетка таба атлады.

Кызганычка каршы, безгә бүтән очрашу насыйп булмады. Фашист илбасарлар безнең гаскәрләрнең чолганыштагыларын юк итү максатында зур көч туплады. Безнекеләр моңа каһарманнарча каршылык күрсәтте.

Ә 20 майдан башлап исә чолганышта калган частьларга ярдәм итү, аларны Волховның көнчыгыш ягына күчерү бурычы куелды. Кавалерия корпусы, авыр артиллерия, тагын бүтән кайбер берләшмәләр, дошман ныгытмаларын җимереп, тар бер участокта моның өчен юл ачтылар.

Эчке сызыкта калган башка частьларны туплау бурычын хәрби совет члены И. В. Зуев башкарды. Муса Җәлил дә шунда булган. Әмма көчләр тигез булмаганга, дошман үзенең камау боҗрасын кысканнан-кыса барды. Июнь ае урталарында политбүлектән бирген телеграммада болай диелгән иде:

«13 июньдә немец фашистлары 92 нче дивизия өстенә 30 танк җибәрде. Шуларның 18 е яндырылды, дүрт самолет бәреп төшерелде һәм 1200 фашист юк ителде...»

Кызганычка каршы, дошманны кысрыклап ясалган тар гына «коридор» да бөтенләй ябылды. Камалудан төркемләп чыгу да мөмкин түгел иде инде.

Июль аенда А. А. Власовның илгә хыянәте бөтен фронтка билгеле булды. Аңа карата нәфрәт чиксез иде.

И. В. Зуев һәм өлкән политрук Муса Җәлилнең язмышы бер мине генә түгел, аны белгән һәр солдатның, командирның күңелен борчыды. Төрле сүзләр йөрде, әмма Муса Җәлилнең намусы сафлыгына мин бер генә минутка да шикләнмәдем, дәреслекнең өскә чыгачагына өметемне өзмәдем.

> Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
> Муса инде үлгән дисәләр,
> Син ышанма, бәгърем!
> Мондый сүзне
> Дуслар әйтмәс сине сөйсәләр...

Бу сүзләрне мин күз яшьләрсез укый алмыйм. Бу аның тормыш иптәше алдында гына түгел, бөтен халык, Туган ил алдында биргән изге анты булып яңгырый...

Шагыйрьгә тирән ихтирамымны белдереп, бу язмаларымны мин дә хәлемнән килгәнчә шигырьгә салынган юллар белән тәмамлыйсым килде.

### Өлкән политрукка

*Муса Җәлилгә*

> ...Ул елларның хатирәсе истә —
> Бергә узган көрәш юллары,
> Йөрәкләрдә тирән эз калдырган
> Сөйгән Татарстан уллары.
> Менә килдем — «Казан утлары»на —
> Дуслар сине, Муса, табалар.
> Үткән канлы көрәш юлын уйлап,
> Күз яшьләре җиргә тамалар...
>
> Кердең, чордаш, тарих битләренә,
> Изге юлда булды язмышың.
> Батырлыкны синең төстә күреп,
> Каршы алдым Җиңү балкышын.
> Мәрмәрләргә бик күп сүз уйды ил
> Һәм җырлана җырың табында.
> Кабатлана исемең — кабатланмас
> Гарасатлы көннәр тагын да!..

**Гафият ӘЮПОВ,**
отставкадагы полковник.
Уфа.

# А. Н. АННЕНСКАЯ КАЗАНДА

Үз чорының танылган балалар язучысы А. Н. Анненская (1840—1915)— кыз чактагы фамилиясе Ткачева — тормышы Казан шәһәре белән дә бәйләнгән.

Александра Никитична алпавыт семьясында туып үсә, әмма аның алдагы бөтен тормышы демократик мохитта үтә. Ул — революцион народниклыкның мәшһүр идеологы, публицист һәм әдәби тәнкыйтьче П. Н. Ткачевның сеңелесе, прогрессив җәмәгать эшлеклесе, журналист һәм зур статистик Н. Ф. Анненскийның хатыны.

Инглиз, немец, француз телләрен бик яхшы белгән А. Н. Анненская гомере буена диярлек чит ил әдәбиятын тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. Ул Бичер-Стоуның «Том агай алачыгы», Оскар Уайльдның «Дориан Грей портреты романнарын, М. Твенның «Гекльберри Финн мажаралары»н тәрҗемә итә. Төрле тәрҗемәләргә һәм библиографик белешмә китапларына сүз башлары, С.-Петербургтагы югары Бестужев курсларының 25 еллыгына багышланган очерк авторы буларак та билгеле ул. Әмма А. Н. Анненская бигрәк тә балалар язучысы буларак популярлык казана. Ул XIX га-

сырның икенче яртысында балалар әдәбиятын демократлаштыру һәм андагы реалистик юнәлешне үстерүдә мөһим роль уйный. Тел-теш тидермәслек әдәпле геройлар турындагы төче-сентименталь хикәяләр урынына язучы социаль тигезсезлек, гаделсезлек картиналары дөрес тасвирланган әсәрләр иҗат итә.

Ул елларның педагогик һәм балалар журналларында, библиографик белешмәләрдә А. Н. Анненская әсәрләре балаларга уку өчен иң әйбәт дип тәкъдим ителә. Матбугат та аңа игътибар итә. Д. Дефоның «Робинзон Крузо» (1873) һәм Д. Гринвудның «Бәләкәй йолкыш» (1876) романнарын балалар өчен яраклаштырып эшкәртеп чыгарганнан соң А. Н. Анненская турында «Санкт-Петербургские ведомости», «Голос» газеталары, «Дело», «Русская жизнь» журналлары һ. б. язып чыга. А. Н. Анненская иҗатына «Отечественные записки» журналы да югары бәя бирә. «Абый һәм сеңел» (1880) повестена язылган рецензиядә аның китапларының кыйммәте педагогик тирәнлектә, гражданлык-патриотик пафоска ия булуда икәнлеге күрсәтелә. Анненскаяның хикәяләре, повесть һәм романнары яшь буында югары әхлакый сыйфатлар тәрбияләүгә булышлык итә. «Балалар язучысы,— дип яза «Отечественные записки» журналы,— балаларда кешеләр алдында бурычлы булу, аларга мәхәббәт, фидакарьлек, акыл һәм әхлак мөстәкыйльлеге — тормышта тапталган юллардан тыныч һәм гамьсез үтү максатлары өчен бик тә уңайсыз сыйфатлар тәрбияли. Анненская ханымның сюжеты бик катлаулы түгел: ул үзе өйрәткән нәрсәгә ышана. Аның көче — инанган моралист көче».[1]

Шунлыктан А. Н. Анненская әсәрләренең Ульяновлар гаиләсендә укылуы гаҗәп тә түгел. 1890 елның 7 ноябрендә М. И. Ульянова югары Бестужев курсларында укыган Ольга Ильиничнага болай дип яза: «Моңа кадәр мин Анненскаяның барлык хикәяләрен һәм тагын башка хикәяләр укыдым, ә кәзер әле нәрсәләр укыйсымны белмим»[2].

Анненская исеме балалар әдәбияты өлкәсендә эшләүче совет язучылары һәм галимнәре игътибарыннан да төшеп калган дип әйтеп булмый. 1910 елда Куоккалада булу чорында Анненскаялар белән танышкан К. И. Чуковский аның турында якты хатирәләр калдыра. Балалар язучысы һәм әдәбият галиме Анненскаяның «үз рухи шәхесе формалашкан бөек эпоха идеяләре белән сугарылган»[3] китапларына югары бәя бирә.

Балалар әдәбияты турындагы бөтен дәреслекләрдә дә диярлек Анненскаяның әдәби мирасына мәкаләләр багышлана. Әмма бу кыска-кыска гына мәкаләләрдә балалар язучысының иҗатына, әлбәттә, тулы характеристика бирелә алмый. Аларда аның балалар өчен язылган китапларының гомуми идея юнәлеше генә ачыла; хатын-кызлар иҗтимагый хәрәкәте белән бәйләнеше, кызлар өчен атап язылган повестьларның проблематикасына төп игътибар юнәлдерелә. Революциягә кадәрге чыганакларда да Анненскаяның тулы фәнни биографиясе ачып бирелми. Аның Петербургта, Казанда һәм Нижний Новгородта яшәве турында кыскача мәгълүматлар автобиографиясендә бар, соңыннан алар сүзгә-сүз диярлек некрологларда, био-библиографик белешмәлекләрдә, совет чорында басылган дәреслекләрдә дә кабатлана. Бу мәкаләдә Казан чоры турындагы биографик мәгълүматлар А. Н. Анненскаяның, аның туганының кызы Т. А. Богдановичның истәлекләре, шулай ук Татарстан АССР Үзәк дәүләт архивы материаллары белән шактый тулыландырыла.

Төп Петербург кешесе дип әйтерлек А. Н. Анненская губерна шәһәре Казанга ничек килеп эләккән соң?

Эш шунда: аның ире Н. Ф. Анненскийның революцион подполье даирәләре белән бәйләнештә торуы хөкүмәтнең эзәрлекләүләренә сәбәп булып тора. Александра Никитична өйләрендә тентү ясауларны да, иренең кулга алынуларын да гаҗәп батыр кичерә, к⋯алып калмый. Ул 70 нче елларның кыю фикерле хатын-кызларыннан берсе була; «Р⋯ хатын-кызлары» дигән поэмасында декабристлар хатыннары образында Н. А. Не⋯расов әнә шундый хатын-кызлар образларын искиткеч осталык белән ачып бирә.

---

[1] Отечественные записки, 1880, 253 т., № 11, 11 бүлек, 228—229 битләр.
[2] Переписка семьи Ульяновых. 1883—1917. М., Политиздат, 1969, 41 бит.
[3] Чуковский К. И. Короленко в кругу друзей. «Короленко в воспоминаниях современников» дигән китапта. М., 1962, 416—418 битләр.

Себергә җибәрелгән Н. Ф. Анненский беркадәр вакыт Вышний Волочектагы пересылка төрмәсендә тотыла, шунда инде ул В. Г. Короленко белән таныша. Шушы танышлык алар арасындагы озакка сузылган дуслыкның башы була. Бу хакта В. Г. Короленко үзе болай дип яза: «Анненский һәм аның гаиләсе белән мин дә, минем янга килгән әнием һәм сеңлем дә шулкадәр нык дуслашырга өлгердек, бу дуслык гомерлеккә китте. Бергә ябылып яту яки тоткынлыктагылар янына бергә бару шартларында башланган мондый элемтәләр гомумән бик нык булучан, һәм мин, Анненский белән бәлки әле бер урынга эләгербез, дип хыялланам. Александра Никитична, ул вакытта инде танылган балалар язучысы, туганының кызы белән бергә иреннән калмаска карар итте» [1].

Әмма Короленконың хыялы тормышка ашмый. Анненскийны Көнбатыш Себергә җибәрәләр, ә язучы Көнчыгыш Себердә сөргендә була.

Т. А. Богданович соңрак болай дип искә ала: Анненскийның Петербургта калган дуслары аны сөргеннән коткару өчен бик ныклап артыннан йөриләр, һәм бу уңышлы барып чыга. 1880 елның декабрь ахырында Анненскийларга, Петербург, Мәскәү һәм Таврида губерналарыннан кала, Россиянең Европа өлешендә яшәргә хокук бирелә. Яшәү урыны итеп алар үзләре Казанны сайлый. Беренчедән, бире дә Анненскийның зур җирбиләүче Крамерга кияүгә чыккан апасы яши, икенчедән, Казан аларны юл өстендәге университетлы зур шәһәр буларак та үзенә тарта.

Эчке эшләр министрлыгының дәүләт полициясе департаменты яшерен күрсәтмәсендә Казан губернаторына түбәндәгеләр хәбәр ителә: Тобольск губернаторы Н. Ф. Анненскийга Себердән үз исәбенә китәргә рөхсәт биргән. Ул, үз теләгенә карап, Тверьга яки Казанга конвойсыз барырга тиеш. Аңардан юлда туктамаска һәм барып җиткәч җирле губернатор каршына килергә дип имза алынган.

Анненскийлар «юлда туктамаска» дигән күрсәтмәне үтәмиләр. Александра Никитичнаның истәлекләренә караганда, юлда аларга танышлары очрый; Ялуторовскида бераз туктыйлар, анда 1 март һөҗүмендә катнашучыларның җәзалануы турында ишетәләр; аннары Екатеринбургта Т. А. Богдановичның әтисе А. Криль янында тукталалар. А. Криль бирердә Урал тимер юлының контролеры булып эшли, полиция аңардан да политик яктан ышанычсыз дип шикләнә.

Анненскийлар Казанга 1881 елның 22 мартында караңгы реакция чорында килеп төшәләр. Казан полицмейстеры губернаторга болай дип хәбәр итә: «Надворный советник Николай Анненский Казанга килде һәм Покровская урамында (хәзер Зур Кызыл урам — М. М.), Де-Прейс йортында, җирбиләүче Крамер квартирасында тукталды» [2]. Аның ачык полиция күзәтүе астына алынуы да хәбәр ителә.

80 елларның авыр иҗтимагый атмосферасы, фикердәш дуслары һәм танышлары булмау Анненскийларның рухи халәтләренә бик авыр йогынты ясый. Александра Никитична истәлекләренә караганда, хәтта замандашлары оптимист кеше дип йөрткән, нинди хәлләрдә дә күңелен күтәрә белгән Николай Федорович та боегып кала. Шәһәр үзе Анненскийларда бик күңелсез тәэсир калдыра. «Земство бик артта калган аллавытлар кулында иде,— дип яза Анненская,— шәһәр үзидарәсе үзен бер яклап та күрсәтми; студентлар өлкән иптәшләре мактанып сөйләгән җыелып эчү, типтерү чорыннан чыгып кына киләләр. Интеллигенция катлавы бик юка, шәһәрдә бер бәләкәй газета үлле-мәлле чыгып килә, театр еш кына буш була» [3].

1881 елның июнендә Казанга килгән Г. Успенский белән очрашу Анненскийлар өчен зур шатлык була. Ул вакытта «Отечественные записки» редакциясенә җитәкчелек иткән М. Е. Салтыков-Щедринга хатында Успенский болай дип яза: «Казанда мин Н. Ф. Анненский һәм В. В. Лесевичны күрдем... Анненский бик авыру... Икесе дә бик күп кызык нәрсәләр сөйлиләр, көзгә «Отечественные записки»га кызыклы әйберләр җибәрәчәкләр» [4].

Хәтта телгә алынган Владимир Викторович Лесевич танылган журналист һәм әдәби тәнкыйтьче, Анненскийларның Петербургтагы дусты була, аның белән Казанда оч-

---

[1] Короленко В. Г. История моего современника. Әсәрләр, 7 том, 1955, 145 бит.
[2] ТАССР УДА, 1 ф., 3 тасв., 5224 саклау бер., 3 кәгазь.
[3] Анненская А. Н. Из прошлых лет. (Воспоминания о Н. Ф. Анненском.) Русское богатство, 1913, № 2, 57 бит.
[4] Успенский Г. И. 1881 елның 29 июнендә язылган хат. Әсәрләрнең тулы җыентыгы. 13 т. М., 1951, 259 бит.

рашалар. Николай Федорович кебек, ул да кулга алынган була һәм Енисейскида сөргендә яши. Сөргеннән соң ул, башкала губерналарыннан кала, Россиянең Европа өлешендәге берәр губернада яшәргә рөхсәт ала. Лесевичлар яшәү урыны итеп Полтаваны сайлыйлар, ләкин Владимир Викторович юлда авырып китә һәм властьларның рөхсәтен алып, семьясы белән Казанда туктала. 1881 елның көзендә Лесевичлар һәм Анненскийлар бер квартирага урнашалар.

Полициянең ачык күзәтүе астында яшәгән Н. Ф. Анненский җирле властьларның махсус рөхсәтеннән башка Казаннан китеп йөри алмый. Александра Никитична исә, 1882 елның башында, чыгып йөрү тыелмаган булгач, Петербургка барып кайта. Ә сәбәбе шул: Анненскийларның үз балалары булмый. Ләкин замандашлары алар өендә һәрчак кем дә булса сыенуын, үзенә урын табуын әйтеп үтәләр. Александра Никитична үзе дә өйләрендә һәрвакыт балалар булганлыгын искә ала, аларның кайсысы кайдан икәнен ул кайчакта тегәл генә әйтә дә алмый. Анненская иренең кече энесе Иннокентий Анненскийны тәрбияләүдә зур гына роль уйный. Соңыннан символист шагыйрь булган И. Анненский, яшьтән ата-анасыз калып, турыдан-туры Александра Никитична кул астында тәрбияләнеп үсә. Ул үзе дә абыйсы Николай Федорович һәм җиңгәсе Александра Никитична аркасында гына «интеллигент» булып китүе турында яза. «Сестре» дип исемләнгән шигырен Александра Никитична истәлегенә багышлый, анда ул үз күңеленә тирән эз салган рухи остазының поэтик образын тудыра.

Т. А. Богданович үзенең истәлекләрендә язганча, Анненскийлар семьясында 10 яшендә әтисе Бессарабиядән китергән Ваня Емельянов дигән малай тәрбияләнә. Ул яшьтән үк революцион романтика белән мавыгып китә һәм өлкән классларда укучы яшьләрнең революцион түгәрәкләреннән берсенә керә. Николай Федорович сөргенгә озатылган чакта Ваня реаль училищены тәмамлый һәм Бельгиягә югары техник мәктәпкә җибәрелә, Анненскийлар аның турында озак вакыт берни дә белмиләр. Ә хәзер исә аның Петербургта кулга алынуы турында хәбәр килә һәм бу Анненскийларны бик борчуга сала. Балалар яшьтән үк тормышның төрле ягын күреп үссен дип исәпләгән Александра Никитична, үзе белән туганының кызын да алып, Петербургка китә. «Улы кебек яраткан» Емельяновка ничек булса да ярдәм итәргә өметләнә. Әмма, башкалага килгәч, аңа берничек тә ярдәм итеп булмасына ышана. Чөнки Емельянов «беренче мартчыларга бәйле революцион вакыйгаларда турыдан-туры катнашучы итеп кулга алынган була. Аңа суд инде булган һәм ул үлем җәзасына хөкем ителгән, аннары җәза, балигъ булмаганлык сәбәпле, гомерлек каторга белән алыштырыла». «Әнисен алмаштырган тәрбияче буларак» Анненскаяга, хөкем карары игълан ителгәннән соң, Емельянов белән күрешергә рөхсәт итәләр. Күрешү вакытында Т. А. Богданович та була. Аның истәлекләреннән күренгәнчә, Емельянов бомба ыргытучылардан берсе була. Беренче ике бомба — Гриневецкийныкы һәм Рысаковныкы — максатка китермәсә, үзендәге бомбаны ташларга дип, ул Екатерина каналында көтеп тора. Әмма беренче бомбадан атлар һәм кучер үлә, икенчесе Александр II нең аякларын өзә. Әйләнә-тирәдә булган кешеләр куркып качышып бетәләр, үлем ярасы алган патша канга батып ятып кала. Емельяновта патшага карата кызгану тойгысы уяна булса кирәк. Егет хәтта аны чанага күтәреп салышырга да ярдәм итә, патшаны алып киткәч кенә үзенең хәвефсезлеге турында исенә төшерә һәм конспиратив квартирага китә. «1 марттан соң әле Емельянов бер ел буена Петербургта яшеренеп яши, таркалган оешманы тергезергә ярдәм итә. Рысаковның ачыктан-ачык сөйләп бирүе Емельяновның патшаны үтерүдә катнашуын ачыклый, аның эзлиләр һәм ахыр чиктә табалар».[1]

Т. А. Богданович истәлекләрендә китергән фактлар Емельянов хакында беренче мартчылар турындагы кичкенә белешмәдә булган мәгълүматларны шактый дәрәҗәдә тулыландыра. Ул белешмәдә Емельяновның чыннан да бомба ыргытучыларның берсе икәнлеге генә әйтелә. Аның алга таба язмышы болай була: сроксыз каторганы ул 1889 елга кадәр Карада үтте; аннары, чыбыклар белән суктырып җәзалаудан һәм башка репрессияләрдән соң, Емельянов, башка күпләр кебек үк, ярлыкауларын үтенеп яза, төрмәдән азат ителә, Хабаровскига барып эләгә. Анда баштарак ул Ленага

---

[1] Богданович Т. А. Повесть моей жизни. Истәлекләр. В. И. Ленин исемендәге китапханә, кульязмалар бүлеге, 218 фонд, 363 катыргы, 49 бит.

шулай ук сөрелеп килгән миллионер П. Пьянковта укытучы, соңрак управляющий булып тора. 1916 елда Емельянов үлә.

Петербургка шушы барып кайтуны исәпкә алмаганда, А. Н. Анненская беркая да чыкмыйча Казанда яши һәм, үз сүзләре белән әйткәндә, алар Казанда «иң ышанычлы гражданнар кебек яшиләр». Шулай да жандармнар идарәсе Аннескийлар һәм Лесевичлар семьяларын даими күзәтү астында тота. Лесевичлар тиздән Полтавага китәләр.

Казанның яңа билгеләнгән губернаторы, тегенди-мондый хәл килеп чыкмагае дип, шәһәрне политик яктан ышанычсыз, күзәтү астында торган кешеләрдән тазартырга карар итә. Анненскийлар властьлар рөхсәте белән Зөядә Гладышевлар номерларына урнашалар, аннары М. А. Зайцев йортында яшиләр. Квартира юеш булып чыкканга, Анненскийлар туганнарының кызын анда тота алмыйлар — Казанда, Николай Федоровичның кардәшләрендә калдырырга мәҗбүр булалар. Александра Никитичнаны күп төрле йорт мәшәкатьләре күмә, аңа Зөя белән Казан арасында гел йөреп торырга туры килә. Николай Федоровичның ачык полиция күзәтүе срогы беткәч (1883 елның 9 сентябрендә) Анненскийлар бөтен семьялары белән Казанда, Поперечно-Красная (хәзер Кече Кызыл урам) урамында урнашалар.

А. Н. Анненская Казанга килгәндә инде формалашып беткән язучы була. Аның балалар язучысы булып формалашуы тулысынча диярлек «Семья и школа» дигән педагогик журналга бәйле; бу журнал Петербургта «Семейное чтение» һәм «Воспитание и обучение (родителям и воспитателям)» дигән ике кисәк булып чыгып килә. Анненская әсәрләренең күпчелеге журналның «Семейное счастье» дигән китабында 70 нче елларда һәм берәзы 80 нче елларда басыла. Шул ук елларда аның балалар өчен язган аерым әсәрләре һәм җыентыкларының да күпчелеге чыга: «Абый һәм сеңел» повесте (1880), «Анна» романы (1881), «Туганнарымның ике кызы» (дүрт хикәя: «Туганымның кызлары», «Семья өмете», «Апа», «Гувернантка») җыентыгы (1882), 1888 елда «Северный вестник» журналының унынчы санында В. Г. Короленко тәкъдиме буенча (ул журналның беллетристика бүлеге редакторларыннан берсе була) А. Н. Анненскаяның «Җинаятьче кыз (балалар тормышыннан драма)» дигән кечерәк кенә хикәясе урнаштырыла.

Остаз һәм педагог буларак, А. Н. Анненская әсәрләрендә яшь буынның нинди изге максатларга омтылырга тиешлеген күрсәтә. Аның бу тенденцияләре күп ягы белән безнең чорга да аваздаш.

**М. МОЛЧАНОВА,**
Казан дәүләт педагогия институты
укытучысы.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

29 июльдә Татарстан Язучылар союзының ачык партия җыелышында «Дүрт кешелек каюта», «Очар кошлар белән янәшә», «Кичке уйлар», «Капитан Хәкимов», «Сагышлы кояш» повестьларының авторы язучы Рәфкать Кәраминың иҗат отчеты тыңланды. Докладчы Мансур Вәлиев аның иҗатына тулы анализ ясады, аерым әсәрләренә тукталды. Фикер алышуларда язучылар Г. Бәширов, Ә. Еники, С. Сабиров, Б. Камалов, Р. Ишморатова һәм М. Хәбибуллин катнашты. Соныннан әдип үзенең киләчәккә иҗат планнары белән уртаклашты.

## ЛЕНИНГРАД ЯЗУЧЫЛАРЫ ТАТАРСТАНДА

Язучылар союзы идарәсе һәм республика китап сөючеләр җәмгыяте чакыруы буенча 19 июльдә Казанга бер төркем Ленинград язучылары — шагыйрьләр В. Суслов, Р. Халит, И. Сергеева, Е. Вечтомова һәм прозаик В. Суров килделәр. Алар бер атна буена республикабызның культура тормышы белән таныштылар, хезмәт коллективларында булдылар. 22 июль көнне Алабуга һәм Чаллы шәһәрләренә сәяхәт кылдылар. Әдәбият сөючеләр һәм татар язучылары белән очрашулар аеруча җанлы, эшлекле узды. 24 июльдә ТАССР Язучылар союзында «Ленинград белән Казан арасындагы әдәби элемтә» дигән темага дискуссия булды. Аны Г. Ахунов алып барды.

## ДУСЛАР СӘНГАТЕ

М. Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрының Казанга гастрольләрга килүен меңнәрчә тамашачылар бисл да шатланып каршы алды.

Үз иҗатлары белән казанлыларны күптәннән сокландырган СССРның халык артисткасы З. Бикбулатова, РСФСРның атказанган артистлары А. Садыйкова, Х. Кулашев, Х. Фәхриев һәм театрның талантлы яшь буын артистлары катнашында уйналган спектакльләрне караган тамашачылар чын-чынлап бәйрәм хисе кичерделәр. Кунаклар Казанга 13 спектакль алып килгәннәр иде. К. Тинчурин, М. Фәйзи, М. Гафури, М. Кәрим, Р. Сафин, Ә. Атнабаев һәм башка язучыларның әсәрләре буенча эшләнгән бу спектакльләрне Казан һәм республиканың төрле районнарыннан килгән меңнәрчә кешеләр карады.

Гастрольләр тәмамланыр алдыннан башкорт дусларның иҗаты турында фикер алышу булды. Сәнгать эшлеклеләре, театр белгечләре, язучылар һәм тамашачылар катнашкан бу сөйләшүдә театр белгечләре Р. Игъламов, Д. Гыймранова, язучы А. Гыйләҗев, Татарстанның атказанган артисты И. Баһманов һәм башкалар чыгыш ясап, дуслар иҗатына олы бәя бирделәр. Җавап сүзе белән М. Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрының баш режиссеры, БАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Р. Исрафилов чыкты.

## ЯҢА КҮРГӘЗМӘ

Июль аенда Татарстан Художниклар союзының күргәзмә залында рәссам Равил Нурмөхәммәтовның шәхси күргәзмәсе ачылды. 40 елга якын иҗат итүче бу нәкыш һәм графика остасының иҗаты сәнгать сөючеләргә яхшы таныш. Әлеге күргәзмә рәссамның иҗат географиясенең киң булуын, әсәрләре заманның сынлы сәнгать телендә язылган елъязма икәнен расләды.

* * *

Шагыйрә Г. Зәйнашева, яшь прозаик К. Кәримов, җырчы Х. Хәсәнова һәм баянчы Т. Хөсәеновлар Баулы районы хезмәтчәннәре белән иҗади очрашуларда булып кайттылар. Алар «Южный», «Панаринский», «Уруссинский» совхозларында һәм «Правда», «Берлек», Киров исемендәге колхозларда, җәйләүләрдә, печән чабу болынлыкларында, механизатор йортларында иҗади кичәләр үткәрделәр.

* * *

Прозаик М. Хәсәнов, яшь шагыйрь Г. Садә, ТАССРның атказанган артисты Ш. Әхмәтҗанов һәм баянчы Р. Бәширов Мөслим районының Киров исемендәге «Трудовик», «Алга», «Маяк» колхозы хезмәтчәннәре белән очраштылар, игенчеләргә багышланган әсәрләрен укыдылар, җырлар башкардылар.

* *
*

Прозаик В. Нуруллин, драматург Д. Вәлиев, шагыйрь Р. Гатауллин, тәрҗемәче К. Миңнебаев Казанга семинарга килгән авыл мәктәпләре укытучылары белән очраштылар. Алар авторлар өчен дә, укытучылар өчен дә бик файдалы булды һәм җанлы үтте.

* *
*

Хәрби тема прозасы остасы, аларның геройлары эзләреннән бик күп йөреп иҗат итүче Ш. Рәкыйпов «Восток-2» пионер лагерендагы балалар янында булды. Аларга ул үз әсәрләренең язылу тарихын сөйләде. Советлар Союзы Герое И. Кабушкинга багышланган соңгы китабыннан өзекләр укыды һәм иҗат планнары белән уртаклашты.

* *
*

«Казанский», «Шеланга», «Ливадия», «Васильевский», «Түбән Морквашы» ял йортларында һәм санаторияләрендә прозаиклар М. Хәбибуллин, М. Скороходов, шагыйрьләр М. Хөсәен һәм М. Зарецкий әдәбият сөючеләр белән очрашуларда катнаштылар.

## ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Чаллы язучылар оешмасы Камгэсэнергостройның йортлар төзү комбинаты коллективы белән ныклы иҗади бәйләнештә тора. Июль аенда язучы Эдуард Касыймов, яшь язучылар Мансур Сафин һәм Николай Алешков 61 нче төзү-монтаж идарәсенең инженер-техник хезмәткәрләре, эшчеләре белән очраштылар. Алар үз әсәрләрен укыдылар, сорауларга җавап бирделәр, иҗади планнары белән уртаклаштылар.

* *
*

17 июльдә Чаллының «КамАЗ» культура сараенда шәһәрнең «Орфей» һәм «Ләйсән» әдәбият-сәнгать берләшмәләре членнары КамАЗ комплексы төзелешләрендә эшләүче студентлар белән очраштылар. СССРның төзелүенә 60 ел тулуга багышланган шигърият кичәсендә яшь язучылар Р. Асылбаева, М. Сафин, Н. Дмитриева, А. Макаров һ. б. катнашты. Кичәдә шулай ук студентлар Чаллы шагыйрьләренең үзләре яраткан шигырьләрен укыдылар.

* *
*

Язучылар Кадыйр Сибгатуллин, Нәҗип Мадъяров, яшь шагыйрь Мансур Сафин һәм үзешчән композитор Евгений Кузнецов Алабуга районындагы «Тарловский» санаториясендә әдәби-музыкаль кичә үткәрделәр. Матур әдәбият яратучыларга Яр Чаллы язучыларының китапларыннан төзелгән күргәзмә күрсәтелде. Китап сөючеләр кичәдә катнашкан авторлардан автографлар алдылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татар дәүләт филармониясе солисткасы Нажия Абдрахмановна Теркуловага Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1982 ел, 15 июль Указы белән, «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Татар дәүләт филармониясе концертмейстеры Алия Котдусовна Фәйзуллинага «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

* *
*

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Минзәлә татар дәүләт драма театры артисты Фәез Зәйнетдинович Бәдриевкә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1982 ел, 15 июль Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

* *
*

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен республика мәгариф работниклары йортының «Ветеран» хоры җитәкче-баянчысы Рокыя Габдрахимовна Ибраһимовага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1982 ел, 2 август Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

# Разия ханым Фәезова

Аңа китәргә иртә иде әле, яше дә әллә ни зур түгел, сәламәтлеге дә түзәрлек шикелле иде. Кулындагы эшен тәмамлаганнан соң, ул яңадан сөекле язучысы Галимҗан Ибраһимов иҗатына кайтып, аның русча басылмаган әсәрләрен тәрҗемә итү дәрте белән рухланып яши иде. Ләкин рәхимсез үлем аңа теләкләрен гамәлгә ашырырга форсат бирмәде. Балтик диңгезе буена эшләргә һәм дәваланырга киткән җиреннән барып тапты. Разияның яза торган җөмләсе уртасында өзелде, әйтәсе сүзе әйтелеп бетмичә калды.

Шулай да күп милләтле совет әдәбиятында, меңләгән укучылары һәм дуслары күңелендә Разия ханымны сагынып сөйләрлек якты истәлекләр күп саклана.

Разия Зыятдин кызы Фәезова М. Горький исемендәге әдәбият институтын уңышлы тәмамлаганнан соң озак еллар совет матур әдәбиятының үзәгендә — А. Фадеев һәм Н. Тихоновлар заманында СССР Язучылар союзы оешмасында эшләде. Ул милли әдәбиятларга аңа хас киң күңеллелек, юмартлык һәм тырышлык белән колачларын тагын да киңрәк җәяргә, яшь талантларга Бөтенсоюз мәйданына кыюрак атларга ярдәм итте. Урта Азиядә, Идел буе әдип һәм шагыйрьләре арасында «Разия ханым» дигән исем шул заманнардан бирле һәркем тарафыннан зур ихтирам белән, рәхмәт хисләре белән телгә алына.

Разия ханымның тагын бер иң кадерле истәлеге — аның тәрҗемәләре. Галимҗан Ибраһимовның иң мәшһүр романнары, Г. Бәшировның, А. Расихның роман һәм повестьлары миллионнарча тираж белән бөтен союзга рус телендә аның тәрҗемәсендә таралды. Шулай ук ул русчага кайбер кыргыз һәм үзбәк язучыларын да тәрҗемә итте. Рус һәм милли әдәбиятларның специфик үзенчәлекләрен, ике телнең дә нечкәлекләрен бик яхшы белүе, тирән теоретик белеме, бай тормыш тәҗрибәсе һәм искиткеч тырышлыгы нәтиҗәсендә Разия ханым тәрҗемәнең оригиналга сокландыргыч дәрәҗәдә тәңгәллегенә ирешә. Ул, мәрхүмә, һәр китапның тәрҗемәсен, гүя әсәрне үзе иҗат иткәндәй, дәртләнеп һәм кайнарланып эшли, әерата уңышлы чыккан урыннарына балаларча куана торган иде.

Әйтәсе сүзләре күп иде әле Разияның. Ул Мәскәүдә Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи, Мәхмүд Максудлар белән якыннан аралашып, алар белән дус булып яшәде. Дусларының тормышы һәм иҗатлары хакында бик җитди мәкаләләр язарга ниятләнә иде.

Чын мәгънәсендә матур кеше иде Разия ханым. Төсе-бите, өсте-башы гына түгел, холкы-фигыле, эчкерсез киң күңелле булуы, якты чырае, кешеләргә туганнарча яхшы мөнәсәбәте, кылган гамәле белән дә матур иде. Шәхси тормышында булсын, әдәбиятта булсын, ул гомере буена ялганга, ясалмалылыкка, фальшька каршы булды, гомере буена гаделлек өчен көрәште. Бик күпләрнең якын дусты, акыллы киңәшчесе иде Разия ханым.

Без, аның якын дуслары, замандашлары, аны якыннан белүче төрле милләт язучылары хөрмәтле Разия ханымның барыннан да бигрәк әнә шул кадерле һәм затлы кешелек сыйфатларын сагынырбыз.

**Гомәр БӘШИРОВ.**

*Август, 1982.*

Бәясе 90 тиен.
Цена коп.

Индекс 73210

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

«Казан утлары»на язылу дәвам итә. Язылу Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә хат ташучылар, җәмәгать башлангычында матбугат таратучылар тарафыннан бернинди чикләүсез кабул ителә. Элемтә бүлекчәләрендә язылган вакытта журналның төгәл индексын белергә кирәк. Ул Бөтенсоюз каталогына кертелгән. **Индексы — 73210.** Бәясе елга — 10 сум 80 тиен.

Журналга үзегез язылу белән генә чикләнмәгез, бергә эшләгән иптәшләрегезнең, якыннарыгызның, туганнарыгызның һәм күршеләрегезнең дә исләренә төшерегез!

**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)** ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал, орган Союза писателей Татарии